ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2015



# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

## *Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итү турында*

Татарстан Республикасының икътисади һәм социаль үсешендә нефть һәм газ чыгару тармагының, Лениногорск шәһәренең зур роль уйнавын билгеләп, карар бирәм:

1. 2015 елда Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итәргә.

2. Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга (кушымтада бирелә).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә, аларны үткәрү вакытларын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль,*
*2014 ел, 01 сентябрь*
*№ ПУ - 830*

## Кадерле укучылар!

**Лениногорск шәһәренә – 60, «Лениногорскнефть» идарәсенә 70 ел тулу уңаеннан «Казан утлары»ның июль саны шушы вакыйгаларга багышланачагын хәбәр иткән идек. Журналның июль саны сезнең кулда. Без анда шәһәр, район тарихи елъязмасының яңа сәхифәләрен, шушы туфракта туган, шушында яшәп ижат итүче каләм ияләренең, рәссамнарның ижат үрнәкләрен, әлеге төбәктә яшәүчеләрнең данлы эшләре турында язмалар, бу яктан чыккан атаклы шәхесләрнең истәлек-хатирәләрен тәкъдим итәбез.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Рәгать ХӨСӘЕНОВ. Татарстан нефтенең туган жирендә. ....7
Рафаэль НУРМӨХӘММӘТОВ. Данлы үткәннәрдән – лаеклы киләчәккә! ....39

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гәрәй РӘХИМ. Чал тарихны салган инәнә. *Шигырьләр.* ....3
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. Күнелләрдә булды яхшылык. *Шигырьләр.* ....35
Таһир ШӘМСУАРОВ. Куәт бирә Ватан җылысы. *Шигырьләр.* ....44
Шамил ХӘНИФОВ. Кеше булып калырга. *Әдәби-документаль бәян.* ....48
Әнәс ИСХАКОВ. Уйларым – йөрәк тибешем. *Шигырьләр.* ....96
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. *Хикәяләр.* ....99
Людмила АЛАНЛЫ. Тормыш — шундый... *Шигырьләр.* ....117

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Наил ШӘРИФУЛЛИН. Ялгыз кеше язмалары. *Бәян.* ....10

*100нче бит:* Гәрәй РӘХИМ. Беренчеләр. ....100

*Яңа исемнәр:* Зилә МӨДӘРРИСОВА. *Хикәяләр.* ....120

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Шамил БИКЧУРИН. Кайту. *Хикәя.* ....128

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әнвәр ШӘРИПОВ. Кешеләрең синең чын хәзинә... ....137
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Батырша эзеннән. ....145

**СӘНГАТЬ**

Дания ГАЙНЕТДИНОВА. Гамьле рәссам. ....152

**ФӘН**

Рафаэль ВӘЛИЕВ. Еракка китеп карасаң... ....155

**ХӘТЕР**

Индус ТАҺИРОВ. Гомеремнең чишмә башы – Шөгерем. ....158
Фирдәвес ХУҖИН. Мәңгелек һәйкәл. ....164
Лирон ХӘМИДУЛЛИН, Булат ХӘМИДУЛЛИН. Җиңүләр җиңел бирелмәде. *Тарихи-публицистик язма.* ....171
Миләүшә МОРТАЗИНА. Бар кадер Бәкердә. ....181

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....183

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

Рәсим ХӘБИБУЛЛА. «Чишмә» ага да ага. ....186
Н.ГЫЙЛӘҖЕВ, Н.СӘЛМАНОВА, Х.БИГҖАНОВА, Г.ӘХМӘТОВА *шигырьләре.* ....186

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Равил ФӘЙЗУЛЛИН әзерләде.* ....126
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

ТМ
татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1268).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.06.2015, график буенча 30.06.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1745. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Гәрәй
Рәхим

# ЧАЛ ТАРИХНЫ САЛГАН ИҢЕНӘ

## Туган ягым Колмаксар

*Колмаксар — минем туган авылымның гаҗәеп гүзәл бер төбәге. 1955 елда анда биек нефть вышкалары пәйда булды. Хәзер бу төбәктә мул итеп кара алтын чыгарыла.*

Урманыңа кереп җырласам да,
Сандугачлар мине тыймаслар.
Тик куркам шул, ташкын хыялларым
Урманыңа гына сыймаслар,
Туган ягым минем, Колмаксар!

Кайчан гына нинди тыныч иде,
Ялгыз иде монда сукмаклар.
Нефть эзләп килгән шат егетләр —
Бүген синең якын кунаклар,
Туган ягым, гүзәл Колмаксар!

Кая киткән тап-тар кыр юллары,
Асфальт өсләрендә кырпак кар.
Машиналар шавын тыңларга да
Өйрәнсеннәр әле колаклар,
Әй гүзәл як, туган Колмаксар!

Вышкаларга ак бәс кунаклаган,
Вышкалар бит — безнең юлдашлар.
Кыштыр-кыштыр миңа серен сөйли
Күз коелмый калган колмаклар,
Әй яңа як, таныш Колмаксар!

Урманыңа кереп җырласам да,
Сандугачлар мине тыймаслар.
Тик сыймас шул, бетмәс шатлыкларым
Урманыңа гына сыймаслар,
Бик яратам сине, Колмаксар!

Гәрәй РӘХИМ (1941) — *Татарстанның халык язучысы; биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә чыккан күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Сездәй ирләр яшәгәндә

*Нефть якларында туып, бүгенге көнгә кадәр шунда ут уйнаткан күренекле якташ егетләргә*

Җәйрәп ята илем киңлегендә
Әлмәт, Шөгер, Баулы, Бөгелмә,
Азнакае, Зәе, Шушмалары —
Чал тарихны салган иңенә.

Тугайларда — яшел әрәмәләр,
Әрәмәдә — яшел балтырган.
Шул балтырган шулпасыннан гына
Арык тәндә бер уч җан торган.

Тик тупылдап кына торган җаннар.
Тик сулкылдап кына типкән каннар
Безне исән-имин саклаган.
Чөнки сине, минем бөек халкым,
Үзеңә хас ирләр яклаган.

Туган халкым мул яшәсен өчен,
Җирнең маен сыгып ала торган,
Туган халкы инде янадан да
Ашамасын өчен балтырган,
Бөтен җанын-тәнен фида кылган
Фидакарьләр туган бу якта.
...Үз җирендә үз җырларын тапкан
Ирләр алган илне кочакка.

Ватанпәрвәр егетләр сез бүген,
Туган якның патриотлары!
Нефть якларының титаннары,
Алга табан барыр хутлары!

Инде Әлмәт, Шөгер, Баулы, Зәйләр,
Азнакайлар, Шушма, ямьле җәйләр
Артка табан юл алмаячак!
Илдә сездәй ирләр яшәгәндә,
Туган халкым югалмаячак!..
Татар халкы югалмаячак!..

## Без — Шөгердән

Без тумыштан нефть якларыннан,
Төгәлрәк әйтсәк — Шөгердән.
Шөгернең дә әле ин түреннән,
Чишмәләре бәргән җиреннән.

«Шөгер» белән «йөгер» дигән сүзне
Без рифмага салдык яшь чакта.
Һәм ил буйлап чыгып йөгердек без,
Уналты яшь тулар-тулмаста.

Чабаталар киеп йөгердек без
Заводларга, шахта, далага.
Шунсы рәхәт: нинди эш тә бата
Чабаталы гади балага.

Тулып ташты хезмәт кенәгәсе
Без татыган төрле һөнәрдән.
Аннан торып чаптык белем эзләп,
Без бит йөгерергә өйрәнгән.

Ләкин менә Сабантуйларында
Жыелышып эчеп булмады
Шөгердәге Алан авылының
Бәреп торган чишмә суларын.

Берәребез әгәр ялга кайтса,
Яшьтәшләрен эзләп Шөгергә,
Икенчебез ил йомышы белән
Себерләргә чыгып йөгерә.

Йөгерәләр минем яшьтәшләрем,
Инде күптән әти үзләре.
Киләчәккә карап йөгерәләр,
Яңа өмет тулы күзләре.

Йөгереп менеп китәр кебек алар,
Айда яңа эш бар дисәләр.
Йөгереп кенә качып китәр кебек,
Шыксыз үлем үзе килсә дә.

Тумышыбыз нефть якларыннан,
Төгәлрәк әйтсәк — Шөгердән.
Без — тынгысыз, без бит кин дөньяга
Шул Шөгердән чыгып йөгергән.

## Минем күңел... Синең күңел...

Сезнең авыл Шушма буенда,
Безнең авыл Куак[1] суында.
Куак суы коя Шушмага —
Бездән сезгә көмеш су ага.
Су түгел ул, минем моңнарым,
Шушма суын чумырып ал, жаным.

Сезнең яктан жилләр исәләр,
Сездән башланалар иртәләр.
Эссе көндә безнең авыллар
Сезнең яктан яңгыр көтәләр.
Сезнең яктан килгән яңгырлар
Шундый жылы булып яудылар.

[1] Шушма, Куак — Лениногорск районындагы елгалар.

Шушмагыздан безнең инешкә
Йөзеп менә ап-ак балыклар.
Сезгә кадәр тезелеп киткәннәр
Безнең якта үскән таллыклар.
Балыклардан хәлең сорыйм мин,
Таллар аша сәлам юллыйм мин.

Сезнең авыл Шушма буенда,
Безнең авыл Куак суында.
Минем күңел Шушма буенда,
Синең күңел Куак суында.

## Кулың алтын

*«Татнефть» ААҖнең быел 70 еллыгын бәйрәм итүче данлы «Лениногорскнефть» идарәсе җитәкчесе Рафаил Сәет улы Нурмөхәммәтовка*

Минем туган җирләремнең
Куенында кара алтын.
Аны сыгып чыгарырга
Кемнәрнең соң кулы алтын?

Якташларым белән бергә
Кем юл бирер хәзинәгә?
Алтын куллы егет килде —
Икеләнми әз генә дә.

Сәет улы Рафаил ул —
Унган егет! Булган егет!
Туган ягымны яшәртә
Кара алтын, кара дегет.

Сәет улы Рафаилгә
Рәхмәт әйтә туган халкым:
«Гомеркәең озын булсын,
Күңелең саф, кулың алтын!»

# ТАТАРСТАН НЕФТЕНЕҢ ТУГАН ҖИРЕНДӘ



Лениногорск шәһәренең барлыкка килүе, үсүе Шөгер, Ромашкино нефть ятмалары ачылу белән бәйле. Әлеге үзенчәлекле вакыйгалардан соң Татарстанның көньяк-көнчыгышында үсешнең яңа этабы старт ала, безнең шәһәрнең тарихы языла башлый.

Быел алтмыш еллыгын билгеләүче шәһәребезнең үткәне чын мәгънәсендә горурланырлык. Татарстан картасында 60 ел элек барлыкка килеп, ул республиканың көньяк-көнчыгыш шәһәрләре арасында лаеклы урын алды.

Юбилей якынлашкан саен, тарих сәхифәләренә ешрак күз салабыз. Шәһәрнең барлыкка килүе Яңа Писмән авылы белән бәйле, аңа 1795 елда Иске Писмән авылыннан күченеп килүчеләр тарафыннан нигез салына. Яңа авыл тиз үсеп китә. 1914 елга Яңа Писмән төбәкнең иң эре торак пунктларының берсе булып санала. 1918 елда әлеге волостька 20 авыл керә. 1930 елда ТАССР районнарга бүленеп, аның нәтиҗәсендә Яңа Писмән Бөгелмә районында кала, ә 1935 елда Яңа Писмән районы оеша, аның үзәге Яңа Писмән авылы була. Район 48 колхоз, ярымкустар май заводы, «Заря» промартеле һәм ике аз егәрле машина-трактор станциясеннән тора. Кешеләр авыл хуҗалыгы белән генә шөгыльләнә, аяк астында зур нефть хәзинәсе булуын уйламый да.

Ә җир асты байлыклары галим һәм тикшеренүчеләргә өч йөз ел буена тынгылык бирми. Бары тик 1943 елда гына Шөгер авылы янындагы 1нче номерлы скважинадан беренче промышленность нефте алына, бу Татарстанда әлеге кыйммәтле чималның булуын исбатлый. 1945 елның җәендә Шөгер авылында Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы барлыкка килә, соңрак ул «Лениногорскнефть» идарәсе дип атала башлый. Бүген ул — шәһәрнең иң өлкән предприятиесе. «Лениногорскнефть» идарәсе — аз чыгым белән нефть табуны арттыру һәм аның сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән йөзләрчә башлангычның инициаторы, фәнни эшләнмәләрне, яңа техника һәм технологияләрне промышленностька кертү буенча үзенә күрә бер тәҗрибә мәктәбе. Идарә «Татнефть» берләшмәсенең — «Әлмәтнефть», «Азнакайнефть», «Елховнефть», «Иркеннефть» кебек мөстәкыйль яңа идарәләрнең барлыкка килүендә база ролен үтәде.

1948 елда Тимәш авылы янында 3нче номерлы скважинадан көчле девон нефте фонтаны бәреп чыга. Әлеге мизгелдән илнең иң эре нефть чыганагын үзләштерү башлана. Әлеге уникаль Ромашкино чыганагының даны меңнәрчә кешене үзенә тарта. Илнең төрле почмакларыннан белгечләр һәм эшчеләр килә. Баку, Грозный, Краснодар, Башкортстан, Сахалин һәм башка төбәкләрдән килгән бораулаучы, нефть табучы, төзүче һәм башка һөнәр ияләре төзеләчәк шәһәрнең халкы булып китә. Монда шулай ук тирә-як авыл һәм районнардан кичәге колхозчылар да агыла. Яңа урында тормыш чатыр, землянка, бараклардан башлана. Нефть чыганагын үзләштерү белән бер үк вакытта шәһәр дә төзелә.

1950 ел уртасында беренче йортлар торгызыла башлый, нефтьчеләрнең беренче бистәсе төзелә, халык аны Зеленогорск дип атый. Эш көндез дә, төнлә дә алып барыла. 50нче еллар азагында Зеленогорск чокырлар белән әйләндереп алынган зур төзелеш мәйданчыгын хәтерләтә. Мәктәпләр, хастаханә, балалар бакчасы,



*Яңа теннис-холл.*

һөнәри уку йортлары, клуб, кибетләр, промышленность предприятиеләре төзелә башлый.

Яңа Писмән авылы янәшәсендә яңа шәһәр үсә. РСФСР Югары Советы Президиумы Указы белән 1955 елның 18 августында Яңа Писмән эшчеләр посёлогы Лениногорск шәһәре дип үзгәртелә.

Алтмыш ел вакыт узып та киткән. Әлеге чорда шәһәр гел үсештә, алга китештә булып, үзенең кабатланмас йөзен тапты. Иң төп объектларга, әлбәттә инде, алтмышынчы-житмешенче елларда ук нигез салына. Шәһәрнең үзәк китапханәсе, телеүзәк, шахмат клубы, Техниклар йорты, балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәпләре, «Яшьлек» стадионы, нефть музее, музыка-сәнгать педагогика училищесы, колхоз базары, типография, универмаг халык яратып йөри торган урыннарга әверелде.

Социаль-икътисади үсеш җәһәтеннән караганда, Лениногорск муниципаль районы республика районнары арасында беренче унлыкка керә. Үсешнең нигезен беренче чиратта нефть промышленносте алып тора. Мәсәлән, үткән ел районда 18 миллиард сумлык промышленность продукциясе житештерелде. Район үсешендә кече һәм урта эшмәкәрлек тә мөһим роль уйный, бездә 600дән артык кече бизнес предприятиесе һәм 1 мең ярым тирәсе шәхси эшмәкәр бар. Аларда 4 мең ярым тирәсе кеше эшли. Авыл хужалыгы предприятиеләре тарафыннан үткән ел 1 миллиард 600 миллион сумлык азык-төлек житештерелде. Бүгенге көндә ике дистәгә якын фермер хужалыгы уңышлы эшләп килә, шәхси хужалыкларда 3 мең баш мөгезле эре терлек тотыла.

Шәһәр елдан-ел үсә, матурлана бара. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов башлангычы белән тормышка ашырыла торган төрле милли программа-проектларда актив катнашуыбыз үзенең нәтижәсен бирә. Республика хөкүмәте ярдәме, «Татнефть» акционерлык җәмгыяте булышлыгы белән шәһәрдә күп кенә социаль объектлар торгызылды. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре өчен йортлар төзелде. Күп фатирлы йортларга капиталь ремонт ясалды. Жылылык челтәрен модернизацияләү буенча зур күләмле эш башкарылды. Бернечә заманча автоном котельный төзелде, жылылык челтәрләре реконструкцияләнде, 49 ике катлы һәм 6 күпкатлы йорт шәхси жылылык системасына күчерелде. Мәдәният учреждениеләре, спорт корылмалары, сәламәтлек саклау һәм белем бирү объектлары ремонтланды. Соңгы елларда гына Садриев, Толстой, Шашин, Ленинградская урамнарында унлап күпфатирлы йорт төзелде. Садовая һәм Добролюбов урамнарында ветераннар, ятим балалар, чернобыльчеләр өчен торак йортлар салынды. «Ал жилкән» мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәгенә капиталь ремонт ясалды. «Бәләкәч» программасын гамәлгә ашыру нәтижәсендә шәһәр балалар бакчаларында йөзләрчә өстәмә урын булдырылды. Яңа жиденче микрорайонда «Родничок» дигән 14нче балалар бакчасы ачылды. 3нче, 6нчы, 7нче мәктәптә, 11нче гимназиядә капиталь ремонт ясалды. Алар мультимедиа жиһазлары белән тәэмин ителеп, уку, тәрбия бирү, балаларның ялын оештыру өчен унайлы шартлар тудырылды. Юбилей алдыннан шәһәребезнең иң алдынгы уку йортларының берсе булган 2нче мәктәп өр-яңа заманча бинага күчәчәк. Лениногорскида яшь буынга белем һәм тәрбия бирү — һәрвакыт игътибар үзәгендә. Бу җәһәттән ул республикада беренче унлыкка керә. Мәктәпне тәмамлагач белем алу мөмкинлеге дә зур. Моның өчен КНИТУ-КАИның Лениногорск филиалы, нефть техникумы, музыка-рәсем педагогика колледжы, политехник колледж бар.

Алар нигездә «Татнефть» һәм «Төньяк-көнбатыш магистраль нефтьүткәргечләр» җәмгыятьләре өчен кадрлар әзерли.

Лениногорск — спорт каласы. Житмешенче елларда ук монда спорт үзәкләре, стадионнар төзелә башлый. Трамплиннар комплексы үзе генә дә ни тора. Спортның әлеге төре буенча база 1972 елда булдырыла. Башта — 20 метрлы, аннары 65 һәм 40 метрлы трамплиннар сафка баса. Кырык ел инде трамплиннан сикерү буенча «Олимпия резервы» спорт мәктәбе эшләп килә. Бирелә тәрбияләнүчеләр Россия күләмендә һәм халыкара ярышларда җиңүләр яулыйлар. Сочи олимпиадасында катнашкан Иван Панин — Лениногорскиның горурлыгы. Бүген дә шәһәребездә яңа спорт корылмалары төзелә тора. Күптән түгел «Теннис-холл» спорт сарае ачылды. Аннан ерак түгел Вахитов урамында спортның экстремаль төрен үз итүчеләр өчен скейт-парк булдырылды. 7нче, 8нче, 10нчы, 13нче мәктәп, 11нче гимназия һәм 12нче лицей янында яңа универсаль спорт мәйданчыклары барлыкка килде.

Яшеллекнең күп булуы — Лениногорскиның бер үзенчәлеге. Шуңа аны «Татарстанның яшел хәзинәсе» дип атыйлар. Шәһәр хуҗалыгы үсешендә, аны төзекләндерүдә халык зур ярдәм күрсәтте, бакча, скверларга агачлар утырту өчен өмәләргә чыкты. Лениногорскилылар көче белән меңнәрчә төп тирәк, юкә, миләш, өрәнге, каен, чыршы, нарат утыртылды. Бездә шәһәрне биектән карау мөмкинлеге дә бар. Моның өчен баскычтан махсус мәйданчыкка менәсе. Кала уч төбендә кебек күренә.

Әйе, матур безнең шәһәребез. Тукай урамын гына күрегез: ике якта эскәмияләр, уртада бизәкле беседка, шуның янында җәен тамашалар күрсәтер өчен сәхнә, бераз китсәң, «Балерина» фонтаны... Шәһәрнең нәкъ уртасында — Ленин исемендәге парк. Анда заманча плитәләр түшәлде, бизәкле беседкалар урнаштырылды. Шушында ук — Михаил Фомин барельефы. Ул шәһәрне яшелләндерүне башлап йөрүче фидакарь кеше иде. 2010 елда Җиңүнең 50 еллыгы проспектында Дан орденнарының тулы кавалерлары М.Алаевка, Г.Мотыйгуллинга, Я.Николаевка барельеф куелды. Быел Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан «Мәңгелек ут» тирәсе төзекләндерелде. Тиздән монда Җиңү паркы ачылачак.

«Урман паркы» дигән бик матур урыныбыз да бар әле безнең. Соңгы елларда анда зур күләмдә төзекләндерү эшләре алып барылды, юллар салынды, балалар өчен яңа аттракционнар булдырылды. Шәһәрдәге тагын бер паркны «Мәхәббәт паркы» дип атадык. Аңа күперчекләр, «Ак Барс» фонтаны ямь биреп тора. Фонарьлар куйгач, махсус үлән чәчелгәч, бу парк тагын да матурланды. Шәһәребезнең матурлыгы талантларның күп булуына да тәэсир итми калмыйдыр. Аларны үстерү өчен дә мөмкинлекләребез җитәрлек: районда 37 мәдәният йорты, шәһәрдә Мәдәният сарае, балалар музыка һәм сәнгать мәктәпләре бар. Аларда меңнәрчә укучы белем ала. Туган якны өйрәнү музее, үзәкләштерелгән китапханәләр системасы эшләп килә.

Үзгәрешләр күз алдында бара. Хәзер безнең бурыч — меңнәрчә кеше хезмәте белән булдырылганны тиешенчә бәяләү, саклау.

Быел Лениногорск шәһәренең — 60, «Лениногорскнефть» идарәсенең 70 еллыгын бәйрәм итәчәкбез. Әлеге юбилейларны бер-берсеннән аерып булмый. «Лениногорскнефть» идарәсе шәһәр инфраструктурасын һәм социаль өлкәне үстерүгә гаять зур өлеш кертте. Бу уңайдан идарә коллективын барлык лениногорскилылар исеменнән олуг юбилей белән котлыйм, предприятиенең киләчәктә дә чәчәк атуын телим. Шәһәр юбилеена килгәндә, аның төзелешенә меңнәрчә кеше үз өлешен кертте. Менә шулай бергәләп заманча шәһәр булдырдык. Иң мөһиме — анда тырыш, булдыклы кешеләр, өметле яшьләр яши. Һәрберсен әлеге юбилей белән котлап, исәнлек-иминлек, уңышлар, рух күтәренкелеге телим.

Шәһәребез киләчәктә дә чәчәк атсын, безне гел куандырып торсын.

**Рәгать ХӨСӘЕНОВ,**
*Лениногорск муниципаль районы башлыгы,*
*Лениногорск шәһәре мэры*



Наил Шәрифуллин

# ЯЛГЫЗ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

БӘЯН

## Гаҗизлек әчесен йотып

«Татар авылларында ул чорда әхлак мәсьәләсе катыдан иде әле. Шуны бик яхшы белгән мин — унике яшем дә тулмаган оялчан һәм юаш малай — әчке бер тоемлау белән әнкәйнең ярамаган, оятлы гамәл кылганын сизеп, ныклап торып кайгыра, күңелемнән акрын гына сыза башладым. Бала булсам да, вакыйганың тирәнлеген, чынга ашканда, үтә гарьлекле хәл икәнен аңлап, хәтсез вакыт беркемгә бернәрсә дә әйтмичә, әйтергә кыймыйча, үз-үземә бикләнеп, ут йотып йөрдем. Ышанасым килмәде. Алай була алмый, булырга һич тә тиеш түгел бит! Әнкәйнең үсеп килүче эчենә карыйм да хафалана башлыйм, карыйм да кайгырам, карыйм да читкә китеп тавышсыз гына елыйм. Миңа ифрат та кыен иде. Безнең әти кешебез юк, әнкәй — аерылган хатын, димәк, аның авырлы булырга да хакы юк. Ә әнкәй үзе бернәрсә дә әйтми, аңлатмый. Мин аның саен ныграк пошаманга төшәм, аның саен астыртын гына әнкәйне күзәтәм. Ашарга дип өстәл артына килеп утыргач бигрәк тә. Ашаган ризыгымның тәме югалгандай була. Сорыйсым, әнкәйнең «юк» дигәнен, акланyын, барысын да инкарь итүен ишетәсем килә. Тик куркам, оялам. Ялгышасым, ул хафаларны, шикләнүләрне бөтенләйгә онытасым килә. Әмма оныта алмыйм. Әбекәй дә, мине кечкенәгә санаптыр, күрәсең, әнкәй хакында башта берни дә әйтмәде, белгертмәде. Тик шулай да, берсендә, аның да кайгы савыты мөлдерәмә тулып:

— Әнә, бик әйбәт булган инде, юньсез! — дип, әнкәйне чын йөрәгеннән ачынып тиргәп ташлагач, мин ялгышмаганлыгымны аңладым. Аңладым да, әбекәйне кочаклап, үкси-үкси еладым. Шикләнүләремнең дөреслеге, әнкәйнең чыннан да ирсез-нисез килеш бәби алып кайтачагы инде хәзер тәгаен иде. Йә Хода, безгә хәзер нишлисе? Бу оятны кая куясы? Әбекәйгә мин андый сорауларны бирмәдем. Шулай да, елап арыгач, миңа аз гына җиңел булып китте. Башка ишелеп төшкән бу гарьлектә таянып кешем барлыгы ачыкланды. Кызганды мине әбекәй, бик кызганды. Башымнан сыйпый-сыйпый: «Ул турыда уйлама, балам, оныт. Мин кайгырганнар да житкән», — дип, үзенчә юатырга тырышты. Әйе шул, хурлыкның юан башы кызы өчен аңа төшми кемгә төшсен? Яшьләрем кибүгә мин элек боегуны һич белмәгән әбекәйнең суырылып калган, хәтта бераз саргайган йөзенә игътибар иттем. Килеп туган хәлдә чарасыз ике жан: житмешне куучы карчык белән үсмер малай, мин

әбекәйнең инәнә башым салган, ул мине кочаклаган хәлдә, боегып, гаҗизләнеп шулай хәтсез утырдык...

Вакытны туктатып булмый, көннәр үз агымы белән үтә, әнкәйнең эче дә һаман зурая торды. Хәтерлим әле, балалык белән, кайвакыт уен белән мавыгып, мин ул хәлләрне онытып та куйгалый идем. Әмма жанны җәфалаучы ул борчу, капылт кына яңадан искә төшә дә тагын күңелне кимерә, тырный башлый. Каткан башым белән шул бер үк уйны уйлап, хурланып һәм кимсенеп, көне буе сөмсерем коелып, нишләргә белми йөрим. Янә әбекәемне барып кочаклыйм да, икебез дә артык сүз сөйләшмәстән, бертын тик торабыз. Башым шул арада аз булса да ял итә, тынычлангандай булам. Тик гел генә әбекәйнең итәгенә тагылып йөреп булмый шул. Аяза башлаган күк йөзен кабат болыт каплаган кебек, авыр уйлар яңадан күңелне биләп ала. Әмма күпме генә уйласам да, чишелеш табылмый, мин кабат гаҗизлектә калам. Бернәрсәне бик яхшы аңлыйм: бераздан өебезгә, әбекәйгә, миңа, әнкәйнең үзенә дә мәсхәрә ишеләчәк. Әхлак законнары, беркайда да язылмаган намус, оят кагыйдәләре ул заманнарда шактый катгый, бәяләүләр кискен иде шул әле...»

Төрле вакытларда, төрле төстәге каралар белән язылган; бөтенләй үк тулы булмаса да, буш урыннары аз калган, шактый таушалган ул дәфтәр кулыма килеп эләккәч, аны-моны уйламыйча, ваемсыз гына урта бер җирен ачып караштырганда, беренче булып күзгә чалынган язма шулайрак башланып киткән иде. Укыйсым, алга таба дәвам итәсем бик килсә дә, ирексездән димме, дәфтәрне шул урында яптым. Күз алдыма керфекләре мөлдерәмә яшь белән тулы уникe яшьлек малай булып дәфтәр хуҗасы — иске яңа танышым Миргаяз килеп басты. Колакта аның сабыр тавышы ишетелгәндәй булды. Миңа ничектер кыен булып китте. Болай эшләргә, ягъни теләсә кайсы урыннан, кызык эзләп, йолкып алып укырга ярамый иде кебек бу дәфтәрне. Язмалар андый җилбәзәклеккә лаек түгел иде төсле. Дәфтәр хуҗасының үзе белән булган очрашулардагы, кыска булса да эчкерсез гәпләшүләрдәге кебек, бирелә дә барысы да артык шәхси һәм бик ихлас иде. Шунлыктан мин, иркенрәк вакыт табып, авторга, аның кичерешләренә хөрмәт саклап димме, язмаларны эзлеклелек саклап укырга, ул гына да түгел, андагы четерекле вакыйгаларга, япь-яшь малайның өзгәләнүләренә, уйлап чыгарылмаган әрнү-газапларына таянып, житди әсәр язарга тәгаенләдем. Тик менә эзлеклелек дигәндә генә сүземдә тора алмадым шикелле.

...Инде дистә еллар күрмәгән элекке бакча күршемне шәһәрнең урам-парклары буйлап сәйранга чыккан җиремдә — һава сулыйм, тәнемә саулык өстим, хәрәкәтләнәм дип, бер көн дә калмый үтәлә торган җәяүле сәяхәтемдә очраттым мин. Ул да кичке сәйраннарны үз итә, чыккалый икән. Юлларыбыз гына моңа кадәр ни өчендер кисешмәгән. Шулай очраштык без. Очраштык та, соңыннан көн саен ук үтәмәсәк тә, бер вакыттарак чыгып, бергәрәк йөрергә сүз куештык. Ялгызлык җанына үткән булгандыр — мондый килешүгә сөенүе Миргаязның күзләренә үк чыкты, моңарчы артык яктырырга уйламаган житди йөзенә беразга булса да кунган нурларны, елмаюны да яхшы хәтерлим әле.

Көзгә шыксыз чак иде ул. Агачлар, яфракларын тәмам коеп бетереп, шәрә калганнар. Көне-төне, бер туктаган булып, бер шәбәеп, салкын яңгыр сибәли. Һава торышының начары юк, бар фасыллар да үзенчә матур диючеләр йә бик ваемсыз, йә артык оптимист кешеләрдер. Октябрь азакларын, йә ноябрь башын, урталарын күркәмгә санаганнар, миңа калса, барыбер алдаша, икейөзләнә. Шыксызлык — шыксызлык инде. Һәм нindидер соры, ялыктыргыч ярымкараңгы төссезлек. Күкләрдә башка фасылларда күзәтелгән фирүзә зәңгәрлек, урамнарда, бакча-паркларда күзне иркәләүче ник бер мөлаем яшеллек булсын. Мондый

чакта кеше затына киләчәккә, иртәгәгә өмет-ышаныч, җылылык, әчтәге уй-хисләрне кемгәдер ирештерү, аралашу кирәк. Күңелгә, болыт аша күренеп киткән кояш кебек, аз булса да яктылык, нур кирәк. Ялгызы яшәгән кешегә бигрәк тә. Миргаязның да шуны аңлаган, тойган гына түгел, бер-беренә охшаган соры көннәр һәм һаман озыная баручы караңгы кичләр буе күңеленә җыелып килгәннәрне тышка чыгаруга, бушануга, әчкерсез әңгәмәгә чын-чынлап сусаган халәте иде булса кирәк.

Беренче көннәр күбрәк хәл-әхвәл белешеп, дөнья хәлләренә кагылып дигәндәй, юк-бар сөйләшеп узды. Күбрәк ул сөйләде. Үзе, тормышы, үткәннәре турында сөйләүгә кучкач тә, мин «әйе», «шулай шул» дип җөпләп, сүзләренә пичәт сугып баручы рольдә калдым дисәм дә дөрес булыр. Баштагы көнне берничә сүз белән генә ялгызы гомер сөргәнен белгертсә дә, никтер җәелеп китеп ул турыда сөйлисе итмәгән, сәбәпләренә кагылмаган иде. Өченчеме, дүртенчеме очрашуда, Миргаяз башта капылт кына балачагына, үсмер вакытларына кайтты. Сүз башым бит шүрәле, дигәндәй, шуннан башлады да, ни өчендер ул бәянны да кисәк кенә өзеп, гаиләле көннәренә, үзе дә балалар үстергән, бүген дә баргалап торган бакчасына, анда бергәләп йөргән вакытларга әйләнде. Җыелып килгән сүзләр, аерым вакыйгалар, берсен-берсе ашыктырып, эткәләп-төрткәләп чыгу сорыйлар, шул сәбәпле эзлеклелек, чират белән дә артык исәпләшмиләр иде кебек. Мин исә, аның ишегә артык игътибар итмәстән, колагымны шомрайтып, һаман да аны тыңлап йөрдем генә түгел, язган чакларымда кирәге чыгар дип, ул сөйләгәннәрне хәтеремә сырлап, киртләбрәк тә бардым. Чөнки уртача калынлыктагы яшел тышлы таушалган дәфтәрнең кулыма килеп эләгәсен мин ул вакытта белми идем әле.

«Беренче олы күңел төшенкелеге, хәзергечә әйткәндә, депрессия миңа шулайрак килде. Хәзер уйлыйм: бишенче сыйныф баласы ул хәлләрдән шул тиклем кара көяргә тиеш булды микән? Юктыр. Тик үзеңә «исеңә алма, оныт!» дип боерып кара, качып кара син ул борчулардан. Андый көчне каян алырга? Ничек ваемсыз булып, бала гына булып калырга? Бәгырьне боргычлап, бөтереп торган нечкә, сизгер күңеллелектән, оят хисеннән ничек котылып торырга? Авылдагы әхлак, кеше теленә калу белән ничек исәпләшмәскә? Ни генә булмасын, ул ипсез вакыйга әле ныгымаган җанда, начарны, пычракны кабул итәргә әзер булмаган күңелемдә шактый тирән эз, яра калдырып, киләчәк язмышыма, аннан соңгы холык-фигылемә дә олы йогынты ясады кебек.

Бүгенге көннең бернәрсәгә дә шаккатмас битараф һәм мәнсез күзлеге аша караганда, әлбәттә, барысы да җиңелләр ул. Хәзерге әхлак калыпларына салып бәяләгәндә, уникe яше тулар-тулмас малайның күңелен телгәләгән ул хәлләрдә каш җимерелеп, күз чыгарлык сәбәпләр бөтенләй юк та төсле. Ушың киткән икән, хәзер әнә, өч ирдән өч бала табып та, берни булмагандай яшиләр. Бала-чаганың да аның ишегә аптыраганы юк. Шул җәһәттән әнкәй очрагын, аның ни сәбәпле ул гамәлгә барганын да бүген гади генә итеп аңлатып, шәрехләп биреп була кебек. Ә ул тарих элек-электән килгән, бүгенге заманда мәхәббәт өчпочмагы дип аталган гап-гади вакыйгага кайтып кала иде. Миңа әти тиешле кешене ничек булса да янабаштан үзенә карату, аны хатыныннан йолкып алу, кайтару. Янадан бергә яшәп китү теләге, шул теләктә алны-артны карамый ашкынулары әнкәйне, башын тәмам югалттырып, мине кара хәсрәткә салган шул адымга барырга мәҗбүр иткән. Кыскасы, бүгенге көннен гади генә драмасы. Тик андый мөнәсәбәтләр кабул ителмәгән чорда, миндәй самими, пакь һәм сизгер җан өчен бу хәлләр чып-чын трагедия, фаҗига булды.

Мин әнкәйнең әлеге «җинаятенең» сәбәпләрен абайламыйча, нәтиҗәләреннән җир ярылса, шул җир тишегенә кереп китәрдәй булып йөргәндә, әнкәй, вакытын

житкереп, бәби табарга дип бүлнискә дә китте. Шикләнүләр аңынчы ук беткән, күңелне теткәләгән хурлык чынбарлыкка әйләнгән иде инде. Әйткәнемчә, аның ише гамәлләр ул заманда азгынлык, юньле хатын һичкайчан эшләмәс эш саналып, андый бәбиләрне авыл кешесе авыр һәм мыскыллы итеп «уйнаштан туган» дип атый иде. Шундый «уйнашудан» яралган бәбине табарга дип китте әнкәй...

Йә Хода! Менә шундый мыскыллы бәя, үзенең һичбер гөнаһы булмаса да, туачак, биткә кара булып ягылачак ул бәби, уенга чыкканда да минем белән чыгачак, мәктәпкә барганда да миннән калмаячак. Ул хәлләрдә минем аз гына да гаебем юк, мин элеккечә карагыз, ким-хур итмәгез дип, барысына да сөйләп, исбатлап йөреп булмый бит. Башлангыч класстагы кебек ваемсыз, аны-моны белмәгән, аңламаган чак булсын иде ичмаса. Партадашларым да барысын да беләчәк. Укытучы абый-апалар да. Башкасы — башка, менә шунысын, мәктәптәгесен ничекләр итеп күтәрерсең? Кара күзле, нурлы йөзле, класста бер матур Гөлчәчәк тә, карашында кояш чыгарып, миңа карап бүтән елмаймаячак инде...

Күңелем читлектәге коштай бәргәләнгән шул чакта, бу дөньяда иң якын, иң газиз булырга, ул — мине, мин — аны чиксез яратырга тиешле кешегә рәнҗеп, кимсенеп, күңелемдәге тыелгысыз ризасызлыкка буйсынып, мин әнкәй өйгә кире кайтмасын, бәбие белән бергә күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә китеп югалсын иде дип теләдем. Әбекәемнең дә балтасы суга төшкән, кызы хурлыгыннан йөзе тәмам боеккан, суырылып калган иде. Ул да тәмам аптырап, хәтта мине куркытып: «И-их, машина asларына кереп үлимме икән соң әллә?!» дип бәргәләнә, үзенә урын таба алмый иде...»

Үзе элеккедән әллә ни үзгәрмәгән кебек күренсә дә, тора-бара мин Миргаязның эре җыерчыклар кискәләгән йөзен ачык чамаладым. Вакыт кемгә генә рәхимле соң. Тик йөрешендә барыбер элекке, бакчада бергә эшләгән заманнардагы житезлек, күзләрендә боеклык катыш булса да яшәү дәрте сизелә иде әле. Бакча дигәннән, ул аны әле дә, шәһәр халкы дәррәү аннан качып беткән заманда да ташламаган булып чыкты. Өч йөз кишәрлекле бакчачылык ширкәтендә җәмгысы 3-4 кеше калганын, шул исәптән Миргаязның да һаман да булса шунда йөргәнен белгәч, мин хәтта тел шартлатып куйдым. Бу гамәлне гади хезмәт сөючәнлек белән генә аңлатып булмый иде төсле. Биредә күпмедер сәерлек тә бар бит. Шулай инде, ялгыз зат сәер булмыйча нинди булсын. Ялгыз булганга сәер ул, сәер булганга ялгыз. Тик аның шушы көнгә кадәр түтәлләрдә казынуының төп сәбәбе бераз башкачарак булып чыкты. Һәрхәлдә, үзе шулайрак аңлатты. Аның бакчаны хәзергәчә ташламавы физик хезмәткә мөкиббәнлек, кулга шөгыль эзләү, шәһәрдән азга булса да качып тору, эшләп юанудан икән. Чынлыкта исә болар барысы да шул җанга тигән ялгызлыктан котылу эзләүнең бер рәвеше булгандыр.

— Анда да бармагач, кая гына барып бәрелим соң? — Ул шулайрак дип күрсенгән иде. — Башны чистартыр өчен, акылны җуймас өчен дә кирәк ул бакча.

Бакча хәлләренә авыл, андагы салмак һәм иркен тормыш, шул тормышка багышланган мәдхия-монолог ялганып китә. Үзем дә авыл тарафына битараф булмагангамы, әңгәмәдәшемне бу юлы да бүлдермичә тыңлавымда булам.

— Шатлыклар белән кимсенүләр бергә үрелеп барган гомер башымның унҗиде елы авылда үтте минем. Соңгы унҗиде елы да шунда узып, үзем яралган туфракка киредән керсәм, бер дә үкенечле булмас иде. Нәрсә инде ул шәһәрдәге тартма-фатир? Сыерчык оясында йомырка өстендә утырган кош кебек бит без. Сыерчык та очып чыгып китә дә бер җилләнеп керә. Их, авылга кайтсаммы.

Йортлы, ихаталы, яшел чирәмле ишегалды, кечкенә генә хуҗалыклы, бакчалы булсаммы... Өстемә бәхет ишелеп төшәр дип өметләнмим анысы. Тик андый шартларда тиле генә шыр бәхетсез булыр иде. Ярты ялгызлык анда да каладыр, ә менә дөм ялгызлык... Беләсеңме, халык белән шыгрым тулы шәһәрдә ялгызлыктан качкагында бүре кебек күккә карап улыйсы килә. Ә анда көченнән килгән шөгыль, хезмәт янәшәңдә генә. Бәлки нәкъ шул тирәләрдә миңа насыйп яр да көтеп торадыр... Әлегә бар булган юаныч шул алты сутыйда инде. Тик менә, хәерчегә җил каршы дигәндәй, сезонны тагын язга тиклем ябасы вакыт килеп җитте. Ярты ел буе каңгырып тагын май башларын көтәсе...

Ул шулай йә көрсенеп-моңсуланып, йә хыялга бирелеп эчен бушатканда, яки мавыгып гаиләсен, кызларын, аларның кыланмышларын сөйләгәндә, безнең аерылыр вакыт та җитә иде. Вакыт дигәнең бик тиз узып китүчән шул. Өстәвенә соңгы сәфәрннан соң безгә хәтсез генә күрешмичә торырга туры киләчәк иде. Минем чираттагы ялым җитеп, иртәгесе көнгә ял йортына китү планлаштырылган, билет алынган иде. Моны Миргаяз да белә.

— Булат, кара әле, син бит матур гына хикәяләр яза идең. Хәзер дә ташламагансыңдыр, шәт. Мин сиңа үземнең көндәлекләремне бирсәм, бәлки берәр гыйбрәтле язма, повесть кебек нәрсә әвәли алырсың. Мин үзем аның ишене булдыра алмыйм инде. Маташып та караган идем, барысын бергә бәйләп, кеше укырлык итеп очына чыгарыма ышанычым булмагач ташладым.

Мин шунда ук кистереп, ярар, бирерсең, карап чыгармын, дип әйтмәсәм дә, кайтыр юлыма чыкканчы, үз урамыма таба борылганчы ук Миргаязның язмалары кулымда иде инде. Хушлашканда аның чырае янәдән ярыйсы гына яктырып китте.

— Шушы яшемә җитеп әле беркем белән дә бүлешмәгән кайбер уйларым, озак еллар күңел түрендә йөреп, бары шул дәфтәргә генә чыга алган, бәяләүне көтеп яткан хисләрем, бәхет-бәхетсезлекләремнең үзем аңлаган һәм аңламаган сәбәпләре — кыскасы, гомеремнең бер өлешенең ельязмасы биредә. Укып чык әле син аларны. Вакытыңны кызганма. Үкенмәссең. Биредә капчык төбеннән үк тотып ахыргача селкенгән. Уйдырмалар юк. Үземне кызгандырасым килүдән дә түгел. Барысы да ничек булган — шулай. Мин, беләсеңме, аларны нәкъ менә синең кебек кешене, сырлаганнарымны бер рәткә салып дөньяга чыгара алырдайны, каләм белән азмы-күпме дус затны очратырмын, бирермен дип йөргән идем. Инде менә теләгем кабул да булды кебек...

Бу хәлгә мин дә разый идем. Бирәм дигән колына... Язарга «ризык» таба алмый җәфаланганда... Әйткәнемчә, әрсезләнеп, хәтта сансызланып, уртасына ук кереп, берничә бит укыганнан соң, дәфтәрне чемоданыма салып куйдым да юл мәшәкатьләре, барып җиткәч урнашу, теркәлү, бүлмәдәшләр белән танышу ыгы-зыгылары аркасында берничә көнгә онытып тордым. Ял итүнең икенчеме, өченчеме кичендә, бүлмәдәшем каядыр чыгып китеп, ни сәбәп беләндер шул чемоданны ачкач, исемә төшеп, дәфтәрне алдым һәм янадан укырга тотындым. Ул гына да түгел, кичке чараларга, кино-фәләннәргә бармастан, һәр кичне шушы язмаларга багышлармын, вакыт калса, үзем дә яза башлармын дип, күңелемә беркетеп куйдым.

«Әнкәй беркая да китмәде дә, югалмады да. Майның егермеләре узып, чын җәй килгән, шомырт, сиреньнәр шаулап чәчәк аткан вакыт иде. Тик андый гүзәллек белән хозурланыр чакмы соң? Без аны гел күрмәдек тә төсле. Кич җитеп, булган малларны абзарга ябып, ишекнен элгечен эчтән элеп, урын җәеп, йокларга гына җыенган идек. Караңгы тәмам төшеп җиткәнче кинәт кенә ишек шакыдылар. Ачуыбыз булды, кызгылт көрән юкарак одеалга төрелгән бәбиен күтәреп, мыштым гына әнкәй кайтып керде. Ә без, әбекәй белән, бер сүз дә

катмастан, ул кайткан унайга, ул ачкан ишекне дә япмыйча, дәшми-тынмый гына өйдән чыктык та киттек. Елга аръягына, Вафирәттәйләргә. Бу ризасызлык кына түгел, безне рисвай иткән кеше белән бергә яшәүдән баш тарту, нәфрәт белдерү кебек гамәл иде. Әбекәй юл буе: «Менә нинди көннәргә төштек бит, балам. Йә Аллам, тагынниләр күрербез икән?» — дип көрсенде дә көрсенде. Мин исә, башымны түбән игән хәлдә, тамагымдагы төерне йотарга тырышып, язмышка буйсынып, аның артыннан атладым».

Бу кечкенә кисәкне дә, мин, үзем куйган тәртипне үзем үк бозып, өйдә чакта ук укыган идем... Укыган саен гади дә, бер үк вакытта катлаулы да, әмма һәрдаим эчкерсез уй-кичерешләр күнелемә ныклап торып кагыла, язма авторы тойган газаплы уйлар бер-бер артлы күз алдымнан кичә тордылар. Язучыларның бай фантазиясе җимеше булган әдәби әсәрләргә, гәрчә мавыктыргыч булсалар да, күпчелек очракта билгеле бер киная белән карау гадәтем саклангангамы, бу язмаларның бәясе мина ни өчендер югарырак тоелды. Чөнки болар тормыш үзе язган хикәяләр, әйтер идем, хәтта документаль язмалар иде. Шул вакыттагы беренче уем — язмаларны хуҗасына кире кайтарып: «Синең барысы да барып чыгачак, әйдәле, тот та үзең матур гына бер повесть яз, биредә бит бернәрсә дә уйлап чыгарасы юк», — дип әйтәсе килү булды төсле. Чөнки Миргаяз язганнарның барысы да булмаса да, хәтсез өлеше күпсанлы каләмдәшләремнекеннән бер дә ким түгел иде кебек. Шулай уйлап, язмаларны укуны дәвам иттем. Бу юлы инде урта бер җиреннән түгел, ә башыннан.

Дәфтәр хуҗасы язмаларын, гәрчә үзе ул вакытның шаһиты булмаса да, туу көненнән, үзенең чакырылмаган, көтелмәгән килеш, әрсезләнеп дигәндәй, фани дөньяга килү тарихыннан башлап киткән, аны кечерәк бер хикәя рәвешендәрәк тасвирлап биргән иде. Гомумән, язмаларда, авторның тормыштан артык бернәрсә дә сорамастан, бары тик бәгыренә тигән күнелсезлекләрдән арынып, уйларында бәхеткә ирешү теләге ятып, андый халәтнең ни сәбәпледер килмәве, эзләп-эзләп тә табылмавы, табылганда да санаулы вакыт аралыгында эреп югалуы, Миргаязның исә шуның белән килешә алмавы бәян ителгән иде.

## Чакырылмаган кунак

«Әнкәй мине тугачтын, ак биләүгә биләгән. Ак биләүләргә биләгән, бәхете булсын димәгән». Элекке заманнарда гаиләләрдә бала ишле булган. «Заманалар авыр, еллар ябык» булу сәбәпле, зәгыйфьләре үлә торган, ныклары калган. Исән калганнары да хәтсез булып, ата-ананың мәхәббәте барысына да житеп бетә алмагандыр. Һәр туган балага зурдан кубып бәхет теләү йоласы, алда китерелгән шигырьдәгечә, ихтимал, булмагандыр. Ләкин бәхет теләгәндә дә бәхетсез булырга яисә, киресенчә, теләмичә дә бәхеткә тиенергә мөмкинлекне исбатлыйсы юк. Барысын да, күрәсең, күкләр хәл итә. «Бер бәхетсез — гел бәхетсез» дигән иң гаделсез хөкем карарын, аның үтәлешен дә. Әмма тоташ, өзлексез бәхетсезлекнең дә сирәк күренеш икәнен искәртү урынлыдыр. Дөнья бәндәгә алды белән борылган вакытлар да барыбер чыккалап тора бит.

Җиһанга аваз салган мизгелдә бәхет теләүләрен мин, гомумән, көтмәгәнмендер дип уйлыйм. Кая инде безгә, каткан тезгә... Чөнки, әнкәйнең беренче баласы булсам да, бу якты дөньяга яралырга бөтенләй тиеш булмаганмын. Дөресрәге, әнкәйнең мине табасы һич тә килмәгән. Төшертергә дә тырышып караган, тик, ни сәбәп беләндер, аның бу гамәле барып чыкмаган. Күрәсең, тагын да шул күкләр, табигать башкачарак хәл итеп куйган булса кирәк. Дөньяны ярыйсы гына аңлый башлагач, үз-үземә еш биргән сораулар арасында: «Ни хаҗәт, нинди кирәклелек мине бу җиһанга китергән соң?» — дигән сорау да була иде. Әмма

гомер тоташ карангылыктан гына тормый, куанычлы көннәр яралганда яисә искә төшкәндә, барыбер, нәкъ Такташча итеп: «Кирәк булган минем тууым!» дип нәтиҗә ясап куйган чакларым да булмады түгел, булды...

Җиргә яна җәй килергә җыенган чак иде ул. Карлар инде бөтенләй эреп беткән, ялан җирләрдә яшел хәтфә келәм булып, ямьгә, матурлыкка сусаган җиһанны, салкын кышны, язны кичкән барча тереклекне сөендереп, тәүге чирәм чыккан. Май башының көләч кояшы көн саен җылырак карый, назлырак, шәфкатьлерәк була бара. Җылыны көткән, аны күптән тансыклаган табигать, һәммә җан ияләре — терелеп, җанланып килүче бөҗәкләрдән, җәнлек-җанварлардан алып кешеләргә кадәр әчке бер хозурлану, яңару кичергән вакыт. Агачлар яфрак ярырга әле әзерләнеп кенә килсәләр дә, җәй үзе бөтен барлыгы белән башланмаган булса да, кышкы кырыс шыксызлыктан соң яңадан туу, яшәрү чоры иде бу.

Нәкъ шундый көннәрнең берсендә, шаулап-гөрләп табигать уянганда, дөньяга килдем мин. Авыл читендәге салам түбәле тәбәнәк кенә өйдә, киез җәелгән агач сәкедә, жан көчемә кычкырып, моңарчы мине белмәгән, күрмәгән дөньяга аваз салдым. «Җиһанга яңа жан иясе килде, каршы алыгыз, яратыгыз, сөегез, сөенегез!» дигәнмендер инде үземчә. «Жан жылыгызны, күкрәк сөтегезне бирегез тизрәк!» дигәнмендер. Күркәм йола, шатлыклы вакыйга — бәби туе көткәнмендер.

Әмма... Кечкенә кешене, ягъни мине, яңа жан иясен, алда искәртелгән сәбәпләр аркасында, бик алай сөенеп каршы алмадылар. Үзе, кемдер әйтмешли, гариза язып, сорап, әрсезләнеп килмәсә дә, әлеге кечкенә зат бу гүзәл, әмма каршылыклы дөньяда берничек тә зарыгып көтеп алынганнардан санала алмый иде. Һәм шул сәбәпле, туар вакыты житеп килгәндә, ул газаплы да, сөенечле дә булган хәлиткеч мизгелне дулкынланып көтүләр, малай булырмы, кыз булырмы дип, көннәр буе уйланып йөрүләр дә, бар гаилә, булачак әти кеше, әби-бабайлар, туганнар белән кинәшә-табыша исем эзләүләр дә булмады.

Якын кешеләре: «Ярар, килергә җыенгансың икән, кил, ту инде», — дигән сыман, шактый битараф каршыладылар нәни кешене.

Һәм мин тудым. Һәр бала үз бәхете белән туа дигән сүз дә бар бит әле. Дөрес микән ул сүзләр дип сорыйсым килми. Чөнки беләм, дөрес түгел. Туган һәрбер зат дөньяга бәхетен ияртеп килсә, җирдә нинди камиллек, нинди гармония, нинди тормыш булыр иде. Ә мин шулай да тудым. Табигать, нурлы һәм якты җиһан мине бәлки көткәндер, мондый күчеш-әверелешкә әле бәлки чиксез сөенгәндер дә. Башкача булырга тиеш түгел бит. Җиһанга яңа җан иясе өстәлде ич. Табигать үзе теләде. Тик якыннары, бигрәк тә аны дөньяга китерүче өчен ул, үзе әлегә сизенмәсә дә, артык зат, көтелмәгән, чакырылмаган кунак кебек, мәшәкать чыганагы, анын бәхетен урлаучы булып яралды.

Шул сәбәпле, балалы йортта сөенеч-шатлык аз гына да сизелмәде. Киресенчә, җыйнак сәкедә тәбәнәк түшәмгә карап ятып торган, бала табу ыгы-зыгысы белән уйларынын очына һаман да чыгып житә алмаган яшь анада гына түгел, әле яңа гына әби булган кешедә дә ниндидер бер пошаманлык, күзләргә, чырайга чыккан аптыраш, бер гажизлек күренә иде кебек.

«Ир йортында бәбилисе урында монда бала табып ята бит, булмаган!» Азмы-күпме юылган, биләүләнгән бала, елавыннан туктап, йоклап киткәч, яткан кызы янына — сәкегә чәй әзерли башлаган әби кеше эченнән генә берничә тапкыр шулай дип кабатлады. Өстәлдән тастымалга төрелгән түгәрәк ипине алып, бик калын итмичә генә ике-өч телем кисте, күпне күргән сай пыяла савытка берничә шакмак шикәр салды да бер-берсенә охшамаган тоткасыз ике чынаякка чәй агызды. Ана белән кыз, шушы бар булган сый-хөрмәт белән,

янәшәдә тавышсыз-тынсыз йоклаган нәни жан иясенә артык игътибар итмичә, сүзсез генә чәй эчтеләр.

Чырае һаман да карангы калган яшь әнинең күңелендәге төксе уйлары чәй эчкән мәлне дә, аннан соң да аз гына да яктырмады. Башында өзлексез бер чарасызлык бөтерелде дә бөтерелде. «Мондый «койрык» белән хәзер кая барасы да нәрсә эшлисе? Кем генә мине монын белән кияүгә алыр? Бер килмәсә килми икән шул ул. Төшертеп тә төшмәде бит шунда. Эшнең рәтен белмәгәч, нигә тотынырга иде? Житмәсә акчасын да кире кайтармады».

Бераздан анын күз алдына баланың атасы — ярты елдан да азрак яшәп алган ире килеп басты. «Бәлки Галиәкбәрнең, бала тугач, күнеле йомшар? Беренче баласы бит. Житмәсә ир бала. Ул килергә тиеш, килми кала алмас. Тик менә, әйдә, кайт инде, аеры-чире яшәмик, дисә, нишләргә? Янадан шул явызнын да явызы булган каенана янына кайтыргамы? Юк, анысы булмас!» Инде нурланып китәм дигәндә генә йөз янадан чытылды. «Ә ул бөтенләй килмәсә, күренмәсә? Ул чагында бер генә юл кала. Тәвәккәлләргә дә мендәр капларга, бу йөктән бөтенләйгә арынырга. Дөньяга ничек килгән булса, шулай китеп тә барсын. Вакытлы-вакытсыз яралган шушы имгәк дип гомер буе ирсез яшәргәме?»

...Адәм баласының бу дөньяда өч туе була, диләр. Анын беренчесе, иң тәүгесе, билгеле инде, бәби туе. Туй сәбәпчесе, бу якты, әмма шактый буталчык дөньянын яна әгъзасы, үзе шунда булса да, әлеге бәйрәмне, әлбәттә инде, белми, сизми. Ул әле дөнья мәшәкатьләрен, сөенеч-көенечләрен аңларлык хәл-халәттә түгел. Тик мондый чакта ничек туй итми калу кирәк? Бәби туе. Исеме генә ни тора бит. Бәхетле ата-ана, өстәл тирәсенә жыелышкан туган-тумача. Барысы да шау-гөр киләләр, котлыйлар, шатланышып сөйләшәләр. Ә сөенеченнән ни эшләргә белмәгән ана кешенең күзе бары сабыенда гына. Ходай ана дөньяда иң олы бүләк — бала бирде бит. Мондый бүләктән, мондый туйдан, матур теләкләрдән соң ул һәм анын газизе ничек инде бәхетле булмасын. Була, әлбәттә! Анын йөрәк парәсе дөньяда иң сөйкемле, иң уңышлы, иң затлы, иң бәхетлеләрдән булачак...

Менә кайчандыр биләүдә яткан кечкенә жан иясе инде үсеп, чын ир-егет булып житешкән. Тагын йортка туган-тумача, дус-иш, күрше-күлән жыелган. Йортта тагын туй икән ич. Адәми затның икенче туе, төп туе. Монысында инде ул бишектә шыншып ятмый. Монысына ул үзе хужа. Барысын да үзе хәл итә. Барысы да анынча. Чөнки ул табигать кушкан изге бурычын үтәргә алынган, шуңа жыенган. Ул барлык затларга да хас парлашу гадәтен, гаиләле булу йоласын жиренә житкерә. Яна кешегә жан иңдерү, нәсел калдыру жәһәтеннән. Анын янында ап-актан киенгән, үзе дә шул күлмәге кебек ак, пакь, саф булган жан сөйгәне, алда булачак шатлыкларда да, кайгыда да янында калачак, барысын да бергә күтәрәчәк тормыш иптәше. Түрдә аны кечкенәдән яратып үстергән, аякка бастырган газиз затлары — әтисе белән әнисе. Аларнын да йөзендә мөлаем шатлык, горурлык...

Ләкин беркем дә бу фани дөньяда мәңгелек түгел. Адәм балалары, озын-озак тормыш итеп, жирдәге бурычларын үтәп, кайчагында үтәмичә, аннан-моннан гына башкарып, беркөнне бакыйлыкка күчәләр. Соңгы туй килеп житә. Үзенен соңгы туен бәндә янәдән дә күрми, белми, чөнки мәшәкатьле фани дөнья белән алыш-биреше ул инде өзгән була. Бәби туе хакында ана соңрак тәфсилләп сөйли, житкерә, фотосурәтләр күрсәтә алсалар, соңгы туйның ничек үткәнен ул беркайчан да белә алмаячак. Өченче туй ул — үлем туе. Ярый, бу күнелсез якларга тирән кереп китмик. Беренче туй белән соңгы туйнын янәшә булу, тәңгәл килү ихтималын да, андый вәхшилекләр очраштыргаласа да, онытып торыйк...

Көн кичкә авышып килгәндә, сәке өстендәге ул күренешне, ярлы чәй табынын, андагылар үзләре ул турыда уйламаса да, шунда ук, янәшәдә генә иске-москы чүпрәк белән төрелеп, берни белми йоклап яткан нәни кешенең боек кына үткән беренче туе дияргә дә булыр иде».

Язмалар шулай дәвам итә иде. «Чакырылмаган кунак» — әлеге кисәккә автор үзе түгел, ә бәлки мин фәкыйрегез куйган исем. Шулай дип атасам да, аннан соң туган уем — кем дә кем, тик Миргаяз ише затлар бу дөньяга беркайчан да чакырылмаган, дәшелмәгән килеш, чырай ертып килеп керүчеләр рәтендә була алмыйдыр дигәнрәк фикер иде. Ярты гавам — түң, битараф җаннар, бер уйлаганда, биредә кирәкләре шул кадәрле генә булганнар шулай чакырып йә чакырусыз, дәшеп йә дәшмичә, «юллама»ларсыз гына бу җиһанга килгән нисбәттә, ничек инде Миргаяз бирегә арткы ишектән генә атлаган булып саналсын?! Тормыш-яшәешне кечкенәдән үтә дә нечкә итеп тоя белгән, хисләр аша үткәргән, сизгер җанлы булган өчен генә түгел. Барыннан да бигрәк дөрес кеше булып калган, яшәгән өчен. Бу турыда сүз кузгалган икән инде, чынлыкта Миргаяз кебекләрне Ходай Җиргә сынау өчен җибәрә дип уйлау дөресрәктер. Башкача була алмый. Яраткан бәндәләрен Хак Тәгалә фани дөньяга бары сынар өчен китерә дигән сүз юктан түгел ул. Ә икенче яктан... Яраткан жанны шултиклем тилмертү...

Ни генә булса да, кешенең җиһанга килүе дә, китүе дә аерым затларга, хәтта аны тудырган ата-анага да аз бәйләнгән. Барысын да, дәфтәр хуҗасы язганча, табигать-ана, күкләр, ягъни Аллаһы үзе хәл итә, ахрысы. Алда бәян ителгәннәр дә күпмедер дәрәҗәдә моны исбатлый иде булса кирәк...

## Ятимлеккә тиңдәш үгилек

«Мин әнкәйгә рәхмәтле дә, бер караганда. Ул, гөнаһтан куркыпмы, әллә күнелендә күпмедер микъдарда ана булу хисләре уяныпмы, башында йөрткән теге начар уен гамәлгә ашырмыйча калган — мине мендәр белән каплап, тончыктырып үтермәгән. Тик бераз үсеп, үземә әйтелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлый башлаганнан бирле колагыма еш ишетелгәне: «Шунда туу белән ястык каплап үтермәгәч соң!» — дигән сүз булды. Моны әнкәй миңа ачуы килгәндә, күпмедер үкенеп, күпмедер «менә шундый эшне эшләмәгәнгә рәхмәт әйт, юньсез малай» дигән кебегрәк белдерә иде. Мин, мондый битәрләүгә, сабыйлык белән аңышмыйчарак булгандыр инде, үпкәләми идем. Бераз исәйгәч кенә аның ишене ишетми башладым. Тик, күп кабатлану сәбәпледер, хәтердә калды ул сүзләр. Әмма әни кешедән андый сүз ычкынсын, аның ише үкенүләр килеп тусын өчен мин — биш-алты яшьлек малай нинди тәртипсезлекләр, нинди әшәкелекләр эшләгәнмендер, хәзер дә искә төшерә, аңлый алмыйм.

Ә мин әнкәйгә барыбер тартыла, янына килә, сырпалана, аңа иярергә тырыша идем. Тик «койрык», яратмаган «койрык» бит, аны тагып... Берсендә сабан туена бик барасым килеп, мине иярт инде дип, елый-елый аның артыннан әллә күпме йөгергәнемне, әнкәйнең мине ачуланып, аның саен тирги-тирги кирегә куганы бөтен төсмерләре белән хәтергә уелып калган.

«Чукынмыш бала, бер бәла булдың инде тәмам», — кире килеп, мине ныклап җилтерәткәч, мин, сабан туен күрергә лаек түгеллегемне аңлап, күзләремне җиңем белән ышкый-ышкый, өебезгә таба титакладым.

Мин ул чакта әнкәйнең миндәй «бирнәсен» ир-атларга күрсәтеп йөрисе килмәгәнен аңларлык идеммени? Ачуы чыкканда, миңа төбәп кабатларга яраткан сүзләренең тагын берсе: «Ник тугансыңдыр, тумаган булсаң, күптән кияүгә дә чыккан булыр идем». Балалык белән монысын да бик аңышып

бетермәгәнмендер инде, анын саен йомшак кочак эзләп ана тартылмаган, тагылырга да омтылмаган булыр идем.

Их, әнкәй! Мин бит синең мине яратуынны, сабый чакта гына түгел, егет булгач та, ир-атка әверелгәч тә, гомер буе көтеп, теләп, җылылыкка, назга сусап яшәдем. Җырларда җырланган әни кеше, ана бит ул! Ул йөрәк парәсен — баласын сөйми кала аламы? Алай булмый, тиеш түгел! Хәтта җәнлекләр дә нарасые өчен барысына да, хәтта үзләрен корбан итәргә дә әзер. Тик ни эшлисең, дөнья шул бу. Сабыйларын теләсә кайда ташлап китә алган «күкеләр» дә күренгәләп тора. Аллага шөкер, әнкәйгә дә рәхмәт, мина начарлыкның анын ишесе эләкмәде. Әле янарак кына бер газетада «Балаларым мина кирәк түгел» дигән язма укыдым. Мин әнкәйгә кирәк булдым анысы. Тик үсә төшкәч, ярдәмче сыйфатында. Авыл җире бит, эше бетә торган түгел. Чүкеч, балта тотарга да ир-ат җенесеннән булган зат барыбер кирәк. Аннан соң утыны, печәне дигәндәй.

Их, әнкәй, әнкәй! Бала чагымда бер генә тапкыр алдына утыртып, тупылдатып сөйгән, башымнан сыйпап, «балам» дип дәшкән булсаң икән. Боларны язар идемме сон бүген? Ник мин шултиклем үги булдым соң сина? Хәзер «ник?» дип сорасам да, сәбәпләрен чамалыйм. Беренчел сәбәпләрен. Тик еллар үтә торды. Ярар, син яшьрәк чакта, парлы тормыш корырга, кияүгә чыгарга хыялланганда, мин гаепле дә булыйм. Вакытлы-вакытсыз дөньяга килүем белән. Ә аннан сон? Элеккене куыпмы, сонынннан да, ир-егет булып житешкәч тә мине үз итмәүләрен. Югыйсә, кырык ничә яшемә житкәнче, һәр елны кайтып печәннәренне дә чаптым, утынын да әзерләми калмадым, каралты-кураларны да кирәгенчә карап тоттым. Бу эшләрне, берүземә генә җинелдән булмаса да, авырсынмыйча, хәтта теләп башкардым. Ул гына да түгел, андый ярдәмне һәрдаим бурычым, вазифам итеп саный идем. Тик мин кире шәһәргә кайтырга җыенганда, китеп барганда, бер-ике җылы сүз әйтә, «улым, бу эшләрне дә булдырдын, рәхмәт!» дия белми иден. Җылы сүз — җан азыгы, диләр, әмма андыйны мин ишетмәдем. Ни өчен? Эшләп, булышып, даими кайтып торып та мин сина нигә, ни өчен ярамадым сон, әнкәй? Көтеп алынмаган бала гомерлек үгилеккә хөкем ителгәнгәме? Тик шул дәрәҗәдә... Минем тормыштагы азмы-күпме уңышларыма, шатлыкларыма да сөенә белмәден, ул гына да түгел, андый хәлләрне син йөзенә битарафлык кына түгел, хәтта ки килешмәүчәнлек чыгарып кабул иткән чакларын да булмады түгел, булды.

Нигә? Ни өчен? Мин мондый һәм башка шуның ише сорауларның күп өлешенә җавап эзләп, аны тулысынча табып бетерә алдым дип һаман да исәпләмим. Ә бәлки бетергәнмендер дә. Синен бик тә үзенчәлекле холкын да бар иде ич әле. Бөтен хикмәт тә шул тарафларда булмады микән? Беренче карашка гади булып та, тиз үрталучән, кызу, хәтта гаугалы табигатен. Мине — «койрыкны» бөтенләй исәпкә-санга алмаганда да якыннарына һәрчак кыен ашаткан, чикне-чаманы белмәгән көйсезлеген. Теләсә нинди холыксызлыкның адәми зат өчен бәхетсезлек икәнен, холыкның язмышны билгеләгәнен бик сон, гомереннен соңгы елларында гына анладың син. Ә аңынчы үзенә-үзен китереп торган бәхетсезлекләрне безнен белән мул итеп бүлештен. Минем ныгып житмәгән йөрәгемне яралы итүенне — әтиебез булмаган көе бәби алып кайтуынны әйтәм. Анысы яратмаудан да яманрак булды. Ни эшләгәненне анлап житкермичә, хисләр давылына буйсынып кылдың син ул эшне, тормыш асылын тоймыйча китереп чыгардын. Ярый, анысы турында алдарак сөйләп бетерермен.

Әнкәйнен кияүдән капылт кына аерылып кайту тарихы да шул коры дары кебек гөлтләп кабынып китү гадәте аркасында килеп чыккан, мәзәк эзләгән кешегә мәзәк тә, гыйбрәт белгәннәргә гыйбрәтле дә бер хәл булган. Идән юып йөргән җирендә биана кешенен нидер әйткәнен, нәрсәдер өйрәткәнен күтәрә

алмыйча, юкка үртәлеп, әнкәй, шул идән ышкыган мунчаланы беркая да сыймый торган дуамаллык белән карчыкның чыраена ук төбәп атып, әйберләрен җыеп кайткан да киткән. Әлбәттә инде, мондый гамәлдән соң аның артыннан йөрүче, кайт дип ялынучы, килеп алучы булмаган.

Тик әти кеше безнең тарафларга килми түгел, килгәли иде. Хәтта бик теләп. Юк, әнкәйне сагынып, аны кайтырга чакырырга йә булмаса бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә мина бүләк күтәреп, күрәсе килеп, «улым» дип башымнан сыйпар, яратыр өчен түгел. Хәзер дә бик шикләнәм, туган көннең кайчан икәнен төгәл белде микән ул? Юктыр. Белсә, авылда үткән унҗиде ел эчендә әти кешедән бер генә тапкыр булса да берәр очсызлы күчтәнәч алганым булыр иде. Ул күбрәк мин йоклагач, әбекәй кайда да булса кунакта вакытта безгә сугыла иде. Сәбәбен әйтеп торасы түгел инде, билгеле. Әнкәй кумагач, караңгы чырай күрсәтмәгәч кенә түгел, көтеп тә алгач, ник килмәсен. Тик ул төнге сәфәрләрнең ахыр нәтиҗәләре китергән гаҗизлекләр...

Хәзер барысы да үткәндә инде. Үпкәләрем калган булса да, аларны шушы ак кәгазь битләренә салып, шыңшып алсам да, мин сиңа рәнҗемим инде, әнкәй. Күптән рәнҗемим. Җөйләре калса да, бар булган яралар акрын гына төзәлде. Ялгыштан, хатадан хали түгелдер беркем дә. Тагын Такташны искә төшерәм дә: «Рәхмәт, әнкәй, сиңа, ярый әле мине тапкансың», — димен. Рәхмәтем тагы шуна: сөймәсәң дә, мине үстердең. Өстемне дә карамадың түгел, үзенчә карадың. Тамагым ач йөргән чаклар да, Алланың рәхмәте, булмады. Хәтта читкә китеп укуыма да аяк терәп каршы тормадың, җибәрдең.

Ә менә әбекәй... Рәхмәтләремнең иң олы өлеше сиңа, әбекәй. Мине әниле үгилектән, гаепсездән гаепле булудан үзенчә аралаган, коткарган рәхимле җан. Гел генә сөеп, яратып тормагандыр ул, тик оныгын беркайчан да ят итмәде. «Казлар артыннан да сине күтәреп йөгердем, сепарат аертырга барганда да үземнән калдырмадым, күршеләргә кергәндә дә җитәкләгәнем син булдың», — дип искә алганнары хәтеремдә әле әбекәйнең. Шулай булгандыр. Кибеткә дә мине ияртер иде, кунакка барганда да. Усалрак булса да, вакытында тамагымны туйдыручы да, яклаучы да, саклаучы да шул әбекәем иде. Инде ир уртасы булып җиткәч тә, эшләгән җиремә, ишегалдына чыгып, яныма килеп, «балам» дия-дия аркамнан кагып сөюләреңне һичкайчан онытасым юк. Балам! Әнкәй әйтә белмәгән, теләмәгән нинди назлы, нурлы сүз. Ачык йөзле, шат күңелле, кеше белән сөйләшергә яратучы, аралашучан, юктан да сөенә белгән әбекәем минем...»

...Шакмаклы дәфтәргә ваграк хәрефләр белән тигез итеп сырлап барылган язмаларның бераздан мин башка төрлерәк урынына — көннәр, айлар, ягъни төгәл даталар куелган, кыскача гына шул көннәргә бәйле гамәлләр, кичерешләр язылган өлешкә — классик көндәлек дип атарлык шәрехләүләргә килеп төртелдем. Әмма бу өлеш озакка бармады. Бераздан тагын язма хуҗасының күңеленә генә түгел, минем тойгыларга да ярыйсы тирән уелган, танышым, гадәтенчә артык хисләнеп, түкми-чәчми шушы дәфтәргә күп булса моннан биш-алты ел элек теркәп куйган урынга, дәфтәрне кулыма алгач, иң беренче булып укый, таныша башлаган вакыйгалар арасына янадан кереп киттем.

## Бәхет өчен алтын таулар кирәк микән?

«Әнкәй бәбие белән кайтып кергәч, өйдән чыгып китү, әбекәй белән бергә — Вафирәттәйләргә килеп урнашу, безгә караңгы чырай күрсәтүче булмаса да, икебезнең беребезгә дә тынычлык алып килмәде. Шулай буласы билгеле инде. Кеше өстендә яшәүдә нинди юаныч булсын? Авыр тойгылар җанны басып торганда бигрәк тә.

Чит урамда яңа дуслар табып та аларга ныклап торып ияләшә, онытылып китеп уйный алмадым. Бимазалы уйлар мине ташламады. Ә бит моннан өч-дүрт айлар элек кенә хәлләр гел башкача иде. Бүгенге белән чагыштырганда, мин чып-чын бәхетле идем. Бәхет өчен минем кебек бала-чагага гел дә күп кирәкмәгәнлекне, бары тик оятлы, гарьлекле хәлләр китергән борчулы уйларның башны корт кебек өзлексез кимереп тормау зарурлыгын мин шулай иртә аңладым. Әле кышын гына үзенең җылы кочагында тоткан бәхетне мин, бәлки, сизмәгәнмендер дә. Булганда бәхет беленми, тоелмый, диләр ич. Шуны гына беләм: рәхәт иде. Өйдә дә, күрше-тирәдәге дусларым арасында да, мәктәптә дә. Хәер, барысын да үз тәртибенә куеп сөйлим әле.

Куаныч-шатлыкларымның иң зурыннан — мәктәптән башлыйм. Әйе, кайберәүләргә андый сүз, андый бәхет гаҗәбрәк тоелса да, нәкъ менә мәктәптән. Дүртенче сыйныфны без ваграк бүрәнәләрдән бурап өеп, сугышка кадәр үк салынган, эчтән һәм тыштан кызыл балчык белән сылап, акбур белән яхшылап агартылган, кечкенә тәрәзәле, мичле иске класста тәмамладык та бишенчегә җәен генә эше бетерелгән яңа олы таш мәктәпкә күчтек. Ул яңа гыйлем йортының матурлыклары! Сәкеле, олы мичле, мич башлы тар һәм тәбәнәк авыл өйләреннән башканы бик күрмәгән балаларга үзе бер яңа дөнья иде ул. Олы тәрәзәләр, иркен, якты класслар. Буявы кибәргә дә өлгермәгән яңа парталар. Без белмәгән, күрмәгән приборлар белән җиһазландырылган физика һәм химия кабинетлары, безгә — кепкаларыбыз белән бергә үлчәгәндә дә буйларыбыз метрдан ярты карышка да артмаган малай-шалайга алагаем тоелган спорт залы. Класслар саны да исәпләп бетергесез. Абайламыйчарак йөрсәң, адашырлык инде менә. Башкаларга ничек булгандыр, анысын әйтә алмыйм, тик мина укуны, укытучыларны, мәктәпне яраткан затка, бу хәл олы бер өстәмә шатлык, куаныч иде. Искә төшкәндә, хәзер дә гаҗәпләнеп куям: мәктәпкә мин бәйрәмгә баргандай көн дә теләп бара, рәхәтләнеп йөри идем. Хәзер менә «идем» дим. Тик ул язгы көннәрдә... Хәер, аларын күпмедер бәян иттем инде.

Бу урында бар булган сөенечләремне берәмтекләп, бөртекләп күрсәтәсем, язасым килә минем. Чөнки алар әле дә, ничә дистә еллар узгач та, кадерен аз гына да җуймыйча, күңелем түрендә саклана килә. Без шулай бишенче класска кердек. Һәр фәннән аерым укытучы булу башта бераз шөлләтсә дә, анысына тиз күнегелде. Баш мие, җәйге челләдә кибешкән тамак аның саен су талəп иткән кебек, гелдән-гел гыйлем сорап торгангадырмы, фәннәрнең күбесе миңа гаҗәеп дәрәҗәдә кызык иде. Шул сәбәпле, укуның туйдырганын, тизрәк өйгә качасы килеп ялыктырган чакларны аз гына да хәтерләмим мин. Игътибар белән укытучыларны тыңлыйм. Өй эшләрен дә жирено житкереп, яратып башкарам. Иртәләрен кечкенә тәрәзәле җыйнак өебездән бик теләп чыгып китәм дә, өч чакрымлап еракка, авыл уртасыннан да арырак урнашкан гыйлем йортына барам. Белем дөньясы үтә дә серле икән ул. Гыйлем эстәү дә шатлык, бәхетне мулдан китерә ала икән. Класста беренче булсаң — бигрәк тә. Ул классташлар белән аралашуларны, чем-кара күзле, кыйгач кашлы гүзәл Гөлчәчәккә, сирәгрәк булса да, мәсьәлә чишеп биреп, рәхмәтләр алуны инде әйткән дә юк. Укытучылар да, фәнне яраткач, яхшы укыгач, сине үз итә икән бит. Алар да газиз кешеләргә, хәтта, әйтер идем, җырларда җырланганча, иң изге затларга әйләнә дә куя. Өйдә җылы житмәүдән генә түгел, мин аларны шул гыйлем чәчүләре, исемем белән матур итеп дәшүләре, мактап, дәртне үстереп торулары аркасында бик тә ярата, хөрмәт итә идем. Балачакның бәхетле мизгелләренең олы өлешен мин нәкъ менә алар белән, мәктәп белән бәйләми кала алмыйм.

Арттыруым түгел. Менә абыем урынына күргән, озын буйлы, мәһабәт

гәүдәле укытучы Шәвәли абый. Бизәкле кара указкасын, бар булган күрсәтмә әсбапларын тотып, олы адымнар белән ашыкмыйча атлап, класска килеп керә. Ул керүгә класс уртасында диафильм аппараты инде урнаштырылган, олы карталар кирәкле урынга эленгән, өйрәнәсе тема параграфлары белән тактага язып куелган була. Мин аптырыйм, башкалар тарихтан ничек «өчле» ала икән? Ничек яратмыйлар, ялкауланалар, ничек исләрендә калмый, нигә ичмасам шунда укып булса да килмиләр? Төсле карандашлар белән аллы-гөлле итеп борынгы дәүләтләрнең чикләре билгеләнгән, кызыл ук белән Рим легионерларының яулап алуы күрсәтелгән контурлы карталарны укытучы абый җыеп ала да миннән тикшертә, мин үзем үк аларга билгеләр дә куеп чыгам. Менә бит ничек бәялиләр! Син ясаган карта кибеттән алынган атластан ким түгел, дип мактый мине Шәвәли абый. Шуңа класста кем ничек булдыра ала, шулай бизәгән, сызган, сырлаган, язган карталарны мин тикшерәм. Аннары алгебра дәресе. Тигезләмә, мәсьәлә чишү үзе бер рәхәт мәшәкать. Геометрия дигәне исә тагын да кызыклырак. Әкълимә апабыз өй эшен тикшереп чыга да, иң авыр мәсьәләне бары мин генә эшләгәнен белгәч, такта янына чыгара. Мин тактада аны эшләп, чишеп күрсәтәм дә, бишле алып үз урыныма утырам. Шулчакта алма битле Гөлчәчәк тагын миңа карап, матур итеп елмаеп куя. Минем дә авыз — колакта. Монысы — шатлыкларымның иң зуры. Чөнки барысын да уздырып кына калмыйм, бүләккә якты елмаю да алам. Борынга кызлар исе ныклап керә башламаса да, аларга карата битарафлык юкка чыгып килгән вакыт бит. Гөлчәчәк — үзенең нурлы елмаюы белән моның беренче сәбәпчесе. Мондый халәтне бәхет димичә тагын ничек атап булсын инде. Тик... Тулышып торган шушы бәхетемнең тиздән бәхетсезлек белән алышынасын мин белмим шул әле...

Яңа мәктәбебездә шул рәвешчә беренче, икенче чирекләр узып та китә. Иң озын өченче чирек башлана. Ул ахырына якынлашкан мәлләрдә мәктәптә элеккечә барысы да ал да гөл булса да, өйдә күңелсез хәлләр башлана. Мин әнкәйдә алда бәян ителгән үзгәрешләрне сиземли башлыйм. Көннәремнең кояшы сүнеп, нииндидер эңгер-меңгердә яшәсәм дә, укуга бармыйча калып булмый. Ул мине күпмедер коткарып килә. Күңел куырылган булса да, мин анда беразга онытылам, элекке мәңге бетмәс шатлыклы көннәрне гизгәндәй, дәвам иткәндәй булам...»

Бу юлларны укыганда, Миргаязның җәяүле сәйранда йөргәндә: «Мине бөтенләй үк читләтеп узмаган бәхетле мизгелләр нәкъ менә гыйлем эстәү, башта мәктәп, аннан соң институт еллары белән бәйле», — дигәне искә төшеп, бу чакта ул сүзләрне, артык тиранәгә төшми генә, тагын да шул сәерлек белән бәйләсәм, хәзер фикеремнең үзгәрүен искәртми кала алмыйм. Бәхет формуласы кеше заты өчен төрледән-төрле, күптөрле һәм бик тә үзенчәлекле — аны һәркем үзенчә эзли, таба һәм тоя бит.

## Мин әнкәйдән качтым

«Вафираттәйләрдә яши башлап, бер атна да үтәр-үтмәстән, мәктәптә укулар бетте. Без, бишенче классны (ул вакытта сыйныф дип түгел, «класс» дип сөйләшә идек) тәмамлаган кырыктан артык укучы, ягъни ике параллель класс, үзебездән ун-унбиш чакрым ераклыктагы күрше авылга, ул вакытта аталганча, экскурсиягә, җәяүләп кенә үтешле сәяхәт-сәфәргә җыена башладык.

Әле аңынчы, ул сәфәргә, ягъни походка китеп барганчы булган бер кызык та, кызганыч та хәл — үзенчәлекле урлашу турында да бераз бәян итәсем килә.

Алда искә алынган сәяхәткә мина да, башкалар кебек, үзем белән азмы-

күпме азык-төлек, һич югы ипи белән пешкән йомыркалар алырга, булдыра алганча юлга әзерләнергә кирәк иде. Тик кешедә яшәп, барысын да соранып тору ифрат та унайсыз. Шуны алдан исәпләпме, әбекәй, әле икебез генә яшәгән, әнкәй бәби тудырып яткан чакта, үзебезнен карлыган бакчасына берничә дистә йомырка, гәжиткә кат-кат итеп төрелгән сохарилар, кечерәк савыт белән каймак, башка шунын ишене яшереп куйган булган. Иртәгә экскурсиягә китәсе дигән көннеме, аннан алдагысындамы, әбекәем белән икәүләп, төнне көтеп алдык та, яшерелгән хәзинәләрне алырга дип, гомер иткән өебезгә таба киттек. Ул чакта андый гамәлнең асылын бәлки уйлап, бәяләп тә бетермәгәнмендер, әлеге сәер эшне бүген, бер дә ялгышмыйча, үзеннекен урлау дип атаганда бик дөрес булыр иде кебек. Ә ул чакта...

Бу вакыйга хәтеремә шундый нык сенеп калган, мин аны беркайчан да оныта алмам, ахры. Без, житмешне тутырып килүче карчык белән мин — унике яшьлек үсмер, икәүләп, дөм карангыда инешнең тар басмасы аша чыктык та авыл башлап шыпырт кына үзебезнен өйгә, ихатага якынлаштык. Минем күнелдә чын-чынлап урлашырга, ярамаганны эшләргә баргандагыдай курку. Ни өчендер әнкәй килеп чыгар да якадан эләктереп алыр, жибәрмәс, тавыш куптарыр, авыр сүзләр әйтер, эш бер дә пешмәс кебек тоела. Тик бармыйча да булмый.

Урам инде йоклый, сирәк тәрәзәләрдә генә сонарган тонык утлар күренә. Авыл башынын яшел келәмдәй кин, иркен чирәмлеге безнен карлыган бакчасынын коймаларына ук килеп терәлгән. Урамга кереп тә торасы түгел. Әбекәй тышкы якта калып, мин койма аша сикереп бакчага үтәргә һәм карлыган куаклары төбенә, былтыргы яфраклар астына күмелгән йомыркаларны, башкасын эзләп табып, аларны алып чыгарга тиеш идем. Яшерелгән әйберләрнең кай тарафта булуын әбекәй анлатып та күрсәткән иде төсле. Шулай да, балалык беләндер инде, койма аша сикергәнче үк тагын да нык дулкынланганым, каушавым истә калган. Югыйсә, кешенекен алырга дип килмәдек, үзебезнен өй, үзебезнен бакча, үзебезнен ризыклар бит.

Безнен өйдә дә ут инде сүнгән, бер тавыш-тын да ишетелми. Әмма йөрәк барыбер дөп-дөп тибә, шомландыра, эшнең барып чыгуы шикләндерә. Чыннан да, барысы да без көткәнчә жайлы гына булмады ул кичне. Хәерчегә жил каршы дигәндәй, инде койма аша сикерәм дигәндә генә, төнге куе карангылыкны ярып, авыл башын машина утлары яктыртты. Ташлы дип аталган, бездән 3-4 чакрымдагы зур булмаган авыл ягындагы кыр юлыннан, утларын яктыртып, төнге илаһи тынлыкны гүләве белән бозып, йөк машинасы төшеп килә иде. Без, әбиле-оныклы ике «карак», яшеренеп, аны үткәреп жибәрергә булдык. Икәүләп, йөгерә-атлый барып, каршы күршебез Мингәрәй абыйнын мунча бурасы артына постык. Тик машина дигәнебез берәү генә булып чыкмады. Берсе үтеп киткәнче утларын ялтыратып икенчесе, өченчесе якыная. Авылга керми үзләре. Авыл башы коймаларын, тирәкләрне, йорт, каралты-кураларны яктыга күмеп киләләр-киләләр дә, борылып, ындыр арты юлына чыгалар. Без, түземсезләнеп, аларнын үтеп беткәнен көтәбез. Ул вакыт арасы шундый озак тоелды, әллә шунда тулы бер колонна үтте. Мин инде үземдәге шөбһәләнү-шикләнүләрдән туеп, бернәрсә дә алмыйча, кире кайтып китәргә дә әзер идем.

Ниһаять, машина шавы тынды, авыл башы янәдән куе карангылыкка чумды. Мин бакчага үттем. Карлыган бакчасы шактый олы булып, андагы куаклар да биек һәм куе иде. Шактый озак эзләдем мин ул ризыкларны. Дөм карангыда үрмәләп дистәдән артык карлыган төбен капшап чыкканмындыр. Ахырда йомыркаларны, сөт өстен, башкасын табып алып, койма аша әбекәйгә бирдем. Ничек килгән булсак, шулай шым кына кайтып та киттек. «Бурлык» тәмам,

походка барырлык ризык бар. Эш пешкәнгә сөенсәм дә, дулкынлануым ярты юлсыз бетмәде. Икенче яктан, кайтып житәрәк көнелгә аз-маз сөенеч тә үтте бугай әле. Ни дисәң дә, ниятләгән четерекле эшне башкарып чыктык бит...

Һәм менә «чит мәмләкәтләргә» кылган сәяхәтебез, экскурсия дигәнебез ахырына якынлаша. Бездән ун чакрым ераклыктагы күрше авыл мәктәбендә бер кич куныл, икенче көнне бөтенләй урман эченә урнашкан кечкенәрәк икенче бер салада да булганнан соң, ярты дөньяны гизгәндәй канәгать калып кайтып килүебез, үз авылыбызга кереп маташуыбыз. Керүгә үк урамның бер ягында безнең ихата, өй һәм каралты-куралар булса, икенче якта — Мингәрәй абыйларның таза хужалыгы. Өйгә, үзебезгә керү минем башымда да юк. Әнкәйгә булган рәнжү, үпкә печтек тә кимемәгән. Нишләргә соң? Капкабыз яныннан кермичә генә үтеп китәргәме? Анламаячаклар. Ә анласалар? Өйдә яшәмәвемне классташларыма, укытучыларга сиздерәсем килми. Сүздән, гайбәттән куркам. Мин, үземчә хәйлә корып, алдан ук аяк киемемдәге шнурларны сүттем. Һәм өебезгә житәргә нибары егерме-утыз адым кала, туктадым да, шуларны бәйләгәнгә салышып, барысыннан да артта калдым. Булган бар ниятем — өй ягына әйләнеп тә карамыйча, авыл башлап кына су буена сыптырту, бу урыннан югалу иде. Хәйләм башта барып та чыкты: сабакташларым аны-моны исәпләми генә юлларын дәвам итте. Артка әйләнеп карамадылар. Тик... Әнкәй, капка төбенә чыгып, көтеп торганмы, мине күреп, каршыга ук килә башлады. Уе мине кайтару, алып калу иде булса кирәк. Ике атна буе бәбие белән генә яшәп, үзенчә малаен сагынуы булгандырмы, белмим. Тик мин качтым. Мингәрәй абыйларның бәрәңге бакчасы коймасы буйлап, аякларымны жиргә дә тигерми, жан көчемә инешкә таба йөгердем. Әнкәй, нидер әйтәсе, анлатасы килеп, «улым, улым» дип, артымнан хәтсез генә чабып караган иде дә, куып житә алмасын анлап, туктап калды. Бер әйләнеп каравымда, ул шул туктаган урынында һаман да булса минем якка карап тора иде әле. Аның ул мизгелдәге хәлен, ул кичергән кыенлыкны күпмедер анласам да, аңа булган үпкәләрем тамак төбендәге мәңге йотып булмас төер хәлендә һаман да үз урынында иде шул. Мин әнкәйне кызгана алмадым. Куркынычтан, бәла-казадан, афәттән качкан кебек, йөгердем дә йөгердем.

Укучылар һәм укытучылар авылга кереп киттеләр. Әнкәйнең минем арттан чапканын күрмәделәр дә бугай. Мин, сулышым кабып, инешкә чаклы йөгергәч, туктадым да, азрак хәл алгач, инеш аша салынган агач басма аша Түр урамга, бу дөньяда мине яклаучы һәм саклаучы берданбер кешем — әбекәем булырга тиеш жиргә, Вафирәттәйләргә юнәлдем. Минем уникe яшьлек аңым әнкәй китергән хурлыкны кичерерлек түгел иде әле ул мәлне...»

## «Башка алай эшләмәссеңме?»

«Әбекәй белән без, әнкәй янына кайтмыйча, Вафирәттәйләрдә дүрт-биш атналап торган идек инде. Жәйге каникулның икенче ае башланган мәлдә көтмәгәндә мине класс житәкчем Рәйсә апа эзләп тапты. Минем читтә яшәп яткан аңа да барып житкән, күрәсең. Үз укучысы өчен жаваплылык та бар бит әле. Ул мине «сукбайлык»ны ташлап, әнкәй янына кайтырга, шунда яшәргә үгетли башлады. Янәсе, бала, ни генә булса да, анасы янында торырга тиеш. Эчеп, тузынып йөрми, калганы исәпкә алынмый икән. Шулайдыр да анысы. Бала-чагага үтәрлек итеп анлата алмаганнанмы, ул: «Бер синең анаң гына түгел ирсез бала табучы, әнә фәлән хатын да шулай бала тапты» , — дия-дия, андый гамәлне батырлык үрнәгенә үк китереп житкермәсә дә, әнкәйне аклап, мине кайтырга кыстады, тагын әллә нәрсәләр сөйләде. Ул үзенчә сөйли, анлата, ә

минем яралы күңел андый аңлашуны күтәрә алмый, күзләрдән янә нечкә-нәзек елгалар булып тын гына яшь ага. Гарьләнәм. Өйдәге хәлләр менә кая, мәктәпкә хәтле барып житте бит. Ничек итеп, ни йөзләрем белән көзен, яна уку елы башлангач, анда барып укучыларга, укытучыларга күренермен дә ничек укып китәрмен дип хафаланам.

Артка борылып карый-карый, әнкәйдән бар көчемә чабып качкан ул мизгел хәзер дә кат-кат искә төшә. Бу гамәлгә соныннан үкендемме, юкмы, хәтерләмим. Ә менә Рәйсә апа янында басып торганда, әгәр шул вакытта өйдә калган булсам, бу оятлы һәм хурлыклы хәлдә, гаепсездән гаепле булып, башымны иеп, аптырашта тормаган, укытучым да безнен турыда, бәлки әле, бернәрсә дә белмәгән булыр иде дигән уйлар күп тапкыр башымнан йөгереп узды...

Әле дә менә шул көннәргә кат-кат кайтып фикерлим дә чыгарган нәтижәләрнен дөрес яисә дөрес түгеллеген тагын бер кат үземчә тикшерәм: әнкәй, мине аз гына булса да яраткан, үз иткән булса, баштан ук иплэп кенә барысын да аңлатса, миңа ул кадәр үк авыр булыр идеме икән? Юк, әлбәттә! Болай качып йөрүләр дә, ихтимал, булмас иде. Әмма жаны сөймәгән «малай актыгы — койрыкны», ягъни мине, акны карадан, яхшыны начардан аеру яшенә житмәгән, олылар арасындагы мөнәсәбәтләрне белмәгән, белергә дә тиеш булмаган бала-чага дип карап, андый мәсьәләдә тирәнгә кереп ваклашуны кирәк тапмаган әнкәй. Мине бернича атна күрмәве, монарчы һәрчак янында булган малаеның качып китүе аны бераз айнытып жибәргәндер анысы. Эшнен тирәнгәрәк киткәнен дә сизенгәндер. Тик соңгарак калган иде шул ул...

Узган хәлләрдә мантыйк эзләүне дәвам итеп, вакыйгаларга башка яктан килеп караган чаклар да булды. Инде ярар, мине бала-чагага да санасын, әбекәйгә — үзенең анасына, дөнья йөген үзе белән бергә ничә еллар янәшә тарткан кешегә, инде хәл шуңа барып житкән икән, әйтергә, аңлашырга, хәтта гафу да сорарга кирәк булгандыр. Әмма монысы да юк. Нииндидер тупас һәм хәтта, әйтер идем, беркем дә аңлатып бирә алмаслык аңсызлык һәм сансызлык аркасында димме, әнкәй моны да эшләмәгән. Эшләүне кирәк тапмаган. Мескен әбекәемнең: «Ничек түзим бу хурлыкларга?» — дип, күз яше түгеп кайгырулары исемә төшсә, әле дә бәгырем йөз телемгә телгәләнә.

Соныннан әнкәй минем читләшүемнен сәбәбен әбиемнән күреп, шул гына котырткан малайны дип йөрсә дә, бу һич тә алай түгел иде. Язганымча, яраганны ярамаганнан, яманны яхшыдан аеру гына түгел, хурлыкны да бөтен йөрәгем белән сизә торган яшьтә идем инде мин. Табигать мул итеп биргән нечкә тоемлылык белән хисслелек — хәлләрне кирәгеннән артык куертып, катлауландырып, мине өметсезлек чигенә терәп торган сыйфатлар булуын да искәртмичә ярамастыр...

Класс житәкчесе әйткәнне мин үтәмәдем. Укытучыларны бер сүздән тыңларга өйрәнгән укучы, үземне өйгә кайтырга барыбер мәжбүр итә алмадым. Класс житәкчем китеп, атна-ун көн үтте микән, кеше аша миңа «фәлән вакытка мәктәпкә килсен», дип әйтеп жибәргәннәр. Нигә чакыруларын сизенмәгәч, кая китәсен, бармыйсың түгел, барасың инде. Болай да башы каткан үсмер нишләсен? Баруыма мәктәпнең кара айгыры тарантаска жигелгән иде инде. Класс житәкчесе Рәйсә апа белән завуч Сәлим абый, парлашып шул тарантаска менеп утырдылар да, миңа алга, кузлага урнашырга кушып, дилбегәне тоттырдылар. Шулай кузгалып китсәк тә, башта әле үземә хас беркатлылык белән һаман аңлап бетерә алмыйм: «Болай кыланып өчәүләп кая барабыз, нишләргә жыенабыз соң без?» Бераздан барып житте, төшендем: болар мине әнкәй янына кайтаралар ич...

Бераз елгыр, шомарак малай заты булса, ике дә уйламый качкан, дилбегәне

болгап атып, тарантастан сикереп төшкән дә, күзе кая карый, шунда чапкан булыр иде. Тик мин, аның ише тәртипсезлекне белмәгән жан, әнкәйдән качкан кебек, укытучылардан качуны күз алдына да китерә алмадым. Язмышка буйсынып, өебезгә кайттым.

Өчәүләп йортка да кердек. Әнкәй кулына күпне күргән агач ипи калагы тоткан да мичкә икмәк салып йөри. Бәбинең тавышы-тыны ишетелми, ул йоклый кебек. Ә менә өй эчебез бөтенләй шып-шыр, ялангач. Йортка азмы-күпме ямь биреп торучы тәрәзә пәрдәләре, челтәрләр, стенага эленгән чигүләр — берсе дә юк. Алар юарга дип алынган булгандыр, күрәсең. Безнең фәкыйрьлекне тагын да көчәйткән шул шыксыз ялангачлыктан янә оялганым, читенсенгәнем истә калган. Вакыйганың тегесе генә җитмәгән, бу шыксызлыкны, хәерчелекне дә укытучылар күрде, белде инде менә. Сизгер, гарьлекле җаныма янә бер өстәмә хурлану.

Укытучыларым әнкәй белән бераз сөйләшеп утырдылар да мине калдырып кайтып та киттеләр. Мин калдым. Бәби мич артындагы караватта һаман да йоклавында. Әнкәй һаман юньләп сүз дәшми, сөйләшми, һични сорашмый. Шунда мин, һич тә сүз юктан сүз булсын — ата казыгыз күкәй саламы, дип түгел, әнкәйнең гафу сорагандай берәр сүз әйтеренә өметләнепме, киләчәктә монын ише хәлләр кабатланмасынга, хәзергечә әйткәндә, гарантия кебегрәк нәрсә теләпме, балалык белән сорап куйдым:

— Башка алай эшләмәссенме соң инде, әнкәй?

Әнкәй нәрсә дисен инде, минем җанның һаман да кимемәгән гаҗизлеген, күнелемнең каткан халәттә булганын азмы-күпме сизгән, аңлагандырмы, болай гына җавап биргәндерме:

— Юк инде, улым, юк, — диде дә тагын тынды. Ул көнне, аннан соңгы көннәрне булсын, ачылып китеп башка сүз сөйләшкән истә калмаган. Балачага белән балаларча итеп, эчкерсез, гади сөйләшә белүләр әнкәйнең холыкфигылендә юк иде шул».

Соңгы юлларны укыгач, мин ирексездән үз әнкәемне, аның да кырыс, усал чакларын, безне тетмәбезне тетеп тиргәгәннән соң дәшмичә йөргән вакытларын искә төшереп, күз алдымнан үткәреп, барлап маташтым. Тик күпме тырышсам да, хәтергә тонык һәм өзек-өзек вак сурәтләр, эчтә аз гына да үпкә калдырмаган аерым күренешләр генә ярала алды. Ә менә ягымлыдан ягымлы караш, без белгәннән башлап соңгы көннәренә чаклы барыбызга да тигез тигән күнел җылысы, әнкәйнең киңәш-табышлары, юк кына мәшәкатьләребез өчен дә борчылуы — барысы да бүгенгедәй күз алдында.

Кешеләр төрледән-төрле булган кебек, аналар да бер-береннән аерыла шул. Язма авторының гомергә бер генә килгән ваемсыз, рәхәт һәм үтә дә бәхетле булырга тиешле дөнья — балачактан, ин якын кешесе белән мөнәсәбәтләрдән шатлык-куанычларны үзенчә эзләп тә таба алмавы күнелемә шактый тирән үтеп, үз әнкәмә булган мәхәббәтемне, якты хисләремне дә күпкә, бик күпкә көчәйтте...

## Югалту һәм табу

«Шулай яшәп киттек тагын. Бәбинең кайсыбер төннәрдә каты итеп елаганы, шул тавышка йоклый алмый ятканнарым, кайчакта кечкенә генә өебездән бөтенләй чыгып китеп, йоклар урын эзләп, таң атар-атмас сәгатьтә авыл башларында, су буйларында кангырып йөргәнем, аптыраганнан хәтта берсендә инеш аркылы салынган басма тактасына ятып караганым да истә. Үзем дә белмим, шунда нигә сәндерә тирәсенә менеп, берәр нәрсә җәеп ятып

йокламаганмындыр? Бала-чагалыкмы, шул йоклар-йокламас халәт тудырган мингерәүлекме, тапкырлык житмәүме, элеккедән каткан башмы — хәзер инде белмәссен дә. Күрәсен, барысы да бергә булгандыр.

Әмма шулай да җәй урталары узуга, мин, язмыш белән тәмам килешүдән бигрәк күбрәк бала-чагалык аркасындадыр, булган хәлләрне хәтеремнән бөтенләй җуймасам да, искә сирәгрәк алып, дус малайлар белән элеккечә уйнап, велосипедта жилдертеп, янадан ваемсызлыкта коенып ук димим, күбрәк онытылып, башкалар белән үземне тигез күреп, тоеп яши башлаган идем инде. Кайгырып, гажизләнеп йөргән чаклар калдырган күңел жөйләре сыкрап, сулкылдап алган вакыт та булмады түгел, булды, әлбәттә. Ул елның жәен хәтергә алганда, язгы көннәрнең бер кайтавазы булган, беренче карашка гади генә тоелган бер күренешне искә алып үтәсе килә.

Кояшлы матур көннәрнең берсендә, без, өч дус — Сәлим, Рәсим һәм мин авыл башындагы чирәмдә, Мингәрәй абыйлар коймасы яклабрак, дөньябызны онытып, тыныч кына уйнап утырабыз. Бүгенге кебек кибетләрне тутырган кырыкмаса-кырык төрле уенчыкларның ул заманда, әлбәттә, эзе дә, исе дә юк. Безгә алар кирәкми дә. Ә менә алюмин чыбыкка ул чагында кытлык бик теләсән дә юк. Без шул йомшак чыбыктан ниләр генә әвәләмибез: төрледән-төрле кораллар, үзебез дә белмәгән механизмнар ясап рәхәтләнәбез. Ясагач, бер-беребезгә күрсәтеп мактанышабыз да әле. Нәкъ менә шул чагында, бала-чагага хас ихлас мавыгу белән чыбыктан кечкенә культиватор ясап, жыеп мәш килгәндә, ничек күргән диген, дустым Рәсимнен әнисе, янәшәдән үтеп баручы Халидә апа:

— Бәй, Миргаяз! Агарган чәчләрең бар түгелме соң синең? — дип, яныма ук килеп, житү чәчемне актарырга тотынмасынмы. Аннан соң «уф Алла»ларны кабатлый-кабатлый, янымдагы дусларымны да күпмедер аптыратып, мин — «тумас борын картайганның» шул чәчләрен берәмләп йолкырга да кереште. Бәхеткә, алар артык күп булмады тәсле. Яныма чүгәләгән күрше апа дистә ярым — ике дистә бөртек чәчне суырып алгач, мин янәдән «яшәреп» калдым. Һәрчак якты чырайлы Халидә апа исә, монарчы булмаганча житдиләнеп: «Кара син ә, мондыйны күргән юк иде әле», — дия-дия, үз юлы белән китеп барды. Ни сәбәпле чаларганымны белсәм дә, мин бу вакыйгага артык игътибар итмәдем тәсле. Халидә апа китеп барды, мин янадан бернәрсә булмагандай уенга бирелдем. Соңрак, еллар үткәч кенә, шул теге елның язында күңелемдә йөрткән борчуларның чыннан да житди булганын, ак чәчләрнең исә эчтәге ялкынсынуларның тышка бәреп чыккан кайбер билгеләре икәнен аңладым кебек...

Әйткәнемчә, без, чәч йолкуны берничә минут үтәр-үтмәстән истән чыгарып, тагын уен белән мавыктык. Ул вакытларда, хәзер инде әле дә ярый димен, якын-тирәдәге дус-ишләрем барысы да үзем кебек үк гади, ипле иделәр. Безнең өйдәге вакыйгалардан хәбәрдар булсалар да, алар ягыннан аз гына да кырын карау, ул турыда сүз кату, ирештерү һич булмады. Мыскыллауны инде әйткән дә юк. Балачакта шулай тиештер дә инде ул. Кем инде ун-уникe яшьтә синең өендәге олыларга кагылышлы четерекле хәлләргә карап сине кимсетергә тотынсын. Тик, ни кызганыч, мондый хәлләрдә искәрмәләр дә бөтенләй юк түгел иде. Тыкрык урамнан безнең янга уйнарга килгәли торган масаючан һәм холыксыз Рәдиф, аз гына мина ачуы чыктымы, өйдәге әнемне бик тиз искә төшереп: «Бар, кайтып уйнаштан туганың белән уйна», — дип гелдән-гел мине түбәнсетү, мыскыл итү ягын карый торган иде. Шул сүзләрдән соң, кайтып китмәсәм дә, авызым ирексездән шып итеп ябыла, күңелдә янадан элекке хурлык, рәнжү уяна, уенның тәме бетә торган иде. Ә бит көчем житәме-

житмиме, шул минутында ук ипи шүрлегенә менеп төшкән, пыр тузып бер сугышып алган булсам, икенчесендә бәлки ул сүзләрне Рәдиф кабатламаган да булыр иде. Әлеге дә баягы юашлык инде...

Әбекәй безнең янга әллә җәй урталары узгач, әллә көзгә таба гына кайтты, төгәл хәтердә калмаган. Тик барыбер кайтты. Кая барасың, кызына булган ачуларын басып, ул да тора-бара язмыш белән килеште, килешергә мәҗбүр булды.

Тик ул шактый бетеренгән, тагын да ныграк картайган иде. Өлкән кешене кайгы тиз басканын, күпкә тизрәк чиргә сабыштырганын мин ул вакытта бик аңлап бетерми идем әле. Шулай да элекке нурлы күзләренең ничектер эчкәрәк батканын, андагы шаян чаткыларның сүнгәнен барыбер сизендем. Чәченең дә карасы бөтенләй үк калмыйча, тәмам чаларып, ул гына да түгел, әбекәем кечерәеп һәм хәтта бераз бөкрәеп тә калган иде.

Гомер китабына язылган тәкъдиргә буйсынумы, үсеп килүче ятим нарасыйның гаепсезлеген аңлапмы, кайткан мәлдән бирле энекәшемне аз гына да чититмәде, карады әбекәй. Көзгә таба ук башы-аягы белән колхоз эшенә чумган әнкәйгә җайлы булды. Минем дә әнкәйгә дә, инде шәпләп үрмәли, матур итеп авыз ера башлаган, минем тәкъдим белән, мине тыңлап Илгиз исеме алган нәни җан иясенә дә ачуларым беткән иде. Һәм бу хәл дөрес тә, табигый дә булгандыр. Эчендә айлар-еллар буе бетмәс ачу саклап ничек йөрмәк кирәк? Яшь тә андый түгел. Тик менә әбекәй генә...

Үзе кире әйләнеп кайткан шул көздән соң өч ел вакыт үтеп, энемнең теле ачылып бетеп килгәндә, бәрәңгеләр алынып, базга салынгач, беренче кыраулар җирне агарта башлаган көннәрдә әбекәйнең сәламәтлеге кисәк кенә начараеп китте. Элекке җитезлеге бөтенләй үк бетеп, ул бик тиз арый, аның саен килеп утырып тора, хәлсезлегенә зарлана башлады. Күрәсең, кызына үпкәләре беткән тәкъдирдә дә элекке күңел өзлегүләре, хәсрәте эзсез үтмәгән. Әмма шулай булып та, өч ел элек әбекәй белән икебезнең дә чәчләребезне үзе дә белмәстән агарткан, шуклыклары көннән-көн арта барган энем, әнкәйдән бигрәк һаман да күбрәк аның карамагында иде әле.

Көз узып, суытып, беренче карлар җир өстен каплап киткән вакытта әбекәемдә «ак канлылык» дигән начар чир икәне беленде. Бу чакны ул көнозын ятып тормаса да, өй эчендәге эшләрнең иң кирәклеләрен көчкә башкарып чыгып, тизрәк урын өстенә ава иде.

Ә аннан соң... Бүгенгедәй хәтерлим, ул елны кыш нишләптер җылы булды. Декабрендә дә, гыйнварында да түбәдән тып-тып тамчы тамып торды. Тик февраль җитү белән, тискәре яктан искән әче җил капылт кына чатнама суык китерде. Шул җилдә колакларны өшетә-өшетә мәктәптән өебезгә кайтып керүгә әбекәем өзелгән иде инде. Дөресрәге, иртәнге якта, мин икенче дәрестә утырганда ук дөньядагы иң якын, иң кадерле кешем үзенең соңгы сулышын алган. Кечкенәдән баккан, үстергән, һәрчак «балам» дип торган, күңел күген караңгы болытлар каплаган чакта, кояштай күңелне яктырта белгән әбекәй юк хәзер. Түр караватта хәрәкәтсез яткан әбиемне күргәч, йөрәктә кинәт нәрсәдер өзелеп куйды. Бермәлгә бөтенләй каушап калдым. Ышанасым килмәде. Әбекәй начар чир белән чирләсә дә, сигезенче сыйныфка җитеп, дөньяны азмы-күпме аңлый башлаганда да бетмәгән балалык димме, беркатлылык белән димме, мин әле һаман да аның терелүенә өмет итеп йөри идем бит. Ә хәзер?..

Ул көн нинди дер куркыныч төш кебек, өзек-өзек авыр кара сурәтләре һәм шул чатнама суыгы белән истә калган. Менә ап-ак кәфенгә төрелгән әбекәйне өйдән алып та чыктылар. Аннан соң акрын гына Түбән оч дип аталган урамыбызның башына, әбекәемнең гомере үткән, килен булып төшкәннән

алып шушы яшенә чаклы яшәгән нигезеннән күп булса ике йөз адымда гына урнашкан зиратка юнәлдек. Көн үтә дә суык. Урамнар, бәрәнге бакчасы җирләре, әбекәй мал саклаган, без тәгәрәп үскән чирәмнәр, зират — барысы да тирән кар астында. Гомер дәвамында гадәтенчә йөгерә-атлый мең тапкыр ураган Түбән оч урамын соңгы тапкыр кичкән әбекәйне үзенең бәрәнге бакчасы яклап казылган тар каберга — мәңгелек фатирына төшерәләр. Мин тавышсыз гына елыйм. Эчемнән генә «тыныч йокла, әбекәй, гаепләп китмә, авыр туфрагың җиңел, караңгы гүрең якты булсын» дип, олылар әйтә торган сүзләрне кабатлыйм. Гомер юлымда беренче олы югалту кичергәнемне тоям.

Күземә ак-кара күренмәсә дә, халык арасында кайгымны уртаклашырга килгән берничә классташымны һәм кырыемда диярлек басып торган зәңгәр пальтолы, ак куян башлыклы кызны шәйлим. Гөлчәчәк тә килгән икән бит! Кайгыдан күшеккән җаныма шул мизгелдә аз гына җылы иңә. Класста вакытларда карашым белән гел аны эзләвемне бик белмәсә дә сизенгән, тик томырылып аңа карауларыма җавап бирергә ашыкмаган тыйнак һәм акыллы Гөлчәчәк, кайгым аз булса да җиңеләйсен дипме, укытучылар кушкач, башкаларга иярепме, соңгы ике дәресне калдырып, берничә укучы белән бирегә килгән иде.

Кабер чокыры янәдән балчык белән тулып, томаланып, мулла вазифаларын башкаручы Мирсәяф бабай мондый вакытта укыласы догаларны укып, тиешле хәерләр өләшенеп, халык акрын гына зираттан чыгу юлына юнәлгәч, мин дә, башымны түбән иеп, акрын гына шуларга иярәм. Һәм... янәшәмдә Гөлчәчәк барганын шәйләп, башымны бераз күтәрергә, күзләремне коры тотарга тырышам. Дәшмичә барсак та, мин классташыма күңелемнән рәхмәтләр укыйм. Аның янәшәлеге бүгенге чамасыз кайгымны киметә генә түгел, киләчәк көннәремә дә өмет өсти.

Авыл урамына кергәч тә без күпмедер бергә барабыз да, безнең өй турысына җиткәч, классыбызның беренче гүзәле, миңа күтәрелеп карап:

— Артык кайгырма инде, Миргаяз, мин дә ике ел элек әбисез калдым бит, дөнья шулай корылган инде, — дип, олыларча мине юата да алгарак киткән классташлар тарафына атлый. Мин ятим калган өебезнең капкасын ачам».

## Кыз «урлаганда»

«Ах, Гөлчәчәк, Гөлчәчәк! Исеме дә, үзе дә чәчәк! Әбиемне югалтканнан соң, минем яшәү көчемне саклап калган, көннәремне сөенечле итә белгән ипле һәм акыллы кыз бала. Рәхмәт сиңа ул мизгелләр өчен. Аннан соңгы айлар, еллар өчен. Гөлчәчәк. Колхозның партком секретаре Каюм абыйның дүрт балалы гаиләсендәге өлкән бала. Классыбызның комсоргы. Аның белән без шул кайгылы февраль көннәреннән соң йөреп киттек дисәм, бу арттыру булыр иде. Йөрүдә ул кадәр хаҗәт тә булмагандыр, бәлки. Үзебез ул турыда сүз кузгатмасак та, без ярыйсы гына дуслаштык. Ул, класска килү белән, көн саен ук булмаса да, миңа исемем белән дәшеп, исәнләшеп, хәл белешеп якты итеп елмая да, кирәксә-кирәкмәсә дә, математикадан йә физикадан өйгә бирелгән мәсьәләнең дөрес эшләнешен тикшерергә дип дәфтәрен китерә. Миңа артыгы кирәк тә түгел инде. Аны гына уйлап йөргән чаклар ич.

Тик кичләрен клубка чыккач, бер-беребезгә ерактан карашып алабыз да, ни мин, ни ул шуннан ары узмыйбыз, башкага ымсынмыйбыз. Кайбер классташлар, инде ипләп кенә парлаша башлаган, кыюрак өлкән класс укучылары кебек, янәшә утырып кино да карамыйбыз. Карарга базмыйбыз. Ул күбрәк параллель класста укучы дус кызы белән бергә кала. Шулай да унынчы классның икенче

ярты еллыгына кергәч, бар булган тәвәккәллегемне җигеп, шимбә көннәрендә клубтагы кино, төрле кичәләрдән соң мин аны озаткалый башладым. Монысы инде батырлык һәм шул батырлык китергән өстәмә бер бәхет, шатлыкның аргы ягына чыгу иде. Андый шимбәләр минем өчен атна буе көтеп алына торган чып-чын бәйрәмгә әйләнә. Икебезнең дә, кыюлыгыбыз җитеп, кулларыбызны кулга тотышкан хәлдә, ап-ак карны шыгырдатып, кар яктысы кайтыр юлыбызны гына түгел, җаннарыбызны да яп-якты иткән авыл урамы буйлап янәшә атлауның рәхәтлекләре. Янында кем бара диген син? Һәр елмаюы йөрәккә сары май булып яткан, йөзе, карашы күз алдыннан иртә дә, кич тә китмәгән Гөлчәчәк бит. Мина бу минутлар кайчак гүзәл бер төш сыман тоелгандай була. Уянып китүдән куркам. Уянсаң эш харап бит. Төш төш бит инде — авылны урталай ярып агучы инеш ярын кайбер иртәләрдә каплап алган сыек томандай эри дә югала. Мин исә югалуны һич тә теләмим. Кичергәннәремнең өн икәненә янәдән инанам да тагын да ныграк сөенәм. Гөлчәчәк өенә кереп киткәч тә сөенүем һич кимеми. Әйтерсең лә затлы ул асылташны азга гына кулыма алганмын да, сокланып бераз карап торгач, ефәк-бәрхеттән ясалган тартмасына кире куйганмын. Мин иңемә үскән канатларымны җилпеп, өебезгә таба юнәләм. Иртәгә иртән шул асылташны янәдән дә күрәсемне, күреп сөйләшәсемне, бәхетле буласымны уйлап, сөенечемнән исереп үк бетәм.

Тик шушы тыйнак сөенеч-куанычларымны да язмыш артыкка санадымы, белмим. Уку елы бетеп килгәндә, мина яман сүз ишеттерделәр. Гөлчәчәкнең әнисе, имеш, әйткән: «Кызымны Сәлимә малае белән йөрттерәсем юк. Ирсез бала табып, шуны үстереп яткан имансыз хатынга кодагый буласым килми!» Тагын да шул элекке балык башы — ирсез табылган бала. Төгәлрәге — әнкәй кылган иске гөнаһның онытылды дигәндә, янәдән баш калкытып, тирә-якка үзенең нурсыз чырае белән багуы. Ярый әле, кайбер мәгънәсезләре кебек аты-юлы белән әйтмәгән. Кызын мин — Сәлимә малае озаткалап йөргәнне ишеткән дә, гарьләнгән инде. Тик кая соң әле монда өйләнешү, туганлашу, кода-кодагыйлык турында сүз. Белеп торам, Гөлчәчәк тә ул турыда уйламый. Без әле мәктәпне дә бетермәгән ич. Мин болай да, андый планнар кормыйча да, җиденче күкләрдә бит. Тик менә шул бәхетемнең бәхетсезлеккә әйләнеп китү ихтималы мине әлеге сүзне ишетү белән бимазалый башлый. Гөлчәчәк үзе ни дияр дә бу хәлне ничек кабул итәр? Миннән бөтенләй бизмәсме? Әнисе, урамга чыгып сөйләгәнне, минем кем баласы икәнне иң кара төсләргә мана-мана әйтеп, кызына шелтә белдерми калмагандыр инде...

Шулай итеп, минем бишенчедә яраланган, унынчыда укыган ул көннәрдә инде төзәлде дип йөргән йөрәгемнән тагын сулкылдап кан саркый башлый. Яра кузгалып, әнкәйгә теге чакта булган үпкәләр киредән әйләнеп кайта. Күңелдә ул кылганнар белән кабаттан кискен килешмәү, оят, гарьлек уяна. Бу хәлнең әнкәй гөнаһларының янә дә бер кайтавазы, бәхетсезлекләремнең дәвамы икәненә төшенәм...

Тик ни хикмәт, Гөлчәчәкнең мина карашы элеккечә кала. Ул берни булмагандай елмая, физиканың авыр темаларын йөгереп килеп миннән сорый, кат-кат анлаттыра. Шундый хәлләрдән соң, юкка борчылганымны анлап, мин дә элекке халәтемә кайтам. Әмма... Шимбәләрдә кыз клуб тирәсендә бөтенләй күренми башлый. Мина тагын авыр, башымда төрледән-төрле уйлар давылы. Бераздан биредә Гөлчәчәкнең гаебе юклыкны анлыйм, кич чыгарга анасының рөхсәте булмау дип кабул итәм дә янә тынычланган кебек булам. Барын да кызның үзеннән сорарга исә базмыйм. Чөнки анасы ишеттергән «ирсез бала табып...» дип башланган сүзләр искә төшкән саен җанны көйдереп ала».

Язмалар акрынлап азагына якынлаша иде. Әле генә укылган битләрдә

тасвирланган вакыйгалар «бер бәхетсез — гел бәхетсез» гыйбарәсенең кагыйдә булмавын искәртеп, үзем дә шуна инанып, хәтта язма хуҗасының бәхетенә күпмедер ияреп, аның өчен чын-чынлап сөенеп, инде иплe, матур финалга да әзер идем югыйсә. Тик дәфтәр хуҗасының сөйләгәннәре, озак елларга сузылган ялгызлыгы искә төшкәч...

«Бераздан без, өлгергәнлек аттестаты алып, мәктәптән таралыштык. Гөлчәчәк, алдан ниятләгәнчә, педагогика техникумына, ә мин, әнкәйне ничек кирәк, шулай күндереп, Казанга, институтка барып укырга кердек тә көнаралаш язышa, хатлар алыша башладык. Бик еш булмаса да, ул укыган калада күрешкәләдек тә. Барысы да яхшы, хәтта артыгы белән яхшы кебек үзе. Кайчакта мин, алгарак китеп, Гөлчәчәк белән гомерлеккә бергә калу, кавышу хакында да уйлап куям. Тик әнисе әйткән теге сүзләр... Шулай да берсендә хат аша турыдан-туры: «Әниең безнен бергә булуга каршы, инде нишлибез?» — дип сорагач ул: «Үзеннеке итәсең килсә, авылга кайткач, мине урлыйсын да өегезгә кайтарып куясың инде, безгә башка чара юк, Миргаяз», — дип язмасынмы.

Мондый тәкъдим миндә берьяктан өмет уятса, икенче яктан... Парторг кызын урлау... Авылда онытылып барган искелекне казып чыгару. Кыскасы, мин язган чираттагы хатта «әйе» дә, «юк» та юк иде. Ул гына да түгел, вакыт үтә торды. Ул техникумын бетерде, мин институтны. Өйләнерсен дә, әби тиешлең гел генә «анаң фәлән дә төгән» дип торса? Әле тагын Гөлчәчәкнең буй житкергән ике энесенең икесенең дә минем белән адәм рәтле итеп исәнләшмәүләре...

Тик мин, батучы саламга ябышкан кебек, бернәрсәгә дә карамый тәвәккәлләргә булдым. Соныннан аныма килеп, башкача уйласам да, ул вакытта бүтән чара чыннан да юк кебек иде. Гөлчәчәкне кулымнан ычкындырсам, гомерлек үкенеч булачак. Көндез барысын да әнкәйгә әйтеп куйдым. Әнкәй «ә» дә димәде, «жә» дә димәде. Аңа өстәмә мәшәкать тә, килен дә бер дә кирәкми төсле иде. Шулай буласын мин белә идем инде. Тик әйтмичә дә булмый бит. Гөлчәчәк белән корган план нигезендә, безнен өйдә бер яисә ике кич кунып, кечкенәрәк мәжлес кебек берәр чара үткәреп, икенче көнне иртән үк шәһәргә китәргә, анда язылышырга гариза бирергә тиеш идек.

Кызны атка йә булмаса арба, чана ишегә салып урлый торган вакытлар түгел, машина сөйләшеп куйдым. Классташым Рөстәмнең атасының яшькелт «Москвич»ы бар. Малаена техниканы бер дә кызганмый, ул як ышанычлы. Кызны да толыпка төрәсе дә, чәбәләндерә-чәбәләндерә, кычкырта-кычкырта арткы утыргычка күтәреп саласы юк, үзе шыпырт кына чыгып утырачак. Шулай килешенгән. Утырдымы, Түбән очка чаклы биш минутлык юл. Барысы да шома һәм жинел генә булырга тиеш иде.

Гөлчәчәк белән сөйләшенгән вакытка, кичке сигезгә, иплəп кенә Каюм абыйларның капка төпләре тирәсенә килеп туктасак, койма буендагы тәбәнәк утыргычта жан сөйгәнем түгел, шактый таза өч егет утыра. Мин шунда ук эш пешмәсенә ишарә сиздем. Тегеләр исә, без килеп туктаган унайга, өчәүләп, бердәм генә урыннарыннан тордылар да машина янына килеп тә життеләр. Берсе, мин танымаган олы гәүдәлесе, кулындагы без сыман очлы нәрсәсен шул арада арткы тәгәрмәчкә тыгып чыгарырга да өлгерде. Мондый көтелмәгән хәлгә, «пыш-ш» килеп һава чыккан тавышка Рөстәм дә, кая ул тегенен якасына ябышу, ничектер бөтенләй каушап калды. Мин аны-моны аңышканчы, калган икесе — Гөлчәчәкнең Рамил белән Расих дигән энекәшләре, минем каршыга килеп бастылар да: «Миргаяз абый, әлегә яхшылык белән әйтәбез, апабыз синең өчен тумаган. Ул беркайчан да синең хатының булмаячак. Бүтән аның янында буталып йөрерлек булсаң, үзенә үпкәлә!» — дип, якамнан ук алмасалар да, учларына йодрык белән суккалап, юри генә сөйләшмәгәнлекне

белгерттеләр. Борынгы йоланың үтәлмәячәге мина ныклап торып нәкъ шушы урында анлашылды. Әмма... Алар белән шулай яшь әтәчләр кебек борынга-борын торганда, өй ишеге капылт кына ачылып китеп, аннан Гөлчәчәкнең: «Миргаяз, машинаны кабызыгыз тизрәк, мин монда, хәзер!» — дигән тавышы ишетелде. Рөстәм кабызган да иде машинасын. Тик энекәшләре белән теге мин танымаган әзмәвер кызны йөгереп чыккан хутка эләктереп үк алып, аякларын жиргә дә тигермичә, кире өйгә, сукрана-сукрана чыгып маташучы анасы янына алып кереп киттеләр. «Кыз урлау» шуның белән тәмам да булды.

Эш пешмәүнең сәбәбе исә Түбән очка, төгәлрәк әйткәндә, безнен өйгә барып тоташканлыгын мин икенче көнне генә белдем. Булачак «кодагыеның» сүзләре әнкәйгә дә барып житкән булып, ул шул сүзләргә бик тә үртәлеп, әллә юри, әллә ялгыш минем ниятне карангы төшкәнче үк күршеләргә тишкән. Имеш, егерме дүрте дә тулмаган, үзен ничә ел буе укытып, анасына уч тутырып акча кайтарып бирергә өлгермәгән малаена, эшләнәсе эшләр дә ишегалды тулып өелеп ятканда, кыз алып кайтып йөрмәсә дә бик таман буласы икән бит. Кызның, булачак киленнең кем икәнен, исемен әйтеп торасы түгел, бишбылтыр дигәндәй билгеле. Бер килмәсә килми бит ул, күршебездәге Самания апа Гөлчәчәкнен әнисе эшләгән почтада идән юа. Парторг хатынының күзенә генә карап тора. Телефоннан шалтыраткан да барысын да түкми-чәчми сөйләп тә биргән. Шуннан соң кыз йортында «кияү»не каршыларга тәфсилле әзерлек башланган...

Бу хәлләрдән сон инде мин Гөлчәчәк белән аралашыр хәлдә түгел идем. Адәм рәтле итеп кыз да урлый белмәгәч... Үзем дә хур булдым, аны да унайсыз хәлдә калдырдым. Аның үпкәсе зурдан булды ахры, эшләгән шәһәренә китеп барды да бер генә хат-хәбәре дә килмәде. Мин исә, артык сонга калып димме, тәжрибәсезлегебез аркасында гафу ителмәслек ялгышлык кылганыбызны, бер хажәте дә булмаган мөгез чыгарып йөрүебезне аңладым. Кирәк идеме сон ул без уйнарга жыенган, ахырына житкерә алмаган спектакль? «Урлыйсың да өенә алып кайтып куясың», имеш. Ул сүзләрне Гөлчәчәк хатка, ихтимал, үйламыйчарак язган булгандыр. Ике юләр! Андыйга киткән икән инде, шәһәрдә язылыш та бергә яшәп кит. Аннан соң авылга кайтып, ике якны да булган хәл алдына куй. Әлбәттә, мактау сүзләре ишетмәгән булыр идек. Тик бәхетебез касәсен шул юл белән мөлдерәмә тутыра ала идек бит без...

Мин, шул хәлдән соң ярты ел үтәр-үтмәстән, ни булса — шул булды дип, тоттым да оешмабызда бергә эшләп йөргән, үземнән ике яшькә өлкәнрәк туташка өйләнеп куйдым. Исеменә игътибар итмәстәнме, әллә киресенчә, артык игътибарлы булыпмы — үзем дә анламадым. Исеме, язмышнын янә бер кинаясе булдымы, әллә гап-гади туры килүме, белмәссең — Алчәчәк иде. Исәбем — шушы гамәлем аша икенче бер чәчәк — Гөлчәчәкне оныту иде. Беренче мәлне бәлки күпмедер оныта да алганмындыр...

Артык яратышып яшәмәсәк тә, болай тату гомер сөрдек. Тик... алмадай ике кызыбызны үстереп житкереп килгәндә, өлкәне мәктәптәге чыгарылыш кичәсенә әзерләнеп ятканда, капылт кына йөрәк өянәгеннән китеп барды Алчәчәк-бәгырь. Инде ни эшлим, исәеп килгән кызларны булдыра алган чаклы аякка бастырып, укытып чыгардым. Тик бала күңеле далада диләрме әле, алар, сүз куешкандай, берсе артыннан берсе тормышка чыгып, Себер якларына китеп бардылар. Шул хәлләрдән сон күпме гомер инде менә берүзем. Елга бер күренеп китәләр, сирәк кенә шалтыраткан булалар...

Алар Себергә юл алганда, әнкәй исән иде әле. Ул гына да түгел, энем белән мина әти тиешлебез, гомер буе бездә яшәгән диярсең, хатынынннан китеп, әнкәй йортына жайлы гына кайтты да урнашты. Мин каршы килеп, картлар

белән булышып тормадым инде. Яшәсеннәр генә. Картлык көннәрендә бер-берсенә таяныч булсыннар, дидем. Тик аларнын авылдагы ул тормышы артык озакка бармады. Ничек диләр әле — картайгач, бәндәнен йөз чалымнары гына түгел, холкы да матурлыгын жуя диләрме? Бу кагыйдә бар кешегә дә, бәлки, кагылмыйдыр. Тик кайберәүләргә, Ходай холыкны яшьрәк чакта да кызганганнарга, ифрат та туры килә ул. Барысы бернichә ел бергә яшәп, икесендә дә булган көйсезлекләр янадан бер-бер артлы тышка чыгып, тормыш талашу, гаепләшүләргә калгач, әти кешебез каядыр китеп югалды. Күрәсен, кайдадыр, хәзергечә әйткәндә, «запас аэродромы» булгандыр. Икенче кат ташланган хатын хәлендә калган әнкәй бу вакыйганы ифрат та авыр кичерде. Элек беркайчан да булмаганны, бу юлы анын саен үзен гаепләде. «И-и, холкым бөтенләй юк шул минем». Ялгызы калганнан сон, озак тормады ул, инде яше дә шактый иде, күпмедер булган яхшылыклары, кылган гөнаһлары, юклы-барлы бәхете, үзе тудырган бәхетсезлекләре белән бакыйлыкка күчте.

Шушы дөньяда тулы бер гомер яшәп тә бәхеткә дә, рәхәткә дә юньләп тиенә алмаган, гомер азагында гына тормыш асылына күпмедер төшенгән әнкәйне кызганмый мөмкин түгел иде. Әбекәемә теләгән кебек, әнкәйгә дә мин якты гүр теләдем, гаепләп китмәвен сорадым. Шулай итеп, санаулы еллар эчендә мин башта хатынсыз, аннан әнисез калдым. Бераздан кызларым да, акча дип жир читенә китәргә әзер ирләренә ияреп, Себер якларына чыгып югалдылар...

Ә Гөлчәчәк уйларымнын түрендә үк булмаса да, хәтердән жуелмады. Хатыным вафатыннан сон ул бөтен барлыгы белән хәтер сукмакларын яулап, күнелемә янадан кереп утырды дисәм дә була. Теге вакытта без белән тәгәрмәчебезне тишкән әзмәвер Гөлчәчәккә күптән күнеле төшеп йөргән күрше Артамак — Гөлчәчәкнен әнисенен туган авылы — егете булган икән. Бик әрсез, сүзен һәрчак сүз итәргә өйрәнгән шул зат Гөлчәчәкне үзенеке итүгә ирешкән. Билгеле инде, булачак әбисенен ярдәме белән. Бу хәлләрне авылга сирәк кайтуларымнын берсендә Гөлчәчәкнен сенлесе, төпчекләре Гөлфирә очрап, шул сөйләп биргән иде. Әнисенен сүзеннән чыкмаган ике энесеннән аермалы буларак, Гөлфирә, апасы һәм минем яклы булып, элек-электән очраган саен бик жылы итеп күрешә, хәл-әхвәл белешеп, озаклап сөйләшмичә китеп бармый иде. Ул чагында бер файдалы эш эшләп — бәлки кайчан да булса кирәге чыгар дип, Гөлчәчәкнен тулы адресын язып алып калган булсам да, тора салып кына инде ничә еллар күрмәгән, ин сонгы мәлне онытылмаслык итеп үпкәләткән гаиләле хатын янына ни дип барып чыгасын? Тик үз-үземә биргән сүзем бар: аны мин барыбер күрәм әле...»

## Сонгы сүз

Ял йортыннан кайтып төшкәндә, безнен як табигате мине гел башкача каршы алды. Жиһанга кеше затын азмы-күпме өметкә әйди, төшенкелектән аера торган ак манзаралы яна фасыл — кыш килгән иде. Жир өстенә беренче карлар төшеп, дөнья яктырып, саф төс тантана итә башлаган чорга керелгән иде. Андый вакытларда башта бер айдан Яна ел житә дип үз-үзенне юатып йөрисен, аннан сон ул вакыт узып, кыш акрын гына язга авыша төшкәч, янә бер сөенәсен, инде гөрләвекле апрель белән чәчәкле майларга да ерак калмады дип шатланасын. Киләсе шатлык килгәненнән һәрчак кадерлерәк диләрме әле?

Кайткан көнемнен икенчесендә, кичне житкереп алгач, гадәтләнгән вакытта, элекке гадәтне куып, мин сәйранга чыгып киттем. Салкынчарак һавада тансыклаткан беренче кар исен исни-исни бакча-паркларны хәтсез әйләнсәм

дә, Миргаяз очрамады. Ярар, иртәгә дә очрамаса, өенә сугылырмын, дип, фатирыма кайтып киттем.

Икенче көнне төш вакытлары узып барганда, гәзит өчен яза башлаган бер мәкалә белән утырган чагымда, кисәк кенә ишек кыңгыравы шалтырады. Күршеләремнең берәрседер дип, ашыкмый гына ишекне барып ачсам... Каршымда өстенә өр-яңа соры куртка, башына модалы җылы кепка кигән, карашы сизелерлек яшәреп, яктырып киткән Миргаяз белән уртача буйлы, яше илледән артмаган чем-кара күзле шактый мөлаем һәм чибәр бер ханым басып тора иде. Миргаязның тормышында, минем иске яңа танышымның гомер юлында инде күптән тансыклаткан, яңа, бу юлы күпкә озынрак булырга тиешле бәхетле чор башланганын чамалап, аларны өйгә чакырдым.

Исәнлек-саулык белешкәч, ял йорты, андагы шартлар турында ике-өч сүз сөйләшеп алдык та табын янына уздык. Миргаяз, янында утырган мөлаем ханымга карый-карый, тормышында шушы араларда гына килеп чыккан үзгәрешләрне бәян итәргә тотынганчы, миңа беренче соравын бирде:

— Ничек соң, Булат, теге язмаларны укып чыга алдыңмы?

— Укымаган кая, кичке киноларга да йөрмәдем. Бер сулышта, соңгы ноктасына чаклы. Кайсыбер урыннарын хәтта кат-кат. Инде язасыларым да күңелемдә әзер. Төгәлрәк әйткәндә, анда әллә ни язасы, уйлап чыгарасы да юк, әдәби яктан азмы-күпме эшкәртәсе генә. Берничә атнадан сиңа биреп укыта да алырмын әле, бәлки.

— Ярар, укуың яхшы булган. Хәзер инде менә булачак әсәреңнең геройларының берсе белән якыннанрак таныша аласың. — Миргаяз, янындагы ханымга карап янә елмайды да: — Таныш бул, бу — Гөлчәчәк, — диде.

Мин аларга карап сокланырга өлгергәнче, Миргаяз ниндидер могҗиза белән янәдән Гөлфирәне очратуы, булачак балдызы Башкортстандагы апасының менә инде ике еллап ялгызы гына яшәве, бик еш элекке классташын, ягъни аны искә төшерүе турында әйтеп: «Сыңар канат кагып каңгырап йөрмәгез, иртәгә үк икәүләп апа янына китәбез», — дип, тимерне кызуында сугуын сөйләп китте.

— Теге чакны кыз урлау барып чыкмаган иде, бу юлы тәки урладым, үземнән калдырмадым менә...

Бәхет дигән халәт кемгә ничек шул. Кемдер, күңеленә җанны тилмерткән сары сагыш, боеклык бик тә сирәк кагылса, бәхетнең ни-нәрсә икәнен, ул башка ишелеп торганда да аны кирәгенчә тоеп, сизеп бетермәскә, күрмәскә мөмкин.

Миңа калса, бәхетне бәхетсезлек һәм аның каһәрле әчесе бәгыренә үткәннәр генә чын-чынлап бәяли, тоя ала.

Май кояшыдай балкып каршымда утырган, яшәү нуры тулы күзләрен сөйгәненнән алмаган Миргаяз да нәкъ менә шундыйлар кавеменнән иде төсле.



Җәүдәт
Дәрзаман

# КҮҢЕЛЛӘРДӘ БУЛДЫ ЯХШЫЛЫК

## Мең кат үлеп, мең кат терелерлек

Шагыйрьләрнең шигъри жанын эстәп,
Самум җилләр улый үзәннәрдә.
Илгә тулып, Таһир, Мәҗнүн булып,
Иблис килә асыл гүзәлләргә.

Кайта-кайта кабатлана тарих —
Хәер эстәп йөри зыялылар.
Сандугачлар түгел,
Бәгырьләргә
Кара кошлар кереп оялыйлар.

Җилләр исә, гөлләр кисә-кисә,
Болыт килә ишелеп явар булып.
Инрәү, вәхшәт, дәһшәт, гарасаттан
Мәрмәр сыннар тора авар булып.

Аклык кайда, пакьлек, сафлык кайда?
Кыйбла кайда? Бар да буталганмы?!
Илне, көнне, туар таңнарыңны
Авыр күрү тоташ ут алганны...

Хыялда — Таң. Уйда, зиһендә — Чаң,
Сау калырмы газиз халкым, димен.
И, болай да сүрән гомер шәмен
Ялмамасмы шашкын ялкын, димен.

Җирдә — янгын, яшен — күкләрендә,
Ә җаныма шундый салкын минем.
Мең кат үлеп, мең кат терелерлек —
Сират күперен кичә халкым минем.

*Җәүдәт ДӘРЗАМАН (1945) — шагыйрь, прозаик, публицист; «Күзле кычыткан», «Чорлар кайтавазы», «Җир авазы» һ.б. китаплар авторы. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Казан Кремле янында уйлану

Таш диварлар тора ап-ак булып,
Акшарланган алар, буялган.
Бер карашка гына әйталмассың,
Бусы дөрес, диеп, бу — ялган.

Заманалар салган яраларын
Ямаганнар инде, йомганнар.
Янгыннарда янган олпат ташлар,
Башын иеп, уйга чумганнар.

Ул уйлары, ай-һай, авыр уйлар —
Гасырларга барып тоташкан:
Бүген тоташ чирәм үскән җирләр
Алар өчен һаман тоташ кан.

Ул яралар, юк шул, төзәлмәгән,
Төзәлмәгән иске яралар.
Саркый-саркый иске ямаулардан,
Тик ачыла гына баралар.

Күктән җуйган көмеш аен эзләп,
(Язмышларың язса, ни чара?!)
Заманында мәгърур Сөембикә
Җиргә чүгеп бара, бичара...

Ае юкса янәшәдә генә,
Тик ашмас шул күккә яңадан —
Хаж-хәнҗәрләр аны, чалкан салып,
Чиркәү гөмбәзенә кадаган.

...Янгыннарда янган олпат ташлар
Акшарланган бүген, буялган.
Тарих ясап булмый буяп кына,
Акшарланган икән, бу
Ялган.
          Ялган!

## Сибелә чәчем

*Сибелә чәчем, сибелә чәчем,*
*Сибелә чәчем җилләрдә...*
Татар халык җырыннан

Сибелә чәчем, диеп җыр җырладык,
Сибелгәндә чәчләр җилләргә.
Чәчләр түгел, үзебез сибелдек шул,
Чәчелдек шул ерак илләргә.

Сәйлән идек юкса, бәйләм идек,
Ефәк җепне безнең өзделәр,
Өзделәр дә, ялган ташлар кушып,
Үз дигәнчә кабат тезделәр.

Асылташтай газиз безнең башлар
Ни күрсә дә күрде —
Түзделәр!

Сибелә чәчем, диеп жырлый-жырлый,
Жилдә түгел, жирдә таралдык.
Орлык булып кайда төшсәк тә без,
Татар булып кабат яралдык.

Читтә түгел, хәтта туган илдә
Калганда да кайчак ят булып,
Изге кыйбла безгә терәк булды,
Иман нуры булды яктылык.

Ямьанлыкны байтак татысак та,
Күңелләрдә булды яхшылык!

Сибелә чәчем, диеп жырлый-жырлый,
Бәлки, тагын өзелү кирәктер?
Болгардан ук килгән ефәк жепкә
Янабаштан тезелү кирәктер?!

Сибелә икән, әйдә, сибелсеннәр
Көмеш чәчләр жәйге жилләрдә.
Без сибелмик, тезелик дисбе булып,
Туфрак булыйк туган жирләрдә.

Олтан түгел, мәгърур солтан булыйк
Татарстан дигән илләрдә!

## Утлар эчеп кенә

Кабатланмас димә, кабатлана Тарих,
Кабатлана әле ничек кенә:
Зур дәверләр түгел, хәтта чорлар түгел,
Кабатлана еллар кичеп кенә.

Жан кыешлар, вәхшәт, кан коешлар
Кабатлана, бар да кабатлана.
Милләтләрнең чукып бәгырь итен,
Кушбашлы кош кабат канатлана.

Кушбашлы кош кабат канат кага,
Тарафларга дәһшәт ора-ора,
Тырнакларын язып, корбан эзли
Ике ерткыч, башын бора-бора.

Кабатланмас димә, кабатлана Тарих,
Качып булмый аннан посып кына,
Качып булмый маржа кочып кына,
Бот арага койрык кысып кына.

Без сугәбез һаман үткәннәрне
Һәм сугәбез әле ничек кенә!
Сукмәсләрме димсез үзебезне
Чорлар түгел, еллар кичеп кенә?

Чорлар түгел, еллар кичеп кенә,
Дөмбәсләрләр әле ничек кенә —
Котылулар булмас ялалардан
Шәмен сүнеп, җирдән кичеп кенә!

Нишләтәсең безне, һай, син, Тарих?!
Хәер, без дә сине нишләтмәдек?!
Хаклык белән авыз ачкан саен,
Безме сиңа телен тешләтмәдек...

Безме сиңа телен тешләтмәдек,
Үзебез тәмам телсез калгангача,
«Азатлык» дип авыз ачмас борын,
Ияк аска йодрык алгангача.

Кабатланмас димә,
Кабатлана Тарих,
Кабатлана әле ничек кенә...
Үз җиренә илләр кайта бары
Сулар кичеп, утлар эчеп кенә...

Утлар эчеп кенә!

## Кораб

Яман җилләр екты җилкәннәрне,
Давылларда сынды мачталар.
Ерак юлга дәшкән капитаннар
Давыл саен тик фал ачтылар.

Чөйгән саен дулкын,
Якыная упкын,
Чайкала да кораб, айкала.
Жан, дип, таң, дип типкән йөрәклардән
Тик хач кала бары, ай кала.

«Халык» дигән халык дингез кичә,
Капитаннар кичкән күптәнме?!
Юлдан язып, кыйбла җуйганнарга
Бирә Ходай күктән көткәнне.

Шул корабта без ул, җандашларым,
Без йөзәбез анда,
карагыз!
Кайчан гына җилкәнсезләр идек,
Корабсыз да калып барабыз.
Корабсыз да калып барабыз...

# ДАНЛЫ ҮТКӘННӘРДӘН — ЛАЕКЛЫ КИЛӘЧӘККӘ!



«Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе — «Татнефть» компаниясенең чишмә башы. Ә идарәне барлыкка китергән, дөньяга тудырган предприятие — Бөек Ватан сугышында җиңүнең артиллерия салютлары тынар-тынмаста ук, ягъни, 1945 елның 30 маенда оешкан эреләндерелгән Шөгер нефтепромыселы. Нәкъ менә шушы вакыттан башлап республикадагы беренче нефть һәм газ чыгару идарәсенең тарихи елъязмасы башлана, башкача әйткәндә, Татарстан нефть сәнәгате үсешенең тиңдәшсез марафонына старт бирелә дә инде.

Шөгер нефть ятмасын ачучы булып Иске Шөгер авылы янында бораулаган Беренче номерлы легендар скважина санала. Әлеге скважина көненә 20 тонна «кара алтын» биреп, сугыш барган 1943 елда ук бирелә нефть запасларының булуы турында бөтен илгә хәбәр итә.

Скважиналар турында сөйләгәндә, аларның тагын берсе, данлыклы Өченче скважина турында да искә төшерми ярамас. Нәкъ менә ул, күптән көтелгән нефть фонтанын аттырып, 1948 елның июлендә исеме еракларга таралачак Ромашкино «кара алтын» ятмасын ачучы булды. Әлеге ике скважина бүген дә сафта. Алар, үзләрен дөньяга китергән, данлы иткән беренче нефтьчеләрнең тиңдәшсез хезмәт батырлыкларын онытмаган төсле, бүген дә нефть бирүдән туктамыйлар.

Ромашкино ятмасы ачылу Татарстанда нефть чыгаруның көчәеп китүенә төп сәбәп булды. Ятма ачылып, сигез ел үтүгә, республикабыз кара алтын табу буенча илдә беренче урынга чыкты. 1950 елда Татарстан нефть промыселлары илгә 860 мең тонна (илдә табылган нефтьнең 2,2%) җир мае биргән булсалар, 1958 елда җир астыннан 28 миллион тоннадан артык, 1960 елда — 42,8 миллион, 1968дә — 83 миллион тонна «кара алтын» чыгарыла. Ә инде 1971 елның маена республика нефтьчеләре чыгарган нефтьнең гомуми күләме миллиард тоннага җитә. Ун ел үтүгә, әлеге санга тагын бер миллиард өстәлә. Ә 2007 ел тарихка республикада җәмгысы 3 миллиард тонна җир мае чыгару белән кереп кала.

Янадан тарих сәхифәләрен актарыйк. 1950 елда СССР Министрлар Советы карары нигезендә «Татнефть» берләшмәсе төзелә. Әлеге берләшмә соңыннан бу төбәкнең үсешен, чәчәк атуын, тотрыклылыгын тәэмин итәр дип уйлаучылар ул вакытта күп булды микән? Шөгер эреләндерелгән промыселыннан ялрган, Союз карамагында булган дәүләт тресты «Бөгелмәнефть» шул елны ук «Татнефть» составына кертелә. «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең хәзерге атамасы исә нефть сәнәгатендә идарә һәм оештыруны камилләштерү нәтиҗәсендә 1970 елда барлыкка килә.

«Лениногорскнефть»нең артык зур булмаган тарихы бер үк вакытта шушы төбәктән чыккан, соңыннан кара алтын чыгаручы зур-зур коллективларның, тармакның, Министрлыкның җитәкчеләре дәрәҗәсенә ирешкән, «кара алтын» тармагы белән бергә үскән күренекле нефтьче-белгечләрнең биографиясе дә дияргә булыр иде. Соңыннан Союз масштабындагы җаваплы вазифалар башкарган хәтсез җитәкчеләр үзләренең беренче университетларын Ромашкино җирлегендә үттеләр.



*Беренче скважина. Шөгер, 1943 ел.*

Мәсәлән, Р.Ш.Мингәрәев — промысел башлыгы урыныннан «Татнефть»нең генераль директоры, СССР нефть министры урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхес. Р.Т.Булгаков — шулай ук промысел җитәкчесеннән Берләшмәнең генераль директоры вазифасына, СССР Госпланы бүлеге җитәкчесенә ирешкән белгеч. Зур җитәкчеләр турында сөйләгәндә, А.К.Мөхәммәтҗановны — оператор ярдәмчесеннән «Татнефть» җитәкчесе биеклегенә генә түгел, хәтта ки СССР нефть министры урынбасары булып та эшләгән легендар шәхесне искә төшерми мөмкинме?! Биредә шулай ук СССР Нефть министрлыгының баш геология идарәсе башлыгы урынбасары вазифасына ирешкән фән докторы, Нефть һәм газ дәүләт академиясе профессоры, хезмәт юлын гади геолог булып башлаган М.М.Ивановны да олы хөрмәт белән искә алырга кирәктер.

Әле тагын шунысын да искәртү зарур: 13 Социалистик Хезмәт Герое, 3 Советлар Союзы Герое — үзләренең хезмәт биографиясен «Лениногорскнефть» идарәсе белән бәйләгән кешеләр.

«Лениногорскнефть» идарәсенең беренче карашка артык озын да булмаган 70 еллык тарихы үзе берничә этаптан торуын да билгеләргә кирәктер. Һәр этапның үз җинүләре, үз казанышлары булган кебек, үз кыенлыклары, проблемалары да була.

1950 елны «Бөгелмәнефть» тресты барлыкка килү унаеннан, аның балансына 41 скважина бирелә. Расланган план нигезендә, трест көненә 921 тонна нефть чыгарырга тиеш була. Әйтергә кирәк, заманы өчен бу шактый олы күрсәткеч. Ул вакытта трестта җәмгысы 200 кеше хезмәт куя, оешмада нефть чыгару буенча биш бригада, скважиналарны ремонтлау буенча янә бер бригада һәм автотранспорт хуҗалыгы эшли. Һәм әлеге коллектив, туып торучы кыенлыкларга карамастан, шул вакытта ук 426 мең тонна нефть чыгарып, еллык планны 25 процентка арттырып үти.

Ул вакытларда промыселларда тракторлар да, бульдозерлар да булмый әле. Беренче скважиналарга хәтта электр тогы килеп җитми. Нефтьне камиллектән ерак торган үтә дә гади насослар суыра. Аларның двигательләре 30нчы елларда ук колхозларда ашлык сугучы молотилкалар өчен ясалган була. Үзәктән куучы беренче насос та бары тик 1953 елда гына кулланыла башлый.

50нче еллар урталарында беренче тапкыр пласттагы басымны киметмичә саклау системасы эшләнә. Ә 1954 елдан башлап Ромашкино ятмасында пластларга су кууга керешәләр. Нефтьле пластларга су тутыру технологиясе үз нәтиҗәсен алай озак көттерми. Республикабыз 1956 елда ук илдә нефть табу буенча әйдәп баручы төбәккә әверелә. Бу казанышта П.С.Васильев, М.М.Иванов кебек геологларның һәм инженерларның хезмәте бигрәк тә зур була. Әлеге алымны куллануның төп нәтиҗәсе шул: 1959 елга республикада нефть табу аена 1 миллион тоннага (!) җитә.

60нчы еллар республикабызга нефть тармагында яна уңышлар алып килә. 1963 елга биредә 18,2 миллион тонна җир мае чыгарыла. «Лениногорскнефть», иң эре идарәләрнең берсе буларак, кара алтынны чыгаруда хәтта СССР масштабында да алдынгылар рәтендә бара.

Шул ук 60нчы елларда скважиналарда «кара алтынны» автомат рәвештә суырту системалары барлыкка килә башлый. Аның беренчесе данлыклы 3нче номерлы скважинага куела. Бер үк вакытта торбаларның парафинлануы белән дә нәтиҗәле көрәш башлана. Парафин ябышмасын өчен, торбаларның эчен пыяла белән каплау технологиясе булдырыла.


*«Лениногорскнефть» аксакаллары.*

1965 елда «Лениногорскнефть»кә караган мәйданда, төгәлрәге, 4090, 3998, 1899нчы номерлы скважиналарда, пласт басымын саклауда революцион алым — автоматлаштырылган су куу чыганаклары булдырыла. Бу эшнең башында башта идарәнең, аннан соң «Татнефть» берләшмәсенең баш геологы, бүгенге көндә ятмаларны үзләштерү буенча Президент киңәшчесе булып эшләүче Р.Х.Мөслимов тора.

1971 елның 14 маена табылган 1 миллиард Татарстан нефтендә Лениногорск «кара алтын» табучыларының өлеше 288 миллион тонна, ягъни республикада чыгарылган нефтьнең биштән берен тәшкил итә. Шушы ук ел идарә тарихында иң күп кара алтын чыгарылган ел булып та тарихка кереп кала. «Спутник» дип аталган группада эшләүче җайланмалар кертү, скважиналарны цикллап суландыру да шушы вакытта башлана.

70нче еллар урталары. Әлеге чор идарә тарихына, беренчедән, скважиналарга агымдагы ремонтны оештыру процессын җайлау, күпләп ремонт үткәрү (елына 3 мең скважинага ремонт) һәм, икенчедән, тирәндә эшләүче насос җиһазларын төзәтү буенча илдә беренче торба базасы оештыру белән кереп кала.

Ә менә 80-90нчы еллар «Лениногорскнефть» өчен яңа технологияләр, техника куллануда, пластларга янача тәэсир итүдә янарышлар вакыты — идарә үсешендә тагын да бер олы этап булды. Шушы елларда ук нефть үткәрүче торбаларның ярылу, тишелүе белән дә нәтиҗәле көрәш башланды. Әлеге максатларны күздә тотып, «ДИНА-1» дип аталучы дефектоскопия җиһазы кулланыла башлый. Бераз соңрак эченә пыяла катламы йөгертелгән су торбалары куллану гамәлгә ашырылып, аннан алда ук диаметрлары 114 миллиметрдан 325кә кадәр булган барлык торбаларны шул рәвешчә, ягъни пыялалап күгәрүдән саклау цехы да сафка баса...

1981 елга республикабызда икенче миллиард тонна «кара алтын» чыгарыла. Әлеге күләмдә «Лениногорскнефть» идарәсенең өлеше бу юлы барлык табылган нефтьнең чирегенә якынын (494 миллион тонна) тәшкил итә.

1992 елда күптән көтелгән металлопластмасс торбалар цехы ачыла. Шушы ук елларда янә бер алдынгы технология — торба һәм резервуарларны протектор юлы белән күгәрүдән саклау ысулы эшләп китә.

«Татнефть»нең алдынгы һәм иң беренче булып оешкан нефть һәм газ чыгару идарәсе «Лениногорскнефть» тармактагы төрле башлангычлар, инновацион технологияләр кертү, яңа техника, җиһазлар куллану буенча да беренче урында бара. Идарәнең промыселларында беренче булып пластны гидроерту (гидроразрыв) технологиясе һәм гидроком агымы белән тишкәләү (гидропескоструйная перфорация) кулланыла башлый. «Лениногорскнефть» идарәсе «Халибартон» фирмасы белән берлектә барлыгы 26 гидроерту башкарып, шуның 25е уңышлы була. Бу юнәлештәге тәҗрибәне тиздән «Татнефть»нең башка идарәләре һәм Башкортстан нефтьчеләре куллана башлый. 1978 елда СССРда беренче тапкыр биредә — «Лениногорскнефть» идарәсендәге промыселларда мицеляр-полимер суландыру технологиясе тормышка ашырыла. Моннан кала янә дә «Татнефть» берләшмәсендә беренче тапкыр, пластлардагы басымны саклау өчен, УЭЦН дигән яңа тип насос сынала. Пластларга реагент куучы горизонталь КНС-14 насослары да тәүге тапкыр «Лениногорскнефть» цехларында беренче чыныгу ала. Шунысын да әйтергә кирәк: КНС-14 насосы, соңыннан, «Татнефть» берләшмәсендә киң кулланыш тапкан пласт басымын саклаучы аз көчәнешле барлык насосларның «агасы» була.



*Татарстан нефтен ачучылар истәлегенә.*

Һәм менә 2007 елда Татарстанда табылган «кара алтын»ның күләме 3 миллиард тоннага житә. Биредә республикадагы беренче нефть һәм газ чыгару идарәсенең өлеше 625 миллион тонна, ягъни барлык нефтьнең янәдән дә биштән берен тәшкил итә...

Идарә коллективына горурланыр өчен сәбәпләр бик күп. Җыеп әйткәндә, үткән 70 ел эчендә Лениногорск нефтьчеләре илдәге нефть сәнәгате үсешенә әйтеп бетергесез зур өлеш кертәләр дисәк тә, хата булмас. Бу — әйткәнебезчә, кара алтын чыгаруның яңа ысуллары, алдынгы технологияләрне сынау һәм куллану, яңа техника һәм җиһазлар белән тәҗрибәләр.

Нефтьчеләребезнең һәрдаим авангардта булуы һәм хезмәт героизмы дәүләт тарафыннан һәрчак лаеклы бәяләнде. 70 ел эчендә ярышларда даими җинеп барганы һәм югары хезмәт казанышлары өчен идарәгә мәңгелек саклауга дип КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, Нефть сәнәгате министрлыгының 16 Кызыл Байрагы тапшырылды...

Бүген «Лениногорскнефть» идарәсе Ромашкино ятмасында эшләвен дәвам итә, Лениногорск районының көнбатышындагы мәйданда, Зәй-Каратай, Куакбаш, Абдрахман нефть мәйданнарында кара алтын чыгара. Идарә эшчәнлеге Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә районнары, Самара өлкәсенең Келәүле районы да кергән 1331 квадрат километр гомуми мәйданга җәелгән.

Идарә балансында бүген 8326 скважина. Шуларның 6309ы «кара алтын»ны өскә күтәрсә, 2017се пластларга су куа. Лениногорск нефтьчеләре бүгенге көндә елына 3 миллион тоннадан артык җир мае чыгарып киләләр. Ләкин тормыш шундый: ул алга янадан-яңа мәшәкатьләр чыгарып, проблемалар да куеп тора. Берьяктан, искереп баручы скважиналар фонды, нык суланган пластлар, икенче яктан, нефть табуны елның-елына азга булса да арттыру зарурлыгы нефтьче белгечләрне һәрчак уяу булырга, эзләнүләрне дәвам итәргә, технологияләр сайлауда ялгышмаска этәрә...

Хронологияне дәвам итеп сөйләгәндә, тагын шунысын да искәртергә кирәктер: 2014 елда идарә тарихында беренче тапкыр девон катламына горизонталь скважина бораулады. Шушы ук елда торбаларны саклауда һәм ремонтлауда цемент җепселле материаллар кулланышлы яңа технология дә гамәлгә кертелде.

Лениногорск нефтьчеләре алдында торган күпсанлы бурычларның берсе — нефть чыгару күләме сакланып килгәндә һәм артып торганда, чыгымнарны чикләү, кимету өстендә эшләү. Бу максатны тормышка ашыру йөзеннән биредә комплекслы чаралар алып барыла, эффект бирүче яңа технологияләр, геолог-техник алымнар куллану арта...

Нефть һәм газ чыгару идарәсе составында бүген гадәти «кара алтын» чыгаручы 8 цех эшләп килә. Алардан башка тагын куе, ягъни битумлы нефтьне табу белән шөгыльләнүче аерым цех та бар. Пласт басымын саклаучы ике, нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру буенча янә ике цех, скважиналарга җир асты ремонты һәм торак-коммуналь цехлары эшли. Коллективта 2300 кеше хезмәт куя. Шунысы да сөендерә: әлеге санның өчтән бере — 33 яшькә кадәр булган яшьләр. Тик идарәнең данлы үткәне онытылмаган кебек, Татарстан нефтенең башында торган кешеләр дә җитәкчелекнең даими кайгыртуын тоеп торалар. Ветераннар оешмасы ике меңгә якын кешене берләштерә. Бүгенге көнгә «Лениногорскнефть»тә, әйтергә генә ансат, 613 хезмәт династиясе бар. Аларның гомуми хезмәт стажын санасаң, ифрат та олы

сан — 62 мең 968 ел килеп чыгар иде. Иң данлыклы 5 династияне генә алганда да, аларның һәрберсенең «Татнефть» составындагы гомуми стажы — 400 ел. Болар — Галиевлар, Абдуллиннар, Ершовлар, Мигачёвлар, Асадуллиннар династияләре...

Нефть сәнәгатендәге уңышлар идарәгә социаль программаларга да вакыт һәм көч кызганмаска мөмкинлек бирә. Социаль юнәлешне һәрчак саклап килгән «Татнефть» компаниясенең состав өлеше буларак, «Лениногорскнефть» идарәсе дә бу максатта эзлекле эш алып бара.

Идарәдә эшләүчеләр һәм аларның гаиләләре өчен «Лениногорский» дигән бик тә затлы санаторий-профилакторий барын да әйтеп үтик. Шулай ук ел әйләнәсендә ачык спорт базасы бар. Идарә һәм аның хезмәткәрләре карамагында «Юбилейный» ябык йөзү бассейнының да ишекләре һәркөнне ачык. Балаларны ял иттерүдә, сәламәтләндерүдә үз өлешен даими кертеп килгән ике җәйге лагерьга ел саен 1500 бала юллама ала.

Идарә үз хезмәткәрләренең генә түгел, шәһәрнең һәм авыл торак пунктларының яшәеш проблемаларын хәл итүдә дә актив катнаша. «Лениногорскнефть» инде менә ничә еллар буе торак төзелешендә, социаль-мәдәни объектларны торгызуда да төп заказчы булып кала. Шәһәрдә яшәүчеләр теләген даими истә тотып, нефтьчеләребез акчасына мәктәпләр, мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, заманча спорт комплекслары, поликлиникалар, кунакханәләр төзелде һәм төзелеп тора.

Татарстан нефтенең 70 еллыгына идарә Карабаш бистәсендәге аквапаркны төзүдә, Иске Шөгер һәм Абдрахман авылларында мәдәният йортларын ремонтлауда, Кама-Исмәгыйль авылында мәктәп торгызуда, Шөгер төбәгендәге юлларны асфальтлауда актив катнашты. Шушы араларда гына Шөгер авылында идарә катнашында яңа балалар бакчасы төзелә башлады.

2005 елның 1 гыйнварыннан алып санаганда, шәһәребездә ипотека төзелеше программасы буенча, нефтьчеләребез булышлыгы белән 13 йорт сафка бастырылды. Татарстан нефтенең 70 еллыгына шушы яңа микрорайонда махсус проект буенча төзелгән, 140 урынга исәпләнгән балалар бакчасы эшли башлады. Шул ук елны өлгертелгән теннис-холл, капиталь ремонт үткәрелгән бала табу йорты һәм үзәк хастаханәнең генекология бүлекләре дә шәһәребез халкына лаеклы бүләк булды. Бүгенге көндә идарәнең турыдан-туры катнашында икенче номерлы мәктәпкә яңа бина, ә санаторий-профилакторий өчен йөзү бассейны төзелә.

Идарәгә квалификацияле белгечләр әзерләп торучы Лениногорск нефть техникумы да «кара алтын» табучылардан күпкырлы даими ярдәм алып килә. Идарә күз уңыннан бер дә төшермәгән Лениногорск балалар йорты да, шефлыкка алынган 2, 5, 12нче мәктәпләр дә нефтьчеләребезнең җылы канаты астында.

Лениногорск нефть һәм газ чыгару идарәсенең — 70, шәһәрнең 60 еллыгын каршылаганда, нефтьчеләребез үзләре яшәгән шәһәргә һәм районга янәдән дә олы бүләкләр әзерләде. 1, 3нче номерлы тарихи скважиналар янындагы һәйкәлләр танымаслык итеп төзекләндерелде. «Зәңгәр күл» буенда элек үлән һәм агачлар каплаган яр хәзер курорт шәһәренең диңгез буен хәтерләтә. Эшчеләрне промыселларга озатып калучы автовокзалга да сокланмый карау мөмкин түгел. Шәһәрне аркылы кисүче Чайковский урамы яңа сулыш алды.

Үз тарихы алдында һәрчак олы җаваплылык хисе тоеп яшәгән, 70 ел дәвамында «кара алтын» чыгаруда күпкырлы тәҗрибә туплап, олы казанышларга ирешкән һәм барыннан да бигрәк санап бетергесез изге эшләр эшләгән «Лениногорскнефть» идарәсе киләчәктә тагын да зуррак уңышлар, яңа үрләр яулар, моннан соң да үзенең күркәм традицияләрен дәвам итәр дигән ышанычта калмый мөмкин түгел.

**Рафаэль НУРМӨХӘММӘТОВ,**
*«Лениногорскнефть» идарәсе җитәкчесе.*



## Таһир Шәмсуаров

# КУӘТ БИРӘ ВАТАН ҖЫЛЫСЫ

## Иске Шөгер

Иске икән, димәк, изге инде,
Иске нигез — газиз төп нигез.
«Шөгер» жырын биргән төбәгемә
Чакырмыйча гына килегез!

Исем китми иске дигән сүзгә,
Яшел күлмәк кигән Шөгерем.
Чандыр гына, юка малай килеш
Шандор тауларына йөгердем.

Ир-егетләр төптән уйлап яши,
Язмыш карурманын күргәнгә.
Кызлар бездә бар да зәңгәр күзле,
Зәңгәр күлдә сулар кергәнгә.

Чорлар кичкән йомры хәтер сөйли,
Могжизага тарыр жай чыккан.
Кара туфрагына аяк бассаң,
Аяк асларыннан май чыккан.

Замананың саллы тәгәрмәчен
Ничә буын тирләп майлаган.
Жирсөярләр гомер сөргән жирен
Оҗмахка тиң итеп санаган.

Син искегә яна караш ташла,
Сылу кыздай үзенә каратыр.
Килер бер көн, Шөгер шагыйрьләре
Бар дөньяга шигырь таратыр!

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) — *шагыйрь; «Моң коесы», «Гомер дисбесе», «Яратудан тора җир шары» исемле китаплар авторы. Лениногорск районының Мөэмин-Каратай авылында яши.*

Яратырга кирәк туган жирне,
Әни төсле, әни шикелле.
Бездә таулар болыт-бүрек кия,
Үзәннәре жәен сипкелле...

Менә төгәл нәкъ житмеш ел тулды
Илгә жину алып кайтканга.
Иске сүзләр, димә, шушы Шөгер
Өч Геройны бирде Ватанга!

Шушмасы да, талгын Шөгер жиле,
Миннән башка, әйтче, кемнеке?
Беркем белми торган серне ачам –
Бөтен татар иле минеке!

Иске Шөгер — моң тудырган урын,
«Шөгер» жырын биргән, белегез.
Кара алтын иле ак күңелле –
Чакырмыйча безгә килегез!

## Ватан җылысы

Ул башлана синең авылыңнан,
Китә калсаң, килсен елыйсы.
Карашыңда сөю ургып торсын,
Ургып торсын Ватан җылысы.

Моң-зарың да, сөйгән яр да шунда,
Жиде бабаң сүзен тыңлыйсы.
Мең кат өшеп, мең кат туңу кирәк,
Тояр өчен Ватан жылысын!

Ялгышырга, адашырга мөмкин,
Бу сынаулар, димә, соңгысы.
Төпсез сазлыкларда батмый кеше,
Өмет суза Ватан жылысы.

Дуслык учагына елышасы,
Иң мөһиме менә шунысы.
Кыя тауга менү — уен гына –
Куәт бирә Ватан жылысы!

Килмешәк тә, мөһажир дә түгел,
Үз жиреңнең кадерен аңлыйсы.
Дошман безгә кагылудан курка –
Өмет ала Ватан жылысы!

Без — тарихта моң тудырган халык.
Шуңа тансык жырның моңлысы.
Нәни илдән — авыллардан язмыйк,
Тигез жылыт, Ватан жылысы!

## Юл чатында басып торам

Ялгыз чатта басып торам,
Нигәдер туктамыйлар.
Буш урыны була торып,
Машиналар алмыйлар.

Кайберләре күз дә салмый,
Җил бәреп узып китә.
Бик сирәге бүтән якка
Юл алганын белгертә.

Бәхет елмайды, заманча
Машинада утырам.
Кәттә татар бае сыман
Дөньяга тамак кырам.

Юл читендә ике юлчы
Ымсынып кул күтәрә.
Буш урын, күңел бушлыгы
Моңсу уйга этәрә.

Күтәрелгән куллар калды,
Ә без алга барабыз.
Ниндидер асыл сыйфаттан
Ераклаша арабыз.

Кабат юл чатында торам,
Инде кул арып бетте,
Шофёр янындагы кеше
Мине күрмичә үтте...

## Мин сине исемә төшердем

Мин сине исемә төшердем,
Онытты диюләр ялгандыр.
Зәңгәр күккә манган яулыгың
Җуелмый күземдә калгандыр.

Без менгән тауларга, мин беләм,
Башкалар менәдер, бүтәннәр.
Күңелләр шул килеш калса да,
Яфраклар, үләннәр бүтәннәр.

Мин бүген дә әле оялчан,
Хәтерлим озата барганны.
Айлы төн, йолдызлар сизенде
Бер балкыш ярату сарганны.

Сөймәгән, сөюне белмәгән
Бу җирдә бик күпне югалтыр.
Мин сине башкага җибәрмим,
Янымда, җанымда басып тор.

Мин сине исемә төшердем
Шатлыклы күз яше — тамчыда.
Күзеңнән мин шуны укыдым:
Саф хисләр үзгәрми тамчы да...

## Үземә кайтып барам

Мин шәһәргә бара калсам,
Уңайсыз хәлгә тарам:
Сагыну тарта авылга –
Үземә кайтып барам.

Вакытлыча китеп торсам,
Калмагач башка чарам,
Җан кысыла. Сулыш җитми –
Үземә кайтып барам.

Төштә башка илдә йөрсәм,
Кузгала йөрәк ярам.
Татарстан, дип уянам –
Үземә кайтып барам.

Чит телне дә ят санамыйм,
Әйтәсен туры ярам.
Туган телгә табынганга,
Үземә кайтып барам.

Туган көннән бүгенгәчә
Алтмыш юл — узган арам.
Үз-үземне аңлар өчен,
Үземә кайтып барам...

## Мине көт

Мин яуга атлаган сукмактан,
Меңенче тапкыр бүген үт.
Син мине ул кайтыр дип уйла,
Башкалар көтмәсен, ә син көт!

Һәйкәлгә чәчәкләр куйганда,
Елама син, бәгърем, яшең сөрт.
Бүгенге поездан төшмәсәм,
Иртәгә каршыла, мине көт.

Табында урыным саклансын,
Гел бергә, янәшә идек бит.
Хәбәрсез югалган дисәләр,
Ышанма, һәр таңда хәбәр көт!

Буй-сыны нәкъ миңа охшаган,
Ак чәчле улымны бүген үп.
Оныклар беләме мин барын?
Оныклар хакына мине көт!

Мин яуга атлаган сукмактан,
Меңенче тапкыр бүген үт.
Мин исән син көткән чагында,
Хәтерлә, онытма, мине көт!...

Шамил
Хәнифов

# КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА

ӘДӘБИ-ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Минем номерым — «19723...»

Көне буе һәм төнлә лагерьга кайткач, нәрсә булыр икән дип уйлап баш ваттым. Колоннадагы урыныма басканчы, конвоир минем шнур белән бәйләп муеныма асылган түгәрәк тимер жетондагы «19723»ле номерымны язып алып калган иде. Шунда ук барак номеры да бар, ул — «5». Икенче көнне иртән мине комендатурада басып кына торырга мөмкин булган кечкенә номерга бикләп калдырдылар. Көн урталарында лагерь комендантына алып киттеләр. Ул — кара формага киенгән карт кына немец — үзенең ярдәмчесе Лысенко аркылы миңа сораулар бирә башлады. «Ничек син немец байлыгына кул сузарга җөрьәт иттең? Җитмәсә, Көнчыгыш фронтта сезне большевизм коллыгыннан коткару өчен кан коючы фронтовикның улына сукхансың», — дип мине гаепли. Хәер, озак сорап тормадылар, экзекуциягә алып китеп, егерме биш таяк суктырдылар да камерага илтеп яптылар. Камерада ике атна тотканнан соң, беркөнне урамга чыгардылар. Анда велосипедлы бер полицай көтеп тора иде. Кулында бау. Ул минем янга килеп, бавының элмәкле очын муеныма ыргытты. «Бетүем шушы икән, асып куялар», — дип уйладым. Полицай бауның икенче очын велосипедның багажнигына эләктереп маташа. Боларның уе башкада бугай. Ул миңа артыннан калмаска кушып кузгалып та китте. Теләсәң-теләмәсәң йөгерергә туры килә. Исәпсез-сансыз тезелгән лагерьларны да үттек. Юлда очраган кешеләр башларын чайкап карап калалар. Ниндидер авыл аша үтәбез, немец үсмерләре бармак төртеп көлә, миңа таш ыргыталар. Ничә чакрым чапканмындыр, төгәл генә әйтүе кыен, тик җеп өзәрлек тә хәлем калмагач, гөрселдәп егылдым. Полицай аягы белән килеп төртте, басарга кушуы. Шулай да ул миңа бераз ял итәргә мөмкинлек бирде. Аннары кабат кузгалдык: велосипедчы аягы белән педален әйләндерә, ә мин егылып буылмас өчен аның артыннан йөгерергә мәҗбүр. Урман полосасын чыккач, бераз арырак, агач бараклар күренде. Бараклар артында тагын урман шәйләнә. Бу — урманнар белән әйләндереп алынган, каты режимлы штраф-лагерь икән. Егерме беренче номерлы ошбу лагерьда төрле гаепләре һәм җинаятьләре өчен башка лагерьлардан тоткыннар китерелә. Шлагбаум каршына җитеп туктауга, будка эченнән беләгенә свастика бәйләнгән сакчы чыкты.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

Мине алып килгән полицай ниндидер кәгазьләрен күрсәткәннән соң, безне үткәрделәр. Шлагбаумнан һәр ике якка чама белән ике ярым метр биеклектәге чәнечкеле тимерчыбык киртә сузылып киткән һәм ул бөтен лагерьны әйләндереп алган. Эчкәрәк үткәч, тимер капкалар тора. Капкаларның ике ягында да прожекторлы сакчы вышкалары. Аларда тәүлек әйләнәсе автоматчылар кизүлек итә. Андый вышкалар бөтен лагерь периметры буенча әллә ничә һәм алар арасына шулай ук чәнечкеле тимерчыбык тарттырылган. Боларына, беренчесеннән аермалы буларак, ток җибәрелгән. Бу капкада да, мине китергән полицай кәгазьләрен күрсәткәч, тоткарлык булмады. Бараклар янында янә бер капка бар икән, анда да документ тикшерделәр. Полицай мине кечкенәрәк бер йортта утыручы хәрбиләр кулына тапшырып китеп барды. Тегеләр озаклап нидер яздылар һәм соныннан бер хәрби мине, бетон бункер янына алып килеп, камера ишеген ачты да эчкә төртеп кертеп җибәрде. Артымда шартлап ишек ябылганы ишетелде. Карасам, идәндә каратут чырайлы ниндидер кеше утыра. Исәнләштем. Теге адәм җавап бирергә ашыкмый. Шулай да беравык торгач: «Франце», — дип куйды. Француз, димәк. Мин: «Рашен», — дим. Кайда ым, кайда хәрәкәт белән үземнең «Шамил — Саша» икәнлегемне аңлатам. Ә ул «Жюльен» булуын белгертте. Нәрсә өчен утыруы белән кызыксынам. Ул туган иленә качарга теләгәндә тотуларын әйтә. Мин аңа монда нигә китереп тыгуларын аңлатам. Ул: «Гут, гут, камрад», — дип елмаеп җилкәмнән кага.

Үтереп ашыйсы, аннан битәр эчәсе килә. Жюльен ишекне аяк һәм куллары белән төйсә дә, ачучы күренми. Төн тынычсыз үтә. Иртә белән Жюльенны алып киттеләр. Саубуллашканда аның күзләре сагыш белән тулган иде. Бу аерылышу сагышы гына түгел, ә тирәнгә яшерелгән, яшәүгә өмете өзелгән кешенең сагышы иде.

***

«Эчәргә бирегез», — дип сорыйм зәгыйфь тавыш белән. Икмәк бирмәсәләр дә, су китерәләр. Бетон капчыкта мине өч көн тоталар. Өч көннән соң һавага чыгарып, кер юа торган урынга алып китәләр. Хәлсезлектән аякларым калтырый. Кер юу бүлмәсендә минем кебек башка тоткыннар да бар. Чәчләрен алырга чират җиткәнне көтәләр. Өч адәм машинка белән хәйран җитез хәрәкәтләр ясап чәч ала. Чират миңа да җитте. Аннары соры төстәге, буй-буй полосалы күлмәк, ыштан, куртка бирделәр, шуларга өстәп козырёксыз баш киеме тоттырдылар — һәммәсе соры төстә. Шнур белән муенга сугылган түгәрәк тимер бирка тагып куйдылар. Фамилия дә, исемең дә юк. Номерыңны кычкыргач, ишетмичә, эндәшми калырга язмасын — сине рәхимсез җәза көтә. Резин тукмаклар яисә такта белән шәрә артыңны каезлыйлар, алай гына аз тоелса, яңгыр яки кар астында пластунча шуышырга мәҗбүр итәләр.

Кайчагында баракта утырганда, сирена улый башлый, барлык әсирләр нарлардан сикереп төшеп чыгу ягына ташлана. Ниндидер сәбәп белән тоткарланып калсаң, җиде кат тиреңне салдыралар. Ишектән чыкканны сагалап торучы, як-якка баскан сакчылар тоткыннарның башларына, җилкәләренә, кай төшләренә туры килә — шунда резин тукмаклары белән тондыралар. Ә кешеләр, удардан качарга тырышып, башларын яшерәләр, иеләләр, этешәләр-төртешәләр. Надзирательләр, кан күргән ерткычлардай ярсып, уңлы-суллы тукмауларын белә. Ниһаять, түбәнсетелгән, кыйналган әсирләр ничек кирәк, алай плац уртасына чыгып тезелә. Аларга барлык вышкалардан прожектор утлары төбәлгән. Номерлап кычкырып тикшерү башлана. Һәркем үз номерын ишеткәч, мондалыгын белдереп җавап бирергә тиеш. Берәрсе, искәрмичә яисә кыйналудан аңгыраеп, ишетмичә калса, барлау әр-яңадан башлана. Плацта

меннәрчә әсир, аларның барысын тикшереп чыкканчы төн уртасы уза. Озак басып торудан аяклар ойый. Аннары «дрессировка» башлана: «Митце аб — башлыкларны салырга», — дигән әмер яңгырый. «Салырга — киярга, салырга — киярга». Шул рәвешчә бер сәгать һәм аннан да күбрәк вакыт үтә. Аның арты: «Ятарга — торырга, ятарга — торырга», — дигән команда ишетелә. Бусы — күз алдында кызыллы-яшелле бөжралар биешә башлаганчы. Инде беткәндер дисәң, пластунча шуышырга кушалар. Лагерь башлыклары шуышуны кайчан тели, шул вакытта гына туктата. Отбой. Төнге сәгать бер, кайчагында — ике. Ә иртәнге биштә янә сирена уларга тотына. Сикереп торып, кабат ишеккә ташланабыз. Һәм бар да яңадан башлана. Безнең аякларда агач башмаклар. Аларда йөрүе искиткеч кыен, чөнки алар бөгелмиләр, шунлыктан аяклар чиләнеп чыга. Иртә белән дә чыгу юлында резин таяклы сакчылар көтә — төнге экзекуция иртән дә кабатлана. Плацтагы тезелүдән соң, иртәнге сәгать җиделәрдә, кухняга чиратка басабыз. Иртәнге аш — чөгендер кушып пешерелгән йөз илле грамм ипи белән бер кружка болганчык төстәге сыеклык. Паёкны алганда елгыррак кыланмасаң, сакчыларның резин тукмаклары төшәсен көт тә тор. Шуна күрә, аш бүлүче паёгыңны ыргытканда эләктереп алып, тизрәк таю ягын карау хәерле. Үзенә тигән өлешне кабып йотуына (әгәр өлгерсәң), тотыкларны лагерьдан чыгару башлана. Инде тышта машиналар көтеп тора. Аларга утыртып төрле эшкә алып китәләр. Эшкә заявкалар, мөгаен, кичтән алына торгандыр, чөнки «штрафниклар» менеп утыру белән, машиналар төрлесе төрле юнәлештә кузгалып китә. Һәр машинага өч сакчы билгеләнгән. Аларның берсе шофёр янәшәсендә — кабинада утыра. Ике автоматчының берсе — алда, ә икенчесе кузовның артындагы махсус урыннарда урнаша. Эш сәгате унар-уникешәр сәгатькә сузыла. Аннары лагерьга кайтаралар. Капкадан аз гына шикле тоелган һәркемне тентеп үткәрәләр. Әгәр юк кына әйбер (мисалга — төпчек) тапсалар да, ник туганыңа үкендерәләр.

Үземнең байтак вакыт тимер юл вагоннарыннан цемент бушатырга йөрүемне сөйләп китү гаеп булмастыр. Моннан да авыр эш булса да, сирәктер. Кәгазь каптагы цементны ансат кына күтәреп алам димә. Вагоннан биреп торучы аны сыртыңа сала һәм син капчыкны штабельгә илтәсең. Ярый да анда алып торучы булса. Ул юк икән, цементны тиешенчә урнаштыруы җинел түгел, кайчагында капчык кулдан ычкынып китеп, төшеп ярыла. Шуны гына карап торган надзирательләр, өстенә ташланып, резин тәпәчләре белән тукмарга тотыналар. Сакчылар күрмәгәндә без капчыкларны махсус та ерта идек, бигрәк тә кыш көне. Чөнки юка өс-баш киеме белән чыдашлы түгел. Вагонда ертып, капчыкта баш һәм куллар өчен тишекләр тишәбез, кием эченнән өскә киеп куйгач, жылырак булып китә. Берсендә капкадан тентеп кергәндә, бу эш беленде һәм башкача инде безне һәрчак тикшереп кертә, әгәр тотылсак, җәзалый башладылар.

Цемент бушатуда барлыгы егерме биш кеше. Эштән кайтканда, безнең өсләр ап-ак, бары тешләр генә елтырап тора. Безне өеребез белән лагерь мунчасына куалап кертәләр һәм югары басым астында брандспойттан салкын суны шәрә тәннәребезгә сиптерәләр. Үзебезне белештермичә төрле якка сибеләбез, ә бу кешелексез бәндәләр, монардан тәм табып, ат урынына кешниләр. Бик күпләр мондый экзекуциядән соң тән температуралары күтәрелеп саташып ята һәм чебен урынына кырыла. Фашистлар өчен бу проблема түгел, үлгәннәрне яна тоткыннар алыштыра. Мин адәм чыдый алмаслык әлеге сынауларга ничек түзгәнмендер, хәзер дә аптырыйм, тик ничектер исән калдым. Мөгаен, иректә чагында яшьтән үк актив рәвештә спортның берничә төре белән шөгыльләнүем ярдәм иткәндер.

Штраф-лагерьдагы газаплануларым ун айга сузылды. Ун айдан соң, көндәлек барлау вакытында, үземнең «19723» номерын бу тәмугтан чыгарылучылар исемлегенә кертелүен ишеттем. Һәм мине элек тотылган лагерь №23кә күчерделәр. Штраф-лагерьга япканда нинди срокка икәнен әйтмиләр. Кагыйдә буларак, ул артык озак түгел. Тик анда бер эләккән кеше кабат эләкмәскә тырыша, чөнки сират күперен икенче кабат кичә алмаска да мөмкинсең ич.

## Янәдән Кайденко белән...

Егерме өченче лагерьда мин янә Кайденко белән очраштым һәм без бер-беребезгә булышып яшәвебезне дәвам иттек. Әсирлектә СССРның төрле төбәкләреннән бик күп милләт кешеләре тотыла, әмма яшәүләре никадәр авыр булмасын, алар беркайчан берсен-берсе җәберсетми иде. Ә хәзер кеше дигәнең үзе шикелле үк адәми затларны төрмәләрдә, армиядә ничек кыерсыта! Төрмәдә — паханнар була, армиядә — бабайлык. Мин, ничек кенә уйласам да, җәмгыятьнең шулай түбән тәгәрәвенең очына чыга алмыйм. Андый специфик урыннарда гына түгел, көндәлек тормышта да кешеләр еш кына үзара мөнәсәбәттә бер-берсе белән тупас, хәтта рәхимсез кыланалар. «Ни өчен?» — дигән сорау куясы килә андый чакта. Болар барсы да үзгәртеп корулар фонында башланды бугай, күпләр демократияне, нәрсә кылансаң да ярый, дип кабул итте кебек. Юк, элекке ягымлы, чиста мөгамәләләрне кайтарырга кирәк! Хәзерге юл — тупикка илтә торган юл ул.

Штраф-лагерьга килгәндә исә, ябылу срогының кыскалыгы анда урын житмәү белән дә аңлатыла. Аның аша мөмкин кадәр күбрәк халык уздыру өчен, кешене бер-ике ай эчендә чак йөри торган скелетка әйләндерәләр. Павел мине күргәч танымады: «Саша, синме соң бу?» — дип кычкырды ул гаҗәпләнеп. Кабат миңа кулыннан килгәнчә булышырга тырышты.

Егерме өченче номерлы лагерьдан төрле эшләргә йөртәләр. Конвоирлар арасында Пауль атлысы бар иде. Әнә шул бәндә баракка йөгереп керә дә: «Рус, ауфштейн! (вставать)», — дип оран сала һәм камчысы белән әле йокыдан да уянып җитмәгән кешеләрне уңлы-суллы кыйнарга керешә. Һәм бу хәл көн саен кабатлана. Кызларны да иртә белән колонналарга тезеп эшкә алып киткәннәре күренә.

Берсендә бөтен халыкны лагерь плацына куалап чыгардылар. Карасак, алдыбызда зур өем булып төрле төстәге һәм үлчәмдәге күлмәк, чалбар, костюм ише киемнәр ята. Безгә: «Лагерь коменданты киң күңеллелек күрсәтеп, сезгә киемнәр китерде, сайлап алыгыз», — диләр. Бу вакытта инде 1944 ел бара, фашистларны Көнчыгыш фронттан — совет гаскәрләре, Көнбатыштан американнар һәм англичаннар кысрыклый. Өченче рейхның соңгы көннәре якынлашканы аермачык. Шуңа күрә тоткыннарга карата мөнәсәбәт тә бераз йомшаграк иде. Канга буялганлыктан, ул чагында әйберләрне беркем дә алмады. Соңыннан гына киемнәрнең фашистлар тарафыннан юк ителгән яһүдиләрнеке икәнлеген белдек. Штраф-лагерьдагыдан аермалы буларак, башка лагерьларда кем нинди киемнән булса, шул киемендә йөри ала иде. Тик өс-башларыбыз нык таушалуга карамастан, мәетләрдән салдырылган киемнәрне кияргә теләмәдек — төннәрен саташтырып интектерер иде.

Алдарак әйткәнемчә, Украинаның бөтен өлкәләреннән егетләр бар иде. Россиянең Кировоград өлкәсеннән дә Петренко дигән берәү бар. Ул чын куркуль булып чыкты. Янәшәсендәге иптәшләреннән ашыйсы килү-килмәве белән кызыксына икән дә, «ашыйсым килә» (ач кешенең ничек инде ашыйсы килмәсен), дигән җавап ишеткәч, үзенең паёгын тәкъдим итә икән бу. Тик

әҗәтне ике паёкны түләү шарты белән. Ахырын уйлап җиткермәгән кайберәүләр чак кына ачтан үлмичә калдылар. Соңыннан аның махинацияләрен белеп алгач, үздән генә буып үтермәделәр үзен.

Берсендә итальян һәм румын хәрби әсирләренең немец сагы астында эшләүләрен күреп гаҗәпкә калдык, чөнки Италия белән Румыниянең Гитлер союзниклары икәнен белә идек. Баксаң, итальян һәм румын солдат вә офицерлары сугышырга теләмичә баш күтәргәннәр. Фетнәчеләрнең шактый өлешен атканнар, ә бер өлешен рәхимсез бастырып, фашист концлагерьларына ташлаганнар икән.

## Кабат Антонио турында

Озак та үтмәстән безне Герман Геринг заводларыннан ерак түгел урында төзелүче бомбоубежищеларга эшкә йөртә башладылар. Монда күп меңләгән халык куып китерелгән. Француз, инглиз хәрби әсирләре һәм без — совет үсмерләре дә бар. Шунда язмыш кабат Антонио Миотто белән очраштырды. Ул минем кая югалуым турында сораштырырга кереште. Штраф-лагерьга эләгүем турында сөйләгәч, миңа үз туганына караган кебек карый башлады. Ул еш кына «Гитлер капут. Тиздән сугыш бетәчәк, шул чагында мин сиңа адресымны бирермен һәм без хатлар алышырбыз», — дип кабатларга ярата иде. Кызганычка каршы, сугыш тәмамлангач, без очраша алмадык. Аннары шунсы: хәтта адреслар алышсак та, хатлар язышa алмаган булыр идек, чөнки ул заманда чит илгә хат салу түгел, ошбу хакта авыз ачып бер сүз әйтсәң дә, автомат рәвештә дошманнар исемлегенә кертелә идең.

Бомбоубежищелар төзелешендә без гравий, цемент ташыйбыз, измә болгатабыз. Ә бу чагында дустым Павел Кайденко, юк кына нәрсә өчен гаепләнеп, штраф-лагерьга эләккән иде. Кайчагында Антонио, җаен табып, миңа нинди дә булса ризык бирә, ә мин эш вакытында аны Павелга тапшырам (эш фронты киң булганлыктан, штрафникларны да еш кына бирегә китерәләр). Болар барсы да надзирательләр күзеннән качырып эшләнелә, әлбәттә. Сонрак Павел миңа хатында: «Саша, беркайчан да синең үз паёкларыңны миңа бирүеңне онытмаячакмын», — дип язды.

## Авианалётлар

Монда миңа инглиз хәрби әсирләре белән танышу насыйп булды, бигрәк тә берсе — Джон Сэвидж белән якыннан таныштым. Аның йөзе һәрвакыт елмаюлы, еш кына үзләренчә: «Гут найт», «Гут монинг», «Гут автенун», — дип сәламләргә ярата. Немецлар совет гражданнары белән хәрби әсирләр арасындагы дустанә мөнәсәбәтләрне күреп, эшне безнең юллар кисешмәслек итеп сайлый башладылар. Аннан соң без читтән генә бер-беребезне баш кагып сәламләүгә күчтек.

Бомбадан саклану бункерларыннан тыш бу тирәдә тагын нәрсәләрдер төзиләр иде. Аларны нинди максатлар өчен төзүләрен анык кына белә алмадык, ә менә эшче көчне бары тик совет хәрби әсирләреннән генә алып килә иде.

Элек сирәгрәк булган союзникларның авиаудардары ешайды. Самолётлар бик биектән һәм берсе артыннан берсе зур төркемләп очалар. Биектән булса да, ташлаган бомбалары тиешле ноктага төгәл эләгә, заводлар хәтта төнлә дә янгыннардан кып-кызыл булып утыра. Без бомбаларның лагерьларга да, эшкә куып китерелгән кешеләр өстенә дә төшмәүләренә гаҗәпләнә идек. Еш кына кайбер бомбаларның безнең лагерь өстенә туры килүен тели идек, бу газаплардан котылыр идек ичмасам, дип уйлаган чаклар аз булмады.

Бомбага тотулар көндез дә, төнлә дә дәвам итте. Әсирлектән коткарылганнан соң, завод конструкцияләренең әллә нинди рәвешләргә кереп бөгәрләнеп беткәнен барып күрдек. Лагерьда, тикшерү белән булса кирәк, ниндидер чит кешеләр пәйда була башлады. Сонрак боларның халыкара оешма вәкилләре икәнлеге һәм әсирләрнең нинди шартларда тотылуы белән кызыксынып, тикшереп йөргәнлекләре беленде. Мин инде алдарак поляк, чех, данияле, голландияле һ.б. кайбер милләт кешеләренең лагерьлары сакланмавын һәм аларның эшкә бару-кайтулары да конвоирларсыз гына булуын әйткән идем. Соңгы вакытта безнең лагерьны да сакламый башладылар. Капкадагы сак калды анысы, электәге кебек эштән кайтканда еш кына тикшереп тә кертәләр. Сак хезмәтен алуларының ике төрле сәбәбе булырга мөмкин иде: беренчесе — фронтларда катастрофик рәвештә җанлы көчләр житмәве һәм икенче сәбәп — лагерьдан яисә эшкә барганда-кайтканда качсаң да, Алманиядә кая барасың, бирәдә урманнар юк дәрәҗәсендә, өстәвенә, тире белән сөяккә калган һәм начар киемле вә агач башмак кигән әсир әллә кайдан аерылып тора — аны җирле халык шундук властьларга тотып бирәчәк.

Фронтның һаман саен якынлашканы сизелә. Бомбадан саклану урыннарын да күпләп төзиләр. Союзниклар авиациясе бомбага тотканда, немецлар гаиләләре белән шунда яшеренәләр, монда ук аларның әйберләре дә саклана.

## Качарга омтылу

Тоткынлыкта инде өченче елым. Сугышка кадәр үткән тормышымны искә төшерәм дә, үзәкләрем өзелә. Аны сүз белән генә анлатырлык түгел. Әни ничек анда? Ул бит берьялгызы калды. Абыем гаиләсе белән хатынының туганнарына кайтып житә алды микән? Башка төрле уйлар керә һәм йокы кача. Әтнекеннән дә яман лагерь тормышы яшисе килү теләген юкка чыгарса да, соңгы вакытта үзгәрешләр исән калуга беркадәр ышаныч тудырды. Ничек тә түзәргә кирәк!

Безнең лагерьда Красюк фамилияле Тагонрог малае бар иде, ундүрт яшьләрдә, бик тере һәм шаян үзе. Гәүдәгә кечкенә генә, чәнечкеле тимерчыбык астыннан шуышып чыгу аның өчен берни тормый. Берсендә ул лагерьдан шул ысул белән шуышып чыккан да, урман буенда сагалап торып, велосипедта үтеп баручы гитлерюгендчы үсмерне үтергән. Аның формасына киенеп, велосипедында йөри башлаган. Алманиядә ул чагында велосипедта йөрүчеләр бихисап, күпләр эшкә дә шуның белән бара. Шуңа күрә Красюкның велосипедта йөрүе шикләнү тудырмый. Ул төннәрен каяндыр чәлдереп, ашарга ризыклар да табып кайта. Тик ул бер нәрсәне исәпкә алып бетерми: фриц баласының юкка чыгуы эзсез калмый, аны эзли башлыйлар һәм киемнәре салдырылып, аннан-моннан агач ботаклары астына яшерелгән гәүдәсен табып алалар. Шуннан гитлерюгендчыларны тикшерә башлыйлар һәм ахырда Красюкка килеп төртеләләр. Штрафлагерьга озатып асалар мескенкәйне. Төрле сәбәпләр аркасында шулай күп үсмерләр үлемгә дучар булды.

Бомбадан саклану бункерына Гриша белән немец гаиләләренең әйберләрен ташыганда, ишекнең эчтән бикләнсә дә, отвёртка белән тышкы яктан шөрепләрен борып алып, эчкә үтү мөмкинлеген шәйләп калган идек. Башыбызда — бункерның киемнәр саклаучы складына үтеп, үзебезгә ярарлыкларына киенергә һәм Брауншвейг шәһәренең станциясенә барырга, ә аннан печән төялгән вагонга утырып, көнчыгыш яисә көнбатышка юл тотарга дигән тәвәккәл план туды. Анда эләгә алсак, фронт аша чыгуы әлләни катлаулы булмас, дип уйладык яшьлек хыялыйлыгыбыз белән. Нарларның шөрепләре

какшаган дигән сылтау белән Антониодан отвёртка сорап алдык һәм аны таш астына яшердек.

Түземсезләнеп төн җиткәнен көттек. Барысы да йоклагач, саклык белән генә бараклан чыктык. Беркадәр атлыйбыз да туктап тыңланабыз: кемнең дә булса килгәне ишетелмиме? Тыныч бугай, димәк, полицайлар лагерь капкасы янындагы комендатурада утыра. Капка төнгә бикләнә һәм анда коралды сакчылар куела. Полицайлар йөреп торганда, гадәттә, үзара сөйләшәләр һәм кул фонарьлары белән тирә-юньне яктырталар. Тимерчыбык астыннан шуышып чыга торган урынга җиттек. Мин чыбыкны күтәрә төштем, Гриша шуышып чыгып, тимерчыбыкны аргы яктан күтәрде. Хәзер минем чират. Ниһаять, без икебез дә лагерьның тышкы ягында. Бункерлар төзелә торган урын безнең лагерьдан ерак түгел — кыр буенча барасы, тик бер җирдә юл аша чыкканда «эләгү» ихтималы аз түгел.

Бункер янына җиткәч тә тиз генә «эшкә» ябышмадык, сизенеп куа чыкмадылар микән дип тыңланып тордык. Ул-бу сизелмәгәч, яшерелгән урыныннан Гриша отвёртканы алып килде. Ишекне салдыру һәм бункер эченә керү күп вакытны алмады. Союзниклар авиациясе чираттагы налётын башламаса гына ярар иде, дип ялвардык эчебездән. Чөнки алай була калса, сирена улый башлау белән, немецлар бункерга йөгереп килә һәм ул чагында баш бетте дигән сүз. Киемнәр саклана торган урынга килгәч, беравык нәрсә сайларга белмичә икеләнеп тордык. Мондагы элгечләрдә костюмнар, ак һәм кара төстәге плащлар һәм тагын әллә ниләр тезелеп киткән; бер кырыйда күлмәк, аяк киемнәре тутырылган чемоданнар өелеп тора, махсус ясалган сәндерәләрдә эшләпәләр, башлыклар һәм фуражкалар урын алган. Берәр плащ, эшләпә сайлап алдык, костюм һәм аякка кияргә ботинканы да онытмадык. Артыгы безгә кирәк түгел. Хәер, аны алып та кая куясың. Озаклап торырга вакыт юк, чөнки полицайлар урамнарда төннәрен кизүлек итә, бункерларга күз салу ихтималы да бар. Бер кулга төргәк, икенче кулыбызга кечкенә чемоданнар тоткан килеш йөгереп чыктык та лагерь ягына ашыктык. Бөтен җирдә тынлык. Элек үткән олы юл янына якынлаштык. Ерактан нииндидер аваз ишетелде, машина тавышына охшаган. Менә ул һаман көчәя бара. Инде тәмам якын. Борылмадан пәйда булган ут тасмасы инде юл өстен капшый. Гриша белән дәррәү якындагы куаклык артына ташландык һәм җиргә сеңдек. Машина безнең турдан аз гына үтеп шып туктады. Сулышны кысып ятабыз, йөрәкнең тукылдавы колакларда ишетелә. Машина эченнән икәү чыктылар. Аларның берсе юл читенә басып кече йомышын йомышларга керешге, икенчесе моторда актарына башлады. Үзара мыдыр-мыдыр сөйләшәләр. Башны да күтәрергә куркып ятабыз. Ниһаять, «шап» та «шоп» машина ишекләре ябылганы ишетелде. Двигатель гүелдәп кабынды. Кузгалып киттеләр бугай. Инде бар да тынды кебек. Шулай булса да без һаман селкенмичә ятабыз. Берничә минут үткәннән соң гына аякка бастык һәм, өсләрне кагынып, юл аша чыгарга батырчылык иттек. Акрынлык белән атлыйбыз. Куркудан, һәр калкып һәм каралып торган нәрсә кеше сымандыр кебек тоела. Атлый торгач, лагерь киртәсенә җиттек. Җиргә ятып, озак кына ул-бу ишетелмиме дип тыңланып тордык — тынлык, лагерь йоклый иде. Бераздан, элек чыккан урыннан кабат лагерь территориясенә үттек. Берничә адым атларга да өлгермәдек, каршыбызга дүрт полицайның йөгереп килгәне күренде. Үзләре: «Стой», «Хальт», — дип кычкырыналар. Күзләрне чагылдырып, кулларындагы фонарь утларын безгә юнәлткәннәр. Мингерәйтелгәндәй басып торганда, ике урыс һәм ике немец полицае безне як-яктан чолгап та алдылар һәм лагерь комендатурасына алып киттеләр. Төргәк белән чемоданнарыбызны почмакка куеп, үзебезне тар гына бүлмәгә яптылар. Анда утырып та, ятып та

торырлык түгел, басып кына сыешлы. Төн буена аяк өсте торып, таңны чак аттырдык. Иртә белән «эт» оясыннан ачып чыгарып, лагерь-фюрер белән «дядя Коля» янына алып киттеләр. Башта: «Экзекуция булачак икән», дигән уй. Безгә бүре карашы белән карыйлар. «Әйберләрне каян алдыгыз?» — дип төпченәләр. Җавап бер: «Таптык».

— Лагерьдан чыгып кая бардыгыз? — Бусы чираттагы сорау.

— Кырдан аз булса да бәрәңге казып аласы килгән иде, — дибез.

Чыннан да, лагерьдан ерак түгел генә бәрәңге басуы булып, анда чыгып казынучыларны тоту очраклары булгалаган иде. Безгә ышанмаганнары күренеп тора. Шулай да без әйткәнебездән кире чигенмибез.

— Менә хәзер икегезне дә эскәмиягә сузып салып суктырачакбыз, телегез тиз язылыр, — диләр сорау алучылар. Миңа инде эскәмиягә ятып ике мәртәбә гумми тәмен татып карарга туры килгәне бар, аның нәрсә икәнен яхшы беләм. Лысенко полицайларга криминаль полициягә шалтыратырга куша. Аларның конторасы лагерьдан ерак түгел. Берничә полицейский машинада тиз арада килеп тә җитә. Күрше бүлмәгә үтеп, озаклап нидер турында киңәшләшәләр. Аннан чыккач, безне төн кундырган тар бүлмәгә кабат кертеп ябтылар. Берничә сәгатьтән ачып чыгарып, кабат сорау алган бинага алып киттеләр. Анда, гаҗәпләнүебезгә каршы, өлкән яшьтәге ниндидер биш немец каршына кертеп бастырдылар. Бөтенесе нәфрәтләнеп безгә карый. Лысенко хәлебезнең хөртилеген аңлата, юкка гына гаебегезне танымадыгыз, урланган чемоданнарыгызда бу әфәнделәрнең документлары табылган, алар инде бу турыда полициягә белдергәннәр, имеш. Полицейскийлар белән гражданский киемдәгеләр үзара нәрсә турындадыр гәпләшеп алдылар. Аннары хәрбиләр чыгып китте. Безне нишләп болар белән генә калдыруларын аңларга тырышып баш ваттык. Кулларыбызны кушырып бәйләделәр дә әмер бирделәр. Лагерьга алып кермәделәр, каядыр әлегә безгә билгесез тарафка алып киттеләр.

## Эт изгелеге

Озак барырга туры килмәде. Безнең лагерьдан ерак түгел тугызынчы номерлы гел немецлар гына яши торган лагерь бар иде. Аның ишегалдына алып керделәр. Бөтен җирдә чисталык, чәчәкләр үсә, биналар матурлап буялган. Подвалга, яшелчә складына алып төштеләр. Эт ияртkән янә бер немец пәйда булды. Без инде монда юкка гына алып килмәүләрен төшенгән идек. Башымнан: «Бетүебез шушы икән, эттән талатып үтермәкчеләр», — дигән уй чагылып үтте. Андый хәлләр еш була. Аларның кешеләрне таларга махсус өйрәткән этләре бар. Бигрәк тә урыс хәрби әсирләре белән мондый хәлләр еш кабатлана. Дәү генә бер эскәмия алып куйдылар. Инде кич якынлашып килә иде — ут яндырдылар. Әүвәлге итеп мине сайладылар. Кулларымны чишеп эскәмиягә яткырдылар да, аларны янә эскәмиянең аскы ягыннан чалыштырып бәйләп куйдылар. Аякларымны да бау белән чорнап куйдылар. Берсе, өстендәге киемнәрен салып, күлмәгенең җиңнәрен сызганды да, кулына резина шланг алып, шуның белән минем аркамнан түбән өлешемне каезларга кереште. Минем бу «эштә» инде бераз тәҗрибәм бар (ике тапкыр кыйналырга өлгергән идем), шуңа күрә аз гына хәйләсен дә беләм: суккан чакта гәүдәне катырмаска кирәк, югыйсә шланг катырак төшәчәк һәм авырту да көчлерәк булачак. Ә гәүдәне йомшак калдырганда — авырту да кимрәк. Җәзалаучы кулындагы җисем белән орган чакта үзенә үк санап та барырга кушалар. Әгәр «таяклар» санын буташтырасын икән, экзекуция яңабаштан башлана. Безне чиратлаштырып суктырдылар: мине — торгызалар, Гришаны яткыралар һәм киресенчә. Гришаны эскәмиягә

бәйләп салган чакта этнең хуҗасы: «Фас, фас русише швайне», — дип миңа өстерә. Гаҗәпләнүемә каршы, эт ырлап ташланса да, аскы өлешемне каплаган кулларымны җиңелчә генә кабып ала һәм бөтенләй дә авырттырып тешләми. Мин бу гаҗәп акыллы һәм юаш карашлы немец овчаркасының күзләрен мәңге онытмадым. Мондый хәлнең башка берәү белән берәр кайчан булганы булды микән? Уникаль очрак иде бу! Ул хәтта безне яткырып суктырганда да, кызганган кебек, чинап-чинап алды. Күрәсең, аның хуҗалары яхшы кешеләр булгандыр һәм этләренә дә яхшы тәрбия биргәннәрдер. Немецлар арасында да кешелекле затлар аз түгел иде бит, тик аларга башка милләтләргә карата уңай мөгамәләләрен күрсәтергә генә куркыныч иде. Хәер, болар нибары минем фаразларым гына.

## Тревога

Әйткәнемчә, эскәмиядә әле беребезне, әле икенчебезне салып суктыралар. Авыртуга түзәр чама юк. Аларның сөйләшкәннәреннән ишетеп калдым: яңадан илле гумми суктырмакчылар да туктамакчылар. Мине янә суктырдылар, чират Гришага җитте. Шулчак сирена улап җибәрде — һава тревогасы, союзниклар авиациясе һөҗүме. Алар үз тиреләре өчен шыр җибәрәләр иде. Тиз-тиз өсләренә киенергә керештеләр. Ә безгә бомба кая төшсә дә барыбер. Ишекләрне бикләп һәм безне подвалда калдырып, җәзалаучылар бомбоубежищега таба йөгерделәр. Һәм иртәнгә кадәр яныбызга беркем дә килеп карамады. Мин инде утырып тора алмый идем, төн буена тезләремә тезләнеп, күкрәгем белән эскәмиягә ятып чыктым. Алай иткәндә, тезләр авырта, ярый әле Гриша буш капчыклар табып, аларны минем аска җайлаштырып салды — тезләрне алмаш-тилмәш «эшкә» җиктем һәм шул миңа төнне уздырырга ярдәм итте. Гришаның хәле беркадәр җиңелрәк, чөнки ул миңа караганда илле таякка кимрәк суктырылган.

Эт иярткән немецтан башкалары иртә белән тагын подвалга әйләнеп кайттылар. Безне өскә алып чыктылар. Кояштан күзләр чагыла. Икебезнең дә муеннарга элмәкле бау ыргыттылар һәм бер-беребезгә якын китереп тарттырдылар. Сугымга алып барган мал кебек алып та киттеләр. Үзләре алдан да, арттан да атлыйлар. Мин бик сызлана идем, чак атлыйм. Шулчак арттан берсе китереп типмәсенме. Башым әйләнеп, аздан гына капланып төшмәдем. Ярый әле Гриша белән икебез бер бауга бәйләнгән — шул коткарып калды. Криминаль полиция якында булмаса, ничек барып житкән булыр идек, әйтүе кыен. Полиция бүлегендә камерага кертеп яптылар. Анда нарлар бар иде. Тик мин һаман ята алмыйм, подвалдагы тезләнеп тору халәтен сайларга туры килде. Үтереп эчәсе килә. Гриша ишекнең «күзе»нә якын килеп: «Су бирегез, су!» — дип кычкыра. Тукмап атмагайлары иде тагын дип шикләнеп торганда, шылтырап ишек ачылды. Ничек әле су бирергә уйлаганнар. Менә без кружкаларга чат ябыштык. Сусаган кешегә аның кадәр су нәрсә инде — мизгел эчендә эчеп тә бетердек. Шулай да бераз җиңел булып китте. Инде ашыйсы килә! Ни гомердән бирле авызга валчык та алган юк, эч аркага ябышкан шикелле. Кич белән берәр савыт баланда бирделәр.

Иртәнге якта камерадан чыгарып, бәдрәфкә алып киттеләр. Коридорда барган җирдән полицай туктатты да актарынырга кереште, бәдрәф ачкычы эзләве икән. Тапмагач, безгә баскан урыныбызда көтәргә кушып, дежуркага юнәлде. Коридорның аргы башындагы ачык ишектән кемнендер илереп кычкырган авазы ишетелде. Шундый авазны төнлә дә ишеткән идек. Гриша белән бер-беребезгә аптырап карашабыз. Кызыксынуыбыз көчлерәк булып чыкты — берникадәр алгарак атлап, ярымачык ишектән кабинет эченә күз

салдык һәм андагы кыргый күренешне күреп, тораташтай катып калдык: өстәл янында безгә яны белән хәрби киемдәге немец утыра, янәшәсендәге шул ук дәү өстәлгә берәү бәйләп куелган. Ул мескеннең куллары чылбыр белән уратылып, ниндидер тимер җайланмага электрелгән, ә читтәрәк, газ белән эшлиме, ниндидер ут яна. Бәхетсез җан әрнүгә түзә алмыйча бәргәләнә, чинап кычкыра һәм башын як-якка чайкый. Фашист палачы җайланманың түгәрәген боргалап, җәзаланучының кулларын беразга читкә алгандай итә дә кабат сорау алырга керешә. Үзенә кирәкле җавапны ишетмәгәч, янә бичараның бармакларын ут белән өтәли. Күңел болгаткыч көек исе, бүлмәгә генә сыешмыйча, коридорга да таралган. Тетрәнүебез шулхәтле көчле булган ки, полицайның яныбызга килеп басуын да сизмәгәнбез. Ул Гришаны сугып екканнан соң гына бераз исебезгә килдек. Надзиратель, немецка да нидер кычкырынып, ишекне япты да безне кабат камерага илтеп япты. Аннары безне допроска алып бардылар. «Карышудан мәгънә юк, бөтенесен ачыкладык», — диделәр сорау алучылар. Аларны инде әйберләрне кайдан алуыбыз кызыксындырмый һәм ошбу гамәлебезне урлашу дип бәяләгәннәр (урлашу немецларда каты җәзага тартыла) иде. Кием-салым һәм башка кирәк-яракны нинди максаттан чыгып чәлдерүебезне сорап тинтерәтәләр. Башыбызга тай типмәгән: иностраннарга сату өчен дип үзебезнекендә нык торабыз, чөнки планыбызны белгертсәк, качарга омтылган өчен иң каты җәзаларның берсенә дучар ителәчәгебезне чамалыйбыз. Шулай итеп безне караклык өчен хөкемгә тарттылар.

## «Ак доктор»

Криминаль полициядән теге чакта байтак лаеш шулпасын чөмерергә туры килгән егерме беренче номерлы штраф-лагерьга алып киттеләр. Анда китерү белән — мунчага. Чәчне кыркып, лагерь киемнәре: буй-буй ак полосалы, соры төстәге һәм аркасына «L — 21» дип язылган күлмәк, ыштан бирделәр; башка — козырёксыз түгәрәк башлык, аякка кияргә агач башмак китерделәр. Чишенеп, душ астына басарга дигән әмер яңгырады. Чәчләребезне алган һәм безнең белән идарә итүче кеше шәрә тәннәребезне күргәч «аһ» итте, чөнки анда күгәрмәгән-чиләнмәгән урын калмаган диярлек. Аз-маз коенгандай иткәч, авыртуга түзә алмаганлыктан, киенергә рөхсәт бирделәр. Чалбарларны кигән генә идек, ниндидер озын буйлы, аксыл чәчле кеше кереп, янә аларны салырга кушты һәм безне әйләндергәләп тикшерергә кереште. Күргәннәре аңа нык тәэсир итте булса кирәк, ул ике куллап башын тотты һәм: «Майн гот! Вас ист дас?» — дип сөйләнде. Тәрҗемәдә: «Йә Аллам! Йә Аллам! Нәрсә инде бу, ә?» — була инде ягъни. Аннары берәм-берәм яныбызга килеп, кыйналган урыннарга сак кына бармаклары белән баскалап карады. Гришага киенергә кушты. Чөнки ул зыянны миңа караганда кимрәк күргән, аның тәнендә чиләнеп торган урыннар юк. Ә минем белән озак мәш килде ул. Авырттырмаска тырышып яралы урынга баса да: «Авыртамы?» — дип сорый. Мин, сер бирмәскә тырышып: «Юк», — дигән булам, тешләремне кысам. Йомшак урыннан чак кына астарак аяк балтырына басуга, аннан шарлап канлы үлек агып чыкты (соңыннан анда гомерлек җөй калды). Аннары доктор мине лагерь лазаретына алып китте. Аны монда барлык ристаннар да үз итеп «Ак доктор» дип атыйлар икән. Лазаретта аңа капма-каршы тип «Кара доктор» да эшли. Анысы чытык чырайлы, усал карашлы. Лазарет башка бараклардан бер ягы белән дә аерылмый диярлек, шул читтә торуы белән булса гына инде. Монда күбесенчә дәваламыйлар, ә ристаннар өстендә төрле экспериментлар үткәрәләр, яңа төр даруларын сынап карыйлар. Аларны соңгы нәтиҗә бары уңай яки тискәре булуы белән генә кызыксындыра:

дәва-метод уңай чыкса — яхшы, кеше үлсә дә берни түгел, андый материал монда буа буарлык. Халыкара оешмалардан тикшерү комиссияләре килгәндә, алар лазаретта барсы да ал да гөл итеп күрсәтергә тырыша, әлбәттә, чөнки дөньякүләм зур гауга кубасын яхшы чамалыйлар.

Ак доктор, мунчадан алып чыккач, мине үзе артыннан ияртеп, лагерь капкасына таба алып китте. Сакчыларга авыру икәнлегемне әйтеп, тимерчыбыклы территориядән читтәге барак-лазаретка кертте. Ишектән якындагы ике ярусл нарның аскы катына күрсәтеп, урынымның шунда булуын аңлатты. Мондагы пациентлар милләтләре буенча аерылмый — төрле ил кешеләре. Икенче көнне ул мине үзенең эш һәм яши торган кабинеты ролен үтәүче бүлмәсенә алып китте. Бирәдәге инструмент вә дәвалау әсбапларының ярлы икәнлеген аңлата: баксаң-күрсәң, хәтта бинтлар да кәгазьдән; ятак хезмәтен үтәүче матрацларның тышлары шулай ук кәгазьдән булып, эчләренә пычкы чүбе тутырылган. Доктор миңа аягымның канга оешып каткан урынын кисеп алырга туры киләчәген, югыйсә анда гангрена башланачагын аңлата. Инструменты — кәкре кайчы. Авыртуга түзә алырмынмы? Бернинди иснәтә-йоклата торган сыекчалары юк иң. «Кирәк икән, нишләрсең, түзәргә туры килә инде», — дип ризалашуым аңа шөгыленә керешергә җирлек бирә.

Ул мине яткырмады, аягымда калдырып, җайлап кына, таш кебек каткан һәм сизү дәрәҗәсе дә нык кимегән «казалы» урынны түгәрәкләп кисә башлады. Баштагы мәлдә авыртуны сизмәдем, тик инде кайчы тимере сөяккә килеп төртелгәч, кыргый авыртудан кычкырып җибәреп, бер якка авып төштем. Доктор мине кушеткага яткырган һәм, күпмедер вакытка аңымны җуюымнан файдаланып, операцияне төгәлләгән: ачык урынга мамык тутырган. Күземне ачуга: «Ятып кына тор», — дип кинәшен бирде. Тагын бераздан аягыма бастырып, ярамны нindидер мазь белән сөрткәннән соң, кәгазь бинт белән бәйләп куйды. Мине хәлсезлек биләп алган иде, калтырата башлады. Доктор хәләтемне күреп тора: «Урыныңа барып житә аласыңмы?» — дип сорый. «Кайтып җитәм», — дим, нык булырга тырышып. Чак кайтып җиттем.

Икенче көнне яныма килеп бимазалаучы булмады. Янә бер көн узгач, Ак доктор дугаланып торган нindидер тартма белән керде, уртасында электролампалар, һәм алар тегү машинасының капкачын хәтерләтәләр. Доктор мине корсагыма яткырып, алып килгән җиһазын электр тогына кушты: лампочкалар гөлт итеп кабындылар. Шул көннән башлап табиб ярамны озаклап җылыта, каралып торган урын да акрынлап кечерәя башлады. Тәнемнен тиресе дә инде үзенең табигый халәтенә кереп бара.

Ак доктор сәяси тоткын икән. Ул миңа яхшы мөгамәләдә. Һәрчак, утны сүндергәч, ул безнең «палатага» кагылып китә. Бәдрәфкә барган булып, бер унайдан мине күрергә һәм газетага төрелгән ипи кисеген күкрәгемә куеп китәргә дә җай таба. Башымнан сыйпап куярга да онытмый. Мин: «Данке — рәхмәт», — дим, ә ул бармагын авыз турына китереп: «Тс-сс», — ди дә ары юнәлә. Икенче вакытта, бинтны алыштырырга баргач, доктор миңа сөйләшмәскә, бары кулларны кысышырга гына кирәклеген аңлатты. Мин инде алдарак тормыш юлымда күбесенчә яхшы кешеләр очрап торуы турында әйткән идем, бу чыннан да шулай. Хәлем тернәкләнүгә китте. Инде 1944 елның ахыры якынлаша. Табиб сугыш менә-менә бетәчәген әйтте. Мин илһамланудан һәм аңа тулысынча ышанудан: «Гитлер капут!» — дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым. Ул бармагын иренено тидереп, башын чайкады: «Саграк кылан», — диюе. Безнең дуслык көннән-көн ныгыды. Мине яшертен генә ашатуын дәвам итә, хәзер инде сәламәтлегем күзгә күренеп яхшырды. Ә Кара доктор нидер сизенә иде бугай: бүре карашы белән карый.

Ак доктор 1933 елда Берлин медицина институтының соңгы курсында укучы студент булган. Ул, Гитлер властька килгәч, демонстрацияләрдә катнашып, аңа каршы пропаганда алып барган. Шуның өчен кулга алып, төрмәгә япканнар үзен, аннары — концлагерьга. Соңрак егерме беренче штраф-лагерьга күчергәннәр. Кулга алынуына һәм ристан булуына инде унбер ел тулган. Ул мине озак дәвалады. Гестапо һәм полиция әһелләре хәтта ни өчен минем лазаретта озак тоткарлануым белән кызыксына башлаганнар. Доктор эксперимент алып баруы белән акланган. Аның бүлегендә ятучыларның байтагының хәле яхшыра, ә Кара докторныкында киресенчә — начарая, ул яктан еш кына авыру тоткыннарның илереп кычкырган авазлары да ишетелә, күпләрне носилкаларга салып алып чыгалар. Минем ярам инде төзәлеп бетә язды, бер тиен акча зурлыгында гына калып, андагы тире кызарып тора. Анысы да нокта гына булып калгач, ул урынга мазь сөртеп, пластырь ябыштырды коткаручым. «Мин сине, тикшерүче комиссия килгәнче, бер ун көнләп үземнең янда тота алам, аннары безгә аерылырга туры килер, Ханниполь», — ди изге җанлы кеше. Ул мине шулай якын күреп «Ханниполь» дип йөртә иде. Бинтны алыштырырга кергәч, ул яхшылап ишекне яба һәм без кайда ым, кайда сүз белән аңлашырга-сөйләшергә тырышабыз. Ул нацистларның алып барган сәясәте ахыр чиктә Алманиянең тар-мар ителүенә китерүен, сугышның кешелек өчен гаять начар нәрсә икәнлеген аңлата, минем белән очрашуына шат икәнлеген әйтә. Әйе, ярый әле бәхетемә язмыш мине Кара доктор белән түгел, аның белән очраштырды, киресенчә булса, мин бу якты дөньяда исән калыр идемме-юкмы, анысы — караңгы.

Беркөнне Ак доктор тикшерүчеләр киләчәген, мине лагерьга чыгарырга туры киләчәген әйтте. Икенче көнне иртән мине плацка үзе озата барды. Анда инде бөтен лагерь ристаннары тезелеп баскан, номерлап барлау башланып киткән. Доктор мине таза гына гәүдәле, тик шундый ук ристан булган бер немецка илтеп тапшырды. Немец барлауны тикшерүче икән, аның хәле, әлбәттә инде, башкаларныкыннан яхшырак. Киткәндә, коткаручы-фәрештәм миңа күз кысып алырга да җай тапты.

Мине кабул итеп алучыга «доктор әфәнде» дип эндәшәләр. Тоткын кеше дә әфәнде була микәнни соң? Ул миңа: «Шунда гына тор», — дип, баскан урынымда калырга кушты. Аның төркемнәрне төрле җиргә эшкә җибәрүен күтәм, ашыгыр сәбәбем юк. Шулчак карт кына чырайлы, башына каурыйлы эшләпә кигән өлкән яшьтәге немец килгәне күренде. Ул эш бүлүче доктор белән нидер сөйләшеп алды. Аннары алар миңа карап та әңгәмә корып алдылар. Мин өлкән яшьтәгенең: «О, дикен, дикен», — дип сөйләнүен ишеттем. Бу — аның канәгать булуын күрсәтүче билге. Әлбәттә инде, Ак докторның тырышлыгы нәтиҗәсендә, гомуми режимда тотылучыларга караганда, минем килеш-килбәтем күпкә отышлырак иде. Ошбу немец мине үзенә ияртеп, ерак та түгел торган машинага таба алып китте. Аның әрҗәсендә берничә тоткын урын алган, шунда ук автоматлы сакчы да бар. Эш бүлүче: «Найн!» — дип, мине аралап калырга уйлады бугай, тик теге картлач тыңларга да теләмәде, машина әрҗәсенә күтәрелергә әмер бирде. Һәм безне бункер төзелешенә алып киттеләр. Минем бункерлар төзү буенча «бәхет» бар да соң!

Төзелеш мәйданчыгыннан дүрт-биш йөз адым чамасы ераклыкта бетон болгаткыч урнашкан. Аннан измә бетон тутырылган вагонетканы рельслар буенча этеп барышлы. Анысы бер нәрсә — йөкне эткәндә, чак кына калкулыкка күтәреләсе. Ә немец арттан камчысы белән сыдыра-сыдыра безне атлардан битәр каһәрләп куалый. Шуңа күрә без — ристаннар — аны үзара «канэчкеч» дип атадык. Аның улы кайдадыр Көнчыгыш фронтта үтерелгән, диләр. Андый немецлар байтак: кемнеңдер малае, кемнеңдер энесе яисә туганы һәлак булган,

ә кемдер исә сугыштан гарипләнеп кайткан. Әгәр андыйларга туры килсәң, сине алда ифрат зур күңелсезлекләр көтә. Бу ерткыч өч атна эчендә безне коры сөяккә калдырды, скелетка әйләнгән гәүдәләребезне чак сөйрәп йөртәбез. Ул кешене шундый хәлгә житкергәч, яңа команда жыя икән. Бәхетсезлегемә күрә, мин шушы фашистка туры килгән идем. Доктор миннән, бөтен тырышлыгын куеп, Кеше ясаган булса, әлеге адәм актыгы өч атна эчендә аяклы скелетка калдырды.

Аннан соң мина металлургия заводы территориясендә алюминий плитәләр ташу белән шөгыльләнүче төркемдә эшләргә туры килде. Плитәләрне әле кайнар килеш вагонеткаларда завод эченнән чыгарып жиргә аударалар, ә без аларны берәмтекләп читкә ташыйбыз һәм штабельгә өябез. Еш кына, өеп куюыбызга, надзиратель килә дә аягы белән плитәләрне тибеп аудара. Аңа өемнең торышы ошамаган икән — яңадан тәртипкә китерергә куша. Кайнар плитәләрне яланкул тотканлыктан, көн дәвамында уч төпләре пешеп кабара. Ярый әле алар авыр түгел, кабыклы бәрәңге кебек бер кулдан икенчесенә сикертү мөмкинлеге бар, алай итмәгәндә, мондый әҗәлгә тиң эшне башкарып чыгып булмас иде. Эшләгәнне күзәтеп торучы надзиратель юк кына гаеп өчен кыйнап ташларга да күп сорамый. Сакчылар аның резин тукмак белән ристаннарны тәпәләвен күреп көләләр генә. Кайчагында завод эченнән яңа өлгертелгән продукция чыгару туктала тора. Фашистлар андый чакта да безне тик тотмыйлар, мәсхәрәләп, кичә өелгән штабельләрне бер урыннан икенче урынга ташырга мәжбүр итәләр. Үзләре туктаусыз: «Рус швайне, шнель!» — дип ашыктыралар. Кол хәлендә булганлыктан, барлык түбәнсетүләргә дә тешне кысып түзәргә туры килә.

Мин башкаларга мондагы тәртипләрнең адәм баласы түзәлмаслыгы турында әйткәч, кайберәүләрдән, ике венгр саклап эшләтүче янә бер төркем барлыгын, андагы шартларның тагын да «кәттәрәк» икәнлеген ишетеп белдем. Алар сөйләвенчә, бертуган венгрлар кул астындагы команда гравий карьерына эшкә йөри ди һәм аларның ерткычлыгына чик-чама юк, имеш. Чак кына тыңламасаң яки, телләрен аңламыйча, башкача эшләсәң, тегеләрдән берсе, кешене читкәрәк җибәреп, качарга теләде дигән сылтау белән бичараны атып үтерә ди. Менә шундый хәлләр. Штраф-лагерьда кая да булса чыгып йөрергә рөхсәт ителми, эшкә бару-кайтуны һәм параша савытын барак буенча билгеләнгән ике дежурныйның чыгарып түгүен санамаганда, әлбәттә. Параша савыты ике тоткасыннан ике кеше күтәрергә исәпләнгән һәм аларны һәркөнне иртән барак капосы билгеләгән кизү торучылар чыгарып түгә. Бүтән төрле чыгып йөрүләр булса, манарада торучы сакчылар төбәп ут ача. Мин лазареттан чыгуга, ничек кенә Гриша белән очрашып сөйләшергә икән дип баш вата башладым, чөнки башка баракларга керү катгый тыелган бит. Шуның өчен үземнең чиратымда гына түгел, еш кына башкаларныкында да алардан сорап кизүлек итәргә алына идем. Капо: «Сина нәрсә, сасы исне иснәү ошыймыни? Менә исәр!» — дип шаркылдап көлә.

Параша савытын алып барганда, еш кына абынам, чөнки таныш йөз күренмәсме дип, күзләрем белән барак тәрәзәләрен капшыйм. Кулдашым ризасызлык белдереп чәпчи, чөнки аңа минем «илтифатсызлыгым» уңайсызлык тудыра. Шулай да мин аны күрә алмадым. Кайчагында, аңа охшатып, тәрәзәгә якын урында туктап калам, агач башмагымны жайлап кигән атлы кыланам, ә үзем: «Гриша, Гриша!» — дип кычкырам. Кем дә булса ишетеп, тәрәзәгә килә. Тик юк, Гриша түгел. Мин ары китәм, тәрәзә катына килгән кеше гажәпләнеп жилкәсен сикертә һәм шулай ук китәргә ашыга, чөнки мондагы тәртипләр буенча тәрәзә каршында басып торырга ярамый.

Шулай итеп, мин Гришаны очрата алмадым. Бик гаярь егет иде, берәр төрле бәхетсезлеккә генә очрамасын инде. Моңа карап өметемне өзмәдем, Аллаһ насыйп итсә, очрашырбыз әле дип уйладым...

## Күмү командасында...

Безне эшкә йөртә торган металлургия комбинатын союзниклар авиациясенен бомбага тотулары ешайды. Бигрәк тә төннәрен. Немецларның кулына корал тота алырдай ир-ат халкы сугышта булганлыктан, иртәнге тикшерү вакытында еш кына кемнең нинди һөнәргә ия икәнлеге белән кызыксына башладылар. Кайбер әсирләр, шул исәптән СССРдан да, эшкә барырга ризалаштылар. Тик нәрсә генә эшләсәләр яисә төзәтсәләр дә, бар да артларыннан ук ишелә-җимерелә иде. Шуннан соң урысларны эштән читләштерделәр, чөнки аларның махсус зыян китергәнен аңлап алганнар иде. Шулай да ниндидер эшләр өчен яна төркем тупладылар. Безнең барактан ун кешене сайлап алып, читкәрәк барып басарга куштылар. Бастык та көтәбез шулай. Төркем туплаучылар ары китте. Әүвәл ун кеше һәм тагын бераздан янә бишне безнең төркемгә китереп куштылар — егерме биш булдык. Немецлар номерларыбызны һәм фамилияләребезне язып алдылар, аларны безнең исемнәр гомумән кызыксындырмый, алар өчен ул юк. Ә без бер-беребезне күбрәк фамилияләп түгел, исемләп беләбез, чөнки үзара исем белән дәшеп аралашабыз.

Безгә: «Сезнең команда фриедгоф дип аталачак», — дип беллерәләр. Әлеге сүзнең нәрсә аңлатканын иртәнге якта «фриедгоф» дип кычкырып, барыбызны бергә җыйганнан соң һәм янәшәсендә кечкенә калкулыклар өелеп торган чокырлар янына куып китергәннән соң гына аңладык. Хәер, беренче мәлдә әле куркуга калдык, шушы каберстаннан котылу юк икән дип уйладык. Ерак та түгел янкорылмалар белән төзелгән йорт тора. Шунда алып киттеләр. Йорт эченнән берәү (каравылчыдыр инде) чыкты һәм, үзенә ияртеп сарай сыман җиргә алып китте. Бер почмакта өелеп торучы көрәкләргә күрсәтеп, шуннан ошаганын сайлап алырга кушты. Көрәкләр кулда, инде кабер казырга кушалар. Бернинди кабер ташлары да, чардуганнар да юк, шулай булса да «фриедгоф» — зират дип атала. Төркемнең яртысын бирге башта калдырдылар, ә яртысын арырак — кечкенә урман артына алып киттеләр. Җир йомшак икән, көрәк туфракка җинел бата, шуңа казуы да авыр түгел.

Өйлә турына берничә чокырны казып та өлгерттек. Алар, әлбәттә, галәти кабергә ни формасы, ни тирәнлеге белән якын да килмәгән. Шулчак машина моторының гөрелтесе ишетелде һәм янәшәдә генә бер җинел һәм бер йөк машинасы килеп туктады. Җинел машинадан офицер формасындагы фриц чыгып, сакчылар белән нәрсә турындадыр сөйләшеп алды. Безгә йөк машинасына барырга куштылар. Аның әрҗәсенә аннан-моннан тупас такталардан сугып әмәлләгән алты әрҗә урнаштырылган, шуларны алып, казылган чокырлар янына илтергә боердылар. Әрҗәләрне күтәрә башлауга ук зур ярыклардан кан агып чыкты — аларда газаплап үтерелгән кешеләрнең гәүдәләре ята иде. Әрҗәләр өстенә калай номерлар сугылган. Бичараларны күчерәбез, аякларыбыз чак атлый. Мескенкәйләрне кызганудан тамак төбенә төер, күзгә яшь килеп бөялә. «Кемнәр һәм кайлардан сез?» — дигән сорау җанга тынгылык бирми. Бернәрсә аермачык — болар фашизм корбаннары, һәм фашизмның ерткычлары Кешелек тарафыннан беркайчан гафу ителмәячәк!

Беренче әрҗәне чокыр янәшәсенә китереп куйдык. Аны чокырга өч-дүрт кеше төшеп кешечә аска куярга рөхсәт юк — фашистлар ашыктыралар, әрҗәләрне бер-бер артлы ыргытырга боералар. Шулай эшләргә туры килде.

Әржәләрне берсе өстенә икенчесен ыргытканда, алардан «гык» иткән аваз ишетелә. Күрәсең, мәетләр бер-берсенә бәрелүдән шундый тавыш килә. Бу коточкыч иде. Мин әле һаман ул көннәрне оныта алмыйм. Көн дәвамында дүрт кабер-чокырны күмдек. Иртәгесе көн өчен янә берничәне казыттылар. Аннары безнең төркемне җәяүләп кенә лагерьга алып киттеләр. Икенче төркем инде күптән баракта икән, чөнки аларны машиналарда кайтарганнар. Сирена улагач, плацка куып чыгаргannарын көтәләр. Безне баланда өләшә торган жиргә китереп, тиешле порциябезне бирделәр. Тик карын ач булса да, ашап булмый, күз алдында теге әржәләр тора. Башка иптәшләр: «Әллә сез тукмы, нигә ашамыйсыз?» — дип гаҗәпләнү белдерәләр. Эшнең нәрсәдә икәнен сөйләп биргәч, барсы тынып кала, кайберәүләрнең күзендә яшь елтырый.

Сирена улый башлады, без чыгу ягына ташландык. Анда гадәттәгечә ике әзмәвер резин тәпәчләр белән уңлы-суллы тукмап чыгаралар. Һәм бу хәл көн саен кабатлана. Көн саен: «Митце ап — башлыкларны салырга, кияргә!»; «Лиеген — ауфштейн — ятарга, торырга!»; «Айн, цвай, минкс — раз, два, левой!» һ.б. әмерләр яңгырый. Агач башмаклар шакылдавыннан колак тондыргыч тавыш хасил була. Плацтагы мондый «күнегүләр» төнге уникегә, ә кайчагында сәгать бергә кадәр дәвам итә, иртәнге биштә кабат тревога белән күтәрәләр. Тик ул төнне, зираттан соң, бөтенләй йоклап булмады: күз алдына билгесез кешеләрнең имгәтелгән гәүдәләре килә дә баса.

Икенче көнне дә шул ук хәл кабатланды. Бусында инде тугыз әржә алып килделәр. Ифрат нык арылса да, бу төнне керфек тә какмыйча чыктым. Нәрсә эшләргә соң? Болай дәвам итсә, акылдан язарга да озак түгел ич. Калагымны алдым да таңга кадәр шуның белән уң кулымның арткы өлешен төеп чыктым. Ул урын күзгә ташланырлык булып кабарып чыкты. Иртән ярамны эшкә билгеләүче докторга күрсәттем. Ул карады да кулын гына селтәде: әллә «көтеп тор», әллә «әй сәнә» дию. Мин төркемнең иң очында басып торам. Карасам, минем коткаручым — Ак доктор килә. Мин инәлеп аңа текәлдем, кулымны күрсәтмәкче булам, тик ул, әллә ара ерак булганлыктан, янымнан абайламыйча узды һәм эшкә билгеләүче доктор янына килеп, нәрсә турындадыр сөйләшә башлады. Тегесе әйтте булса кирәк, ниһаять, Ак доктор минем яныма килде. Ул шулкадәр гади һәм ягымлы иде ки, әйтерсең, аннан нурлар чәчелеп тора, әйтерсең, ул әле кичә генә минем белән аерылган. Кулымны карады да: «О-о-о», — дип гаҗәпләнүен белдерде. Коллегасы янына барып нидер әйтте дә миңа үзе артыннан иярергә кушты. Һәм шулай итеп ул мине лазаретка алып кайтты. Миңа шул гына кирәк тә, үземне күкнең җиденче катындагы кебек хис иттем. Кабинетына алып кергәч, доктор ярамны җентекләп тикшерергә кереште. «Нәрсә булды соң?» — дип сораштыра үзе. Мин аңа: «Калак бирегез», — дим. Ул елмаеп: «Аш юк», — ди. Шулай да калак бирә. Мин аңа төнозын ни рәвешле кул артымны төеп чыгуымны күрсәтәм. Ул: «Ханниполь, ой, Ханниполь», — дип сөйләнә-сөйләнә, бик озаклап көлде. Нindидер мазь сөртеп, кәгазь бинт белән урап куйгач, ак чүпрәк чыгарды да кулымны шул чүпрәк белән муеныма асып та куйды. Бусы травма алганымны күрсәтү өчен инде ягъни. Шулай итеп мин коточкыч кабер казучы вазифасыннан котылдым. Теге егетләр белән нәрсә икән инде анда? Алар исәннәрдерме? Мин аларны башкача очратмадым.

Кулымдагы шеш кайткannан соң, мине лазареттан чыгардылар. Ак доктор мине лагерьга алып китте. Лагерь халкы плацка иртәнге тезелүгә чыгып баскан иде. Эшкә билгеләүче янында калдырганнан соң, Коткаручым китеп барды. Эш бүлүче нигәдер минем штраф-лагерьга ничәнче мәртәбә эләгүем белән кызыксынды. «Өч», — дип җавап бирдем. Ул миңа бер читтә торган зур булмаган төркемгә барып басарга кушты, аңа кадәр муеныма тагылган

калайдагы номерымны дәфтәр битенә язып алырга да онытмады. Төркемдә егерме биш кеше туплагач, безне лагерь капкасына таба алып киттеләр. Брауншвейг каласына алып барасылар икән. Капканың теге ягында сакчылар белән машина көтеп тора. Кузгалдык. Инде көннәр сизелерлек суыткан. Урта урынга эләккәннәргә җылырак, кырыйдагылар җылынырга тырышып, уртадагыларга елыша. Сакчыларның урыны шофёр янәшәсендә. Алар үзара сөйләшеп, шаркылдап көлешәләр. Арадан берсе кесәсеннән авыз гармуны чыгарып,ниндидер күңелле марш уйнарга кереште, башкалары карлыккан тавыш белән җыр суздылар. Аларга күңелле. Ә безгә салкын, һәм, ач булсак та, үтереп йокыга тарта. Озак барырга туры килмәде: штраф-лагерьдан Брауншвейгка кадәр ара унсигез километрдан ары түгел икән.

## Юллар чистартуда...

Шәһәргә кердек. Союзниклар авиациясенең бомбага тотуларыннан күп йортлар җимерелгән. Безне зур һәм күпкатлы бина янына китереп туктаттылар. Аның тәрәзә пыялалары коелып беткән, димәк, ул янган.

Йортның түбәсендә очып китәргә әзерләнгән шикелле, аякларын өскә күтәреп, аягүрә баскан берничә ат скульптурасы урын алган. Йортка кертеп, безне подвалга алып төштеләр. Бөтен стеналары бетоннан коелган бүлеккә керттеләр. Монда ике катлы нарлар тезелеп киткән, уртада — тимер мич, ә мичтән торба бер як стенага тоташкан, бусы төтен юлы була торгандыр инде. Икенче стенада кечкенә тимер рәшәткәле тәрәзә шәйләнә, ул тышкы якта җир белән бер биеклектә. Әгәр анда кем дә булса үтсә, аның аяклары гына күренә.

Безне шушы подвалда тоттылар. Анда юеш һәм салкын. Юллар чистартырга, бомба җимергән биналарны җимерекләрдән арчырга йөрттеләр. Кайчагында брикет ташкүмер бушатырга алып баралар. Төнгә өстебездән бикләп калдыралар. Иртән Юни атлы латыш егете ачып чыгара. Күзлек кигән, интеллигент кыяфәтле, болай кешелекле дә күренә үзе, урысчасы да ярыйсы гына. Аны өлкән яшьтәге бер немец саклап һәм озатып йөри. Юнидан ни өчен немецларга хезмәткә килүе белән кызыксынабыз. Латвияне фашистлар оккупацияләгәч, ирексезләп мобилизацияләгәннәр икән. Күз күрүе начар булгач, строевойга яраксыз дип тапканнар һәм менә безнең кебекләрне саклап-күзәтеп йөрергә куйганнар.

Ошбу йортта сугышка кадәр булачак фашист-гитлерюгендчыларны тәрбияләүче мәктәп урнашкан, диләр. Берникадәр вакыттан соң безне ни сәбәпледер шушы ук бинаның башка, тагын да тирәндәрәк урнашкан подвалына күчерделәр. Монда инде көн яктысы да үтеп керми, урамга да беренче кат аша чыгышлы, һәм ул беренче катка күп итеп прессланган тюклы печән кертеп тутырганнар. Ансын бомба ударын күпмедер йомшарту өчен дип әйткән булалар, тик, ай-һай, алай микән.

Бина янына өзлексез дип әйтерлек «СС» формасы кигән танкистлар, очучылар килеп тора. Юл чистартканда, кайчагында машинадан кулларына богау салынган хәрбиләрне төшереп, эчкә алып кереп киткәннәрен күрәбез. Юнидан аларның кем булуы турында кызыксынабыз. Ул як-ягына каранып алганнан соң, «белмим» дигән мәгънәдә җилкәләрен сикертеп куйды. Ул, әлбәттә, белә иде, тик әйтергә генә курка. Безнең белән Сенька Бакиров атлы егет бар. Аны һәрчак балта остасы бер немецка булышырга җибәрәләр. Алар икәү пыялалау, ишек төзәтү һәм башка ремонт эшләренә йөриләр. Әлеге немец, Сенька әйтүенчә, аңа яхшы мөгамәләдә икән. «Икенче кат коридоры буенча

барабыз шулай, — дип сөйләде Сенька, — ә каршыбызга ике офицерны алып киләләр, куллары богаулы. Күрәбез: ачып куелган ишектән башта хәрбиләрнең берсен, аннары икенчесен кертәләр. Коридор буйлап үткәндә, ишектән эчкә күз салсак, андагы бүлмә стенасын инләп кара материя эленгән һәм анда зур булмаган Гитлер портреты тора. Портрет астында карадан киенгән берничә кеше утыра. Ул тирәдән ары киткәч, мин немецтан моның нәрсә булуы турында кызыксындым. Ул кыскача гына итеп моның хәрби трибунал икәнлеген һәм Гитлерга һөҗүм оештыруга бәйле кешеләрне хөкем итүләрен аңлатты».

## Немец Раштуасы

Без еш кына бөкрәя төшкән озын гәүдәле, күкрәгенә тәре таккан бер офицерның бинага кереп йөргәнен күрә идек. 1944 елның декабрендә шундый бер эпизод булып алды. Декабрьдә немецлар Раштуаларын билгеләп үтәләр. Әлбәттә, бу турыда белмибез, чөнки безне атеизм рухында тәрбияләп үстерделәр. Инде йоклый идек (штраф-лагерьдан аермалы буларак, биредә азмы-күпме ял итәргә мөмкинлек бар). Шулчак йозак шалтыраганы һәм ишекнең шыгырдап ачылуы ишетелде. Юни, аның артыннан безнең телдә «Кащей» дип аталучы (Юниныозатып йөрүче һәм саклаучы) немец һәм теге тәреле офицер килеп керде. Без инде офицерның хәрби трибуналда җанкыяр булып хезмәт иткәнен белә идек. Керүчеләрнең бераз төшереп алганлыклары да сизелә, үзләре елмайгандай итенәләр, «курыкмагыз», дигән булалар. Ике батон, ике кап маргарин тартып чыгардылар. «Бүген безнең бәйрәм, сезнең өчен сюрприз ясыйбыз», — дип, ашамлыкларны өстәл хезмәтен үтәүче лавка өстенә куйдылар. «Ә хәзер, әйдәгез, җырлагыз, — ди офицер. — Поляклар, урыслар, французлар, голландлар ничек җырлыйлар икән, шуны ишетәсебез килә. Әйдәгез, кем беренче?»

Беркем берни дәшми. Төкрекләрне йотып, икмәккә карап утырабыз. Бүлә башласаң, йөзәр граммнан артмаса да, штраф-лагерьның чөгендер кушып пешерелгән ярым чи ипие түгел шул инде бу. Офицер көтә. Юни белән Кащей да дәшми. Көтеп-көтеп тә җавап ала алмагачтыр инде, офицер акырып җибәрде. Сискәнеп киттек, тик һаман тынычлык саклыйбыз. Безнең хәл монда җырлап утырырлык димени соң?! Шулчак арадан берәү, кыяфәте белән чегәнгә охшаган (шуның өчендер инде аны үзара чегән дип кенә атыйлар), алгарак чыгып җыр сузмасынмы:

Өзелеп сөйгәнем минем
Әкияти йортта яши.
Чит-ятларга ул беркайчан
Ишеген киереп ачмый...

Аның җырлавын офицер ошатып: «Гут, гут», — дип сөйләнде. Аннары поляк җырлады. «Польша әле бетмәде», — иде аның җырларының төп мәгънәсе. Французның ни турында җырлавын беркем дә аңламады кебек. Озын, какча гәүдәле голландияле үз телендә җыр сузганнан соң, урысча җырларга теләге барлыгын белгертте. Аның каян килеп урысча белүенә гаҗәпләндек. Һәм ул арада голландияле:

Курва дисәләр диярләр,
Бу паровозны барыбер онытмыйм.
Чечебрике, брикечеге,
Чөнки ул минем борынны канатты.

Бөтенебез көлештек. Ә офицер: «Вас ист дас? Нәрсә ди ул?» — дип кызыксынды. Юни тәржемә иткәч, немец шулай ук елмаймагандай итте. Ниһаять, алар китеп бардылар. Без икмәкне бүлешә башладык. Әкияттәге кебек килеп чыкты — бал эчтек, ирен чыланды, авызга гына эләкмәде.

## Чишелеш

1945 елга кердек. Алманиянең соңгы көннәре якынлашты. Без тиздән ирек якынлашканын сизәбез, шуңа да күңелләр күтәренке. Март аеның бер иртәсендә безгә янә бер батон алып керделәр. Гадәттә, бүлү эше белән шөгыльләнүче Семён Бакиров: «Мин егерме кешегә моны ничек бүлергә икәнен белмим», — дип, бүлүдән баш тартты. Беркем дә алынмый. Утырабыз шулай. Юни белән Кащей килделәр: «Чыгыгыз», — диләр. Селкенүче юк. Юни: «Егетләр, әйдәгез, анда эш бар. Бөкренең әмере шундый, югыйсә, начар булачак бит», — дип тә карый. Һаман да утыра бирәбез. Алар чыгып, өстебездән бикләп китеп баралар. Күпме утырганбыздыр, коридорда аяк тавышлары һәм кеше авазлары ишетелде. Ишек ачылып, резин таяклар белән коралланган биш солдат килеп керде һәм безне тукмап, урамга куалый башладылар. Урамда инде Бөкре көтеп тора иде. Аннары бөтенебезне яңа җәелгән асфальтны трамбовкалаучы, барабанга охшаш каток янына алып киттеләр. Арадан биш кешене аерып алып, катоктан сузган бауга җиктеләр һәм бөкре аларны кулындагы камчысы белән кыйный-кыйный, катокны ары-бире тартырга мәжбүр итте. Кырыйга чыгып та, качып та булмый, чөнки алар үзара бәйләнгән. Киреләнеп торсаң, атарга да мөмкиннәр. Шул рәвешле, егерме кешене икешәр сәгать дәвамында партияләп җигеп эшләттеләр. Бу хәл кичкә кадәр дәвам итте. Кабахәт Бөкре кешеләрне җәфалаудан ямь тапты. Ул шулай итеп безнең тыңламауның үчен ала иде.

Асфальт тигезләүдә бер ай чамасы эшләдек. Һәм менә апрель башларында безне алырга полициядән килделәр. Барыбызны йөк машинасына утыртып, шәһәргә алып киттеләр. Анда зур гына төрмә, лагерь түгел, нәкъ менә төрмә. Төрмә камераларына бүлгәләп тараттылар. Камералар озын коридор буенча ике яклап тезелеп киткән һәм алар төрле зурлыкта. Арада ялгыз камералар да бар. Безне урнаштырган камера ун кешегә исәпләнгән. Егерме кешелек төркемебезне шундый ике камерага бүлеп керттеләр. Монда бөтен стеналар төрле телдәге язулар белән чуарланган. Кешеләр исемнәрен сырлап, кайсы вакытта булуларын язып калдырырга тырышканнар. Латин шрифтындагылар күп. Һәм кинәт урыс телендә: «Кем монда булмады — булыр, ә булган кеше — мәңге онытмас», — дигән язуны күрәм. Астында Чумаченко фамилиясе тора. Дулкынланудан йөрәгем ярсып тибәргә кереште. Ә, бәлки, бу минем дустым Гриша Чумаченкодыр? Фамилиясен куйган, ә исемен — юк. Нигә исемен язмады икән? Шундый фамилиядәге башка берәү түгелме? Минем дулкынлануымны Сенька Бакиров күреп калган һәм сорау бирә: «Нәрсә булды сиңа? Чыраең качкан», — ди. Мин аңа Гришаның кем булуын, аның белән план коруыбыз, качмакчы булуыбыз һәм әләгүебезне, безне кыйнауларын, аннан соң үземнең лазаретка әләгүемне сөйләп бирәм. Лазареттан чыккач, Гриша белән башка очраша алмавыбыз турында әйтәм.

Безне камераларда ике көн тотканнан соң, кабат егерме беренче номерлы штраф-лагерьга җибәрделәр. Килеп җиткән хәбәрләргә караганда, совет гаскәрләре Алманиянең көнчыгыш өлешенә басып кергән инде, ә англо-американнар көнбатыштан кереп киләләр.

Штраф-лагерьда инде бер айлап булуга карамастан, Ак докторны күргән юк әле. Апрельнең унбишләре тирәсе булды микән, төнлә сирена уларга

кереште. Бөтен кеше плацка йөгереп чыкты. Плац кораллы солдатлар белән тулган. Әсирләрне баракларга куалап кертә башладылар. Сайлап тору-ниту юк, әүвәл беренче баракны шыплап тутырдылар, кулны да селкетерлек түгел. Пулемётлардан атып, гранаталар ташлап яки, гомумән, терелэй яндырып үтерәчәкләр икән дигән хәбәр таралды. Кемнәрнендер борын тартып мышкылдаганы ишетелә. Аларны да аңларга була — кемнең үләсе килсен, менә-менә сугыш тәмамланырга тора, ә монда шундый хәл. Шулчак урысчалап кайсыныңдыр: «Иптәшләр, паникага бирелмәгез, минем киңәшкә колак салыгыз. Мәгълүм булганча, безнең барыбызны да урман буйлап тимер юлга алып барачаклар. Урман ягына качарга уйламагыз, анда солдатлар куелган. Юлдан читкә чыгучыларга атачаклар. Сугыш тәмамланырга күп калмады инде, үләргә кирәкми, иреккә чыгу вакыты да кул сузымында гына», — дип әйткәне ишетелде. Караңгы булганлыктан, кемнең сөйләвен аерырлык түгел. Хәер, ул үзе дә күренергә теләми иде бугай. Чыннан да, безне чыгарып колонналарга тезделәр һәм алып та киттеләр. Ләкин кайберәүләр, әллә әйткәнгә ышанмыйча, әллә аңламыйча, юлдан чыгып урманга керделәр. Аннан автомат чиратлары, әрнеп кычкырган авазлар ишетелде.

Тимер юлга алып килделәр. Анда өсте ачык вагоннардан состав тора. Шыгрым тулганчы безне аларга тутырдылар. Почмакларда — махсус урыннарда — автоматчылар урнашкан. Яңгыр ява башлады. Башлар чыланып, су җилкәләрдән агып төшә, ә яңгыр туктарга уйламый да. Без бер-беребезгә терәлеп басып торабыз. Һаман саен ныграк чыланабыз. Ниһаять, состав кузгалды. Тик ул бераз бара да туктый. Шулай итеп, туктала-туктала, төн буе бардык. Баруга караганда туктаулар күбрәк булды. Сөякләргә кадәр суык үтте. Ярый әле анда климат йомшак, хәтта кыш көне дә чагыштырмача җылырак.

Таң атып килгәндә, без ниндидер шәһәргә якынлаштык, әмма состав станциягә житмичә туктап калды. Безнең өстән пар күтәрелә. Ниһаять, состав кузгалып, станциягә кадәр араны үтте. Автоматчылар вагоннардан сикерешеп төштеләр. Без ач, өсләр юеш, өстәвенә, төн буе йокламаган. Күпләр аягүрә баскан килеш башларын күршесенең җилкәсенә салып йокыга чумган.

Сакчы солдатларның дәшми-тынмый гына состав тирәли ары-бире йөргәннәре күренә. Тик нигәдер алар һаман саен азая баралар. Һәм бервакыт состав янында аларның берсе дә калмады. Вагонның борт кырында басып торганнар берәм-берәм җиргә сикерешеп төшә башлады. Аларга кычкыручы да, атучы да күренми. Моны күреп, барыбыз дәррәү вагоннардан тышка атылдык. Басып торабыз шулай, бер-беребезгә гаҗәпләнеп карашып, җилкәләрне сикертәбез, беркем бернәрсә аңламый. Акрынлап составтан читкә китә башладык — тавыш-тын юк. Югыйсә, кагыйдә буларак, читкә чыксаң, шунда ук кычкырып тукталалар яки һавага аталар, атып та үтерергә мөмкиннәр.

Без, ниһаять, сакчыларның безне ташлап качканнарын аңладык. Без азат! Тик нишләргә, кая барырга? Кешеләр төркемнәргә оеша башлады. Французлар — үзаеры, поляклар һәм советныкылар — үзаеры. Без барыбыз да егерме өченче номерлы лагерьдан, аннан штраф-лагерьга күчерелгән кешеләр. Хәзерге вакытта Хельмштадт шәһәренең станциясендә торабыз, бу шәһәр 23нче номерлы лагерьдан нибары илле чакрымда урнашкан. Ә шулкадәр араны төн буенча үтүебезнең сәбәбе — гел тукталып баруда. Киңәшләшеп алгач, киредән егерме өченче лагерьга кайтырга дигән карарга килдек. Чөнки анда үзебезнең совет кешеләре, егетләр һәм кызлар. Берничә чакрым үткәч, баракларда урыс кызлары тотыла торган авылга життек. Ач икәнебезне белеп, кызлар безгә бәрәңге пешереп ашаттылар. Бераз тамак ялгап алганнан соң, без кызлардан Ватенштадтка ничек барырга икәнлеген сораштык.

Өстәге киемнәребез арестант формасы һәм немецлар бездән куркалар. Аларның ир затлары күренми диярлек. Кая китеп беткәннәр диген? Күбрәк хатын-кызлар һәм балалар гына очрый.

Көн ахырында бер лагерьга килеп җиттек, анда да безнең кебек кешеләр, саклары да юк. Димәк, сугыш ахырына якынлаша. Монда төн кунганнан соң, иртә белән кабат юлга кузгалдык. Төш турларында ниндидер кечкенә шәһәргә җиттек. Вольфенбиттен дип атала икән. Кинәт каршыбызга кораллы немецлар килеп чыкты. Автоматларын безгә төбәп, каян качуыбыз турында сорашалар. Ничек булганны сөйләп бирдек. Безнең аркаларда «L — 21» дип язылган. Немецлар безне шәһәрчек читендәге бер сарайга ябып куйдылар. Карангыланып килә. Ишек бикле, сак та юк ахры, чөнки бернинди чит аваз ишетелми. Сарай эчендә кирәкләр һәм ниндидер инструментлар саклана икән. Һәм без ишек астыннан чыгар юл казыдык. Озакка сузмыйча, аннан берәм-берәм тышкы якка чыгып, юл буенча китәргә ашыктык. Өч-дүрт чакрымнар үткәч, юлдан читтә узган елдан калган салам эскерте күрдек. Озак уйлап тормыйча анда барып, саламны йолыккалап, үзебезгә куыш җайлаштырдык һәм иртәнгә кадәр шунда кереп ятарга булдык. Чөнки төнлә бару куркыныч, әгәр кораллы немецларга юлыксаң, атып үтерергә дә мөмкиннәр иде. Яктыра башлагач, кабат юлга кузгалдык. Безнең арттан кемнең дә булса куа килгәне күренми. Лагерьга кайтып җиттек. Капкада автоматчылар тора иде әле, шулай да безне үткәрделәр. Штраф-лагерьның таратылуын монда беләләр икән. Әмма бу лагерьны саклауларын дәвам итәләр, чөнки тоткыннарның моннан бер чакрымдагы Иммендорф авылы кешеләренә һөҗүм итүләреннән куркалар булып чыкты. Лагерьда мин дустым Павел Кайденко белән очраштым, ә Гриша Чумаченконы күрә алмадым. Соңрак аны штраф-лагерьда атып үтергәнлекләрен ишеттем.

Төн җитте. Иртәнгә кадәр безнең лагерь янәшәсеннән чигенеп баручы немец солдатларының аяк тавышлары тынып тормады. Безнең өстән снарядларның сызгырып үтүе ишетелә, менә-менә өскә төшәр кебек. Куркудан тыннар кысыла. Арабызда яше белән бездән күпкә өлкәнрәк кеше дә бар, ул безне: «Курыкмагыз. Снаряд сызгырып очса, еракка-рак китеп шартлый. Әгәр синең өскә төшсә, сызгыру ишетелми», — дип юата.

## Азат ителү

Яктыра башлады. Чигенүчеләрнең аяк тавышлары да, туплар авазы да тынды. Полицайлар белән Лысенко да каядыр китеп югалды. Бераздан көчле дөбердәү ишетелде һәм ул торган саен көчәя генә барды. Без йөгерешеп юлга чыктык. Танклар килгәне күренә, үзләре барган шәпкә аталар. Люкларыннан каскалы башлар сузылган. Танклар инде лагерь капкасына җитеп туктадылар. Сөенечтән кемнең нәрсә кыланганын әйтеп аңлатып бетерешле генә түгел: кемнәрдер баш киемен һавага чөя, кемнәрдер җиргә ятып ауный, ә кемнәрдер яшь бәреп чыккан күзләрен куллары белән каплаган. Берәүләр кычкыра; икенчеләр кочаклашалар, бииләр; җырлаучылар да бар. Экстазга бирелеп, ниләр генә кыланмыйлар, әйтерсең лә акылдан язганнар. Танклар мәҗбүри туктап калган, чөнки кешеләр юлны япкан. Танкистлар кулларын селтәп, таралырга кирәклеген аңлата, ә тегеләре бар дип тә белми. Кайберәүләр танк өстенә үк үрмәләгән, люктан башын тыкканнарны кысып кочаклыйлар, үбәләр. Танкистлар үзләренә комачаулаганнарын аңлатып, кулларын селтәп китәргә кушалар. Югыйсә, хәрәкәтләнеп булмый дию ләре. Танклар урман ягына төбәп кабат атарга керештеләр. Халык таралды. Тик танклар кузгалу белән, халык янә алар артыннан иярде. Кабат тукталу, кабат кешеләргә болай ярамаганлыгын

аңлату. Башта аңлагандай итсәләр дә, танклар урман ягына китү белән, элекке тоткыннар көтүе белән шунда ташланды. Баштарак мин лагерьдан бер чакрым ераклыкта Иммендорф дигән немец авылы булуы турында әйткән идем инде. Бара торгач, шул авылга життек. Инде халык танкларга ияреп барудан туктап, авыл йортларына, сарай һәм базларына ташланды, анда актарынырга кереште. Немецлар бик нык куркынган, чөнки алар лагерьдагы тоткыннарның нинди шартларда тотылуын һәм аларны ничек жәфалауларын белеп торалар, шуна күрә мародёрлыкка керешкән масса күзенә бик үк чалынмаска тырышалар иде. Ә бер кузгалган гавамны инде туктатырмын димә, алар ачлыктан тәмам интеккән. Шуна да кулларына ашарга яраклы ни туры килә, шуны ташыйлар. Сугыш озак барса да, немецларда бөтен әйбер бар: казылык, сыр, төрле кайнатмалар һәм тагын әллә ниләр. Мона гажәпләнәсе юк, чөнки оккупацияләнгән илләрдән фашистлар бөтен таланган байлыкны Алманиягә алып кайтып тутырганнар. Безнең ачыккан халык ни тапса, шуны ашый. Күпләр, ахыры ни белән бетәсен уйламыйча, артыгын да ашап ташлаган. Андыйлар, эчләре боруга түзә алмыйча, жирдә ауныйлар. Хәтта үлүчеләр дә бар. Ничә еллар лагерьда кеше түзә алмаслык шартларда яшәп һәм сугыш тәмамланып килгәндә генә — шундый мәгънәсез үлем! Кызганыч, әлбәттә.

Мондый хәлләр берничә көн дәвам итте. Тулы ирек. Беркем комачауламый, әмер дә бирми. Кем нәрсә тели, шуны эшли. Аппарат ясап самогон куарга өйрәнделәр. Самогонны бәрәңгедән, бодайдан, немецларның базларыннан табылган төрле кайнатмалардан куалар иде. Ул арада халыкның тамагы туя төште, исерешеп сугышучылар да күренгәли башлады. Кайберәүләр әллә каян гына пистолет һәм хәтта гранаталар да табып алдылар. Ир затлары калган авылларда немецлар берләшеп һәм сәнәкләр, тырмалар, көрәкләр белән коралланып, мародёрлык итүчеләргә каршылык күрсәттеләр. Кайбер очракта андый бәрелешләр трагедик рәвештә тәмамланды. Аннары немецлар хәрби комендатураларга мөрәжәгать итә башладылар шикелле, чөнки мона кадәр төрле инцидентларга бармак аша караучы властьлар сугыш чукмарларын үзләренең виллисына утыртып алып китәләр дә: «Рус?» — дигән сорау бирәләр. «Әйе», — дигән жавап ишетелгәч, шундук жибәрәләр. Кайберәүләрнең инде мотоцикллары бар, анда йөрергә каяндыр хокукнамә дә тапканнар. Хәрби полиция туктата калса да, шул кәгазьләрен күрсәткәч жибәрәләр.

Берсендә Ростовтан Вася Скрыпник һәм аның дүрт иптәше бишәүләп мотоциклга төялгәннәр һәм зур тизлектә американыларның авыр йөк күтәрешле «Студебеккер»ларына килеп бәрелгәннәр. Бөтенесе һәлак булды.

Лагерьда хаос. Кешеләр тузгытылган умарта күче шикелле. Өч ел чамасы тоткынлыкта ятып, кинәт кенә ирекка чыкканлыктан, аларны да аңларга була. Туганнарны, Ватанны, андагы тормышны ничек сагынганлыкны белсәгез икән! Чөнки беркем дә үзенең якыннары белән тегендә нәрсә булганын белмәгән кебек, андагы туганнар да безнең белән нәрсә булганын белми.

Үзенең ирекка чыгуын төрле кеше төрлечә кабул итте. Кемнәрдер аяусыз үч алырга теләде. Аның өчен барыбер: ир-атмы, хатын-кыз, бала-чага, карт-корымы. Күп булмаса да, андый очраклар да булгалады.

Шулай да йөгәнсезләнеп йөрүләр озакка сузылмады. Безнең лагерьга иннәренә йолдызлы погон таккан хәрбиләр килде. Алар чиста рус телендә сөйләшә. Безнең барыбызны бергә жыеп: «Иптәшләр, сез барыгыз да СССР ватандашлары саналасыз. Сугыш Советлар Союзы, Англия һәм АКШның бер союзда торып, Гитлер Германиясенең жинелүе белән тәмамланды һәм тиздән сез өйләрегезгә кайтачаксыз», — дип белдерде. Шуннан соң башланган хәлләрне күрсәгез икән: «ур-ра» кычкыралар, кайберәүләр офицерларны кочакларга

кереште... Барсы да тынычлангач, башта беренче булып сүз башлаган офицер (арада чины буенча өлкәнрәк) кырыс чырай белән дәвам итте: «Сезне иң әүвәл тимерчыбык киртәләрсез генә лагерьга күчерәчәкләр, ә монда немец хәрби әсирләре китереләчәк. Аннары шунсы: үзегезне совет кешеләренә хас тәртипле итеп тотыгыз, җирле халыкны талау, аңа зыян салу ише күренешләр булырга тиеш түгел — социализм законнары шуны таләп итә. Совет Армиясенең азат итү миссиясенә тап төшмәсен». Боларга өстәп безгә җитәрлек күләмдә тукландыру да оештырылачагын әйттеләр.

## Америкалыларда

Безне икенче лагерьга күчерделәр. Исемлек төзеп, взводларга билгеләделәр. Элекке хәрби әсир-сержантлар һәм лейтенантлардан взвод командирлары билгеләделәр. Безнең взводка Стрига фамилияле өлкән сержант туры килде. Һәркөнне марш белән атлаталар. Чөнки без — Кораллы көчләрдә хезмәт итмәгән яшьләр. Командирларга ничек мөрәҗәгать итәргә, кайчан һәм ни рәвешле честь бирергә өйрәтәләр. Көненә берничә сәгать строевой әзерлек уздыралар. Күпләр әзерлек эшләренә бик теләп йөри, шулай да, сирәк булса да, арада сачоклар да бар. Яхшы ашаталар. Дустым Павел маршировкаларга йөрмәде, ул кухняда эшли һәм кайчагында миңа берәр тәмле ризык алып кайта иде. Аңарда пешекче осталыгы бар. Безнең ише ачыккан, ябыккан халык акрынлап кеше кыяфәтенә керә башлады, күпләр тазара төште, шулай да арада берничек тә рәткә керә алмаучылар күренә иде әле.

Янәшәдә генә кызлар лагере урнашкан. Кайберәүләр шунда йөри башлады. Мөнәсәбәтләр, мин әйтер идем, тыйнак һәм ихласлыкка нигезләнгән. Әсирлеккә куылганчы аларның барысына да 14-16 яшьләр чамасы гына иде шул әле. Ә монда беренче танышулар, кызлар белән очрашулар. Күпләр танец биюләрен дә белми. Ул чагында вальс, фокстрот, танго, полька кебек биюләр бик модада иде.

Әсирлектә булганнарга караш бик начар иде. Шуңа күрә дә үзебезнең «Пролетарка» шахтасына мин бары тик 1946 елда, егерме яшь тулгач кына кайта алдым. Элекке әсирләрне хәтта дошманга санап, өйләренә кайтармыйлар, теләсә кая эшкә җибәрәләр һәм алар атнасына бер мәртәбә комендатурага барып билгеләнергә тиеш иделәр. Аларны икенче төрле ТФЛниклар гына дип тә атыйлар. Мин соңыннан гына башкалардан моның тикшерү-фильтрацион лагере дип аталуын белдем. Шулай итеп әсирләр немец концлагереннан советларныкына килеп эләктеләр. Алар арасында озак вакытлар канкойгыч сугышларда катнашып, әсирлеккә төшкән һәм Франциядә, Италиядә, Норвегиядә урнашкан лагерьлардан качып, каршылык күрсәтүчеләр рәтенә басучылар һәм хәтта орден-медаль белән бүләкләнүчеләр дә бар, тик барысы да юкка, бөтен элекке әсирләр — Ватанын сатучылар санала иде.

Без — эшкә куып алып кителгән үсмерләрне репатриантлар дип атыйлар. Кайчагында аларны, совет территориясенә аяк басуга, өйләренә җибәрәләр, шулай да күпчелекне зур-зур төркемнәр белән сәнагатьнең төрле тармагына озаталар. Бу аңлашыла да кебек, чөнки сугыш җимерекләрен торгызырга кирәк. Без дә шундый төркемнәрнең берсенә туры килдек. 1945 елның декабрендә бөтен бер эшелон элекке лагерь тотыкларын Мәскәүдән алтмыш чакрым ераклыктагы Электросталь шәһәренә алып килделәр. Хәер, мин тагын алгарак киттем бугай.

Лагерьда чагында, кызлар лагеренда татар милләтеннән булганнар юк микән дип кызыксындым. Миңа баштарак бер татар кызының булганлыгын, тик

хәзер анын күренми башлавын әйттеләр. Ул инглиз телен яхшы белгән икән һәм аны инглиз хәрбиләре алып киткәннәр, имеш. Беренче мәлләрдә көн саен китереп йөргәннәр, ә хәзер инде күптәннән күренми ди. Ул аларда тәрҗемәче сыйфатында йөргән. Аннан соң мин Донецкидан яисә Донецк өлкәсеннән берәрсен очратып булмасмы дип сораша башладым. Кызганычка, андыйлар да юк булып чыкты. Киев, Харьков, Кировоград һәм башка өлкәләрдән бар, миңа кирәклесе юк. Аннары сүзгә бик катнашмыйча гына читтәрәк басып торган түгәрәк йөзле, сөйкемле бер кызны күреп алдым. «Кайдан син?» — дип сорау бирәм. Ул: «Ворошилов өлкәсеннән», — дип җаваплый. Шулай танышып киттек. Әмма безгә озак очрашырга язмаган икән. Эльбаның аргы ягыннан кабат совет хәрбиләре килеп, әзер торырга, якын көннәрдә безне Эльбага алып китәчәкләрен белдерделәр. Эльбаның бер ягында — совет гаскәрләре, икенче ягында американнар тора иде. Без әлегә американнар зонасында. Кызлар лагерена кайчагында америка солдатлары да килә, күбесенчә ак тешле, калын иренле негрлар.

Беренче итеп кызларны алып киттеләр. Мин искә алган кызның исеме Мария иде. Ул миңа сугышка кадәр булган адресын бирде һәм илгә кайткач хат язарга кушты. Мин яздым, әлбәттә, әмма Мария Гаркушина әти-әнисе белән бу адрес буенча яшәми дигән җавап кына килде. Баксаң-күрсәң, сугыш барганда, аларның йорт өстенә фашист самолёты төшеп шартлаган икән.

Китәр алдыннан без лагеребыздагы полицайлар турында да искә төшердек һәм аларны хәзерге вакытта кайда тотуларын сорашып белдек. Унбишләп кеше җыелып, алар ябылган лагерьга киттек. Таптык бит тәки. Алар бик курыктылар. «Чыгыгыз лагерьдан, сөйләшергә кирәк», — дип чакырабыз үзләрен. Тик берсе дә чыгарга уйлап та карамый. Баракка кереп берни эшләп тә булмый, билгеле, чөнки аларны кораллы америка солдатлары саклый һәм алар һәр тәрәзә янында диярлек баскан. Үзләренчә безнең тарафтан полицайларга самосуд ясалмасын диюләре. Андый очраклар булгалады. Әгәр союзниклар баштарак моңа бармак аша гына караса, хәзер таләпләр катгыйланды, кулга алырга да күп сорамыйлар. Кемнен инде, үзебезнең якка чыгарабыз дигәндә, ут белән шаярасы килсен.

Берничә көннән соң безне «Студебеккер»ларга утыртып, Эльба елгасының биек ярына урнашкан Тангюрменде каласына китерделәр һәм качып киткән немецлардан калган берничә буш йортка урнаштырдылар. Бигрәк тә безнең гаскәрләр торган Көнчыгыш Алмания җирләрендә тыныч халык аз, хәтта кайбер шәһәр һәм авыллар тулысынча бушап калган, диделәр. Елганың аргы ягында безнең солдатларның йөреп торганы күренә. Безне әле анда чыгарырга ашыкмыйлар. Йөрәк урынында түгел, тизрәк чыгасы килә! Ул яктан кул селтәп урысчалап кычкырганнары ишетелә. Зур төркемгә тупланып, хәрби комендатурага юнәлдек. Берничә америка хәрбие чыгып, тәрҗемәче аркылы безгә нәрсә кирәклеге белән кызыксына. Без: «Тизрәк үзебезнең якка чыгарыгыз», — дип кычкырабыз. Офицерлардан берәү: «Тиздән чыгарырбыз, менә кайбер формаль эшләрне генә башкарыйк та. Нәрсә, сезгә начармыни? Яхшы ашатабыз. Ял итегез, фашист лагерьларыннан соң көч җыегыз», — дип җавап бирә. Янә берничә көн үтте. Безгә сигаретлар, ә кайчагында берничә ел буе күрмәгән кәнфитләргә кадәр бирә башладылар. Ул да түгел, урысча яхшы сөйләшә торган кешеләр пәйда булды. «Сез кая ашкынасыз? Монда шартлар яхшы икәнен күреп торасыз, соңрак тагын да яхшырак булачак. Калыгыз биредә», — дип сөйләнәләр үзләре. Эш менә нәрсәдә икән. Без янә җыелышып теге як ярга чыгаруларын таләп итәргә киттек. Әгәр дә чыгармасагыз, безнекеләр ишетелерлек итеп хор белән кычкырачагыбызны әйттек. Шуннан соң бөтенесен

жайларга вәгъдә иттеләр. Соңыннан беленүенчә, алар безнең вәкилләргә күбесе өйләренә кайтудан баш тарта дип белдергәннәр икән.

Ниһаять, безне понтон күпер буенча үзебезнекеләр ягына чыгардылар. Ерак та түгел капиталь күпер дә бар, тик ул берничә урыннан җимерек — шартлатылган иде. Эльбаны чыкканда ни американлылар, ни үзебезнең якта бернинди тикшерү-фәлән булмады. Әле бик иртә. Без өелешеп Көнчыгыш тарафка атлыйбыз. Көнозын бардык. Кич белән бер авылга җитеп туктадык. Төн кунарга ашлык көлтәләре суктыра торган бер әвенгә күрсәттеләр. Безгә кадәр дә монда төн кунучылар булган, күрәсең, чөнки бөтен урында изелгән салам ята. Бик арыган идек, яту белән йокыга талдык һәм таң аткач кына уяндык.

## Безнекеләрдә

Американлылар безне Эльбага кадәр машиналарда китергәннәр иде. Кичүдән соң да шулай булыр, диделәр. Тик кая ул, бу турыда искә төшергәч көлделәр генә. Төн кунган авылда безнең гаскәрләр тора иде, һәм менә анда безне берәм-берәм бер торакка кертеп тентү үткәрделәр, корал-фәлән юкмы, янәсе. Кемнән нәрсә тапсалар, сәгатьме, сигаретмы яисә башка әйберме — барсын алдылар. Мин үземнең Татарстанның Шөгер районыннан икәнлегемне әйттем. Язып баручы шундук, мин Кирлегәч авылын атагач: «Син минем якташ икән бит, мин үзем Варваровкадан», — диде. Әлеге урыс авылы бездән ерак түгел. Үзем белән ташландык немец йортыннан табып алынган алтын балдак һәм ике кап сигаретым бар иде, сорашучы аларны үземдә калдырды. Күпләр үзләре белән әллә ничәшәр сәгать һәм башкасын союзниклар зонасында торган чагында, немец авылларын «чистартып» йөргәндә алганнар иде. Безнең якта мондый нәрсәгә юл куелмый икән.

Бер очрак турында сөйләп китәргә телим. Ике атнадан артык шулай тәпилибез. Нык кына арылды да. Бер авылны узып, өч-дүрт чакрымнар чамасы үткәч, арбасына ике ат җигелгән немец килгәнен күрдек. Арбасының тәгәрмәчләре дә резиннан. Без аны туктаттык та, үзен төшереп, «транспорт» чарасын үзебезгә алдык. Унлап кеше менеп төялдек тә юлыбызны дәвам иттек, җыр да сузган булабыз. Тик сәгать ярымлап вакыт үттеме икән, мотоцикл тавышы ишетелә. Бу мотоцикл безне узып юлга аркылы басты. Мотоцикл люлькасыннан бер офицер сикереп төште, аның артыннан ук — без атларын тартып алган немец. Мотоциклчы солдат руль артында утыра. Туктадык та аптырашып карап торабыз. Офицер яныбызга килде дә: «Ну-ка хәзер үк коелыгыз, күрсәтермен мин сезгә ничек итеп илне оятка калдырырга икәнен! Без бит басып алучылар түгел, коткаручылар. Кире борылып, кайсы авылдан чыккан булсагыз, шунда кайтыгыз», — дип кычкырына башлады. Немецка кабат арбасына утырырга кушты. Мотоциклда китеп барганда безне: «Качарга уйламагыз, ерак китә алмассыз, барыбер табармын», — дип кисәтте. Офицер әйткәнчә эшләргә туры килде. Немец безгә карап мыскыллы елмая. Безнекеләрдән берәү: «Көлгән була, әйдәгез аны арбадан төртеп төшерәбез», — дип тәкъдим кертә. «Шаштынмы әллә? Ул бит яңадан әләкләячәк, аннары тагын да начаррак булачак», — диләр башкалар, аның тәкъдимен кире кагып. Авылга кайтып җиткәндә, офицер безне инде көтеп тора иде. Немец атларны туктатуга ул безгә җиргә коелырга әмер бирде. «Бер рәткә тезелеп басыгыз! Үрә катыгыз! Сулга борылыгыз, атлагыз!» — дигән боерыклар яңгырый. Атлап китәбез, янә әмер көтәбез. Аннары: «Йөгерергә!» — дигәнне ишетүгә йөгерә башлыйбыз. Офицер кычкыруын белә: «Борылып карамаска! — ди ул өзми-куймый. — Сез миңа башкача кирәк түгел, күземнән югалыгыз», — ди аннары. Һәм без китеп барабыз. Бу хәл безнең өчен

сабак булды, бүтән беркемгә дә кагылмадык. Озак бардык әле. Бер шәһәрдә ниндидер капкалар аша үттек. Әлеге шәһәрнең Бранденбург булып, капкалары да Бранденбург дип аталуын белдек. Бу — сугыштан соң зур башкисәрләрне халыкара суд хөкем иткән җир икән.

Тукталышлар белән без инде бик күп көннәр юлда. Бер шәһәргә җиттек. Йортларның тәрәзәләре юк, күбесе җимерек, юлларда чүп өемнәре. Исәпсез-сансыз кәгазь кисәкләрен җил ары-бире очыра. Шәһәр Кенигсберг дип атала икән. Монда безнең армиягә дошман искиткеч каршылык күрсәткән, эсэсовчылар подвалларга урнашып, соңгы патроннарына кадәр атышканнар.

Аннары без Польша чигенә таба киттек. Берлекхен дигән шәһәрчектә туктадык. Биредә утыз өченче дивизиянең батальоны тора. Безнең кебек бик күпләрне җыеп роталарга бүлгәләгәннәр һәм немец авылларына урнаштырганнар. Безнең кебекләрдән башка, монда кадәр фашистларны тар-мар итеп, сугыша-сугыша килгән роталар да бар. Батальон штабы шәһәрдә урнашкан. Ул күл буендагы җимеш бакчасы эчендәге ике катлы зур һәм матур йортта урын алган. Әйтүләренә караганда, бу йортның хуҗасы көнбатышка качкан. Гомумән, безнең армия тарафыннан азат ителгән территориядә җирле халык аз калган, алар англо-американлылар зонасына күчеп китүне кулайрак күргәннәр. Югыйсә, союзниклар күп нәрсәгә бармак аша карыйлар, җирле халыкны бик үк якламыйлар да иде. Ә менә безнекеләр зонасында немецларга карата берәр начар гамәл кылып кара — җәза үзен озак көттерми.

### Элемтәче

Без монда ияләшеп җиттек. Мин, Анатолий Яков, Фёдор Магда һәм Павел Кайденко бер тирәдәрәк булырга тырышабыз. Хәрбиләрдән торган роталарны һәм без — лагерьныкыларны, шулай ук роталап, урып-җыю эшләренә җибәрделәр. Минем янга комбат килеп: «Элемтәче булырсың», — дип белдерде. Кызыл төстәге велосипед биреп, йөрергә өйрәнә торырга, авылларда урнашкан роталар һәм штаб белән үзара бәйләнеш тотарга кушты. Кайбер роталарга кадәр ара ераклыгы бер чакрым, ә кайберләренә — өч-дүрт. Юллар бер дигән, велосипедта җилдерүе үзе бер рәхәтлек. Комбат: «Гражданскийлар өчен аерым бер штаб булдырырга янә кешеләр табасы иде», — ди. Мин аңа бу эш өчен кулай иптәшләрем булуын әйтәм. Ул алып килергә куша. Кушканны үтим. Толиктан ничә класс белеме барлыгы белән кызыксыналар.

Ун класс дигән җавап ишеткәч, штабка билгелиләр. Комендант взводының ашханәсенә дә кеше кирәк икән. Минем тәкъдим белән кухняга Яков белән Павел Кайденконы куялар, ә Фёдор старшина Гошко кул астына складка тәгаенләнә.

Шулай да миңа элемтәче булып озак йөрергә туры килмәде. Штабта берсендә комбат минем янга килде дә, рота командиры Куликовтан китергән язуны күрсәтеп: «Бу аның почеркы түгел бит. Син үзең ничә класс бетерден?» — дип сорый. Мин: «Алты» , — дип җавап бирәм. «Яхшы, иртәгәдән писарь булып барырсың, рота старшиналарына продуктлар язып бирерсен, алайса бу старшина Гошко таракан язуы белән яза. Начпрод кече лейтенант Красновка әйтеп куярмын мин», — ди ул.

Миңа аерым бүлмә бирделәр, анда диван да бар. Мин анда эшлим һәм шул ук вакытта яшим дә. Накладной кәгазьләрен ике экземплярда язам, аларга батальон штабында кул куялар. Фёдор Магда кирәк нәрсәләрне җибәреп тора.

Комендант взводына ерак та түгел поляк хәрби часте урнашкан. Алар көндез дә, төнлә дә урамнарда патрульлек итәләр, совет гаскәрләре киткәч,

бу территорияләр Польшага калачак дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Поляк хәрбиләре велосипедларда йөри, аркаларында совет власте биргән иске типтагы винтовкалар. Безнең хәрбиләр автоматлар белән коралланган.

Берсендә шундый очрак булды. Комендант взводы командиры — өлкән сержант — чабып кергән һәм: «Взвод, коралга!» — дип кычкыра. Бөтенесе дә автоматларын эләктереп, сержант артыннан күл буена йөгерде. Нәрсә булды икән? Без дә шул якка ашыктык. Ә анда, күл буенда, безнекеләр белән поляк солдатлары бер-берсенә коралларын төбәп, кара-каршы басканнар. Полякларның командиры майор чинында, безнеке — өлкән сержант. Әгәр кайсы да булса ут ачарга әмер бирсә, кырылыш булачак. Штраф-лагерьда чагында берничә поляк сүзенә өйрәнгән идем. Мин: «Панове, почекайте. Это не добже», — дип кычкырдым да штабка йөгердем. Сулышым кабып, анда комбатка хәлне аңлаттым, һәм алар замполит белән күл буена ашыктылар. Килеп җиткән уңайга сораштырырга керештеләр. Тегесе комендант взводының ятьмәләр куюын, ә полякларның сорамый-нитми көймәләрдә йөреп, эләккән балыкларны җыюын кыскача гына аңлатып бирде. Поляк офицеры моңа каршы үзләренең солдатларын ашатырга ризыклары калмавын әйтә. Безнең комбат: «Әгәр сорасагыз, без сезнең белән һәрчак бүлешергә әзер бит», — дип җавап бирә. Тегесе акланып: «Ярар, минем солдатларны гафу итегез инде», — ди һәм үзенекеләргә коралларын төшерергә боера. Шулай итеп мәсьәлә тыныч юл белән хәл ителә.

Җәй дә үтеп китте. Авылларда безнең репатриантлар солдатлар белән бергәләп урып-җыюда эшләде, ә мин берничә иптәшем белән шәһәрдә урнашкан штаб тирәсендә хезмәт куйдым.

Шәһәрчек яртылаш буш. Авыллар да буш диярлек. Кайберләрендә җан иясе дә калмаган. Тәрәзәләргә ашык-пошык кына такта кагылган. Өй эчендә хәтта карават, урындык, савыт-сабаише әйберләр дә шул килеш калдырылган. Немецлар көнбатышка качып киткәннәр. Нинди дә булса сәбәп белән торып калучылар гына бар. Шәһәрдә халык шулай ук аз. Эшлеклерәк кешеләр икмәк пешерү, кибетләрдә сату-алу эшләрен җайлап җибәрде. Штабтан берничә йорт аркылы гына әбисе белән бер кызчык яши. Әбинең улы фронтта үлгән, һәм алар бик ачыгалар, кая да булса китәргә мөмкинлекләре дә юк. Мин аларга еш кына ипи бирәм. Немец булсалар да, барыбер кызганыч, чөнки алар ярдәмгә мохтаҗ. Бер сержант моның өчен миңа кырын карый: «Нишләп аларга ипи бирәсең, үзеңне күптән түгел генә ачтан интектергәннәрен оныттыңмыни? Комбатка әйтеп кирәгенне бирермен», — ди. Чыннан да әйткән — комбат мине чакыртып алды. Мин аңа карчык белән кызның нинди хәлдә икәнлекләрен сөйләп бирдем. Ул: «Ярый, Хәнифов, син үзең дә күпне күргәнсең, мөмкинлек кушканча чамала инде алайса», — ди. Очрашкач, сержант: «Нәрсә, эләктеме?» — дип кызыксына. «Бар, комбаттан сорашып бел», — дип җавап бирдем. Кызыксынуы шулкадәр көчле, ул һаман төпченүен белә: «Шулай да, әйт инде», — дип аптырата. «Бар, белеш, бәлки, шатланырсың», — дим дә китеп барам. Беравык карап торгач, ул да китә.

Безне төннәрен шәһәр буенча ялгыз гына йөрмәгез дип кисәттеләр. Кайбер качып калган фанатик немецларның кайчагында безнекеләргә һөҗүм итү очраклары була. Шуңа урамда кизүлек итүче поляк патрульләре очрашкан чагында: «Сак булыгыз, панове», — дип кисәтәләр иде.

## Күз

Урып-җыю эшләре ахырына якынлашты. Көннәр суытып җибәрде. Безне, урып-җыю тәгәлләнгәч, өйләрегезгә җибәрәчәкбез, дип ышандырдылар. Монда климат йомшак булса да, йортларда барыбер салкын. Шуңа күрә мин ташландык

йортларга кагылып, кияргә бирәр жылырак кием табып булмасмы дип уйладым. Шәһәр читендәге урман янәшәсендә озын гына дүрт катлы йорт урнашкан. Ул буш тора. Мин аның чарлагына менәргә уйладым. Мендем дә кайсы якка барырга микән дип каранам шулай. Кинәт, мич торбасы янында, автоматын мина төбәгән кеше басып торганын күрдем. Баштагы мәлдә әллә күземә күренәме дип торам. Юк, чыннан да шулай. Мин тораташтай катып калдым. Ул да тик карап тора. Аннары ул кинәт борылып, икенче люк ачыклыгына ташланды. «Әллә мираж гына булдымы?» — дип уйлыйм. Исемә килеп, чарлак тәрәзәсе янына йөгереп килдем һәм аска күз салдым. Анда автомат тоткан кешенең урманга таба йөгергәне күренә иде. Аска төшеп, штабка ашыктым. Күргәннәремне комбатка сөйләп бирдем. Ул элемтәчене комендант взводына жибәрде. Комендант взводы тиз арада машинага төялеп, урман ягына юнәлде. Күп тә үтмәстән качкынны эләктерделәр һәм дивизия штабына жибәрделәр. Аннары комбат мине үз янына чакыртып: «Ну, егетләр, тиешсез урында йөрмәгез дип сезгә күпме әйтергә була. Ярый әле ул синең коралсыз икәнеңне күргән һәм ут ачмаган, тавыш күтәрергә теләмәгән. Әгәр син формадан һәм коралың да булса, ул сине, һичшиксез, атып үтерер иде. Андый очраклар күп булды инде, дошман калдыклары һаман да бар ич әле. Сугыш тәмамлангач кына мәгънәсез үлем нәрсәгә кирәк. Минә әйт әле, ниемә дип шунда үрмәләдең син?» — дип төпченде. Мин: «Тиздән кыш житә, нинди дә булса жылырак кием табып булмасмы дигән идем», — дим. «Эшләр төгәлләнгәч, дивизиягә барырбыз, сезне хәрби хезмәткә чакырырбыз һәм үзебезнең батальонга билгеләрбез. Ә хәзергә, мә, менә бу плащны алып тор. Ул әле яхшы хәлдә, киеп йөрерсең. Киләчәккә сабак булсын: башкача болай йөрмәгез, югыйсә, кошларны аткан кебек атып бетерерләр үзегезне», — дип сабак бирә комбат.

Беренче һәм икенче роталарның командирлары батальон штабына килеп, үзләренә бирелгән участокта эшләрнең төгәлләнүен белдерделәр. Аларның солдатлары һәм егетләр ял итәләр. Өченче — Куликов ротасында гына берникадәр төгәллисе жир калып бара ди. Ике рота егетләре ЗИС-5 йөк машинасына төялеп килделәр. Үзләре белән әллә никадәр алма да алып килгәннәр. Мин инде алдарак юл буенча алма агачлары утыртылган дип искә алып киткән идем. Безнекеләр ансат юлын тапканнар: машина белән алмагач кырына чигенәләр дә икән, агачны селкетәләр ди, алмалар кузовка коела. Жаның күпме тели — аша. Ашханәдә эшләүче немкалар да өйләренә чиләге-чиләге белән алып кайтып киттеләр. Үзләре: «Данке, данке», — дип рәхмәт әйтеп сөйләнәләр.

Ниһаять, өченче рота да эшләп бетерде. Китәргә әзерлек башланды. Комбат мина батальон складыннан жибәрелгән продуктлар буенча хисап төзергә боерды. Тәгаенрәге, боерык начпрод Красновка бирелгән иде, тик ул хисап эшләрендә йомшаграк, шунлыктан булышуымны үтенеп сорады. Үземчә бөтенесен жиренә житкереп, хисапны комбатка алып киттем. Анда өстәмә «самозаготовка» дигән графа да бар иде, ә бу жирле халыктан алынган азык-төлеккә кагыла. Комбатның ачуы килде, ул ирексезләп алынганны аңлата, кайсыдыр ки закон буенча тыела икән. Кабаттан төзәтеп китердем. Комбатның күнеле булды һәм ул: «Әгәр теләсәгез, дивизия штабына барабыз һәм сезне солдат итеп довольствиегә куябыз. Демобилизациягә кадәр хезмәт итәрсез», — дип тәкъдим итте.

## Хата

Минем башка иптәшләр, Павел Кайденко, Анатолий, Фёдор Магда дивизиягә барырга ризалаштылар, ә мин — юк. Мин комбатка өйгә ашкынуымны, анда әниемнең ялгызы гына калуын аңлаттым. Абыемның да гаиләсе белән ни

хәлдә икәнен белмим. Комбат: «Үзенә кара, без ирексезләмибез», — дию белән чикләнде. Беренче хатам шунда булды. Мин, әгәр үземне хәрби хезмәткә язсалар, әниемә, япа-ялгызы буларак, хәрби комиссариатның булышачагын ул чагында каян белим ди. Икенче хатам — азат ителгәннән соң, штабта писарь булып эшләвем турында бернинди дә белешмә алмауда иде. Ул чагында киләчәктә боларның кирәге чыгачагы турында уйлап та карамадык шул. Кайберәүләрнең остарбайтерлар лагеренда булуы турында «аусвайслары» сакланган, ә мин азат ителгәндә штраф-лагерьда идем һәм минем бау белән муеныма тагылган тимер номер кисәгеннән башка бернәрсәм дә юк иде. Күпләр үзләренең «аусвайс»ларын коллык билгесе урынына күреп, аяк астына салып таптауларын да әйтергә кирәк.

Без жыена башладык. Шулчак ашханә кухнясында эшләп йөргән ике немка йөгереп керде һәм, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә: «Сездә эшләгәнлеккә белешмә язып бирегез әле. Юкса монда поляклар баш булып калыр. Безгә карата сезнең мөнәсәбәтегез әйбәт иде, ә поляклардан куркабыз без», — дип ялынырга керештеләр. Мин инде алдарак үзебезнең Польша белән Алманиянең элекке чигендә торганлыгыбызны искә алып үткән идем. Һәм менә хәзер шул территория дә Польшага күчәргә тиеш икән. Немкалар минем янга кешеләрнең кәгазь тотып кереп-чыгып йөргәнен күргәннәр һәм мине ниндидер түрә дип уйлаганнар, күрәсең. Аларга үземнең бернинди дә түрә түгеллегемне аңлатып маташсам да, күз яшьләре белән ялыныпмы-ялыналар. Ахырда түзмәдем, кызыл карандаш белән: «Шундый-шундый фрау шундый урында эшләде», — дип язып, кулымны куеп белешмә бирдем. «Мөһере юк», — мәйтәм. Алар бик канәгать булып: «Данке, данке шон», — диештеләр. Исәр булганмын, үземә дә шундый белешмә язмаганмын, комбат мөһерен баскан булыр иде.

Без иптәшләр белән саубуллаштык. Аерылулары һай авыр ла, тик ул көн кайчан булса да барыбер киләчәк иде. Китүчеләр утыз өченче Кызыл Байраклы Берлин гвардия дивизиясенә юнәлде, ә минем кебек язмышны сайлаучыларны Франкфурт-Майне шәһәренә озаттылар. Павел белән аерылышканда, мин аның белән кабат егерме бер елдан соң гына очрашачагыбызны әле берничек тә күз алдына китерә алмадым.

## «Комбат Хәнифов»

Франкфуртта безнең барыбызны зур бер кварталдагы дүрт катлы йортларга урнаштырдылар. Монда, күрәсең, күп лагерьлардан азат ителгәннәрне СССРга жибәрер өчен жыялар иде, чөнки инде без берничә мең.

Төнне уткәрүгә, иртә белән: «Торырга!» — дигән әмер яңгырады. Йортлар буенча офицер белән солдатлар кереп йөри. Бер офицер минем янга килеп: «Мәктәпкә йөрдеңме?» — дигән сорау бирә. Минем «әйе» дигәнемне ишеткәч: «Ничә класс белемең бар?» — дигән чираттагы соравы яңгырый. «Алты», — дим. «Менә сиңа кәгазь белән карандаш. Бу каттагы бөтен егетләрнең исем-фамилияләрен язып чык, монда бер батальонга жыеладыр әле». Ә мин батальонда ничә кеше икәнен белмим. «Иртә белән, берникадәр вакыттан соң, стройга тезелү булачагын әйтерсең. Син монда комбат булырсың», — ди офицер. Минем көлеп куйганымны күреп, ул: «Нәрсә көләсең? Сез монда барыгыз да военнообязанныйлар, шуңа күрә бернинди көлке юк», — дип кырт кисә. Мин: «Алай дип әйтсәм, бөтенесе көләчәкләр генә, нинди комбат чыксын миннән», — дип аңлатып карыйм, тик файдасыз. «Кушканны үтәргә!» — дигән әмер яңгырый. Ризалашудан башка чара калмый һәм мин кәгазь, каләмемне күтәреп китеп барам. Берникадәр вакыттан тезелергә әмер яңгырый. Һәрбер

кат аерым төркемнәргә тезелеп баса. Мин санау үткәргәннән соң, хисап тотарга юнәләм. Хәрби булмаган кешенең ничек атлап килүен, честь бирүен күреп, офицер елмаеп куя. Каушый төшәм. Ничек кенә комбат Хәнифов хисап тота дип әйтергә соң әле? Шулай да бөтен батырлыгымны җыеп әйтәм бу сүзләрне. Рәтләрдән көлгән тавышлар ишетелә. «Көлүләрне калдырырга!» — дип кычкыра офицер. Бөтенесе тынып кала һәм миңа җинелрәк булып китә.

«Тиздән өйләрегезгә кайтачаксыз», — дип чыгыш ясый бер подполковник. Шуның өчен безне җирле халыкка карата хәерһахлы булырга, торган җиребездән ерак китеп йөрмәскә чакыра.

— Сез, азат ителгәннәр, бик күп. Барыгызны берьюлы җибәреп бетерә алмыйбыз, шуңа күрә бер-бер артлы эшелонлап җибәрәчәкбез. Хәзергә ял итегез, күңел ачыгыз. Зур клуб бар, шунда танцыларга йөрегез. Ерак та түгел кызлар да урнаштырылган, алар да танцыга килерләр. Карагыз аны, китәр алдыннан гына берәр төрле «мөгез» чыгарып куя күрмәгез. Алайса өегезгә кайту да, туганнарыгызны күрү дә тәтемәс! Ашау-эчү тиешле нормада булачак. Кайчагында бәрәңге басуында бәрәңгегә барып кайтсагыз да ярый. Аның сугыш аркасында алынмыйча калганы күпме ята! Ә хәзер таралыгыз!

Клуб чыннан да зур, тынлы оркестр уйный. Уйнаучылары — безнең кебек үк азат ителгәннәрдән. Кем бии белә, рәхәтләнеп бииләр. Тик мин белмим, ялгышып партнёрымның аягына басам, аннары инде оялып чыкмыйм да. Безнең алда офицерлар еш кына нотык тота, армиябез полководецлары — Жуков, Рокоссовский, Говоров, Василевский һәм башкаларның портретлары урын алган.

Үзебезне җибәрү вакытын түземсезләнеп көтәбез, шатланабыз, хыялланабыз, киләчәккә план корабыз. Туганнар һәм дуслар белән очрашу мизгелләрен күз алдына китерәбез, без әле күпләребезгә аларны исән килеш күрү насыйп түгеллеген белмибез, чөнки сугыш үзенең кара эшен эшләп өлгергән.

Күпләрне инде җибәрделәр, ә без әле һаман тәмам туйдырган чит җирдә кала бирәбез. Киткәннәр турында нинди бәхетлеләр дип уйлыйбыз һәм бераз алардан көнләшәбез дә. Җитәкчеләр шулай ук тизрәк барыгызны да җибәрер идек, диләр. Илдә шәһәр һәм авыллар, завод-фабрикалар, шахталар һәм башкалар җимерек хәлдә, аларны торгызу өчен бик күп эшче кул таләп ителә.

## Ватанга! (1945, декабрь)

Ниһаять, безгә дә чират житте. Теплушка дип аталган вагоннардан бөтен бер эшелон тупланды. Инде кыш булганлыктан, вагоннарны «буржуйка» дип аталган мич ягып җылыталар. Ашатулары начар түгел, тик поезд станцияләрдә озак тукталып тора. Бу аңлашыла да, хәрәкәт зур, һәм беренче чиратта, кирәкле поездларны тоткарлыксыз уздыралар.

Өч еллык фашист коллыгыннан соң без үзебезне оҗмахтагыдай хис иттек. Сугышка кадәр чыгарылган җырлар җырлыйбыз. Вакытны күңелсез уздырмаска тырышабыз.

1945 елның декабрендә безне Мәскәүдән алтмыш чакрым ераклыктагы Электросталь шәһәренә китереп житкерделәр. Без бер яктан Ватанга кайтуыбызга шат булсак та, икенче яктан, туган-үскән җирләргә кайта алмавыбыз кәефләребезне бераз төшерә иде. Ни әйтсәң дә, тизрәк әти-әниләрне, туганнарны күрәсе һәм үзебез уйнап үскән, укыган урыннардан үтәсе килә.

Вагоннардан төшергәч, шәһәр читендә, үзебез яшәячәк кварталларга урнаштыруларын көтеп басып торабыз. Безне ундүрт-унбиш яшьлек чагында куып алып киткән булсалар, хәзер инде без унсигез-унтугыз яшьлек егетләр.

Аннары, азат ителгәннән соң, шактый гына түл дә жыеп өлгердек. Тамак туйгач, жырлыйсы да килә бит ул. Жыелабыз да урыс, украин жырларын жырлыйбыз. Арада украиннар күбрәк. Минем үземә дә украин жырлары ошыйрак төшә, чөнки мин шушы халык арасында үстем. Яныбызга кеше байтак жыелды, күбесе хатыннар һәм кызлар. Бу аңлашыла да, чөнки сугыш ир-атны чебен урынына кырды. Танцылар башланып китте. Ул арада безне озатып йөрүчеләр килеп, төн кунарга урын әзер булуы турында белдерделәр. Жыелган халык тагын бераз тоткарлануыбызны сорап ялынырга кереште. Рөхсәт алынгач, жыр-бию һәм уен-көлке янә күпмедер вакыт дәвам итте.

Безгә берничә буш торган йортны күрсәтеп: «Үзегез теләгәнчә урнашыгыз», — диделәр. Бүлмәләрнең зурлыгына карап дүрт яисә алтышарлап урнаштык. Мин кичекмәстән әниемә, «Пролетарка» шахтасына хат язып салдым. Икенче көнне безне эш урыннарына бүлү башланды. Мин балта осталары бригадасына эләктем. Кечкенә генә мастерскойга алып керделәр, анда өлкән яшьләрдәге бер абзый мастер икән. Без станоклар һәм урындыклар ясарга тиеш булып чыктык. Келәй булмаганлыктан, агач кадаклар белән эш итәбез. Житештерелгән товарны начар алалар, чөнки алар бик тиз какшый, өстәвенә, тәжрибәбез дә житенкерәми. Хезмәт хакын аз алабыз. Хәлне күпмедер жинеләйтү өчен, столярка калдыкларын жыеп, кибетләр кырында сатабыз. Сугыш яна тәгәлләнгән, ягулык белән хәл катлаулы. Хәер, кием-салым, азык-төлек белән дә нәкъ шул ук хәл. Күпләр начар киенгән, ә салкыннар утыз градуска житә. Минем өстә плащ кына. Шулай да, яшьлегем беләндер инде, түзәм. Ашханәдә көненә бер мәртәбә туклану өчен талон бирәләр. Бу турыда без очраклы гына белдек. Мастер белән табельщица моны бездән яшергәннәр. Соныннан аларны кысып гаепләрен таныткач, мастер, куркып, элеккеләре өчен дә компенсация бирергә вәгъдә итте. Һәм кайчагында көненә икешәр талон бирә башлады. Андый чакта мин берсен сата идем, акчасы сигарет сатып алырга, кинога тотыла. Кемнәрдер талоннарын акчага алыша. Ызгыш-талашлар, сугышулар да булгалый. Ач халык — ачулы. Берсен-берсе алдау очраклары да аз түгел, акча яки талоныңны тартып алырга да күп сорамыйлар.

### Раиса

Берсендә безне завод территориясенә плотник эшләренә жибәрделәр. Шунда ничектер безнең янәшәдә үлчәү-билгеләү эшләре белән шөгыльләнүче кызга игътибар иттем. Жылы итеп киенгән, аягында киез итекләр үзенең. Бер-беребезгә карап-карап алгалыйбыз. Мин күз кысып куйгач, кызыкай көлеп жибәрде. Мастерга бу хәл ошап житмәде булса кирәк, аның: «Нәрсә акайдың? Эшләвеңне бел!» — дип кычкырганы ишетелде. Кыска ялга туктагач, мин бу кыз янына үзем килдем һәм исәнләшкәннән соң: «Шундый сөйкемле жан иясен кайсы ана тудырды икән?» — дип сүз каттым. Исеме Раиса икән. Әтисе инде исән түгел, әнисе һәм сеңлесе белән кинотеатрдан ерак та түгел яшиләр. Мин аны кинога чакырдым. Ул: «Танышлар күрер бит», — ди. «Шуннан ни булган, бу бит гадәти хәл», — дим. Ул «әйе» дип тә, «юк» дип тә жавап бирмәде, бары жилкәләрен генә жыерды. Кесәмдә бер тиен акчам юк. Икенче көнне мастердан талон алып, ашханәгә йөгердем, исәбем — тиз генә сатып, акчасына кинога билет юнәтү. Кешеләр ары-бире йөреп тора, кемнәрдер кассадан төшке ашка чек чыгарта. Мин кесәмнән талонны чыгаруга, яныма бер егет килеп басты, каш астыннан сөзеп карап: «Сатасыңмы? — дигән сорау бирә. «Сатам», — дим. Ул кулымнан зәңгәрсу төстәге талон кисәген тартып диярлек алды, тик нигәдер акча бирү турында уйлап та карамый. «Акчаңны бир!» — дип кычкырам тегенә.

Егет кесәсенә тыгылды, әмма аннан акча түгел, перчатка тартып чыгарды. «Перчаткадан соң акчасын чыгарыр инде», — дип уйлап бетерергә өлгермәдем, йөземә китереп тә орды бу. Бер читтәрәк аның иптәшләре тора, алар аңа ышанычлы терәк тоелгандыр инде — оятсыз итеп мәсхәрәле елмаеп, миңа аркан борылды һәм китәргә атлады. Булмый гына торсын әле! Кесәмдә калак бар иде, яшен тизлегендә аны алдым да, артыннан килеп, каракның авыз читенә кундырдым. Кечкенә яра барлыкка килде. Ул нидер кычкырып чүгә башлады. Иптәшләре өерләре белән миңа ташланды. Мин калагым белән тагын берсенә селтәндем. «Аның кулында пычак!« — дип кычкырды кайсыдыр. Бөтенесе миннән читкә сибелделәр. Тик кулымдагы «корал»ның нибары калак кына икәнен күреп, кабат өстемә килә башладылар. «Репатриантлар, безнекеләрне кыйныйлар!» — дип кычкырдым, хәлемнең мөшкеллеген күреп. Безнекеләр тиз арада жыелып тегеләрне тәпәләп ташладылар. Мин яралаган тип аларның башлыклары булып чыкты. Аны эләктереп алып: «Безнең белән сөйләшүләргә барсаң, зыян салмабыз. Без — ерткычлар түгел. Фашист лагеренда күпне күрдек. Әгәр бармасаң, һәр жирдә һәм һәрвакыт кыйналачаксың. Баш тарту синең файдага түгел, чөнки без күп, һәм без гаделлек ягында», — дип белдердек. Ул барды, бер өстәл артына утырып сөйләште. Аңа бу ашханәдә яисә башка жирдә командасы белән кемне дә булса рәнжетсә, рәт булмаячагы турында белдердек. Кешеләр соныннан безгә рәхмәт әйттеләр, чөнки моңа кадәр аларны хәтта милиция дә тыңлата алмаган ди.

Талонны миңа кайтарды ул. Раиса белән киногa барып кайттык. Яңадан, башка сеанска дип, кызга тагын акча биреп калдырдым. Килүемә Раиса елап тора, билетларын югалткан икән. Минем дә кесәмдә жилләр исә. Нишләргә инде? Карасам, ерак та түгел Женя Бриль басып тора. Бер вагонда кайткан идек, яхшы егет. Ул Электростальдәге металлургия комбинатында эшли, хезмәт хаклары безнекеннән күпкә югары. Билгеле инде, кайнар цехта һәм авыр эштә паёгы да, яхшы акчасы да тиеш. Мин аннан бурычка алып, кабат кинога билетлар юнәттем.

Бериш иптәшләр шәһәрнең тегү мастерскоенда түбән бәядән пальтолар тегеп бирүләре турында белдерүдән укып белгәннәр икән. Бардык без анда, тик трофейга эләккән яисә үле немец солдатларыннан салдырган шинельләрдән тегелгән пальтолар икәнен белгәч, кире борылдык. Тәмам күрәлмаслыкка әверелгән киемне киеп йөргәнче, туңып йөрүең хәерлерәк дигән карарга килдек.

## Әни янына

Һәркөнне әниемнән һәм абыйдан хат көтәм. Ә вакыт бара. Төннәрен йоклап булмый. Нишләп кин күнелле күршебез Куприяновнага язып карамаска ди әле, дигән уй килде башыма. Һәм мин хат язып жибәрдем дә көтәм шулай. 1946 елның март башларында жавап хаты килде. Куприяновна болай дип язган: «Кадерле Саша, кайт. Әниең берьялгызы, базар буенча калдык-постык жыеп йөри. Абыең һәм апаң гаиләсе турында кайткач белерсең». Мин нык тетрәндем. Кулдан эш китте, йоклап та булмый. Жибәрүләрен сорыйм, жибәрмиләр. Безнең белән тәрбия эшләре алып баручы өлкән лейтенант бар иде, аңа мөрәжәгать иттем. Ул: «Мин берни дә эшли алмыйм, сезгә карата бернинди документ-фәлән бирмәделәр, югарыдан күрсәтмә килергә тиеш», — ди. Мин аңа хатны күрсәтәм, әнинең нинди авыр хәлдә икәнен аңлатырга тырышам.

Моннан тыш Кәрим абый да хат язган иде. Аңа адресымны Куприяновна биргән. Ул, чит кеше булса да, әнине үз почмагына сыендырган. Һәм менә

ниләр яза: «Үзең анла инде, карточка системасы бит, кешеләр ярым ач. Хәрби комиссариатка барган идем, анда берничек тә ярдәм итә алмаячакларын әйтеп кулларын гына җәяләр. Әгәр армия хезмәтендә исәпләнсә, башкача булыр иде, ә куып алып кителгәннәргә карата күрсәтмә юк, диләр».

Шуннан соң мин өлкән лейтенант белән мастерга китәчәгемне әйттем. Алар: «Без сине тоткарламыйбыз, тик хәзер шундый вакыт, ошбу адымың белән үзеңә зыян китерә күрмә», — диләр. Төн буена йокламыйча, мине Алманиягә куып алып киткәннән соң, ниләр булды икән дип уйланып чыктым. Иптәшләрдән киңәш сорап карыйм, тик алар да берни әйтә алмыйлар, бары хәлемә генә керәләр.

Ни генә булмасын, ахыр чиктә әнием янына «Пролетарка» шахтасына кайтырга кирәк дигән карарга килдем. Мин инде кискен адымнарга барырга ияләнгән идем. Мастердан чираттагы авансны бирүен сорадым. Хезмәт хакы алырга да ерак түгел, шуңа күрә берничек тә бурычлы булып калмаячакмын. Мастер беркадәр уйланып торганнан соң кул куйды тагын.

Ял көнне Мәскәүгә баручы электричкага утырдым. Мәскәүнең Павелецки вокзалыннан Харьковка йөрүче поездга эләгергә кирәк. Билет яклары катлаулы. «Куян» булып йөрү минем өчен яналык түгел. Шулай да, язмыш мине еш сынаса да, юлымда яхшы кешеләр күп очрады. Сиздермичә генә берәр вагонга үтәргә дип состав буенча киттем, аннары күз күрер тагын. Бәхетемә, гастрольдән кайтып килүче артистлар һәм киношмәләрдә булган предприятие житәкчеләре утырган махсус вагонга туры килдем. Язмыш мине Донецк заводында зур пост биләүче кеше белән очраштырды. Купеда берничә кеше кәеф-сафа корып утыралар. Үзегез дә беләсездер, кайберәүләр спиртлы эчемлектән агрессивлаша, ә кемнәрдер киң күңеллегә әверелә. Арадан берсе миңа эчәргә тәкъдим итте. Каршы килмәдем. Ул минем кем һәм кайдан булуым турында сораштырырга кереште.

— Бөтенегез алдында сөйләмим, ә менә сезгә мин ачылырга әзер, — дидем.

— Кызык. Дөрес әйтәсең, бөтен кеше алдында сөйләргә ярамаучы нәрсәләр дә була. Ә менә сине мин, туганкаем, бик рәхәтләнеп тыңлыйм.

Мин аңа хатны күрсәттем. «Чит хатларны укымыйм», — диде ул. Мин кыскача гына хатның эчтәлеген, кайдан һәм кая, ни өчен баруымны сөйләп бирдем. Ул тыңлап бетергәч, адресын бирде һәм хезмәткә урнашу буенча катлаулыклар булса, үзенә мөрәҗәгать итәргә кушты.

Чагыштырмача комфорт белән, ревизорлардан курыкмыйча, артистлар һәм элита арасында мин үземә кирәкле станциягә кадәр кайтып җиттем. Ә аннан «Пролетарка» шахтасына бер чакрым гына. Беркадәр акчам калган иде әле, базарда йөреп кайбер нәрсәләр алдым. Дулкынланудан йөрәгем тукылдый, «тизрәк өйгә, өйгә», дип тибә бугай ул.

### Очрашу

Станция артыннан ук шәхси йортлар башлана. Кешеләрнең ары-бире йөргәннәре күренә. Мин тирә-якка күз ташлыйм. Монда бөтенесе якын, бөтенесе таныш. Борылмада кечкенә генә бер хатын-кыз пәйда булды. Мин аның иелә төшеп нидер эзләгәндәй атлавына игътибар иттем. Карашым аңарда озакка тукталмады, кабат тирә-юньдәге сагындырган манзарага күчте. Шулай атлый торгач, чак кына теге апага килеп бәрелмәдем. Икебез берьюлы күтәрелеп карадык һәм мин: «Әби, гафу итегез», — дип авызымны ачарга өлгергәнче: «Шамил улым!» — дигән авазданда иманеп киттем — каршымда әнием басып

тора иде. Ул чайкалып китте, мин аны егылмасын өчен тизрәк кочагыма алдым. Үземнен дә тез буыннарым калтырый, шулай да җебеп төшмәскә кирәк. Акрын гына: «Әни!» — дип эндәштем. Кешеләрнең янибыздан гаҗәпләнеп карап үткәннәре күренә, кайберләре тукталып ук калган. Һәр, безгә барыбер. Әни яшь тулы күзләрен миңа төбәгән, яшь тамчылары аның яңаклары буенча да тәгәри. Ул башын минем күкрәгемә терәтте дә кинәт кычкырып елап җибәрде. Мин аны юатырга тырышам, башыннан, иңнәреннән сыйпыйм. «Тынычлан, барысы да артта ич, менә мин синең каршыңда», — дип сөйләнәм. Тик ул әле һаман тынычлана алмый. Бары тик үзенең нindидер бер таныш хатыны килеп юату сүзләре әйткәч кенә елавыннан туктады. Һәм без атлап киттек. Бер-беребезгә карап атласак та, әлегә сөйләшү ябышмый. Сораулар күп, нидән башларга белмәссең. Аннары сорау арты сорау туды. Аларга җавап биреп бетерерлек кенә түгел. Моның өчен көнең җитмәс.

Әнине сыендырган Кәрим абыйның өенә кайтып җиттек. Тупсаны атлап кергәндә үк әни: «Кәрим, Мәгъзүмә, мин Шамилне таптым», — дип кычкырып керде. Алар кухнядан чыгып исәнлек сорашырга, кочакларга керештеләр. Шахтёрлар бистәсе зур түгел, тиздән «Пролетарка»дагы бөтен кеше диярлек минем кайтуым турында белеп өлгергән иде инде. Яше, карты хәл белешергә килә башлады. Минем янга Мифтах Камалов килде. Ул да фашист лагерена куылган, тик Көнчыгыш Алманиядә булганлыктан, Кызыл Армия аларны алданрак азат иткән һәм ул өенә иртәрәк кайткан. Шулай ук әсирлектә булган Әсма исемле кыз да килде. Кешеләр һаман килә, бөтенесе кызыксынып сорау бирә. Инде кич якынлашып килгәндә, Мәгъзүмә апа: «Кешегә ял итәргә, әнисе белән сөйләшергә дә кирәктер бит. Шуңа күрә гаеп итмәгез, өйләрегезгә кайтсагыз икән», — дип белдерде.

Минем яшьтәшләрдән Борһан Яһудин, Абдул Сәмигуллин һ.б. кайберәүләр өйләренә исән-сау әйләнеп кайтмадылар. Аларның әти-әниләренә бигрәк кыендыр. Кайчагында миңа бик кыен булып китә иде. Чөнки алар туктаталар да: «Әй, безнекеләргә авыр булгандыр инде», — дип сораша башлыйлар. Алар әле һаман да көтәләр һәм нәрсәгәдер өмет итәләр иде.

Икенче көнне мин әни белән күп нәрсәләрне искә төшереп сөйләшә башладым. Әнием базарда облава булуы турында ишеткәч, станциягә йөгергән, тик бу вакытта безне алып киткән булганнар инде. Ул берүзе торып калган. Аның әле беркадәр мин әзерләгән ашамлыгы калган булган. Мине 1942 елның 12 маенда алып киттеләр, ә күп тә үтмәстән безне алырга дип Фатыйх абый кайткан. Ул Вераларның туганнарына кадәр ничек озак кайтканнары турында сөйләгән.

Кыш бик салкын килгән. Ярты юлга житкәч, Павловкада бугай, алар алты айлык Гөлсинәне күмгәннәр. Кечкенә бала өчен юл бигрәк авыр була. Сабыйга салкын тия һәм ул шуннан терелми. Вераларның туганнарына кайтып җиткәч, Фатыйх абый безне алырга кайтырга чыга. Бик озак кайткан ул, күп кенә торак пунктларын әйләнеп узган. Кайчагында полицейскийлар туктатып, кайда баруы белән кызыксынганнар. Ул үзенең шахтёр документларын күрсәткән, әнисе һәм энесен алырга кайтуы турында әйткән, алар ач утыралар, дигән. Шуның өстәвенә, сельсоветтан алган справкасы булган. Әгәр шундый документлары булмаса, аны партизаннарның элемтәчесе дип атып үтерергә дә мөмкиннәр иде бит. Ниһаять, кайтып җиткән. Мин — юк. Аннары ул әнине алып юлга кузгала. Ансында җиңелрәк була. Әни белән булгач, ул кадәр үк шикләнмиләр дә. Исән-сау барып җитәләр. Авылда хет бәрәңге бар. Вераның әти-әнисе сыер һәм башка төрле терлек-туар тота. Немецлар тикшерү белән сирәк кагылалар, чөнки авыл олы юлдан шактый эчкәрерәк

була һәм әйберләрне бөтенләй алып бетермиләр. Безнең әни күпме генә урыслар арасында яшәмәсен, урысча сөйләшергә барыбер өйрәнеп житә алмады. Украинча — бигрәк тә инде. Вераның кызы, кечкенә Валяны авыл хатыннары тәржемәче дип йөртәләр иде. Ул татарча да, украинча да сөйләшә һәм барсын да әнигә тәржемә итә иде. Әни украин хатыннарының Валяны шуның өчен бик яратуларын сөйләде. Вераның әти-әнисе инде шактый ук өлкән кешеләр. Хужалыкны абый алып барган. Безнең гаскәрләр килгәнче алар шулай яшәгәннәр. Хәрби частьлар авылга кергәч, абыем янына командирлары килә һәм немецларны әйләнеп узу өчен урынны яхшы белгән озата баручы кирәклеген әйтә. Абыем ризалаша.

## Абыемның үлеме

Күпмедер вакыттан соң ишегалдына жигүле ат керә. Вера ул чагында ишегалдында була һәм: «Әни, Федяны үтерделәр», — дип аваз сала. Солдатлар аны күтәреп йорт эченә кертәләр. Аның бөтен жире канга баткан һәм бер күзе дә агып чыккан. Бөтен гәүдәсен мина ярчыклары теткәләп бетергән. Хәрби табиб килә, гәүдәсен бинтка урый. Аннары саквояжыннан бинтлар һәм дарулар чыгара. Кайбер кинәшләрен бирә, үзе: «Безгә алга барырга кирәк. Ул каты яраланган, тик мин аны аякка басар дип уйлыйм, ул бик нык мужикка охшаган», — ди. Күрәчәге булгандыр, абыем мина өстенә баскан. Соңыннан әнинең сөйләве буенча, ул аңында булмаган, саташып кычкырган: «Иван! Степан! Пулемёт, граната», — дигән сүзләрен әни аермачык хәтерләп калган. Беркадәр тынычланып тора да, тагын шулай саташа башлый. Бу хәлләр берничә көн дәвам итә. Доктор килермен әле дип вәгъдә иткән була, тик сугыш вакыты бит, аның исендә синең абыең гына тора димени. И-их, шул чагында медсанбатта операция ясаган булсалар үзенә, бәлки исән дә калыр иде. Әниләр аны яшәтү өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләгәннәр, тик примитив әйберләр белән генә нишлисең соң? Әни аның өстенә иелгән дә: «И улым, синнән башка гына ни хәлләр итәрмен инде мин», — дип сөйләнгән. Фатыйх абый ярыманлы, ярымсаташулы хәлендә: «Шамил туганым, ул бар бит. Әни, үзең, балалар», — дип сөйләнгән һәм шул сүзләрдән соң авыр гырылдап жибәргән, авыз-борынынннан кан киткән. Янә бер «дерт» итеп селкенеп куйган да мәңгелеккә күзләрен йомган. Вераның туган-тумачасы йөгереп килгән. Киткән елаш, кычкырыш!

Абыйны авыл зиратына жирләгәннәр. Әнинең башы каткан, нишләргә дә белми. Сугыш һаман дәвам итә. Инде бөтен Украина диярлек немецлардан азат ителгән. Төп юллардан безнең гаскәрләр көнбатышка бара, ә көнбатыштан әсирлектән коткарылганнарны кайтаралар. Юлга кадәр чыгарга ара ерак булса да, әни мине күрә алмаммы дип, барыбер чыга торган булган. Тире белән сөяккә генә калган кешеләрне күреп, мескен ананың йөрәге өзгәләнгән. Кешеләр ташкынына карап, әнием: «Шамил улым, мин монда», — дип эндәшә торган булган. Кайберәүләр туктыйлар да: «Апа, сиңа кем кирәк соң?» — дип сорау бирәләр. Ә ул аларга: «Минем улым Алмания, Алманиядә», — дип жавап бирә. Кечәге мәхбүсләр аңламаганнарын белдереп баш селкиләр. «Исән булса, кайтыр», — диләр. Аннары әни минем «Пролетарка» шахтасына кайту мөмкинлегем турында уйлаган һәм бу турыдагы фикерен килене Вера белән дә уртаклашкан. Вера: «Син инде, әни, бигрәк, нишләп анда кайтсын инде ул, әгәр кайтса да, «Пролетарка»дан, һичшиксез, монда кайтачак», — дип жавап биргән. Әнинең үз туксаны туксан, ул әйткән сүзендә калып, мең бәлаләр белән тәки кабат «Пролетарка»га киткән. Бик күп кимсетүләр, түбәнлекләр һәм

ачлыклар күреп, элекке «Пролетарка»сына кайткан. Ярый әле яхшы кешеләр барлык җирдә дә бар — Куприяновналар үзләре дә ярым ач булсалар да, аны ярдәмнән ташламаганнар.

## Слесарь булып эшләү

«Пролетарка» җимерек иде. Аны сафка бастыру өчен кешеләр яллый башладылар. Шахтаның элекке директоры Шаповалов кайтты. Мин дә эшкә урнашырга карар иттем, тик инде кайберәүләрнең әйтүенә караганда, штат тулганга күрә эшкә алмыйлар иде. Шулай да мин шахта начальнигы янына киттем. Ул сүзне кыска тотты: сметага бәйле рәвештә штат тулганлык белән эшкә алмыйбыз ди. Шулай да сорыйсы итте: «Кем син? Һәм кайдан?» Үземнең Алманиядән кайтканлыгымны яшереп тормадым, фамилиям — Хәнифов, дидем. Ул: «Туктале, тукта... Ә Фатыйх Хәнифов сиңа кем туры килә?» — дип сорау бирде. Мин аның абыем икәнен әйттем.

— Туктап тор әле, сөйләшеп алыйк. Ул бездә зур хөрмәткә ия кеше, стахановчы иде. Кайда ул?

Мин кыскача гына итеп абыем һәм үзем турында сөйләп бирдем.

— Ул чагында, Хәнифов, мин сине үземнең җаваплылыкка булса да слесарь итеп эшкә алам. Штат артыгы белән тулган, без шулай да хәлдән чыгу юлын табарга тырышырбыз, эшләрсең. Кадрлар бүлегенә юллама бирәм мин сиңа, документлар, шуларны тутырт. Озакка сузма.

Минем әле бернинди дә документым да юк иде. Алманиядән кайтканнарны кабул итү пунктына мөрәҗәгать итәргә кирәк иде. Электростальдән тыш мин станциядән унбер чакрым ераклыктагы Яшноватая кабул итү пунктында да эшләргә өлгергән идем. Анда миңа бер тапкыр төшке аш ашарга талон бирделәр һәм шул ашханәгә беркеттеләр. Бу справка белән мин паспорт өстәленә мөрәҗәгать иттем һәм хәрби комиссариатка да кагылдым. Шунсы бар: паспортны алты айга гына бирделәр, кайберәүләргә хәтта өч айга. Соңыннан бу срокны бер елга кадәр озайттылар. Бу кадәресе ник кирәк булгандыр, һич аңлашылмый.

Бардым. Урнаштым. Эшкә керештем. Безгә беренче категорияле карточка бирделәр. Аңа ит, май, шикәр, он, икмәк ише әйберләрне 700-800 грамм алырга була, ә әнигә, иждивенец буларак, 400 грамм. Тормыш акрынлап үз эзенә төшеп килә башлады. Тормыш шартлары да беркадәр җайланды. Артыгы булмаса да, тапкан кадәресе җан асрарга җитә иде. Иң мөһиме — икмәкне көненә бер килодан артыграк ала башладык.

## Бәла

Безнең элекке фатирга ниндидер күп балалы гаилә кертелгән иде. Күп йортлар гомумән җимерелгән. Шахтадан якында гына яшәүче бер ялгыз карчыкка фатирдаш булып кердек. Ул бездән бик канәгать иде, чөнки ни әйтсән дә, ике ялгыз карчыкнын сөйләшеп сүзләре бетә димени.

Беркөнне төшке ашка кайттым. Тик әнинең бер дә кәефе юк һәм ул өстәл янына утырырга уйламады да. Мин аннан: «Әни, берәр нәрсә булмагандыр бит, әллә авырдыңмы?» — дип сорадым. Ул: «Юк» , — ди ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Ә нәрсә булды соң?

Сүзгә хуҗабикә килеп кушылды.

— Шамил, мин сиңа бер сүз әйтәм, тик син ачуланырга тырышма инде.

Әлбәттә, мин әйткәннәр синең кәефеңне бик нык җибәрәчәк, шулай да әниенне орышмаска тырыш, яме.

— Әйтегез соң инде нәрсә булганын.

— Әниең базарга барган иде һәм аның кесәсеннән икмәккә дигән карточканы эләктергәннәр.

Әле яңа ай башланган гына иде һәм карточка нибары бер тапкыр ипи алып калган килеш. Мин башыма кан йөгергәнен сиздем. Ничекләр итеп киләсе айда бирәсе карточкага кадәр яшәргә соң? Карточкага «югалган очракта яңартылмый» дип язып куймасалар ярар иде. Мин, бәлки, әнигә кычкырмыйча түзә алмаган булыр идем, монда өлкән яшьтәге чит кешенең булуы роль уйнады. Аннары аны мин бик нык җәлләдем дә. Күпне кичергән инде ул бичаракаем, өстәвенә, өлкән улы үз кулында җан биргән. Җитмәсә, әниенең бер күзе дә начар күрә. Ни йөзем белән кычкыра алыйм ди инде мин аңа? Аннан ни файда, әнине кабат тирән кайгыга салу гына була ич.

Хуҗабикә угрыларны дөньядагы иң әшәке сүзләрне әйтеп каһәрли: «Күзләре сукырайсын, куллары корысын иде», — ди.

Мин берникадәр дәшми торгач, үземне кулга алдым һәм: «Әни, кайгырма син берүк. Мондыйны гына күргән бар инде. Югалмабыз әле», — дидем. Хуҗабикәнең йөзе яктырып китте, ул елмаеп җибәрде. «Мин сиңа, кайгырма, Гөләйхан, дип әйттем ич, ә син курыккан идең». Әниенең кайгырганы күренеп тора. Аның зур төшенкелеккә бирелгәнен күреп, мин дә авызыма капкан ипиемне чак йоттым.

Халык хәерчелектә яши. Шулай да без күңел ачарга җаен таба идек. Бигрәк тә яшьләр күнелен төшермәде. Төрле вечерлар оештырдылар, урамнарда гармун тартып җырлап йөрделәр. Һәр ял саен кемнең дә булса өендә төрле уеннар, биюләр оештырдылар. Урыслар һәм украиннар: «Татарлар беркайчан да борыннарын салындырып утырмый, һәрчак җырын да, биюен дә оештыралар», — диләр.

Карточканы югалтканнан соң, мин нишләргә икән дип уйлана калдым. Янәшәдә генә зур бер бина төзелеше бар иде. Һәм аның янәшәсендә төрле озынлыктагы штабельләр ятканын белә идем. Алар бик кыйммәт йөри. Бистәдән ерак түгел, балка аркылы гына шәхси хуҗалык йортлары төзү бара. Анда тырышлыклары белән даны чыккан мишәрләр төзи. Алар бик сайланып тормыйлар, такта, борыслыклар, рамнар, ишекләр һәм башкасын алалар. Ничектер яшәргә кирәк иде. Төннәрен мин дә ул якларга барып чыгарга уйладым. Тырыш мишәр халкы нәрсә китерсәң, шуны ала иде. Төнлә башта ул-бу куркынычы янамый микән дип карыйм да «ауга» китәм. Башта каравылчының кайда икәнлеген карыйм. Әгәр бар да тыныч икән (каравылчы будкада булса ягъни), мин тавышсыз гына килеп, будкадан ерак түгел өемнән биш метрлы биш тактаны алып таю ягын карыйм. Мин һәрвакыт бер үк сатып алучыга алып бара торган идем. Түләвен дә саранланып түләми иде ул кеше. Һәрхәлдә, икмәккә җитә иде. Эштә мине йокы туймаганлыктан иснәтә. Ябыгып та киттем. Минем белән эшләүче кулдашым: «Әһә, төн буе кызлар белән типтергәнсеңдер әле», — дип көлә. Чынлыкта эшнең ничек торганын белсәләр, нәрсә әйтерләр иде икән алар?.. Шулай акрын гына ташуымны беләм.

Берсендә килдем дә каравылчының будкасын күзәтергә керештем. Ул күп вакыт тәрәзәсе буена утырып чәй эчә яисә укып утыра. Ә хәзер әле күренми. Мин аны ниндидер йомышы чыгып, өенә кайтып киткәндер дип уйладым. Сак кына атлап такталар өеме янына килдем дә берәмтекләп читкә алып куя башладым. Өемдә төгәл биш данә җыелган такталарны саклык белән генә

жилкәмә салдым. Инде китәргә җыенган җирдән кемдер кулымнан килеп тотмасынмы? «Тукта!» Мин кулымдагы йөгемне җиргә ташладым. Тик мине таныдылар. «Ә, Хәнифов, син икәнсең әле». Моңа гаҗәпләнәсе юк, посёлок зур түгел, күпләр бер-берсен танып беләләр.

— Будкага керик әле.

Кердек. Берни эшләр хәл юк. Мин каравылчыга бөтенесен сөйләп бирдем.

— Әйе, мин бу турыда ишеткән идем. Беләсеңме нәрсә, син алганнан гына әлләни зыян килми. Мин кайчагында прорабларның үзләренең дә күпләп каядыр озатканнарын беләм. Һәм билгеле инде, бушка түгелдер. Тиздән ай ахыры җитә, яна карточка биргәнче ташый бир әйдә. Әниең белән сиңа ачка үләргә димәгәндер бит инде. Түлке шуны бел: әгәр дружинниклар яисә участковыйлар кулына эләксәң, мине бу эшкә бутама.

Бөтенесе дә әйбәт кенә бара иде, кызганычка, тиздән әлеге изге җанлы каравылчы авырып китте. Аның урынына сыңар куллы дружинникны куйдылар. Кулын сугышта югалткан, диделәр, үзе шундый явыз, аңа эләкмәвең хәерле. Янадан бер атна гына түзәсе калды, ә такталарны алырга берничек тә әмәл юк. Шулай да мин ул бер кулсыз каравылчы белән уртак тел таптым тагын, аңа да өлеш чыгара башладым. Шулай эшләмичә башка чара юк, шулай эшләмәсәң — ач үлем көтә.

Мин инде ташкүмер ташу эшенә хирысланып киттем. Тимер юлда ташкүмер төялгән йөзләрчә вагон җибәрергә үз чиратларын көтә. Кизү тимер юл составының бер ягында булганда, без — ташчылар җайлап кына икенче яктан сайлыйбыз. Әле бөтен шахталар да ташкүмер бирә башламаган. Кайберләрен ремонтлап кына киләләр. Күмер җитеп бетми. Төнлә берничә чиләк ташып куясың, ә икенче көнне кич белән шул ук күмерне тагын базарга илтергә кирәк, акчасына ипи сатып аласы.

Тырыша торгач, без икенче айның башына кадәр җан асрый алдык. Ниһаять, мин яна карточка сатып алдым һәм без тернәкләнеп киттек. Шулай да ягулык яклары такыр иде. Әле газ һәм электр плитәләре заманы түгел. Плитәләрне ягып җылытышлы. Утын да, урманнар да юк, әллә кайларга җәелеп киткән далалы Украина. Юкка гына җырда: «Донецки даласына яшь егет кырга чыкты», — дип җырланмый торгандыр инде.

## Кулга алу

Минем Габидулла исемле дустым бар иде. Аларның гаиләсендә янә дүрт ир балалары бар. Җиңелдән яшәмиләр. Берсендә ул минем янга килде дә: «Без бүген төнлә әти һәм тагын ике энекәш белән ташкүмергә барабыз. Безгә иярәсеңме?» — диде.

— Барам.

Бишәүләп киттек. Капчыклар аркада, юлга якынлашып кына киләбез, вагоннар янына да килеп җитмәдек, засадада яткан җиреннән берничә милиционер күтәрелеп чыкмасынмы?! Арадан берсе: «Тукта! Урыныңнан кузгалма!» — дип кычкырып, берничә тапкыр һавага атып җибәрде. Безне төрле яктан урап, тимер юл милициясенә алып киттеләр. Бөтен өс-башыбызны тентеп чыктылар, бигрәк тә аркаларны җентекләп карадылар. Аннары идәнгә утырырга әмер булды, исәпләре иртәнге якка кадәр шунда утырту инде боларның. Хәерле булсын, мондыйны гына күргән бар анысы. Иртә белән следовательләр килеп сорау алырга керештеләр.

— Вагон ишекләреннән пломбаларны куптаргансыз һәм аннан берничә

капчык он алгансыз. Сез аларны вакытлыча каядыр урнаштырып торгансыз һәм хәзер калганнарын алырга килгәнсез.

Әнә ни өчен безнең киемнәрне җентекләп тикшергәннәр икән. Тик безнең өстә бернинди дә онга буялган урын табылмады шул. Без бернәрсә дә белмибез дип җавап бирдек. Следователь миңа: «Син нәрсәгә киреләнгән буласың. Әнә, дустыңның энекәше бөтенесен әйтеп бетерде инде», — дигән була. Мин моңа каршы: «Әгәр гаебен таныган икән, җавабын да бирсен», — дип җавап бирдем. Мин тагын болай дип тә өстәдем: «Без күмергә дип бара идек, ә бернинди дә он турында белмәдек».

Габидулланың әтисен, өч малаен белән урлашырга йөрергә оят түгелме сиңа, дип оялтырга маташтылар. Ул: «Нәрсә эшләргә соң безгә, катып үләргәме?» — диде. Бу вакытта ташкүмер урлап тотылган өчен бер елга кадәр төрмәгә ябу турында закон чыккан иде инде. Ә бит без күмергә килеп кагылырга да өлгермәдек. Коридорда утырабыз шулай. Берәмтекләп допроска чакыралар. Шул чагында тимер юллар буенча милиция полковнигы килеп керде һәм: «Кайда сезнең каракларыгыз?» — дигән сорау бирде. Бер милиционер безгә төртеп күрсәтте.

— Хәзер үк өйләренә кайтарып җибәрегез. Эшләпәләр! Чын каракларны ычкындыргансыз бит. Кем шулай эшли инде, җә? Тегеләрнең килгәннәрен көтеп алырга кирәк иде, капчыкларга тотынгач кына «шалт» итеп атып җибәрергә һәм тоткарларга кирәк иде. Югыйсә, юл буенча үтеп барган кешеләрне эләктереп алгансыз бит. Аларны күмер өчен дип тә җавапка тартып булмый. Алар бит аңа да кагылмаганнар хәтта.

— Өйләрегезгә кайтыгыз.

Без кайтып киттек. Тик минем бу матавыклар аркасында эшемдә прогул килеп чыкты.

## Кыскартуга эләгү

Күпмедер вакыт үткәннән соң, мине Шаповалов урынына шахта начальнигы булып калган баш инженер Поляков чакыртып алды. Шаповаловны дәрәҗәсе буенча күтәреп, Мәскәүгә алганнар икән. Поляков мине чакыртып алу белән турыдан-туры: «Сине эшкә абыең аркасында алып тордылар. Ансын ничек эшләгәннәрдер, миңа караңгы һәм ул миңа кирәк тә түгел. Мин сине штаттан тыш тота да алмыйм. Өстәвенә, прогулың да бар», — дип, минем белән саубуллашырга теләвен белдерде. Мин Поляковка отгулның нәрсәдән килеп чыкканын аңлатырга тырыштым. Поляков моның сылтау була алмавын белдерде. Шулай итеп, мин яхшы урыннан колак кактым. Төзелешкә эшкә алалар иде алуын, тик анда карточканы да икенче категориянекен генә бирәләр. Һәм хезмәт хакы да бик түбән. Анда баруны кирәксенмәдем.

## Стропальщик булып эшләү

Бездән өч чакрым ераклыкта 13 нче номерлы шахта бар иде. Миңа анда җир асты эшләренә стропальщик итеп эшкә алырга мөмкин булуы турында әйттеләр. Кайчагында мин бу шахтаның бистәсендә кичке уеннарда булгалаган идем. Анда кайберәүләрне беләм дә. Шулай итеп, эшкә керештем. Мин тиздән Поляковның үз туганын минем урынга алганын белдем. Мастер аның слесарь эшендә бернәрсә дә белмәве турында әйтте. Үзе, тирәге барын белеп, борынын күтәргән була ди. Ачуым килеп, Поляков янына киттем шулай. Һәм аңа болай дип белдердем: «Сез минем белән нәрсә эшләдегез? Шаповаловның булмавы

кызганыч. Ул моны болай гына калдырмаган булыр иде». Поляков күзен дә йоммый: «Штат берәмлеген күтәрделәр, шуңа күрә алдык». Ызгышып киттек, мин аңа шактый гына авыр сүзләр әйттем. Ул милиция чакырам дип куркытты. Китеп барудан башка чарам юк иде.

Яңа эш урыным якында түгел, гел җәяү йөрешле. Аннары вагоннарны элэктерүчеләр гел диярлек чабып эшләргә тиеш булып чыкты, чөнки житешә алмыйлар. Минем аякларымда бердәнбер ботинкалар. Кем әйтмешли, ашка да шул, эшкә дә шул. Ботинкаларым инде таралырга житкән иде, шахта начальнигы янына кердем, башка төрле аяк киемнәре юк микән дип белешүем. Складта югыйсә аяк киемнәре бар икән. Тик аларны шахта начальнигы ризалыгы белән генә бирәләр. Кемнәргәдер эләгә, ә кемнәргәдер — юк. Мин кабаттан шахтага киттем: «Складта запас киемнәр бар ич», — дидем. Ул: «Син аны каян белдең?» — ди. Мин: «Белдем инде», — дигән булам.

— Завсклад әйттеме?

— Белмим, кемдер ул анда. Мин завскладны йөзгә танып белмим, — дим.

Начальник телефон трубкасын алды да завскладны утлы табага бастыра башлады. Мин аптырап калдым, түзмәдем:

— Сез нәрсәгә бер гаепсез кешене орышасыз? Аның бит бер гаебе дә юк. Иң яхшысы — сез миңа аяк киеме — спецовка бирегез, мин бөтенләй яланаяк, — дидем.

— Син бит немецларда яланаяк та, яланөс тә эшләгәнсең, тагын ни кирәк?

Мин инде тыелып кала алмадым, аның адресына матур гына сүзләр ычкындырдым һәм кабинет ишеген шапылдатып ябып чыгып киттем. Ул минем артымнан: «Хулиган, мин сиңа милиция чакыртам», — дип кычкырып калды.

— Үзең ычкын моннан!

Һәм мин башка анда борылып кермәдем.

## Туган авылым Кирлегәч (март, 1947)

1947 ел бара. Авылдан Фәрхури абыстай: «Өйгә кайтыгыз. Ничек тә яшәрбез әле, ачтан үлмәбез», — дип язган. Ул ел шулай ук җинел булмады, авылда да халык ачыкты, шулай да бәрәнге коткарды.

Мин Кирлегәчкә март аенда кайтып төштем. Туганнарым белән очраштым — Гаделша абый белән, яшьлек дусларым Яхъя, Шахразый белән. Кайтып төшүемә бригадир чабып килеп житте, һәркайсы үз бригадасында эшләргә чакыра. Чөнки ир затлары аз калган.

Шулай итеп, мин колхозчы булып киттем, ләкин бер бригадага да бармадым. Ул чагында колхоз рәисе итеп Чыршылы авылыннан Салахов дигән кеше куелган иде. Кагыйдә буларак, колхоз рәисләрен партия райкомы күрсәтмәсе белән башка авыллардан билгеләп куялар иде. Бу — төптән ялгыш фикер, чөнки чит авыл кешесе ят авыл һәм аның кешеләре өчен дә тырышмый шул инде. Аңа бары тик өстән төшерелгән күрсәтмә генә кирәк. Авыз-борыны канаса да, амбарында бер уч запас орлык калмаса да, ул үзенең имиджын гына кайгыртачак. Бу Салахов дигәннәре дә шундыйлардан иде. Дәүләткә икмәк тапшырганда, дәрәҗәсе югары булган. Безнең авылда яшәмәгән ул, шәп тарантаска җигелгән яхшы ат белән авыллар арасын жилдереп кенә узган.

## Чыршылы канэчкече

Минем документларымда слесарь дип язылган иде. Миңа авыл хуҗалыгы машиналары: чәчкечләр, сукалар, тырмалар ремонтларга куштылар. Эшкә керештем. Кайбер нәрсәләрне ремонтладым, тик запчастьлар юк, хәер, инструментлар да бик примитив. Шулай да мин кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырыштым. Председатель баштарак хәтта мактау сүзләрен дә кызганмады. Тик берникадәр вакыттан соң эш-ремонт эшләрне башкарырга берни дә калмады. Ул юк әйберне таләп итә башлады. Мин аның белән конфликтка кердем. Бер чәчкечне тиешле хәлгә китерергә кирәк, ә детальләрен алыштырырга запас частьлар юк. Күз күтеп тормый, чәчү дә бөтен хутына бара. Шул чагында председатель миңа күрше колхозның басуына барып, аларның төнгә калдырган чәчкечләреннән детальләрен салдырырга кушты. Мин бу хәерсез эштән баш тарттым. Иң яхшысы, басудагы бригадага эшкә чыгам, дидем. Председатель шуннан соң миңа кырын карый башлады. Шулай да чәчү эшен уңышлы гына төгәлләдек. Үсентеләр дә дәррәү күтәрелде. Бригадирлар халыкны канатландыралар: яхшырак эшләсәгез, игеннәр дә яхшырак булыр, тамагыбыз да икмәккә туяр, диләр.

Печән вакыты житте. Печән чабарга чыктык. Шулай да халык ач. Кемдер ашарга яраклы ат кузгалагы, алабута, кычыткан белән туклана. Кемнәрнеңдер сыерлары бар, сөтле аш пешереп ашый, казанына 2-3 калак он сала да, шуның эштиен пешерә. Печән чабу җиңел эш түгел. Көнозын чалгы белән эсседә селтәнүне күз алдына китереп карагыз әле. Печән чапканда көненә 200шәр грамм ипи бирәләр. Кайберәүләр шунда ук хәлсезләнеп егылалар. Шулкадәр ярлы безнең колхоз гына иде бугай. Салахов шундый хәлгә китереп житкерде аны. Күрше авылларда печән өстендә яхшы ашаталар иде. Председательләре дә хезмәтләренә тиешле игътибарны күрсәтә. Чәчү вакытында орлык урлау очраклары да булгалады. Урлашучыларны эләктерделәр.

Игеннәр өлгерде. Уңыш начар түгел. Бөтен кеше шатлана. Бер хатын бодай басуына кергән дә әле урып-җыю эшләре башланмаган җирдә берникадәр бодай сабаклары урып ала башлаган. Кырларны күзәтеп йөрүче аны эләктереп алган да, социалистик милекне урлаучы дип, авыл советына алып килгән. Сугыштан соңгы авыр елларда бу хатынны 12 елга төрмәгә утырттылар. Өендә биш баласы утырып калган.

Ул заманда бик күп кешеләрне кайсын өч елга, кайсын биш елга ирektән мәхрүм иттеләр. Дөкәнтәдә Газизәнең күршесе Мөкәррәмә яши иде. Аның абыйсы Гыйммаметдинне, 800 грамм бодай өчен әйберләрен конфисковать итеп, 8 елга төрмәгә утырттылар. Аның конфискацияләргә әйберсе дә юк иде, ахыр килеп арбаның ике тәгәрмәчен конфискацияләделәр. Бусы инде активистка Сәхибкамалның «тырышлыгыннан» килә иде. Шундый хатын бар иде, кемнең кем булуына карамастан туктатып тенти. Кайбер ир затлары 2-3 кг орлыкны кечкенә капчыкка салып билләренә бәйлиләр һәм ул ике бот арасына төшеп тора. Сәхибкамал андыйларны тентергә дә кыенсынмый, «эх» тә димичә бот араларын капшый.

Минем үземне дә аздан гына төрмәгә утыртмый калдылар. Салахов Мөхәммәтшиннар гаиләсен дошман күрә иде, ә без — Хәнифовлар — Мөхәммәтшиннар белән якын туганнар. Ничектер Мөхәммәтшиннар (минем ир-абый туганнарым) Салаховны кеше күп җыела торган җирдә нык тәнкыйтьләгәннәр. Ул шунда әйтеп куйган: «Мин бу Мөхәммәтшиннарның тамырын корытам әле», — дип. Хәнифовлар да туганлык ягыннан шуларның бер тамыры була бит инде. Мин еш кына Салахов белән сүзгә килә идем, алай

гынамы соң әле, эш кайчагында йодрык белән бәргәләшүгә кадәр барып җитә иде.

Берсендә орлык суктырган вакытта Салахов салам эскертләү бригадасын үзе җыештырды. Андый чакта саламны биеккә агач сәнәкләр белән утыртырга кирәк. Минем кулым авырта иде. Сәнәк белән саламны күтәргән саен, мин авыртудан чыраемны сытарга мәҗбүр булам. Эшне ашыгып башкарырга туры килә, чөнки яңгыр ява башлаганчы өлгерергә кирәк. Төнлә трактор уты яктысында да эшне туктатып тормыйбыз.

Кулым бөтенләй диярлек буйсынмый башлады. Көндез медпунктка киттем. Анда яшь кенә шәфкать туташы, ул курсларны да әле яңарак кына бетергән. Минем ярамны караганнан соң: «Мин моны бернишләтә дә алмыйм», — ди. Мин Салаховка киттем, ә ул миңа: «Симулировать итмә, эшләвеңне бел», — ди. Төнгә кабат эшкә чыгарга туры килде, ә кул үтереп сызлый, аннан һич котылу юк. Сәнәкне тотып аттым да өйгә кайтып киттем. Бер көн чыкмадым эшкә, ике көн. Өченче көнне Салахов үзе килде. Урамнан: «Шамил, Шамил», — дип кычкыра бу, ә үзе тарантасыннан да төшми. Каккан казыктай, бүкәнгә охшап тик утыра. Мин берни дә эндәшмим. Ул кычкырынды-кычкырынды да китеп барды. Мин мунча яктырып, анда яхшылап парланып чабындым. Кул һәм җилкәне нindидер үлән белән яхшылап парладым, шуннан соң җиңелрәк булып китте. Кич белән колхозның әйтеп йөрүче йомышчысы килмәсенме?! Кич идарә утырышына чакырып килүе икән. Утырышны Салахов ачып җибәрде: «Без сине колхоздан чыгарабыз», — ди бу. Мин бик аптырап китмәдем: «Рәхим итегез, мин бик рәхәтләнеп үзем эшләгән Донбассыма китәм», — дидем. Ул: «Без сиңа документларыңны бирмибез, колхоз члены булып торуыңны да яздырмыйбыз», — ди.

— Миңа сездән берни дә кирәк түгел. Минем паспортым да, хәрби билетым да бар.

— Ничек инде? Кем дә кем документ белән кайта, аларны участок милиционеры ала бит! — дигән сорау һавада эленеп калды.

Милиционер монда иде. Салахов аңа: «Ни өчен документлары аның үзендә калды?» — дип ташланды. Ә ул: «Поездда өйгә кайтып барганда, юлда ташландылар һәм тартып алдылар, дип акланды бит», — дип җавап бирде. Мин инде аптырап сөйләшмим: «Ярар, сау булып торыгыз инде. Мин китәм һәм кабат шахтёр булачакмын. Сезнең алда баш игәнче, шулай хәерлерәк».

Салахов, беразйомшара төшеп: «Ярар, кызма әле син. Әйдә яхшылап кына сөйләшик», — диде. Өстәвенә, бригадир да мине яклап арага керде. «Сез нәрсә инде шулхәтле текә кыланасыз, ул бит яхшы эшчеләрдән санала». Мин беркадәр киреләнеп маташканнан соң, калып торырга ризалаштым.

Янәдан эшкә керештем. Икмәк суктырабыз, бөтен әзер икмәкне дәүләткә озатып баралар. Йөкләмәләрне үтик тә, аннары артык калганын өләшербез, диләр. Көтәбез. Тапшыру һаман дәвам итә. Безгә һәр хезмәт көненә 200 грамм бирделәр дә, әлегә шуның белән шул. Беркөнне Салахов минем белән тагын ике кешене чакырды да: «Яңгырлар ява башлаганчы, орлык складының салам түбәсен алыштырасы бар иде», — ди. Искесен төшереп, яңасын күтәрергә кирәк була инде ягъни. «Башкарган өчен сезгә ит һәм икмәк белән түләячәкмен», — ди. Без кичекмәстән эшкә керештек һәм тиз арада житкерелгән бурычны башкарып та чыктык. Ә ул безнең янга килә, мактый, вәгъдә итә һәм китеп тә бара. Тагын бер тапкыр безнең янга килде бу. Мин аңа: «Без инде эшне төгәлли яздык, кайчан исәп-хисап ясыйсың?» — дигән сорау бирәм. Ул эндәшми. Мин түзмәдем: «Кайчанга кадәр кешенең башын әйләндерергә була?» — дигән сорау бирдем. Үзем дә сизмәстән, штыклы атакага барган шикелле, сәнәк белән

аның өстенә киләм икән. Исәбемдә явызлык юк, бары күнелгә җыелганнарны гына әйтү уемда. Ул куркып калды бугай, атының сыртына чыбыркы белән берне сыдырды да, чак кына тарантасыннан мәтәлмичә, җан-фәрманга чабып китте. Киткәндә авызыннан: «Ну, Шамил, кара аны!» — дигән сүзләре генә сытылып чыкты. Якын-тирәдәге бөтен халык шаркылдап көләргә керешге. «Ну председательне куркыттың да соң», — диеште алар. Ә минем андый нәрсә уемда да юк иде.

Кич белән идарәдә утырганда ул: «Хәнифов мине сәнәк белән кадап үтерергә теләде», — дип сөйләгән, имеш. Мине чакырып алдылар. Салахов: «Ну, Хәнифов, идарә членнарына мине ничек сәнәк белән кадап үтерергә теләгәнеңне сөйлә инде», — ди.

— Сез нәрсә? Мин бу турыда хәтта уйлап та карамадым. Сәнәкне читкә алып куярга гына өлгермәдем. Халыкны тагын күпме алдап йөрисең, дип кенә сорыйсым килде. Сезнең вәгъдәләрегезне бер мин генә ишетмәдем. Без үзебез әйткәнне инде төгәллибез, ә сез биргән вәгъдәгезне үтәргә уйлап та карамыйсыз, — дим. — Ә хәзер мәсьәләне махсус кабартасыз. Гаепләү өчен форсат килеп чыгуга шатланасыз.

Бригадирлар мине яклап чыктылар: «Юк, Салахов абзый, ул беркайчан да андый адымга бармаячак».

Салахов бу юлы да чигенергә мәҗбүр булды. «Ну ярар, Шамил! Ну күрерсең әле син дә миннән», — дип кенә куйды.

## «Активистка» «Сәхибкамал»

Кешеләр шулай да азлап булса да ашлык ташыдылар. Чөнки беркемнең дә ачка үләсе килми, яшәргә кирәк. Аннары аны ярма яргычтан чыгарып, бодай ярмасы рәвешенә китерделәр. Активистка Сәхибкамал турында шундый сүзләр йөри иде, имештер, ул ярма яргычта он чыгармыйлар микән дип өй борынча иснәнеп йөри икән. Берсендә, эскерт кырыннан үтеп барганда, бер ир заты аның ярма тартканны тыңлап торганын күреп алган да, чыдарлыгы калмагач, сәнәгең өстенә ыргыткан. Тик үтерә алмаган, табанын гына җиргә кадап куйган. Шуннан соң бу хатын бик озак аксаклап йөрде. Ничек кенә булмасын, бу ирне гаепкә тартмадылар. Күпчелек халык Сәхибкамалның үзен гаепләп чыкты.

Аның турында басудагы кыр эшеннән кайтканнарны да саклап тора дип сөйлиләр иде. Бригадир малае шундыйрак очрак турында сөйләде: «Язгы чәчүдә басудан кайтып киләм, анда бодай чәчкән идек. Инеш аркылы чыга торган күпер янына якынлаштым. Инде караңгы төшеп килә иде. Карасам, күпер астыннан адәм баласына охшаган нәрсә чыгып килә. Чәчләре озын үзенең, таратып салган. Юлга чыгып басты бу, кулын күтәрә. Якын ук килдем, кулымда тимер чиләк. Тоттым да шул тимер чиләк белән теге сурәтнең башына берне китереп ямадым, атымны камчы белән куалап, алга ыргылдым».

Ә кич белән идарәдә колхозның бөтен активы соңга кадәр утырды. Иртәнге планнарны да тикшерделәр. Шулчак канга баткан Сәхибкамал килеп керде. Аның киемнәре генә түгел, таратып салган чәчләре, йөзе дә канга баткан иде. Бөтенесе «ах-ух» итте. Ул бригадир Әхмәдулланың улы китереп сукканын сөйләде. Әхмәдулла малаен алып килергә кеше җибәрделәр. Озак та тормады, малай килеп җитте. Аннан эшнең ничек булуы турында сораша башладылар. Бригадир малае үзенең начар күрүе турында, чәчләрен таратып салган хикмәтне су анасына охшатуы турында сөйләп бирде. Бөтен кеше дәррәү көлеп җибәрде. Кызык булса да, көләргә унайсызрак иде. Сәхибкамал авыртуы турында зарланып сөйләнә. «Ярар инде, нишләрсең, хата килеп

чыккан бит», — диеште кешеләр. Сәхибкамал һаман: «Ой, авырта бит», — ди. Кешеләр аның зарлануыннан туя башладылар бугай. Кайберәүләр: «Иснәнеп йөрмәскә кирәк иде, мондый нәрсә килеп чыкмаган булыр иде», — ди. Шуның белән ошбу хакта сүзләр дә төгәлләнде. Бригадирның малае өенә кайтып китте. Әле аннан соң да бригадир малаеның «су анасы» белән очрашуы турында сүзләр күп йөрде.

## Председательнең явызлыгы

Ничектер көтмәгән җирдән председатель миңа карата үзен яхшы мөнәсәбәттә тота башлады. Тик ул аны икейөзлеләнеп кенә эшләгән икән. Мине алда бик зур күңелсезлекләр көткән, кайсылары турында мин хәтта күз алдыма да китерә алмаган идем. Хәер, күңелсезлек дип әйтү генә аз булыр. Әгәр дә ул тормышка ашса, аны чын трагедия дип әйтергә булыр иде. Без өйдә булмаган чагында — мин эштә, ә әни хатыннар белән урманга чикләвеккә киткән — безнең сарайга Сәхибкамал җитәкчелегендә берничә активист килеп кергән һәм тарткычта берничә килограмм бодай тапкан. Мине шундук колхоз идарәсенә чакырып кайтардылар һәм колхоз милкен урлауда гаепләделәр. Мин анда бодай булуын танудан баш тарттым. Миңа: «Менә рәхим ит, Сәхибкамал, берничә активист белән, урланган әйберне табып алган», — диләр. Салахов: «Хәзер урып-җыюның иң кызган вакыты, ә без аның дәүләткә каршы корткычлык алып баруы нәтиҗәсендә эштән аерылырга мәҗбүр булдык, — ди. — Икмәк ул — хөкүмәт байлыгы. Ярый, хәзергә вакыт юк инде. Кич белән бөтен халыкны колхозның идарә утырышына чакырачакбыз һәм анда участок милиционеры да киләчәк. Ә син, Миннегол абый, — дип конторада кизүлек итүче абзыйга мөрәҗәгать итте Салахов, — бу кешене чыгарып җибәрмә». Һәм мине идарә бинасының иң аргы башындагы бер бүлмәгә ябып, ишегенә йозак элделәр. Утырам шулай. Берникадәр вакыттан соң тәрәзә каршына килеп бастым. Конюшня күренә. Акрын гына тәрәзәне ачтым, тышка үрелеп карадым — беркем күренми, тып-тын. Уйланып шактый озак басып торам. Болай булса, Салахов һәм аның төркеме мине төрмәгә утыртып куячак бит! Ниндидер килограммнар өчен күпме халыкның башына җиттеләр инде. Болай батмый әле бу. Тышкы якка чыктым. Әгәр урам якка алып чыгучы капкага барсам, Миннегол абый мине, һичшиксез, күреп калачак. Беркадәр уйланып басып тордым. Бөтен әйләнә-тирәдә төзелгән корылмалар. Кабат ат абзарының түбәсенә мендем һәм урам ягына сикердем. Урам буенча өйгә кадәр кайту озак вакытны алмады. Өйгә кайтсам, ишек йозакта, ә ачкыч әнидә. Күрә торып ишекне ватып булмый бит инде. Нишләргә соң әле? Сарайда балта бар иде. Мин аны алып, тәрәзә янына килдем. Кәкрәйтеп куелган кадакларны турайтып, тәрәзә рамнарын алдым. Өй эченә үттем, киендем, кирәкле документларны җыештырдым. Янадан урам якка чыктым да тәрәзәне урынына куйдым. Аннары тизрәк авылдан чыгып таю ягын карадым. Карасам, урамнан каршыма берничә хатын-кыз кайтып килә (бүген базар көне бит әле). Базарга бары тик бригадирның рөхсәте белән генә җибәрәләр, чөнки урак өстенең иң кызган чагы. Бу бер яктан аңлашыла кебек, тик барыбер крепостное право вакытларының исе килеп киткән кебек тоелды. Мин хатыннарның килеп җиткәнен көтеп тордым. Алар минем белән тигезләшкәч, сорау яудырырга керештеләр: «Кая җыендың син болай?» Ә минем кыяфәтем бик күңеллеләрдән түгел. Турысын әйтеп сөйләштем: «И-ии, яхшы күңелле авылдашларым, күз алдыгызда: беркемгә дә начарлык кылганым юк. Авылны ташлап китәргә

туры килә. Әнигә әйтегез инде, мина Донбасс якларына китмичә булмый һәм аны юатырга тырышсагыз икән, минем өчен бик кайгырмасын. Әгәр мин хәзер уйлаганымны эшләмәсәм, начар булачак». Ә хатыннар сорау белән күмеп ташладылар: «Нәрсә килеп чыкты соң? Юк нәрсә өчен генә төрмәгә утыртмыйлар» һ.б. Мин сүзне озакка сузмастан: «Озаклап сөйләргә вакыт юк, мине теләсә кайсы вакытта килеп эләктерергә мөмкиннәр. Сәбәбен авыл буенча чыны катнаш уйдырмасы таралгач белерсез. Нәрсә дип сөйләсәләр дә ышанмагыз. Бу хәерсез гамәлләрне үч алу максатыннан Салахов оештырды. Аның мине нинди генә юллар белән булса да төрмәгә утыртасы килә». Һәм мин китеп бардым. Хатын-кызлар күздән югалгач, бөтенләй башка якка борылдым. 16-17 яшьлек егетләребез эшләп ятучы басуга килдем. Алар арасында безнең күршенең Мәхмүт исемле малае да бар иде. Алар кырда кунып эшлиләр. Мин алар янында ике көн үткәрдем. Егетләр минем хәлемә кереп, үзләренең болай да такыр тәгамнәре белән бүлештеләр.

Өченче көнне кинәт кенә басуга агроном булып эшләүче Җәүһәрия килеп чыкты. Кияүдә түгел әле ул, безгә кардәш тиешле Хафиз исемле укытучы белән эшләп йөри иде. Җәүһәрия сөрелгән җирләрне карап чыкты, тырманың нинди тирәнлеккә кергәнлеген чамалады. Ул, әлбәттә, мине монда очратуына нык гаҗәпләнде. Авылда мине Донбасс якларына киткән икән дигән сүз таралган булган. Салаховның мине төрмәгә утыртасы килү теләге бик көчле, ди. Ул үзенә сәнәк белән ташланганны һич кенә дә гафу итмәгән.

Җәүһәрия мине сатмаска сүз бирде. Тик ул күздән югалгач, Мәхмүт напарнигының читкәрәк киткәнен көтеп алды да: «Син караңгы төшү белән авылга кайт һәм сиздермичә генә безнең сарай түбәсендәге печәнлеккә менеп ят. Ә минем напарникка станциягә китәм дип әйтерсең. Әтине мин үзем кисәтермен. Ул, әлбәттә, куркып калыр инде, тик мин аны ничек булса да күндерергә тырышырмын. Соңыннан берәр нәрсә уйларбыз тагын». Без нәкъ Мәхмүт әйткәнчә эшләдек тә. Төннәрен зур саклык белән генә өйгә кайтып килгәләдем. Әнием бик нык курка. Мин шулай бер атна чамасы качып йөрдем. «Иртәнге якта берсендә килгәннәр дә малаең кайтмадымы?» — дип әнкәйне тинтерәткәннәр. Ике төн өйгә кайтмадым. Печәнлектә ятам шулай, кемнеңдер кергәнен ишетеп алдым. Кайсы булыр? Тынымны да чыгармаска тырышып ятам. Кемдер баскыч буенча өскә таба үрмәли. Селкенмәскә дә тырышам. Баш түбәсе күренде, аннары ул бөтенләе белән пәйда булды. Гәүдәсен турайтты һәм мине күреп алды да чак кына аска мәтәлеп төшеп китмәде. Мин аны эләктереп алдым һәм: «Тавышыңны чыгарма!» — дим. Бу — күрше малае икән, ул шунда ук еларга һәм акланырга кереште. «Мин башкача болай эшләмәм», — дигән була. Мин: «Нәрсә эшләмәм дисең?» — дим. Ә ул: «Йомыркаларны урламам бүтән», — ди. Мин аңа утырырга ымладым да: «Ярар, — мәйтәм, — дускай, мин беркемгә дә әйтмәячәкмен». Ә ул һаман елый бирә: «Беркемгә дә әйтмә инде», — дип ялына.

— Юк, юк, әйтмим. Әйдә, шулай килешәбез: мин сине күрмәдем, син мине.

Малай сөенеченнән нишләргә белмәде һәм алдамаячакмын дип ант итте. Мин аннан: «Урлашырга килгән кешенең алдашмаячагына ышанырга була микән?» — дип сорыйм. «Юк инде, ышан сүземә», — дип ант эчә. Шулай итеп, без «ике карак» үзара килештек. Ул ишегалдыннан йөгереп чыгып китте. Кичен әти-әнисе белән Мәхмүт килде, мин аларга бөтенесен сөйләп бирдем. Алар да пошаманга калдылар. Яшереп саклаган өчен аларга да ярыйсы ук каты эләгергә мөмкин иде.

## Китү. «Ташкент — икмәкле шәһәр»

Шул кечне үк үземнең яшеренеп яткан җиремне ташлап, бездән 18 чакрым ераклыктагы Чыршылы авылына китеп бардым. Соң килгән идем, бу вакытта йоклыйлар. Шакыдым. Ишекне Сәетгали җизни ачты. Ул гаҗәпләнеп калган иде, минем ни өчен төнлә соңлап йөрүем белән кызыксынды. Фәхрүшә абыстай да торып чыкты, ул да минем соңлап килүемә аптыраган иде». Әниең белән берәр нәрсә булмагандыр бит», — диде. Мин башымнан кичкәннәрне сөйләп бирдем. Һәм аларның печәнлекләрендә ике атна яшәдем. Аннары җизни үзләренең колхоз рәисеннән штамплы һәм бланклы кәгазь табып бирде. Анда ул мине колхозларында тимерче итеп яздырган иде. Җизни үзе үк председатель һәм секретарь урынына кул да куйган. Бу справка әле һаман да миндә саклана.

Алгарак китеп булса да, шуны әйтим: 30 ел узганнан соң, хатыным Нурияи белән безнең Кирлегәч авылына кайттык, кайчандыр шунда яшәгән урынны күрәсебез килде. Билгеле инде, безнең ул вакытта яшәгән йорттан инде берни дә калмаган. Шулай да мин кабаттан чишмәне һәм башка урыннарны күрүем белән бәхетле идем. Бер уңайдан үземнең коткаручыларны — Мәхмүт белән аның әтисе Нургаян абыйны күрәсем һәм алар алдында баш иясем килгән иде. Кызганычка, аларны исән килеш туры китерә алмадым. Урыннары җәннәттә булсын! Мәхмүт миннән ике яшькә кечерәк иде, ул трагик рәвештә үлгән.

Сентябрь ахырларында көннәр салкынайтыбрак җибәрде, мин Урта Азия якларына акча эшләргә чыгып киттем.

Апам миңа котелоктан алып бераз май бирде һәм янына сохарилар өстәде, җизни сандыктан алып, кара көнгә дигән запастан 150 сум акча бирде. Мөгаен, бу барлык кагылгысыз запасларының тулы суммасы булгандыр дип уйлыйм. Һәм аларның алты бала үстергән бер вакытларында. Апа Хатыйп абыйның адресын бирде. Ул — туганнар арасында иң өлкәне.

Поезд көткән арада, әйтерең бармы, мин авылдашымны очраттым. Ул гаҗәпләнеп, кая юл тотуым белән кызыксынды. Мин инде үземнең Урта Азиягә баруымны тәгәл хәл иткән булсам да, Донбасска дип ялганладым.

Сугыштан соңгы бу чорда билетлар юнәтү бик катлаулы иде. Мин билетсыз гына Куйбышев шәһәренә (хәзер — Самара) барып җиттем. Вагонның тимер баскычларына басып, вагон өсләрендә, хәтта тамбурда килеш бара алсаң, сиңа уңайлы туры килде дип санарга була иде.

Куйбышевта үзара нәрсә турындадыр бәхәсләшә торган кешеләр яныннан үткәндә, мин аларның «билет» дигән сүзләрен ишетеп калдым. Аларга, авыру буларак, билетны бушка бирәләр икән, дәваланырга барыр өчен ягъни. Ә аларның барасылары килми һәм Ташкентка кадәр билетларын сатмакчы булалар. Миңа исә Чирчикка эләгергә кирәк, Хатыйп абый шунда яши. Сатулаша торгач, килешеп, аларга барлык акчамны биреп, бер билетларын алдым. Ә икенче билетны башка бер ир алды. Юлда барганда, ул миңа база мөдире булып эшләве турында ачылып китте, тикшерү килеп, житмәүчелеген тапканчы чыгып киткән һәм шулай төрмәдән котылып калган. Ана, следовательгә ришвәт биреп, чак качып котылу мөмкин булган. Хәзер Сәмәркандка баруы икән.

Ниһаять, Ташкентка кадәр барып җиттек. Минем юлдашларыма башка поездга утырып барырга кирәк иде. Юлдашлар белән саубуллашканнан соң, шәһәр яны поездына күчеп утырдым. Туганым Чирчик янындагы Боз-Су станциясендә яши.

Килеп җиттем. Кирәкле йортны эзләп таптым. Бер ир-ат кулъюгычта юынып тора. Кычкырып эндәшәм, җавап бирүче юк. Нindидер хатын чыкты. «Ул колакка каты. Сезгә кем кирәк?» — ди бу. Мин адресымны күрсәтәм, тик

минекеләр Сәмәркандка киткән икән. Аларнын уллары Шәһит тә армиядән демобилизацияләнеп кайткан һәм, Алманиядән тикле кайта торып, аларны тапмаган.

Минем акчам калмаган иде. Апам биргән акчаны күптән «ашап бетердем». Шулчак әлеге хатын күрше йортка керергә кушты. Анын хуҗасы синен абыен белән бик дус иде, диде. Мин шулай эшләдем дә. Эшнен ничек торышы турында башыннан ахырына кадәр анлатып бирдем. Хуҗа кеше хәлемне анлап, тамагымны яхшылап туйдырганнан сон, абыйнын яна адресын һәм юлга җитәрлек акча бирде.

Шулай итеп, мин кабат Ташкентка килеп төштем. Татарстаннан киткәндә һавалар суыткан, суда бозлар ката башлаган иде, ә монда кояшлы, җылы һава торышы саклана.

Перрон буенча йөренәм, алга таба нишләргә икән дип баш ватам. Шулвакыт: «Шамил, каян килеп чыктын син монда?» — дигән тавыш ишетәм. Карасам, минем элекке юлдашларым Фәрит Сталинабад поездын көтә, ә база мөдире Сәмәркандка кадәр билет алган һәм әле кич белән генә китә. Мин баштан кичкәннәрне сөйләп бирдем. База мөдире: «Бергә кайтырбыз», — ди. «Минем акчам юк ич», — дим. База мөдире: «Пальто белән пиджагынны сал да мина бир, мин аларны вагонга кертәм, минем билетым бар. Син чишенгән килеш, күлмәкчән генә бар. Проводник сине бу вагоннан дип уйлар», — диде. Ул әйткәнчә эшләдек тә. Барсы да җайлы килеп чыкты. Ә билетлар тикшерә башлагач, мин эскәмия астына үрмәләдем.

## Хатырчи — район үзәге

Сәмәркандка төнлә килеп җиттек. База мөдире: «Мин хәзер кая барам инде? Әйдә, ин яхшысы — синен белән барыйм», — ди. Каршы килмәгәч, иярде бу мина. Хатыйп абзыйны эзләп таптык. Кыен вакытлары булуга карамастан, безне яхшы кабул иттеләр. Минем юлдаш бер кич безнен янда кунгач, үзенен дусты янына китеп барды. Әмма ул кичкә кире әйләнеп килде. Безнен янда вакытлыча яшәргә туктады бу. Бер атна яшибез, ике. Берсендә туганымнын хатыны: «Әйдәгез, Хатырчи дигән район үзәгенә барабыз, ул Сәмәркандтан ерак түгел һәм анда базар да яхшы була. Кайбер теккән әйберләремне шунда сатарбыз да», — диде. Киттек шулай. Халык аз күренә. Кешеләрнен күбесен мамык җыярга җибәргәннәр. Аларны урамда ук эләктереп алып, мамык җыярга мәҗбүри куалар. Хатыйп абыйны да шулай кумакчы булганнар иде, әмма ул үз урынына кызы Гөлсемне җибәрде.

Базар ябылды. Без чәйханәдә утырабыз. Иртәгә әгәр машина тапсак, әйберләрне төяп, кире кайтырга исәп. Машина табу гына җинел эш түгел, чөнки бөтен техниканы басуга куганнар. Карангы төште, тапчанга утырдык та эчәргә чәй алдык. Шәһитнен гармуны бар иде. Ул гармун тарта, мин җырлыйм. Безнен тирәгә байтак кына кеше җыелды. Татарлар инде, әлбәттә.

Ниндидер бер интеллигент кыяфәтле кеше килде дә бездән сораштыра башлады. Без үзебезнен Сәмәркандтан килүебез турында әйттек. Тик иртәгә китәчәкбез, чөнки монда көндез дә урамга чыгарга куркыныч икәнен әйттек. Ул райбашкарманын культура бүлегендә инспектор булып эшли икән. «Мин иртәгә килермен һәм сезгә эшен дә, фатирын да табарбыз», — дип вәгъдә итте.

Икенче көнне ул төш алдыннан килде һәм үзе артыннан ияртеп китте. Ул безгә шактый гына кызыклы һәм үзенчәлекле кибитканы күрсәтте: идәне — җир, миче юк; бер зур тәрәзәсе бар, ишегалдына чыга торган; ягарга кирәк

булса, бер якка таба этеп ача торган капкачы бар, төтен шуннан чыга; ике якка ачыла торган ишеге бар.

Элекке база мөдире юкка гына безнең арттан калмыйча йөрмәгән икән. Измайлов мине райисполкомга алып китте. Анда мине 600 сум оклад һәм икмәк карточкасы белән китапханә мөдире итеп билгеләделәр. Аннары мин Хатыйп абзыйның кызын, минем туганым Гөлсемне китапханә мөдире итеп урнаштырдым. Китапханә кинотеатр бинасында, кечерәк кенә мәйданда урнашкан иде. Хатыйп абзыйның үзен клуб һәм китапханәнең каравылчысы итеп эшкә алдылар. Шәһит белән элекке база мөдиренә эш табылмады. Шәһитне Берлинга кадәр барып җиткән, фашистларны җиңгән офицер буларак ерак түгел бер шәһәрчекнең почта начальнигы итеп алмакчылар иде — риза булмады.

База мөдире безнең янда яши бирде. Тик берсендә, хәтта безнең белән саубуллашмыйча да, юкка чыкты. Ни булды икән дип кызыксынсак, безнең кайбер әйберләребез һәм 17 метр яхшы костюмлык материалыбыз юкка чыкканы беленде. Аларны Шәһит Алманиядән алып кайткан булган. «Рәхмәте» шул булды бу кәкре куллы адәмнең. Шәһит әле сөенеп тә йөргән иде, адәм рәтле кием киячәкбез, дип. Бу вакыйгаларга бигрәк тә нык мин кайгырдым, чөнки бу адәмне мин ияртkән идем бит.

Эшли башладык, әмма тормыш җинелләрдән түгел иде. Барлык нәрсә кыйммәт, ә хезмәт хакы чыпчык борыны кадәр генә. 500 грамм икмәкне дә хезмәткәрләргә карточкага гына бирәләр иде. Ансын да, чиратлар зур булганлыктан, көн саен сатып алып булмый.

Хатырчинский райбашкармада культпросвет бүлеге белән минем шикелле үк агартучы Пардаев дигән үзбәк идарә итә иде. Ул Шәһит белән миңа: «Районның хәрби комиссары подполковник Филин сезне кышлаклар буенча алып бармакчы була. Әгәр почеркларыгыз матур булса, хәрби билетларны алыштырганда, сезне писер итәргә исәбе, бер унайдан партбилетларны алыштырганда да сезнең хезмәттән файдаланмакчы. Мин бармаска киңәш итәр идем. Язганда почеркынны кәкре-бөкре ит», — диде. Ике көннән соң безне чыннан да Филин янына чакыртып, повестка килде. Без хәрби комиссариатка киттек. «Ә, Хәнифовлар, килдегезме? — диде Филин. — Утырыгыз». Филин әүвәл минем язганны алды, карап-карап торды да, язганымны бракка чыгарды, үземне кире җибәрде. Шәһит, киресенчә, тырышыбрак язды, военком аның язганнарын ошатты. Военком аны үзе белән кышлакларга алып чыгып йөри башлады. Бер атнадан ул юынырга һәм өс-башын алышырга кайтты. Шунда ул миңа: «Юкка гына кеше сүзе белән бармадың, чөнки һәрбер колхозда, кышлакта туйганчы ашаталар, кунак итәләр, кайчагында хәтта йөз грамм да салып бирәләр әле», — диде.

Ул вакытта сайлау алды кампаниясе башланды. Мине райбашкарма рәисе Заһидов һәм Пардаев чакырып алдылар һәм өч колхоз белән өч кышлакка агитпункт эшенең ничек баруын тикшерергә чыгарга куштылар. Баруын бардым, тик телне яхшы белеп бетермәвем бераз комачаулады. Мин ике кышлакны тикшереп чыктым. Юлда нинди транспорт туры килсә, шуңа утырдым. Үзем белән райисполком рәисе Заһидов имзалаган документ бар иде. Ул да нык ярдәм итте. Ниһаять, Сталин колхозына барып җиттем. Аннан соң районга кайтырга тиеш идем. Барлык тикшерү эшләренә бер атна вакыт бирелгән. Тиз генә бөтенесен тикшереп чыктым: клуб ашлык саклагыч итеп кулланыла, ә агитация дигәннәре бөтенләй диярлек уздырылмый. Хәрби комиссариат эшли иде. Кереп, Шәһитнең хәлен белеп чыгыйм әле, минәйтәм, дип уйладым. Керсәм, алар язып утыралар, ниндидер бер майор килеп керде. Фамилиясе Смелый икән. Ул

хәзер миңа ялына: «Хәнифов, булыш әле, югыйсә житешмибез. Сроклар кыса», — ди. Мин аңа каршы: «Филин минем почеркны бракка чыгарды. Аннары минем запаста бер генә көн калды, кайтасы да бар», — дидем.

— Ну, бер көн генә булса да ярый. Тутырырга булыш. Баштарак бер хатын булышкан иде, соныннан авырып китте һәм без аны өенә кайтарып җибәрдек, — ди.

Мин утырдым да матур итеп язарга тырыштым. Шулчак Филин килеп керде. Майор Смелый: «Менә бер көнгә писарь таптык», — ди. Филин минем янга килеп басты да, исәнлек-саулык сорашканнан соң: «Син нигә теге вакытта кәкре-бөкре хәрефләр чыгардың соң, әнә ничек матур язасың ич», — диде.

Мин бер көн эшләп калдым. Икенче көнне хәрби комиссариаттан печәнгә килделәр. Аларга утырып киттем, чөнки командировкамның срогы чыккан иде. Ике-өч чакрым чамасы китеп өлгергән идек микән, арттан мотоцикл килгәне ишетелде. Безне узып, юлыбызга аркылы төшеп туктады. Карасам, мотоцикл бишегеннән Филин төшеп килә. Җәлт кенә арбабыз каршына килеп басты. «Төш әле», — ди бу, исән кулын селтәп (бер кулын фронтта югалткан). «Төш!» — ди коры гына. «Минем срок чыкты бит инде», — дигән булам. Ул аты-юлы белән сүгенгәч, йөк өстеннән ничек төшкәнемне сизми дә калдым. Филин: «Мотоциклчы артына утыр», — дип әмер бирә, ә үзе мотоциклга үрмәли. Йөртүчегә: «Нәрсә карап каттың, хәзер үк районга куала», — ди. Шулай итеп, без райцентрга әйләнеп кайттык. Филин миңа: «Безнең белән азакка кадәр булырсың», — диде. Мин калдым һәм моңа бер тамчы да үкенмим. Колхоз председательләре Филин янына килгәч: «Ой, начальник, зур штраф салма инде. Сугыштан соң халык ярлы. Акча юк», — дип ялыналар. Билетсызлар күп. Нәрсәсен яшереп торасың, күпләр яшьләрен үзгәртеп яздырырга мәҗбүр булдылар. Филин андый председательләргә: «Минем хезмәткәрләремне яхшылап ашатсаң — штраф кечкенә, начар икән — значит, штрафлар да зур», — диде.

Уены-чыны бөтенесе бергә шулай булды бугай инде. Яшькә карата да шундый нәрсә булып алды. Рудникта эшләгәннәр пенсиягә 50 яшьтән чыга иде, ә бик күп җирле кешеләр, бигрәк тә Үзбәкстанда, миңа инде 52-53 яисә 55 яшь дип җиффәрәләр иде, чынлыкта исә, документлар буенча, үзләренә 50 яшь тә юк.

Шулай итеп, хәрби комиссар янында янадан ике атна эшләдек. Безне малны сугымга ашаткан шикелле ашаталар иде. Хәтта берничә килограммга арттык та...

...Язмамны гел кара буяулардан гына торган пессимистик рухта тәмамлыйсым килми. Адәм баласын өмет яшәтә, өметсез шайтан гына, диләр бит. Язганнарым киң публикага барып ирешкәндә, мин, бәлки, бу якты дөньяда булмам да инде.

Балаларның, оныкларның һәм, гомумән, хәләл көч берлә көн итүчеләрнең хезмәтләренә күрә хөрмәт белән яшәүләрен телисем килә. Минем озын тормыш юлымда күргәннәрем-кичергәннәрем урта һәм яшь буын өчен гыйбрәт булса иде.

Бигайбә.

*Тәрҗемәче һәм әдәби яктан эшкәртүче* — **Фирдәвес ХУҖИН.**



Әнәс
Исхаков

# УЙЛАРЫМ — ЙӨРӘК ТИБЕШЕМ

## Туган авылым Чыршылы

Инешләрен төбәп ага
Шушмаларга күзләрен.
Басуында ялан тәпи —
Бала чагым эзләре...

Дулкын-дулкын Әби тавы
Кылган чәчләре белән.
Янгырдан соң күнел җилси
Калган яшьләре белән...

Салкын чишмә җыр чыгарган,
Белик дип кадерләрен.
Җил канатлары сәламли
Яудагы каберләрне...

Бәбкә үләнен уйнатып
Чаба бала-чагасы.
Капка төбенә утырып
Күзәтә ил агасы...

## Игенче турында проза

Басуда туа, картая,
Гомере шулай уза.
Бу җиһанда ул берүзе
Буразналарга хуҗа.

Сабый сымак ул гөнаһсыз,
Эше тора хикмәттән.
Патшалар да кече кала
Ул пешергән икмәктән.

---

Әнәс ИСХАКОВ (1945) — *шагыйрь; «Бу дөнья нигә уйчан?», «И тормыш агышлары», «Үткәннәрем кайта җыр булып» исемле китаплар авторы. Азнакайда яши.*

Туганын күтеп алгандай
Каршылый ел фасылын.
Күнелендә кояш анын
Тәшкил итә асылын.

Күктә янган кояшка да
Иядер кебек кеше.
Ике кояш җимеше бит
Гәрәбәдәй бу көшел.

Басуда туа, картая,
Юк, картаймый, яшь кала.
Игенченен йөрәге ул
Әйтерсең лә яшь бала.

## Миңнурый чишмәсе

*Каршымдагы чишмәбезнең*
*Исемнәре Миңнурый.*
*Чишмә суыдай саф хисем*
*Җырымда урын сорый.*

Халык җыры

Исемең калган, инәй, чишмәләрдә,
Игелегең — безнең йөрәктә.
Кайткан саен еллар кайтавазы
Дулкын булып кага күкрәккә.

Зыярәт кылып китәр өчен генә
Без кайтмыйбыз, инәй, янына.
Җылы кулын, якты карашларын
Гел янарып китә аңымда.

Телем, денем, инәй, синнән күчкән,
Әти биргән исем каралмас.
Самум җиле исеп актарса да,
Сездән күчкән хисләр таралмас.

Нигезебез каршысында чишмә
Исеменне җырлый балкытып.
Уч тутырып эчсәм салкын суын,
Кайгыларым китә юылып.

Безнең күңелләрдә яшәр шулай
Мәнге тынмый торган моң булып.
Биш баласы кебек биш улакка
Көмеш суы агар җыр булып.

Фатихасын биреп озатыр да
Көтеп алыр безне «Миңнурый».
Чишмә тамчысында, инәй, синең
Чагыла төсле якты күз нурың.

## Озата барсын иде

Дөнья маллары эзләмим,
Тапканым — маңгай сырым.
Аралый каралыклардан
Йөрәктәге чын жырым.

Бәрәкәтле булсын иде
Эзләгәнем — табышым.
Уйларым — йөрәк тибешем.
Язмышым бар, ялгышым.

Дөнья маллары бер көнлек,
Жырларым калсын иде.
Үземнән соң дусларны да
Озата барсын иде.

## Чишмәләр иле

Чишмәләр иле син, Туган як!
Зәмзәмсу чишмәләр — саны юк.
Жырлыйлар, ургыйлар чишмәләр,
Жиремнең сусаган чагы юк.

Су ала яшь кызлар — чык кипми —
Чиләкләр кайталар жыр белән.
И хозур! Чишмәләр чылтырый, —
Ярлары — ямь-яшел үр-келәм.

Ял итеп кит бездә, мосафир,
Отып кит чишмәләр көен син.
Туганнар ишетеп шат моңны,
Сөенсен, дошманнар — көенсен!

Чишмәләр иле син, Туган як!
Еракка китмәгез су сорап.
Бу жирдә таулардан көй алып,
Чишмәләр яшиләр чылтырап...

## Яңа дуска

*Иске дошман яңа дус булмас.*
Халык әйтеме

«Елан ята куенында», дисәләр дә,
Кабул иттем ялган сүз итеп.
Якын күреп, ихлас күңел белән
Йөргән идем сине үз итеп.

Кыен чакларымда серем ачтым,
Гел-гел сиңа барды юлларым.
Үз-үземә аптырыйм, күрмәгәнмен
Яшеренеп ятуын еланның...

Юк, рәнжемим инде, үпкәләмим,
Пакьлек өчен жаным яралган.
Ә шулай да мин өйрәндем бугай
Аерырга чынны ялганнан.

Дәверләрдән кучеп дәвергә,
Яши әле һаман яман көч.
Ташла инде, ташла хөсетлеген,
Янап карый аннан үкенеч.



Рәмзия
Габделхакова

# ХИКӘЯЛӘР

## Даладан килүче

Ул нидер исенә төшергәндәй, барган жиреннән кинәт туктап калды. Тирә-якка бакты. Зур итеп ачылган күзләрендә аптырау, курку, сискәнү иде. Гүя бу дөньяны тәүге тапкыр күрде. Гүя яңа туды, яңа уянды.

Әлегә хәтле ул барды да барды. Кая барганын белмәде. Кайдан килүен дә белмәде. Һәм бу турыда уйламады да. Чөнки, туктап калганчы, боларның анын өчен бернинди әһәмияте юк иде.

Ләкин ул туктады, тирә-якка бакты.

Алда кара тасма сузылып ята, артта да шул ук тасма, һәм алар тарая-тарая, офыкларга барып тоташкан иде. Ә тирә-якта дала, иксез-чиксез ак бушлык...

Кеше курыкты. Аптырады. Ярдәм көткәндәй, гажиз карашын өскә, жиргә бик якынайган күккә төбәде. Тик кояшны күрмәде. Кояш тау-тау болытлар артына кереп качкан иде.

Әле бер, әле икенче якка төбәлеп, өмет уты эзләгән кеше, ниһаять аңлады: бу олы дөньяда ул япа-ялгыз иде... Тирә-ягында бер генә тереклек иясе дә юк, ни кош, ни жанвар, ни бөжәк, ни агач, ни үлән...

Миңгерәгән, гүя зиһенсез калган башын учлап, юлчы жиргә тезләнде, инәлеп-инәлеп уйларын, хәтерен чакырды. Тик учларга кысылган башта «Мин кем? Кая барам?» дигән сораулардан башка бер уй юк, кешенең хәтере әллә үлгән, әллә йоклаган иде.

Әлегәчә ул барды да барды. Каядыр ашыкты, нидәндер качты. Туктап калганчы аның башында бернинди уй да, бернинди сорау да юк иде. «Мин кем? Кая барам?» дигән сораулар туктап калгач кына килде, утлы уклар булып миенә кадалды. Димәк, ул ялгышкан, туктарга кирәк булмаган.

Кеше уйлау сәләтен югалтмаган иде. «Мин кем? Кая барам?» дигән сорауга әкрен-әкрен генә өр-яңа уй ялганды: «Юл бар, димәк, ул каядыр илтә!»

Бу уй аның күңелен жылытты. Һәм ул сикереп торып, кабат атлап китте. Атлаган саен тар тасма, киңәя-киңәя, аяк астына шуды. Тик офык үзгәрмәде. Офык һаман шул ук иде.

---

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА — *язучы-прозаик; «Көзге яшен», «Көмеш төн», «Тау артында кояш бар», «Нишләттегез Гөлкәйне» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан язучылар берлегенең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Лениногорскида яши.*

## БЕРЕНЧЕЛӘР

Моннан нәкъ 70 ел элек, ягъни 1945 елның 27 июлендә, Советлар Союзының нефть җитештерү баш идарәсе Татарстан АССРның Шөгер районындагы Иске Шөгер авылында «Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы» оештырылуын игълан итә. Бу — бөтен Татарстанда нефть эзләү, чыгару һәм эшкәртү эшләренең дәүләт күләмендә оештырылуына нигез сала. Татар нефтенең бүгенге башкаласы Әлмәтнең, нефть эзләү, табу һәм эшкәртү эшендә гаять зур уңышларга ирешкән Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Азнакай, Алабуга, Минзәлә, Түбән Кама, Зәй, соңрак Нурлат, Чирмешән, Әгерҗе, Мөслим, Актаныш һәм республикабыздагы башка төбәкләрнең данлы нефть тарихы шушы кечкенә генә Иске Шөгер дигән татар авылыннан башланып китә.

Шулай итеп, бездә нефтьчелек эшен беренче булып башлаучылар Шөгер районы кешеләре иде. Без бүген күкрәк кагып, горурланып: «Безнекеләр — беренчеләр!» — дип әйтә алабыз (үзем дә Шөгер районында туганмын).

Шөгер авылы янындагы беренче скважина Бөек Ватан сугышының иң фаҗигале елларында хәрби техника өчен яралы солдатка донор каны дәрәҗәсендәге әһәмиятле ягулык бирә. Әлбәттә, Татарстан нефте Бөек Җиңүне тизләтүдә бик зур роль уйный. Сугыштан соңгы авыр чорда, бигрәк тә узган гасырның илленче, алтмышынчы, җитмешенче елларында Советлар Союзының ныклы сәнәгатен автономияле республика итеп кенә тотылган Татарстанның нефте тәэмин итте.

Татар язма әдәбиятына нигез салган шагыйрь Кол Галинең «Йосыф кыйссасы» әсәрен беренче мәртәбә фәнни эшкәрткән (1839 елда ул аерым китап булып басылып чыга) күренекле татар шагыйре Утыз Имәни яшәгән Тимәш авылында, шагыйрь өеннән ерак та булмаган тау битендә атаклы Ромашкино нефть чыганагын ачып җибәргән 3нче скважина 1948 елның июлендә девон ятмасындагы нефтьне көчле фонтан итеп күккә чөя. Ул тәүлегенә 120 тонна нефть бирә башлый һәм СССР нефть промышленностенда рекордлы скважина була. «Лениногорскнефть» идарәсенең горурлыгы булган бу скважина Татарстанда нефть чыгару эшенең гаять тиз һәм киң колачлы үсеп китүенә нигез сала һәм бүген дә нефть бирүен дәвам итә.

Татарстан нефть оешмаларының иң өлкәне, аларның нигез ташы булган данлы «Лениногорскнефть» идарәсе катлаулы, киң колачлы, гаять зур фидакарь хезмәт юлы үтеп, үзенең 70 еллык юбилеена килеп җитте. Идарә хезмәтчәннәрен бүген бөтен республикабыз халкы, Россия Федерациясенең нефть промышленносте җәмәгатьчелеге бу олуг юбилей белән котлый.

**Гәрәй РӘХИМ**

«Мин бараммы? Әллә бер урында таптанаммы?» — дип шомланды кеше. — Әллә соң бу юлның ахыры юкмы? Әллә соң бу жир түгел, башка планетамы?!»

Күңелгә оялаган курку зурайды, кинәйде, бөтен күзәнәкләргә кереп тулды. Өметкә урын калмады. Кешене тоташ шом биләп алды. Ул адымнарын тизләтте, сулышына кабып йөгерә башлады. Кара тасма да, аның тизлегенә ярашып, тизрәк шуышты. Тик офык үзгәрмәде. Офык һаман шул ук иде...

Юлчы туктады. Арып, хәлсезләнеп жиргә утырды. Бөтен тәне яна, үлеп эчәсе килә иде. Сусавын басарга теләп, бер йомарлам кар алып капты. Кар баллы иде. Шул тәм дөньяда шул кардай ак, баллы шикәр барлыгын искә төшерде. Бу югалган дөньядан килгән тәүге хәбәр, тәүге истәлек иде. Кеше, сөенә-сөенә, тагы нидер исенә төшерергә азапланды, тик хыянәтче хәтер башка хәбәр салмады.

Билгесезлектән, чарасызлыктан тәмам йончыган Юлчы салкын асфальт өстенә бөгәрләнеп ятты. Инде беркая барасы килми, инде селкенәсе дә килми, инде яшисе дә килми иде. Кеше тормышның ни икәнен онытакан, аның кайдалыгын белми, аңламый, шуңа күрә барлыгына да ышанычы беткән иде. Тәненә суык үтте. Иксез-чиксез кара тасмадан, ак карлы даладан, авыр болытлардан торган сәер дөнья да әкрен-әкрен генә югалды...

... Аны кемдер төртеп уятты.

— Әй син, нишләп юлда ятасың? Катасың бит!

Юлчы күзләрен ачты, башын күтәрде. Каршында ала-кола бүрекле, кызыл чырайлы адәм баласы басып тора иде.

— Бу төшме? — дип сорады Юлчы, каршындагы жан иясенең югалуыннан куркып. Буш, салкын дөньяда кинәт пәйда булган бу затны күреп, ул чиктән тыш гажәпләнгән иде.

— Акыллы бәндә юлга сузылып ятамы? Синең өчен төрмәдә утырырга тагы! Хәсрәт! — дип мыгырдана-мыгырдана китә башлады кинәт пәйда булган серле зат. Ни могжиза, ул чынлап та бар, бу төш тә, саташу да түгел, чынбарлык иде!

— Китмә! Калдырма мине! — дип кычкырды Юлчы.

Әллә кайдан көч тапты, сикереп торды, ятим баладай кызыл чырайлы адәмгә килеп сарылды: «Калдырма мине! Куркам мин!»

— Вот идиот! Курыккач, эчмәскә иде! Нишлим мин синең белән?

— Эчмәдем мин, эчмәдем... — үзен чакыручы булмаса да, кеше ала-кола бүрекле иргә иярде. Шунда ул озын әржәле, зур тәгәрмәчле соры машинаны күреп алды.

Машина! Дөньяда шундый әйбер дә бар бит! Кеше калтыранган куллары белән салкын тимергә кагылды. Хәтер төбеннән башка сурәтләр калкып чыкты, күз алдында елга булып агылган төрле-төрле машиналар пәйда булды. Алар да чуар тасма булып офыкка тоташкан иде.

— Утыр инде, алайса, — диде теләмичә генә Кызыл Чырай.

Юлчы, арыган гәүдәсен авырлык белән генә күтәреп, биек кабинага менеп утырды. Тәнен рәхәт жылылык төреп алды. Тынлыкка өйрәнгән колакларын сагайтып, ят тавыш ишетелде, аннары офыкка тоташкан кара тасма зур тизлек белән аларга таба шуыша башлады.

— Кая барасың? — дип сорады машина хужасы.

— Белмим, — диде кеше.

— Кы-ыы-зык... ничек инде белмисең? Шулай буламыни?

Кеше дәшмәде. Ул каршыга йөзеп килүче кара тасмага карап онытылган иде. Ни булды соң бу? Берни дә үзгәрмәде бит! Һәм үзгәрергә охшамаган да... Барысы да шул ук: иксез-чиксез ак дала да, офыкка тоташкан юл да, өскә ишелеп төшәргә торган тау-тау болытлар да... Аерма тик шунда: әлегә хәтле бу

олы дөньяда ул бер ялгызы һәм җәяү атлый иде. Хәзер алар икәү, озын арбалы машинада баралар...

— Ә кулында ни ул? Нинди тартма?

Юлчы беренче тапкыр күргәндәй, кулындагы тартмага карап куйды.

— Белмим.

— Ник соң ачып карамыйсың?

— Минеке түгел ул.

Ялтыравык кәгазьгә төрелгән тартма, чынлап та аныкы түгел, ул аны кемгәдер тапшырырга тиеш бугай. Тик кемгә, ир моны үзе дә белми. Бары аң төбенә төшеп егылган бер уй кисәге генә шундый бурычы барлыгын искәртә иде.

— Бәлки анда шартлаткычтыр? — дип шикләнеп сорады Кызыл Чырай.

— Юк, — диде Юлчы бик ышандырып. — Анда шартлаткыч түгел.

— Кайдан беләсең?

Чынлап та кайдан? Ләкин белә, тартма эчендә ниндидер матур, затлы әйбер ятканын әллә нинди тойгы белән сизә. Тик тартманы ачарга ярамый, аны шулай матур итеп төргән килеш кемгәдер бирергә һәм бүләк иясен шатландырырга кирәк.

— Исемең ничек соң синең, Ходай бәндәсе?

Кеше уйга калды.

— Исемем... белмим...

— Сә-ә-ер... исемсез бәндә була димени?! Ну эчеп тә куйгансың син, туган! Исемсез ничек яшәмәкче буласың? Давай, исеңә төшер! Бәлки Иван? Бәлки Абдулла? Милләтең кем синең? Бәлки чукчадыр? — Кызыл Чырай кычкырып көлеп җибәрде. — Ну экземпляр элакте миңа бүген! Карале, әллә башыңа типтеләрме? Бәлки сине кыйнаганнардыр, ә? Безнең баш бит шырпы кабы кебек кенә. Раз и готово — бөтен миең боткага әйләнә. Йөриләр аннары бичаралар иләс-миләс чайкалып.

— Мин белмим... Хәтерләмим...

— Бәлки сине больницага илтергәдер?

— Кайда соң ул?

— Нәрсә?

— Больница.

— Син бигрәк... артыгын кыланма инде.

Юк, ул кыланмый иде. Больницаның ни икәне, нинди икәне шул сүзне ишетүгә исенә төште. Күз алдына күп тәрәзәле зур таш йорт килеп басты, ак халатлы хатын-кызлар йөгереп үтте, соры җәймәле караватлар чагылып узды. Больницаның ни икәнен хәтер саклый иде. Ләкин кайда соң ул? Офыкларга тоташкан буш даладан, елан булып сузылган очсыз-кырыйсыз юлдан гайре дөньяда башка берни юк ич.

— Слушай, мин бу юлда егерме елдан артык йөрим. Синең кебек чудакны очраткан юк иде. Чынлап та, кайдан килеп чыктың син? Дала уртасында япялгызың. Әллә айдан төштеңме?

— Белмим.

— Сә-ә-ер... сөйләсәң, кеше ышанмас. Бәлки син, теге ни, чит планетадандыр, ә? Марсмы анда, Венерамы... Чит планета хәерчесе! Өстеңә еламый карарлык түгел, ёлки-палки.

Кеше, тәүге тапкыр күргәндәй, үзенең өс-башына күз салды. Чалбар тезләре шомарып, ялтырап тора, ботинкасы шактый тузган икән... Курткасы да мактанырлык түгел, бер төймәсе өзелеп төшкән.

Һәрнәрсә чагыштырганда беленә. Әлегә хәтле дөньяда япа-ялгызы калган кеше өчен чагыштыру бигрәк тә мөһим иде. Кызыл Чырайның да кием-

салымы гадәти генә, бер дә шаккатырлык затлы түгел. Тик нигә кимсетә ул аны, ник үзен өстенрәк саный, шунысы аңлашылмый. Ә машина хуҗасының тынычланырга уенда да юк.

— Карале, бәлки син төрмәдән качкансыңдыр, — дип, Юлчы өстенә чираттагы шик-гаебен ташлады.

Сорау кешене куркытмады, гаҗәпләндермәде. Ул балаларныкыдай саф, самими карашын рульдәге иргә төбәп, битараф кына сорап куйды:

— Кайда соң ул?

— Кайда-кайда... Магаданда! — Кызыл Чырай ямьсез итеп сүгенеп алды. — Юри кыланасың син! Бәладән башаяк, әллә төшереп кенә калдырыйммы үзеңне?

Машина туктады. Офык әле үзгәрмәгән иде.

Юлчы ялварулы мескен карашын машина хуҗасына төбәде:

— Анда салкын. Мин куркам...

— Мин дә куркам! Кем син? Уеңда ни? Куеныңда ни? — дип ярсый-ярсый кычкырды Кызыл Чырай.

Кеше аңлады: дала уртасында кабат ялгыз басып калмас, бу җан иясеннән аерылмас өчен нидер сөйләргә, аңлатырга кирәк иде. Һәм ул тигезсез, карлыккан тавыш белән ашыга-ашыга тезеп китте:

— Мин бик озак бардым. Аңлыйсыңмы, бик озак! Мин кичәге көнне хәтерләмим! Миңа туктамаска кирәк иде. Туктамасам, берни уйламый идем. Сораулар туктагач килде. Ә җаваплар юк! Мин куркам. Бик куркам! Бу дөньяда мин ялгыз идем. Инде син дә ялгыз. Күрмисеңме, аңламыйсыңмыни, дөньяда шәһәрләр дә, йортлар да, кешеләр дә юк. Мине кусаң, син бөтенләй ялгыз калачаксың. Мин дә булмам. Тик мин дә ялгыз калачакмын. Бу бик куркыныч. Син әле белмисең, синең машинаң бар. Машинаң туктагач, син дә аңларсың...

Кызыл Чырайның бу сафсатаны тыңлап бетерергә түземлеге җитмәде, мыскыллы елмаеп:

— Идиот! — диде. — Психбольницадан качкансыңдыр син! Ничек инде дөньяда берни булмасын ди?! Сафсата!

— Ә кайда соң? Кайда тормыш? Кешеләр кайда? Мин килгән якта ул юк. Ләкин алда да юк. Без синең белән күпме юл үттек! Ә дөнья буш. Буп-буш!!!

— Ничек инде... Ничек алай?!

Машина хуҗасы бермәл аптырашта калды. Юлчының сүзләре күңеленә шомлы. Ул инде икенче тәүлек шушы юл буйлап килә. Ул барасы калага тагы илле чакрымлап ара бар. Туган каласыннан чыгып киткәндә, ул әле исән, калада тормыш гөрли иде. Ләкин ирнең күңеленә шик керде, чөнки ул далада төн кунды. Димәк, машинасын туктатып ул йоклаган арада, нидер булган, дөнья үзгәргән... Бәлки чынлап та ахырзаман булган... Кешелек дөньясыннан бары тик шул өтек адәм генә исән калган. Дөнья аның күз алдында беткән, шуңа күрә бу бичара акылын җуйган, берни аңламый, берни хәтерләми...

Кызыл Чырай, ямьсез уйларыннан арынырга теләгәндәй, ала-кола бүрекле башын чайкап алды. Юк, юк, булмас! Бу тиле адәм саташа гына, ни сөйләгәнен үзе белми.

Ир кабаланып газга басты. Кара елан бөтерелә-бөтерелә, зур тизлек белән машина астына шуды. Аның койрыгы ифрат озын, нечкә очы офыкларны биләп алган күксел болытларга барып тоташкан иде.

Тизрәк! Тизрәк! Илле чакрымны үтәргә, алда тормыш барлыгына ышанырга! Шул тормышны үз күзең белән күрергә!

Кызыл Чырай, юлдашын сискәндереп, кинәт кычкырып җибәрде:

— Әнә ич! Барысы да элеккечә! Дөнья бетмәгән! Бетмәгән!

Ул шатлыктан җырлап ук җибәрде. Шәһәр утлары якынайган саен, тавышы

күрәйде. Юлчы да, йотыла-йотыла офыкны күзәтте. Офык үзгәргән иде. Офык кына түгел, тирә-як та үзгәрде. Даланы кала йотты. Күз алдында зур-зур таш, биек йортлар пәйда булды. Юл инде аларныкы гына түгел, анда әрле-бирле төрле машиналар агыла иде.

— Дөнья беткән, имеш! Идиот! Йөрисең кеше куркытып. Дөнья бетми ул, без бетәбез.

Тормыш кайнап торган кала эченә тирәнрәк кергән саен, ни хикмәт, Юлчының куркуы тагы да зурайды. Болай булырга тиеш түгел иде кебек. Ләкин шулай булды.

— Кайда төшәсең? — дип сорады машина хуҗасы.

Кешенең күзләрендә аптырау иде. Ул бу сорауга әзер түгел иде. Төшү турында ул гомумән уйламады. Әгәр төшсә, аны ыжгырып торган машиналар, бихисап күп кешеләр таптап-изеп китәрләр төсле иде. Далада ул ялгызлыктан курыкты. Ләкин дала һәрьяклап ачык, куркыныч кай тарафтан килсә дә, күзгә күренеп, алдан кисәтеп, кешегә әзерләнергә, сакланырга вакыт, мөмкинлек биреп киләчәк иде.

Калада мыжлап, кайнап торган тормыш эчендәге ялгызлык күпкә куркыныч икәнлеген Юлчы инде аңлап өлгергән иде. Шуңа да ул машинадан төшәргә, даланы бергә кичкән юлдашыннан аерылырга теләмәде. Үзе утырган машина әйтерсең туган йортына, ә аның хуҗасы, ни сөйкемсез, тупас булса да, газиз туганына әйләнгән иде. Чөнки Юлчы бу дөньяда башка беркемне белми, бердәнбер якын кешесе ул — Кызыл Чырай.

Тик тегесе моны аңламады, кырыс тавыш белән:

— Кайда төшәсең? — дип кабатлады.

— Мин төшмим, — диде Юлчы әкрен, күндәм тавыш белән.

— Ничек инде төшмисең?!

— Мин куркам. Зинһар, үзеңнән калдырма мине...

Кызыл Чырай аңа ачулы караш ташлады:

— Җүләр! Нәрсәдән куркасың? Кара, урам тулы кеше. Бу урман түгел, шәһәр! Монда бүреләр юк.

— Нәрсәдән икәнен белмим. Ләкин куркам... — диде Юлчы, гаепле кешедәй акланып. — Әгәр төшсәм, мин кабат югалачакмын.

— Ну дускай, мин сиңа нәнке булалмыйм инде. Минем үз юлым. Акча сорамаганга рәхмәт әйт. Телисеңме, юкмы, әнә теге тукталышта төшәсең дә каласың.

Машина туктады. Кызыл Чырай, юлдашы аша үрелде дә, киереп ишекне ачты.

— Төш! Төш тизрәк!

Бу бәндә үз сүзеннән кире кайтыр диган өметкә урын юк иде. Кеше теләмичә генә җылы урыныннан кузгалды.

— Хуш! — диде Кызыл Чырай. Шап итеп ишеген япты. Алагаем зур машина, төтеннәр бөркеп кузгалып китте...

Ул китте... Далада очрашканнан соң ике күңел арасында сузылган нечкә, зәгыйфь җепләр шартлап өзелде дә, авырттырып, чеметеп, кешенең йөрәгенә килеп бәрелде.

— Нидән куркасың? — дип сораган иде аннан Кызыл Чырай.

Юлчы моны үзе дә белми, аңламый иде. Аның хәтере дә, зиһене дә юк, барысы урынына мөлдерәмә булып курку кереп тулган иде.

Хәлбуки тәнен-җанын, бар халәтен биләп алган, кешенең рухын сындыра, җанын кол итә торган бу куркуның сәбәбе бар, әмма аны тудырган вакыйга кеше хәтереннән сызып ташланган иде.

Вакыйга Яңа ел бәйрәме алдыннан булды. Кеше кәефсез генә эштән кайтып

килә иде. Кɵтелгән хезмәт хакы ул кɵнне дә бирелмәде... Димәк, бәйрәм табыны булмаячак, кызына вәгъдә ителгән бүләк алынмаячак. Хатыны, мескен тормышларына эчтән генә мең кат кимсенеп-үртәлеп, ни булган ризык белән тыйнак кына табын корыр. Ә телевизор эчендәге шешенке йɵзле, мул авызлы Ил хуҗасы кɵр тавыш белән «халык» дигән җан ияләрен Яңа ел белән котлар, тик күп, бик күп ɵйләрдә бәйрәм шатлыгы юклыгын аңламас...

Кешенен ул кɵнне ɵйгә кайтасы килмәде. Шуңа да ул бик әкрен атлады, ɵенә урау юл белән кайтты. Утлары әллә кайдан балкып торган биек тәрәзәле кибет каршында туктады да витриналардагы аллы-гɵлле уенчыкларга, матур-купшы киемле курчакларга кызыгып карап торды. Яңа ел бәйрәмендә кызын бик шатландырасы килгән иде шул. Әмма насыйп булмады, вәгъдә ителгән хезмәт хакы бирелмәде.

Ир шуларны уйлап, эчтән кɵрсенеп уйга батып торганда, аңа дәштеләр. Никтер нәкъ менә аңа дәштеләр.

— Дяденька!

Ир борылып карады. Янәшәдә генә, тротуар кырында туктаган чия тɵсендәге җиңел машинаны күрде. Аның арткы тәрәзәсе тулысынча ачылган, шул тәрәзәдән яртылаш диярлек чыгып, ал башлыклы, сары бɵдрә чәчле биш-алты яшьлек нәни кыз, елмая-елмая аңа кул болгый иде.

— А у вас кошелёк упал! — диде кызчык һәм кычкырып кɵлеп җибәрде.

Кызчык шаярта иде. Ир моны аңлады, әмма үпкәләмәде. Ул балаларны ярата иде, үзе дә елмаеп кызга бармак янады.

— А у меня собачка есть! — диде кызчык.

Тәрәзә уемында зәңгәр бантиклы ак йомгак күренде. Кɵчек, яңа туган бәрәндәй, бɵдрә ефәк йонлы иде. Ул үзенең этлеген итеп ɵргән булды, әмма йомшак һәм ягымлы иде.

— Аның исеме Джулия. Матурмы? — дип сорады кызчык.

— Матур, бик матур! — дип елмайды ир.

Шулчак машинаның алгы тәрәзәсе дә ачылды, анда ифрат сɵйкемле чибәр йɵз пәйда булды. Коңгырт чәчләрен иңнәренә таратып салган, ɵстенә затлы кɵмеш тун кигән ханым, елмая-елмая:

— Кызым, абыйны йɵдәтмә, — диде. Аннары аксыл йɵзен иргә тɵбәп: — Минем кызым шундый инде, һич сɵйләшми тора алмый. Юлыгызны бүлгән ɵчен гафу итегез, — дип ɵстәде.

Ир урыныннан кузгалмады, сихерләнгән кебек яңа танышларына карап торуында булды. Чɵнки күптән, бик күптән йɵзләренә елмаю кунган бәхетле кешеләрне күргәне юк иде. Шуңадырмы, алардан аерыласы килмәде, бу шат, матур кызчыкка, аның сɵйкемле әнисенә караган саен карыйсы килә, гүя шул ике зат ирнең караңгы шыксыз дɵньясына җылы нур сибә иде.

Менә машина янына, ялтыравык кәгазьле тартмалар кочаклап, энә-җептән киенгән мәһабәт кыяфәтле бер ир килде, арткы ишекне ачып, кулындагы тартмаларны шунда ташлады.

— Ой, папочка! Сколько подарков! — дип кул чаба-чаба сɵенде кызчык.

— Сезнең заказны 100 процентка үтәдем! — Әти кеше горур һәм канәгать, аның да зур кара күзләре дɵньяга сɵенеч һәм бәхет нурлары чәчә иде. Баласын, хатынын сɵендерә алган гаилә башлыгы ничек бәхетсез булсын ди?!

Ир исә ɵенә буш кул белән кайтып керәсен уйлап, күңелсезләнеп куйды. Аның кызы кул чаба-чаба сɵенмәячәк. Аның хатыны, менә бу чибәр ханым сыман елмаймаячак...

— Әти, ярыймы, мин бу абыйга бүләк бирәм? Яңа ел белән. Ярыймы?

Кызчыкның яңгыравык шат тавышы ирне авыр уйларыннан аралады. Ата кеше бераз икеләнеп торганнан соң:

— Алай бик телисең икән, бүләк ит, — диде.

Кызчык иң өстә яткан тартманы аптырап басып торган иргә сузды:

— Это вам от Катюши и Джулии. С Новым годом, дядя!

Ул көчегенең нәни тәпиеннән тотып: «Абыйга сау бул дип әйт», — диде. Үзе дә нәни кулларын тәрәзәдән чыгарып болгады.

Машина кузгалып китте.

«Дөньяда бәхетле кешеләр бар. Болай булгач, хәлләр өметсез түгел икән әле. Киләчәктә, бәлки, безгә дә бәхет елмаер», — дип уйлады ир.

Шат күнелле, тормыштан канәгать кешеләрне очрату, җитмәсә көтмәгәндә бүләкле булып та кую аның кәефен күтәргән иде. Ул өенә ашыкты. Шәһәрнең көндәлек, таныш сулышын бозып яңгыраган ят, дәһшәтле тавыш аны сискәнергә, туктарга мәҗбүр итте. Ни булганын аңларга теләп, ул як-ягына каранды. Күрде һәм катып калды: әле генә аның яныннан кузгалып киткән, дүрт бәхетле җанны үз кочагына алган чия төсендәге машина дөрләп яна, барысы да тоташ ялкын эчендә калган иде...

Ир кешеләрнең кычкыруын ишетмәде, аларга кушылып чапмады. Ялтыравык кәгазьле тартманы күкрәгенә кысып, шашкан карашы белән бу коточкыч күренешкә карап катып калды...

Аннары йөгерде. Бик озак йөгерде. Берни күрми, берни тоймый, берни уйламый, ник йөгергәнен дә, кая йөгергәнен дә аңламый йөгерде...

... Әйе, кеше әллә бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә, бу вакыйганы тулаем оныткан, ул аның хәтереннән мәңгегә сызып ташланган иде. Кеше курыкты, тик нидән куркуын белмәде...

Машиналар, кешеләр бертуктаусыз агылган шәһәр урамында ул япа-ялгыз калды. Кай тарафка юл тотарга да белми икеләнеп торганнан соң, тукталыш кырындагы белдерү-игъланнар белән чуарланып беткән баганага килеп сөялде. Аның күнелендә нәни генә өмет баш калкытты: «Бәлки, кем дә булса мине таныр? Бәлки, бу йөзләгән-меңләгән кешеләр арасында минем танышым да бардыр?» Әмма күпме генә басып торса да, аңа игътибар итүче булмады. Барысы да каядыр ашыга, бер-берсен этә-төртә йөгерә иде. Кеше ялварулы, гаҗиз карашын халык агымына төбәп: «Мине күрегез!» — дигән сыман, калкынып, башын күтәребрәк басты. Ләкин баганага сөялеп торучы бичара кешедә беркемнең эше юк иде.

— Ярдәм итегез! Зинһар, булышыгыз! Мин югалдым. Үземне табарга ярдәм итегез! — дип аваз салды кеше.

Аны ишетмәделәр. Ишеткәннәре дә аңламады. Ярдәм сораучының аяк астына вак акчалар сибелде. Тик кеше аларның нигә, ни өчен кирәклеген оныткан иде.

Вакыт узды.

Халык төркеме, машиналар агымы әкренләп саега башлады. Инде алар берәм-берәм генә үтә иде, аннары берсе дә калмады. Җан ияләре таш йортларга кереп тулды. Урам бушады. Бөтен җир тып-тын калды. Шәһәр гүя буш далага әйләнде.

Инде кеше дә баганага сөялеп тормый, хәлсезләнеп җиргә чүккән иде. Аны йокы басты, тәненә салкын үрмәләде. Багана башындагы ут аны җылытмый, бары салкын яктылыкка гына тәрә иде. Шул яктылыкта кеше җирдәге вак акчаларның җемелдәвен күрде. Күктәге йолдызларның җемелдәвен күрергә үз баганасындагы һәм башка баганалардагы җансыз утлар комачаулый иде.

Кеше күзләрен йомды. Бүтән ул берниндии яктылык күрмәде...

***

Кеше бөтенләйгә югалды.

Дөнья югалмады. Дөнья калды. Җылы кояш, якты ай, нурлы йолдызлар, шау чәчәкле гөлбакчалар, яшел болыннар, иксез-чиксез диңгезләр, биек таулар,

мәгъруӧ кыялар — барысы-барысы калды. Шаулы калалар, тын авыллар, озын-озын юллар калды. Миллионлаган төрле тереклек: очар кошлар, көчле җанварлар, пакь күңелле горур кешеләр калды.

Әмма кансыз ерткычлар, жирәнгеч хәшәрәтләр дә калды. Шәһәрне төн пәрдәсе каплап алгач та, алар юеш тараканнар сыман, яшерен ояларыннан чыктылар да, кара эшләрен таң атканчы башкарып өлгерер өчен, таш урамнарга сибелделәр.

Хәшәрәтләрнең берсе белдерү-игъланнар белән чуарланып беткән багана янына килде, пычрак тупас итекле аягы белән кешегә китереп типте. Корбанының көчсезлеген, һичнинди каршылык күрсәтмәвен аңлап, кабалана-кабалана, аны чишендерергә кереште: башындагы куян бүреген йолкып алды, мышный-мышный ботинкаларын салдырды. Аннары комсызланып, курткасына килеп ябышты. Шулчак ир кочагындагы купшы тартманы күреп, аны мизгел эчендә ботарлап та ташлады.

Тартма эченнән кара бөдрә чәчле, алсу йөзле, озын керфекле, зәп-зәңгәр күзле курчак килеп чыкты. Күз явын алырлык матур, нәфис иде ул. Өстендәге алсу күлмәгә жем-жем итеп тора, чәчләренә дә нәкъ шундый бант тагылган иде. Курчакның күпереп торган алсу иреннәре чак-чак ачылып, энже тешләрен күрсәтеп елмая иде.

Затлы тартмадан үзе өчен бер кирәкмәгән әйбер килеп чыгуына хәшәрәтнең ачуы килде. Ул төнге дөньяны тагы караңгылатып, ямьсез итеп сүгенде дә матур курчакны ачу-нәфрәт белән болгап атты. Курчак берара һавада бөтерелеп алды, аннары шапылдап трамвай юлына килеп төште.

Авыртуның, югалтуларның, җан-тән әрнүенең ни икәнен белмәгән таш курчак, энже тешләрен күрсәтеп, әле һаман елмая, бәхетле елмая иде...

## Мөгез

Кайгы аларга озакка дип килде. Киерелеп түр башына менеп утырды да, кабер суыклары бөркеп торган карашы белән өтә-өтә, өй эчендәге җан ияләрен күзәтте. Шатлык чыгып качкан йортта күләгәдәй хәрәкәтләнүче бу тере мәетләр ана ошый иде. Кайгы тантана итте. Чакырмасалар да, хуҗалар белән бергә табынга утырды. Ашларына кара таракан булып төште. Кайгы белән уртаклашкан табынның яме, ашның тәме бетте, аның агулы карашы төшкән ризыклар тамактан үтмәде. Кайгы әрсез, оятсыз иде. Аның боз сөңгеләредәй салкын бармаклары һәркайсының күңеленә сузылды, йөрәкләрен телде-тапады, болай да кан саркып торган җаннарын умырды. Бу йорттан йокы качты, тынычлык качты, яшәү яме качты.

Кайгы йорт анасын чиргә сабыштырып урынга салды, атаны хәмер шешәсенә бөгәрләп тыкты, йорттагы бердәнбер ир баланы куркак җан итте.

Ана көне-төне «улым» дип ыңгырашты. Ата эчеп кайтты да, каешын алып, малайны кыйнады: «Ник энеңне ташлап киттең? Ник карамадың? Ник үзең белән урманга алып бардың?»

Ә малай елады да елады. Югыйсә ул гаепле дә түгел иде. Зәкине беркемнең дә урманга алып барасы килмәгән иде. Ул үзе, киреләнеп, ялына-ялвара, аларга иярде. Ул үзе, арыдым дип ыңгырашып, аланда утырып калды. Ана кат-кат кисәтеп әйттеләр, шунда гына тор, беркая китмә, безне көт, диделәр. Зәки утырып калган алан олы юлдан ерак түгел иде. Зәки анда адашырга тиеш түгел иде! Ләкин адашты, югалды. Авылга ансыз кайттылар. Ул мөгаен кайтып киткәндер, дип уйладылар. Тик Зәки кайтмаган иде. Аны өч көн, өч төн буе бөтен авыл белән урманны айкап эзләделәр, тик тапмадылар.

Алар урманында бүреләр юк иде. Ләкин алар урманында Дию сазлыгы бар иде.

Шуннан шикләнделәр, шунда баткандыр балакай, дип малайны кызгандылар. Ләкин күрәзәчеләр, барысы бергә сөйләшкән кебек: «Ул исән, табылачак», — дип күнелгә җылы өмет салды. Ә бер йөзьяшәр сихерче карчык: «Оланыгыз адашып йөри. Аны әнисе ризыгы кайтарачак», — дип тә өстәде. Әмма аның сүзенә кеше ышанырлык түгел иде. Чөнки әниләре ризык пешерү түгел, үз йомышына да тора алмый иде. Чөнки әниләре сөекле төпчеге югалып, ел үткәч тә, җан бирде. Бу йортта Зәкине тартып кайтарырлык ризык пешерүче юк иде...

***

Имтияз күзләрен ачты. Башта ап-ак түшәмне күрде. Карашын сулга күчерде. Ул якта пәрдәсез ялангач тәрәзә, тәрәзә буена куелган өстәл шәйләнде. Күзләр күрә иде. Аннары колакларын сагайтып тынлыкны тыңлады. Колаклары аңа хыянәт итмәде, тынлыкның бәллүр савытын җимереп, дөньяның чуар авазлары килеп иреште. Урам ягыннан машина кычкырткан тавышлар ишетелде. Коридорны яңгыратып, авырткан башын чыңлатып, кемнеңдер үкчәле туфлиләре тык-тык басып үтте.

Күзләр күрә, колаклар ишетә иде... Олпат гәүдәсе белән тар караватны тутырып яткан ир җинел сулап куйды. Бу инде яшәргә өмет бар дигән сүз иде. Хәзер аяк-кулларны тикшереп карау кирәк. Имтияз сул аягын селкетте, уңын... Аяклар аны тынлый иде. Чират кулларга җитте. Учларын йомарлады. Уң кул аны тыңлады. Сулы җавапсыз калды. Сул кулга баш мие җибәргән сигнал барып җитмәде. Ул хәрәкәтсез иде.

Аллага шөкер, аяклар сизә, хәрәкәтләнә, уң кул аны тыңлый. Иң мөһиме, һәр әгъзаның падишасы булган зиһен югалмаган, баш эшли, уйлый. Бу дөньяда башсыз яшәп булмый, тормыш итәр, гомер кырын иңләр өчен акыл кирәк!

Гомере булгач, менә кире кайтты. Югыйсә караңгылыкка очкан, «беттем!» дип уйлаган, шул уйдан бәгырен үкенү-үртәлү, ачыну хисе телеп алган иде.

Хәтерендә үз аңында булган соңгы мизгелләре яңарды. Әкрен генә тирбәлеп, эчпошыргыч бертөрле җырын көйләп поезд бара. Тәрәзәдән сузылган кояш нурлары вагондагы пычрак, тынчу һаваның хисапсыз тузаннарын учларына салып, күрәсезме, ни сулыйсыз, дип юлчыларны үрти кебек. Юл арыта, талкый, ике көн буе каршында бер үк йөзләрне күреп, кемнәрнеңдер зар-моңын тыңлап бару туйдыра. Тизрәк бу ирекле тоткынлыктан котылып, язгы саф һавага чыгасы, күкрәк тутырып сулыйсы, тәннәрне яздырасы килә.

Имтияз каршында өстенә озын кара капчык-күлмәк кигән, кара сакаллы урыс рухание утыра. Карап торышка 40-45 яшьләр чамасындагы аксыл йөзле, зәңгәр күзле мөлаем гына ир-егет. Күкрәгендәге көмеш тәресендә кояш нурлары чагыла. Вагон тирбәлеп барган шәпкә өстәлдә буяулы йомыркалар әрле-бирле тәгәри.

Поп бик пөхтә. Ипине бик кадерләп, валчыкларын учларына җыеп ашый.

— Христосе воскресе! — дип Имтиязга яшел күкәй суза.

— Рәхмәт, — ди Имтияз. — Киләсе станцада мин төшәм.

Ул инде курткасын кигән, төенчеге кулында. Чиләбегә җитәргә тагы егерме минутлап вакыт бар.

Поп юл буе нәсарә диненең өстенлеген, хаклыгын, Исусның изгелекләрен сөйләп килде. Имтиязның юлдашлары, ирле-хатынлы гаилә аны авыз ачып тыңладылар. Тегесе боларга Тәңре улы хакында ялтыравык тышлы китаплар бүләк итте. Кешеләрне изге юлга тартуына поп ифрат шат иде.

Имтияз сөйләшүгә кушылмады. Күңеленнән Аллаһка, аның берлегенә, барлыгына ышанса да, мөселманлыгы «бисмилла» һәм «иншалла» белән генә чикләнә. Үз динен яклап, күкрәк сугып бәхәсләшерлек белем-гыйлеме дә,

кыюлыгы да юк. Болай да аз сүзле, урыс телен белүе дә чамалы булган авыл агае, бик теләсә дә, менә бу яшь, гайрәтле поп сыман кешеләрне үз авызына каратып, уй-фикерләрен болай сендереп сөйли алмый. Шуна күрә «аерым калхуз» булып дәшми баруны кулай күрә.

Имтияз артык юаш, куркак бала булып үсте. Ул гел читтә, гел ялгыз иде, гомере буе күңелендә, кара йомгак булып, шом яшәде. Бала чагында җанына сеңеп калган ул шом елдан-ел үсә-үрчи барып, аның бар булмышын ялмап алды, олыгайгач та кимемәде, киресенчә, искеләре урынына яңалары кереп оялады. Имтияз хатыны авырып китүдән, аны югалтудан, ялгыз калудан курыкты. Шуңа күрә Мөслимәсен күз карасыдай саклады. Йорт анасы сәламәт, шат, көр күңелле булырга тиеш. Әни кеше елмаеп яшәсә генә, өйдә ямь була, шул чагында гына бу йортта балалар да көлеп-сөенеп яши. Ә Имтияз әнисез үсүнен, ятимлекнең ни икәнен яхшы белә иде. Үги ана һәм каты куллы исерек ата белән яшәүнен дә ни икәнен белә иде ул. Имтияз хәмергә иялэнүдән курыкты. Хәмер кешенең акылын томалый, исерек бәндә хәтта үз баласына кул күтәрә башлый. Имтияз начар әти булудан, балаларын рәнҗетүдән, күңелләрен кимсетүдән курыкты. Балалары аның иң кадерле һәм иң олы байлыгы иде. Ул аларны беркайчан да ялгызларын урманга җибәрмәде...

Имтиязның очып-канатланып газиз улы янына баруы. Фаязының бәхете булды, хезмәт итәргә Чиләбегә эләкте. Ә анда Имтиязның бертуган апасы яши. Ялга чыккан саен, малай туп-туры шунда элдерә, Сәрия апасы пешергән бәлеш-өчпочмаклар белән сыйлана. Ата белән ана шуна сөенеп бетәлми. Бер баруда апасын да, улын да күреп кайтачак Имтияз. Ул инде очрашу шатлыгы белән балкып утыра. Анда буяулы күкәй кайгысымы. Чукынган халык: «Христос воскрес!» — дип сөенә. Имтиязның шатлыгы да аларныкыннан ким түгел. Улын сагынуы чамадан ашты. Күңеле белән газиз баласын кочып-сөеп, ана җиткерәсе сүз-хәбәрләрен барлап, алда көткән күрешү шатлыгыннан ләззәтләнеп утыра...

Шулчак поезд кисәк кенә тартылып куя, тәгәрмәчләр тигез тукылдаудан туктый, күкрәгән-дөбердәгән ят, куркыныч тавыштан җанга аңлаешсыз шом йөгерә. Өстәлдәге буяулы йомыркалар идәнгә тәгәри, аларны алырга иелгән поп үзе дә бар буе белән аяк астына сузылып ята... Имтияз да әкрен-әкрен генә никтер сулга авыша... Өстенә өске полкалардагы чемодан-сумкалар коела. Имтияз башы белән каршы яктагы тәрәзәгә килеп бәрелә, шул арада, ни хикмәт, вагон эчен күреп-күзәтеп өлгерә. Ул гына түгел, башкалар да сулга авыша икән. Баласын күкрәгенә кыскан хатын өстенә әзмәвердәй ир ава... Ике кулын алга сузган карт авызын зур итеп ачкан... Калын беләкле хатын таза куллары белән йөзен каплаган, ә үзе сулга янтайган... Вагон идәненә ак мендәрләр, ак җаймәләр, буй-буй матрацлар коела... Барысы да шундый әкрен хәрәкәтләнәләр, вакыт гүя сагыз кебек сузылган. Коточкыч авыртудан Имтиязның башы яңгырап-чыңлап китә, сул ягына гүя балта белән китереп чабалар... Шул мизгелдә бәгырен әрнетеп-йолкып, яшен угыдай соңгы уй атыла: «Беттем!!! Гаиләм ятим кала...»

***

Палата ишеге ачылып китте дә, ишек уемында тоташ зәңгәрдән киенгән озын буйлы шәүлә пәйда булды. Титаклый-титаклый, култык таякларына таянган 15-16 яшьләрдәге үсмер егет килеп керде. Егетнең кашлары күмер кебек кара, калын иде, ач яңаклы кечкенә йөзенә баксаң, караш иң әүвәл шуларга туктала. Егет Имтияз ягына күз ташлады, аның уяу икәнен күргәч, нечкә иреннәре белән үз итеп рәхәтләнеп елмаеп куйды. Елмайганда куе кашлары биеп-сикереп алды.

— Син дә безнең поездданмы? — дип сорады Имтияз.

Тавыш, үз юлындагы элпе-пәрдәләрне җимерә-ерта, авырлык белән булса

да ирекк ә чыкты. Ул әле артык зәгыйфь, көчсез иде. Шулай булса да бар иде, югалмаган иде!

Егет аны ишетте, җавап бирде:

— Юк, абый, мин машина белән сөзештем.

— Белмисенме, үлүчеләр бармы?

— Бар, абый. Алгы вагоннардан беркем исән калмаган, диләр. Сез кайсы вагонда идегез соң, абый?

— Жиденчедә...

Жиде — бәхетле сан шул...

Имтиязның сул җилкәсенә нииндидер тимер кисәге кадалган булып чыкты. Башта шуны тартып алганнар, аннары ямап, бәләген генә түгел, ярты күкрәген бинт белән чорнап куйганнар. Ул кул эшләсә дә, хәрәкәтсез ята торгач, ахры, оегандыр. Бәлки наркоздан айнып бетмәгәндер. Ничек булса да, ярасы зыянлы түгел, терелеп аякка басуына өмет бар. Иртән обход ясаган врач хатын шулай диде.

Поездагы күршесе, юлда пасха күкәйләре ашап барган поп та алар палатасына эләккән икән. Имтияз каршында ята. Ак җәймә өстендә кара сакалы гына сатуга куелган парик сыман калкып-күренеп тора. Операциядән соң йоклый да йоклый атай, тавышы-тыны чыкмый. Кичкә таба гына наркоздан айнып, күзен ачты, култык таяклы малайдан су китертте, пышылдап кына үзенчә догалар укып алды. Имтияз колагына «Спаси и сохрани» дигән сүзләре генә килеп ирешт е.

Икенче көнне Имтияз янына апасы килеп җитте. «Бөтен балнисларны айкап чыктым, көч-хәл белән таптым үзеңне», — ди. Яралы пассажирларны төрлесен төрле җиргә таратканнар, беркемнән берни белә торган түгел. Кешеләр дә, документлар да, әйберләр дә буталып беткән. Кайсы кем икәнен дә, кемнеке икәнен дә аңлап-белеп бетерә торган түгел. Ярый әле Имтиязның бар язуы кесәсендә иде.

— Фаязга әйтмә, борчылып тормасын, — диде Имтияз.

— Ул белә инде, анда бөтен Чиләбе ду килә. Товар поезды белән бәрелешкәнсез, тилвызырдан көн-төн шуны сөйлиләр. Ничек Фаяз гына ишетми-белми калсын ди. Аллага шөкер, үзең исән, калганы җайланыр.

Апасы алып килгән күчтәнәчләрен сумкасыннан чыгарып өстәлгә тезә башлагач, Имтияз көлемсерәп баш чайкады:

— Боларны ашап бетерергә бирәнме әллә мин? Ник шулхәтле төяндең?

— Аша, энем, аша. Ашаган малда өмет бар дигәндәй, тизрәк тернәкләнерсең. Бергәләп сыйланыгыз, сез дә авыз итегез, — диде Сәрия, палатадагы башка авыруларга күз салып.

Поп агай, бинт уралган башын бора төшеп, карашы белән өстәл өстендәге ризыкларны капшый башлады. Ике тәүлек буе авызына ризык капмагач, тамагы ачкандыр шул.

— Ашагыз, аша, — диде Сәрия, аңа бәрәңге тәкәсен сузып. — Әле кап-кайнар, суынырга өлгермәгән. Әллә ничә кат тастымалга төрдем.

Поп ыңгырашып, авырлык белән генә урыныннан кузгалды. Аксыл нечкә кулларын ризыкка сузды, ләкин авыз итәргә ашыкмады, тәкәне кулларына алгач та, әйләндергәләп карап-тикшереп чыкты:

— А что это?

— Безнең якларда тәкә диләр... Эчендә бәрәңге дә суган, кайнар килеш бик тәмле була инде. Шикләнми ашагыз.

Сәрия ирнең ризыктан бер-бер гаеп табарга теләгән сыман төпченүен өнәп бетермәде бугай. Ризыктан гаеп эзләү, чиркану иң түбән җанлы бәндәнең эшедер инде ул. Тәрбияле кеше бала-чага сыман болай килешсез кыланмас. Урысларның камыр ризыгына исләре китми, анысы хак. Аларга тозлы кыяр, кәбестә булсын. Ошамаса, баш кына тарт, ни дип ризык тикшереп утырасың.

— Тәкә... — дип кабатлады ир. — Тәкә...

Шулчак могҗиза булды, дөньяга икенче тапкыр туган ир кинәт ап-ачык итеп саф татарча сөйли башлады:

— Минем әни дә тәкә пешерә иде. Тик мин аңа «мөгез» дия идем. Мөгез... Странно... я это вспомнил... Тәкә... Әни...

Аның сүзләрен ишетеп, апалы-энеле өнсез калдылар. Икесенең дә уйлары үткәннәргә, туган якларга йөгерде. Күз алларына урманда адашып югалган энеләре килеп басты. Ул да бит шулай дия иде, миңа мөгез кирәк, мөгез ашыйсым килә, дип әниләрен йөдәтә иде. Аның бу сүзеннән Имтияз белән Сәрия тәгәрәп көлә иде. Тәкә ул, мөгез түгел, дисәләр дә, Зәки киреләнеп үзенекен тукыды... Төпчек малай гаиләдә иң кадерле зат иде, аның сүзе өскә чыкты. Ул шулай теләгәч, Зәкигә ияреп бәрәнге тәкәсен «мөгез» дип йөртә башладылар...

Хәтердә сихерче карчыкның сүзләре янарды: «Ул исән... Аны әнисе ризыгы кайтарачак...»

Имтияз, башын күтәреп, урыныннан калыкты, тынгысыз карашы белән юлдашы йөзеннән таныш чалымнарны эзләде, күңелендә талпынган өмет күзләре тапкан нәни генә охшашлыкка да сөенде. Әле бая гына җиде ят булып саналган кешенең аксыл йөзендә Зәкинекедәй яшькелт-соры күзләр балкый иде.

— Син... урманда адашып калган энебез... — Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, болай да көчсез тавышы дулкынланудан калтыранып-өзелеп чыкты.

— Син Зәки түгелме? — дип кистереп сорады Сәрия.

Үз уйларына батып мәрткә киткән поп кинәт күзләрен зур ачып, башын артка ташлады, аның йөзе агарынып, иреннәре күгәреп китте, куллары, тотыныр-ябышыр урын эзләгәндәй һавада чәбәләнә башлады. Бичара ир коточкыч тавыш белән илереп җибәрде, бәргәләнгән тәнен кай тарафка атарга белмәгәндәй, унга-сулга чайкалды да гөрселдәп идәнгә килеп төште. Кулындагы ризык ныгытып кысылган бармаклар арасында изелеп калды...

Күренеш котны алырлык иде. Палатага йөгереп кергән шәфкать туташы авыруның авызына тимер калак каптырды, беләгенә укол кадады. Шул арада палатадагыларны тынычландырырга да өлгерде:

— Курыкмагыз, эпилепсия өянәге генә бу, бераздан үз хәленә кайтыр.

Ләкин авыру күзләрен башка ачмады... Җирдә йөргән көннәренә, гамәлләренә соңгы ноктаны шунда куеп, йоклаган килеш бакый дөньяга күчте. Имтияз белән Сәрия өметләнеп көткән җавапны, язмышының бар серен үзе белән мәңгелеккә алып китте...

Кара күлмәккә төренгән авыру тәнен ташлап, кайларга ашкынды, кай тарафларга очты икән бу бичара җан?

Ә бит ул, чынлап та, урманда адашкан татар малае иде...

## Яңгырдан соң

Басу уртасындагы тар юл буйлап бер атлы килә. Соры бия ашыкмый гына атлый. Хәер, аны ашыктыручы да юк. Сыртында хуҗаның нәзек, ачы чыбыркысы уйнамый. Ә хуҗа, утыз-утыз биш яшьләрдәге такыр башлы ир, дөньяда бер гаме юк кеше сыман, дилбегәсен итәгенә җыеп торкан да, мәрткә киткәндәй, үз уйларына чумып утыра. Бәлки яңгырдан соң сафланып, яктырып киткән дөньяга сокланып-хозурланып баруыдыр, бәлки җәйге татлы һавадан исереп, изрәп-йомшап киткәндер.

Ә бит матур, бигрәкләр дә матур безнең якларда җәй башы! Яңгырларына

хәтле көләч, җанга тансык бит! Әле генә күк йөзен тау-тау болытлар каплап алган, бар җиһан карангылык кочагына кереп чумган иде югыйсә. Инде күр, ул болытлар кай арада таралышып беттеләр дә, кай арада җиргә алтын нурларын коеп, кояш та балкый башлады. Җылы яңгырдан соң һава сулап туймаслык тәмле, тузаннан арынган дөньяның садә, пакь төсләре күзләрне генә түгел, күңелне дә иркәли. Яшел генә димәссең, аның да әллә ничә төрле балкышы бар. Яңа яфрак ярган агачлар, сабыйларның ефәк чәчедәй куерып үсеп килгән чирәм, һаваны баллandырып, борын төртүче яшь игеннәр — җәйнең сафлыгыннан, илаһи төсләреннән, бу кадәр гүзәллегеннән акылың шашарлык, валлаһи! Шул матурлык эчендә кара тасма булып сузылган туфрак юлның яңгырдан соң төерле боткага әйләнеп, җәяүлегә түгел, дүрт аяклы атка да көч-хәл белән атларлык хәлгә килүе дә күңелне тырный алмый. Җир бит ул, туган җир! Читкә киткәннәр шул газиз җиргә тезләнеп, туфрагын, үбә-үбә, учларына салып ашардай булып сагынып-ашкынып кайталар лабаса!

Арбада утырган ир бәлки шуларны уйлап тын калгандыр. Бәлки ул да бик ерактан кайтадыр? Әле чагыштырмача яшь булса да, аның шома уйчан йөзендә бу җирдә яши-яши арыган, күпне күргән картлар сагышы ята.

Ә кызлар шырык-шырык көләләр дә көләләр. Әйе-әйе, ир бит арбада ялгыз түгел. Аның аркасына терәлеп диярлек, аякларын арба артына салындырып ике кыз утыра. Каптырмалы җиңел туфлиләрен кара кәлүшкә әйләндереп, калын саз катламы ябешкән.

Ә кызлар барыбер шат, чөнки юллары унды. Яңгыр астында юешләнеп, саз ерып, көч-хәл белән кайтып килгәндә, бәхетләренә менә бу атлы очрады. Очрады гына түгел, сорамаган килеш арбасына да утыртты. Югыйсә авылга тагы өч чакрымлап атлыйсы бар иде әле.

Кызлар шат. Чөнки бүген соңгы имтиханнарын бирделәр. Алда чыгарылыш кичәсе, алда бәхет-шатлык тулы озын гомер. Әнекәй генәм, ничек күңелле бу якты дөньяда яшәүләре! Бигрәк тә яшь, матур чагында.

Кызларның берсе аеруча шат. Ике ел буе, гыйшык утларында яна-көя, яшерен генә яратып йөргән кешесеннән уч кадәрле хат кисәге алды бит ул бүген! Беренче тапкыр шундый назлы хат алды! Шул хат аның иңнәренә канат куйды, көне буе йөрәгендә, талпына-талпына, бер серле кош сайрый. Кыз үзен алда бик зур, татлы бәхет көткәнен бөтен җаны-тәне белән тоя. Дөньяга сыймаслык бу олы шатлыкны иптәш кызы белән уртаклашмакчы була, тик тегесе, юк, аңламый бит моның йөрәк хәлләрен.

— Ярату ничек була соң ул? Ник син нәкъ менә аны яратасың? Нигә кирәк ул сиңа? — дип баш катыра.

Яшьлекнең Мәхәббәт дигән татлы алмасы эләкмәгән шул әле аның кулына. Бу кызыйда егетләр кайгысы түгел, илһамланып-дәртләнеп Буран исемле эте турында сөйләп кайта. Иртән Буран аларны озата барган иде. Өйгә кайттымы икән, яңгыр астына эләгеп, юешләнмәде, өшемәдеме икән дип, көне буе ут йотты кыз.

Шулай итеп, берсе — этен, икенчесе егетен сөйләп, бер-берсен үртәшеп, шаяра-көлешә кайта кызлар. Ә ир аларны гүя ишетми дә.

Аның күз алдында нур чәчеп торган ай йөзле, назлы карашлы, йомшак тавышлы бик кадерле бер генә кеше тора. Инде ничә ел тора. Күпме рәнҗеде ана Мисбах, күпме гаепләде! Ә күпме сагынды! Елый-елый, саташа-саташа сагынды. Ник китте, ник кайтмый дип тәмам гаҗиз булды. Күпме хатлар язды ана...

Бик соң ачтылар аңа дөреслекне. Гаепсез икән бит кадерле кешесе. Ул да аның кебек газапланган, хәсрәт сулары эчкән икән бит! Ә бит әйтмәделәр... Кат-кат килгәнен дә, ишек шакуларын да, елый-елый ялваруларын да, очрашу өметләнеп капка төбендә кунуларын да әйтмәделәр...

Белгән булса, шул гомер күрми торыр идеме, шул гомер бер хәбәрсез йөрер идемени?! Әллә үзеннән, әллә анардан, әллә ачы язмышыннан качып, ничә еллар буе туган җирдә тамырланып калган бәхетен читтән эзләде. Бугазыннан үлем килеп тоткач кына әйтте әтисе:

— Улым, барып күр син аны. Юкка рәнҗеттек, минем өчен дә бәхиллек сора, — диде. Кайда яшәвен дә шунда гына әйтте.

Инде менә Анын янына бара Мисбах.

Күңелендәге сагыш-моң күкрәгенә генә сыймый, җыр булып дөньяга түгелә:

— Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул, шул;
Караңгы төн, болытлы көн —
Без аерылган көн бит ул...

Ир бар йөрәге белән әрнеп-сызланып, бала чагыннан ук күңеленә сеңгән, гомеренең мәңгелек юлдашына әйләнгән таныш җырны суза...

Ә кызлар көләләр. Аларның әлегә бер хәсрәте дә юк. Алар әле хәсрәтнең ни икәнен дә белми. Күңелләре кояшлы көн кебек яп-якты, ап-аяз. Йөрәгенә Мәхәббәт кошы кунган кызның күзләреннән нур түгелә, елмаюлы иреннәреннән сөйгәненең исеме талпынып чыгарга гына тора. Күңеленнән генә ничә тапкыр пышылдады инде ул дөньяда бер матур исемне! Әллә сулыш алган саен, тынына кушылып чыга инде?!

Калкулыкка күтәрелгәч, авыл да күренде. Түбән авыл. Серле яшерен авыл ул, тәмам килеп җитмичә, барлыгын да сиздерми, мәче баласы сыман чокырда шыпырт кына йомарланып ята.

Шул авылда Кизләү тыкрыгы янында шифер түбәле җыйнак кына бер йорт бар. Ул йортта карт белән карчык тыныч кына гомер итәләр.

— Аллага шөкер, — ди Гайния апа. — Тормышыбыз җитеш, балалар исән-сау. Табыннарыбыз тулы.

Татар кешесе гомер-гомергә шулай, азга да канәгать, сабыр. Кайгы килсә дә, зарланмый-уфтанмый, тешен кыса да: «Күрәчәктер, Ходай кушмаган эш булмас. Алдагысы хәерле булсын», — ди.

Гел ачык йөзле, үзалдына елмаеп йөргән Гайния апаның бәгырен нинди уйлар телгәнен, йөрәгендә нинди хәсрәт йомарланып ятканын бары берәү генә белә. Ул аның җан дусты, ахирәте, гомерлек күршесе Минҗиан. Минҗиан астай — кырык йозакка бикләнгән сер сандыгы ул. Кешенекен кешегә түкми, җилгә чәчми. Әңгәмәдәшен сабыр гына бүлдерми тыңлый да кулына ышанып тапшырылган сер йомгагын күңел төбендәге сандыкка яшереп-бикләп тә куя. Ул белә: беркем дә аннан ярдәм өмет итми. Һәр кешенең сабыр касәләре тулгач, мөлдерәмә тулы күңелен кемгәдер бушатасы килә — шул гына.

— Әй, Минҗиан астай, төшемә керсә дә, шатланып уянам бит. Үткән айда Сәкинә килгән иде. Килендәшне әйтәм. Коточкыч хәбәр әйтте: балакаем төрмәгә эләккән икән бит. Инде ике ел утыра ди. Авылга шундый хәбәр кайткан. Ышанмадым. Бигрәк йомшак күңелле иде бит ул, мәче баласына да ризыкны чәйнәп каптыра иде. Берчак шулай чебиләр яңгыр астында калды. Бәбкәчәем шуларны җыеп кергән дә мич башына тезеп куйган. Үлгән чеби тереләмени ул? Ташлатмады тәки, шулар янына беркемне якын да китермәде. Үзе йоклап киткәч кенә, чыгарып күмдек бичараларны. Нишләп төрмәгә эләксен ди инде шундый йомшак күңелле бала?! Юк-юк, мәңге ышанмыйм.

Ничәнче кат сөйли инде бу сүзләрне Гайния. Тик Минҗиан астай аны

барыбер бүлдерми. Сөйләсен. Аллаһы Тәгалә адәм баласына телне юкка гына бирмәгәндер. Хәсрәтенне эчкә жыя башласаң, көннәрдән бер көнне сабыр жепләрен өзелеп, упкынга тәгәрәвең бар. Тәнендә жаны-күңеле булган кеше генәме, ерткыч булып ерткыч та, наныйларын жуйса, бөтен дөньяны тетрәтерлек итеп улый лабаса.

Дустын тынлый-тынлый да, тегесе тын алган арада, тыныч, йомшак тавышы белән Минжиан да сабыр гына үз сүзен кыстырып куя:

— Эләгүе дә бар шул, Гайния... Бер гаепсезгә дә тыгып куялар бит бәндәләрне. Кешесе булса, эстәтясе генә табыла инде аның. Алла сакласын, диген.

— И-и балакаем... Караңгы зинданнарда дөнья яктысын күрергә тилмереп утырсын өчен таптыммыни мин аны?! Үз янымда булса, мондый хәсрәтләр күрер идемени?! Анаң үги булса, атаң жизнигә әйләнә шул... Исән чакта күрешүләр насыйп булырмы икән безгә, Минжиан астай? Никләр генә шундый ачы язмышлар язган икән мина, беркемгә зыяным тигәне юк лабаса.

Белә Минжиан, белә, Гайниянең дөнья бәясе кеше икәнен дә, башкаларга явызлык кылу түгел, тел тибрәтеп, авыр сүз әйтергә дә кыймавын белә. Ләкин якты жиһанның тузанлы юлларында байтак йөргән карчык тагын шуны да яхшы белә: бу дөньяда Гайния кебек игелекле жаннар никтер күбрәк кагылалар, күбрәк михнәт-газап күрәләр шул.

— Яратканыма бирермен, дигән бит, Гайния. Бу бәндәм бик сабыр, күтәрер әле дигәндер.

— Сабырлыклар төкәнеп килә шул инде, Минжиан астай. Үзем генә беләм хәлләремне, үзем генә беләм... Абзыема да сөйли торган түгел. Ир-атның күңеле барыбер каты. Каян аңласын ул мине, аныкылар атна саен янында бит...

Гайния кытыршы бармаклары белән күз тирәләрен сыпырып ала. Көмеш жепләрдәй яңагына тузгып төшкән берничә бөртек ак чәчен кабат чуар яулыгы эченә яшереп маташкан була. Берничә тапкыр тамак кырып куя. Бәгырьгә яшьләр төелгән бу мизгелне ничектер үткәреп жибәрергә кирәк...

Аның хәлен яхшы аңлаган Минжиан, жәһәт кенә урыныннан кузгала да, Үзбәкстанда яшәүче кызы алып кайткан ялтыравык бизәкле касәләргә шаулатып кайнар чәй өсти. Авылда шулай, бусаганнан атлап кергән кешене чәй эчерми чыгару юк.

— Суынганчы эч әле, Гайния, кәнфитләреннән авыз ит. Әкәмәт тәмле, йомшак кәнфитләр, әфлисун тәмнәре килә. Кала күчтәнәче, энемнең кызы кертеп чыккан иде. Ирләрне гаепләп булмый инде, Гайния. Аларныкыннан түгел, безнең йөрәктән өзелеп төшә бит бала. Ирләрнең хатын-кызны мәңге аңлыйсы юк.

— И Раббым, исән чакта бер күрешәсе, нурлы йөзләрен бер булса да күрәсе иде. Кан дошманы түгел ләбаса, тудырган, имезеп үстергән анасы. Яшьлеге белән аңламыйдыр инде балакай. Бер гөнаһым юк та бит, котыртучылар житәрлек. И бу дөньялар...

Ул тирән итеп бер уфтана да, боек карашын тәрәзәгә күчереп, үзалдына жырлый башлый:

Су буйлары моңсу иде
Без аерылган чагында, шул;
Тормыш дулкыннары безне
Кушар әле, тагын да...

— Кушар, кушар, боерса. Аллаһының кодрәте киң. Исән булсын дип телә, Гайния. Исән кешеләр кайчан булса да бер күрешә. Менә минеке бакча

башында, аяк астында гына да бит... Үкереп еласаң да, яннарына төшеп булмый, жир астына юллар юк... — дип юата аны ахирәте.

Яшь иде әле ул чакта Гайния. Утызы да тулмаган иде. Сугыштан исән-сау кайту бәхетенә ирешкән Нургата белән ярапышып-йөрешеп, гаилә кордылар, көтеп алган нарасыйлары туды. Авылда егет белән кыз гомерлеккә дип кавыша. Гаилә бозып, хатын аерып, бала ятим калдыру Саклык авылы тарихында моңа кадәр юк иде. Нургата беренчесе булды. Ярты Европаны йөреп, башка халыкларның тормышын күзәтеп-күреп кайткан таза-шәп солдатка бер хатын гына житмәде, күрәсең. Беркемнән яшерми, ни Ходайдан, ни бәндәдән оялмый, каладан кайткан яшь, чибәр китапханәче кыз белән чуала башлады. Утлар йотты Гайния, уртлары канаганчы тешләрен кысты. Мендәр кочып кайнар яшьләрен койса койды, әмма күңел яраларын ятларга түгел, жан дусларына да сиздермәде. Чуалыр-чуалыр да туктар-басылыр дип көтте. Жиләк кебек хатынын, күз нурыдай баласын ташламас бит ире.

Дөрес, баласын ташламады Нургата... Сөяркәсен өй түренә кайтарып утыртты да Гайнияне урамга куып чыгарды... Бусы инде авылда гына түгел, дөньясында да сирәк очрый торган, бөтенләй кеше ышанмаслык хәл иде.

Бигрәк яклаучысыз иде шул Гайния. Яшьли әтисез калган, ялгыз анасына берданбер бала иде. Ятимә хатыннар белән санашучы булмады. Дөрес, кача-поса көндәше килде, алдына тезләнеп:

— Апа, кичерә күр, бала көтәм, бармый чарам калмады бит, — дип зар елады.

Кичерде, каргамады аны Гайния. Ир бирмәк — жан бирмәк, дисәләр дә, Нургата өчен дә өзгәләнмәде алай. Бары тик:

— Баламны бирегез! — дип кенә ялварды.

Сабые үз янында булса, бу кадәр әрнемәс, утлы күмер йоткандай янмас-көймәс иде.

Ләкин бирмәделәр... Рәхәтләнеп сөяргә түгел, хәтта күрергә дә рөхсәт булмады. Максатлары баланы үз анасыннан биздерү, анын барлыгын оныттыру иде.

Ире дә, каенанасы белән каенатасы да нык торды. Бу йортның ишекләре Гайния өчен мәңгегә ябылды. Йөрәк өзгәләнүләренә түзә алмый, оланын ерактан булса да бер күрер өчен, килен булып төшкән йортның коймаларына ябышып, капка төпләрендә ауный-ауный еласа да, ананың жан әрнүләренә колак салучы булмады. Хатын сабыен сагынудан чиргә сабышты, ашау-эчүдән калды.

Аны Казанга акылы жиңеләйгәннәрне дәвалый торган больницага илтеп салдылар. Савыгып авылга кайтканда, Нургата, анын бәгырь жимешен дә ияртеп, гаиләсе белән читкә күчеп киткән иде...

Гайния өчен тормыш мәгънәсе югалды. Үзенә бикләнеп, кайгысына уралып жан асраган булды. Күзенә кояш та, ай да күренмәде.

— Болай булмый, кызым, — диде әнисе. — Гомерең заяга үтә. Яшь чакта тормышыңны көйләргә кирәк. Сине урнаштырмыйча, бу хәлдә калдырып, ни күңел белән китим? Минем дә тынычлап үләсем килә ләбаса.

— Мина барыбер, — диде Гайния.

Шуна күрә Түбән авылдан үзен хатынлыкка сорап килгән ике балалы тол иргә кияүгә чыгарга берсүзсез ризалык бирде. Күңеленә юаныч, зур шатлык булып кызы туды. Баш өстендәге авыр болытлар акрын-акрын таралгандай булды, күзенә дөнья яктысы күренә башлады. Юк, онытмады ул беренче нарасыен. Йөрәгеннән өзелеп төшкән, күкрәк сөтләрен имезеп үстергән сабые мәңгелек жан әрнүе булып аңа ияргән иде. Кызын сөйгәндә дә, аны уйлады.

Авылга кайткан саен, кардәшләреннән баласы турында сорашты, тик күңел юатырлык сүзләр ишетмәде.

— Ул атасы янында түгел, имеш. Каядыр читтә кайтмый йөри ди. Үзләре дә белми икән кайдалыгын. Чыккан да югалган, — диделәр.

Ә аннары, бурлыкта йөргән, шуның өчен төрмәгә ябканнар, дигән бик тә авыр, күңелсез хәбәр килеп иреште...

Бер утка икенчесе өстәлде. Түзсәң —түз, түзмәсәң — ела.

Еламый Гайния, яшьләренә түелә-түелә җырлый гына:

— Идел буйларына барсам,
Әйтер идем Иделгә, шул;
Минем кайгыларымны да
Илтеп сал, дип, диңгезгә.

Кем елап, кем җырлап юана...

Авыл очына килеп җиткәч, ир юлдашларына таба беренче тапкыр борылып эндәште:

— Зыятдин абыйлар кай тирәдә тора?

— Беренче урамга кергәч тә, уң якка борыласы. Без дә шул якка кайтабыз, абый. Килеп җиткәч әйтербез, — диде кызларның берсе.

Икенчесе, мәхәббәтеннән кояш булып балкыганы, дустына төртеп куркып кына пышылдады:

— Кем бу? Мин бу абыйны белмим.

Дусты исә, кем белгән инде аны дигәндәй, иңнәрен генә сикертте.

Алар бу кешене танымый иде.

Урамның болай да пычрак юлын тагы бер кат актарып бара торгач, кирәкле капка турына килеп җиттеләр.

Иң башта арбадан көләч кыз сикереп төште...

Шулчак Минҗиан астайның капкасы шыгырдап ачылды да, аннан әкрен генә басып, тулган айдай түгәрәк йөзле, ягымлы карашлы олы яшьләрдәге бер хатын-кыз килеп чыкты.

— Әни! — дип ана таба йөгерде Гөлфия. — Мин имтиханны «бишле»гә бирдем!

— Яхшы булган, кызым, бик әйбәт булган.

Гап-гади билге өчен дә шулчаклы сөенер, коштай очынып икән баласы. Яшьлекнең шатлыклары да бөтенләй үзгә шул...

— Әни, бу абый безгә килде, — диде Гөлфия, арбадагы кешегә ишарәләп.

Гайния апа кызыксынып, ул күрсәткән якка төбәлде. Арбадагы кешене танырга тырышып, күзләрен кыса-кыса, игътибар белән карады. Йөзендәге тыныч шатлык әллә куркуга, әллә аптырауга әйләнде. Күзләре тулы сорау иде. Шулай байтак кына һушсыз калып, ангы-мингә торганнан соң, бар йөрәге белән инрәп-пышылдап бары бер сүз әйтә алды:

— Улым?! Улым... Улым!!!

Ул бу сүзне бәгырь яшьләренә түелеп, мең-мең тапкыр пышылдады!

Ул бу сүзне ничә еллар буе җан авазы белән бушлыкка кычкырды!!!

Ләкин аны бары бүген ишеттеләр...



Людмила
Аланлы

# ТОРМЫШ — ШУНДЫЙ...

## Без — төрки халыклар

Борынгы бабаларыбыз
Уңган булган, нык булган.
Алар данын мирас итеп
Атлыйбыз туры юлдан.

Дус, тату булып яшибез,
Без бит төрки халыклар!
Үз рухыбыз, үз дөньябыз,
Безнең сүздә хаклык бар.

Телебез төрле булса да,
Жаныбыз белән бердәм.
Бер-беребезне аңлыйбыз
Бер караштан, бер йөздән.

Буын чылбырын өзмичә,
Рух ныклыгын да аклап,
Чит милләт вәкилләренә
Яшибез хөрмәт саклап.

## Язларыңа кайтыр идем

Язларыңа кайтыр идем...
Озын кышларың аша үтеп.
Безне кавыштыралмаган
Серләр йомгагын сүтеп...

Язларыңа кайтып киләм...
Алларымда, ләкин
күзең бар.
Мине янә сынар өчен
Ява микән шушы җепшек кар?..

*Людмила АЛАНЛЫ — яшь шагыйрә; «Бәхет телим сиңа» исемле китап авторы. Әлмәт шәһәрендә яши.*

Язларында калыр идем.
...Рөхсәтең бирсәң икән –
Мин бит гомер буе
«Жаным», — дип дәшер чагыңны,
Тилмереп көтәм...

## Хисләрең — мәңге

Язлардан соң җәйләребез
Житмәгән әле.
Сөйләшеп сүзләребез дә
Бетмәгән әле.

Күрешеп күзләребез дә
Туймаган әле.
Яшьлегебез сөю дәртен
Жуймаган әле.

Ул чәчләреңнең хуш исе,
Йөзеңнең яме!..
Синдә генә була торган
Иренең тәме...

Синең миңа гына диган
Хисләрең — мәңге.
«Яратам», — диеп әйт тә син,
Кочакла әле.

***

Алтын йозакларга
биклэп куеп хисләремне,
Йөгәнләгән чагым тойгыларым,
серләремне...
Синең алда бераз кырыс булып
тоелсам да,
Жинә алмам сыман нечкә хисләремне...

Алтын йозакларга
бикләп куеп сүзләремне,
Синең янда бары ялган сүзләр сөйләрменме?..
Дөрес фикер табармынмы
ялган сарган чакта?
Чын уйларым башкасыннан сизәрсеңме?..

Алтын йозакларга
бикләп куеп тойгыларны,
Синең алда буш җан гына булып тоелмаммы?
Тышкы яктан битараф калырга тырышсам да,
Сизәрсең күк моң дәрьясы — үз дөньямны...

Тормыш шундый –
Ул ниндидер кысаларга куып кертә.
Хисләренне яшерергә дә мәҗбүр итә.
Ләкин...
йөрәк түрләреннән ургып,
шашып чыккан
Ихлас,
садә,
саф хисләргәниләр җитә..

***

...Ничәмә ел узган...
Яңа хисләр сызган...
Хәзер килеп: «Кичер», — дисеңме?
Мәхәббәтең белән
Күңелем төрмәгәнсең,
Йөрәк җуйган синең исемне...

Җәрәхәтләремә
Кемдер шифа булып,
Назлар булып җылы тын өргән.
Сөю ишекләрен
Йөрәк сиңа мәңге
Ачмаска дип ябып өлгергән...

## Мин җәйләрдә калам

Мин жәйләрдә генә калам,
күнел көзгә
Һич игътибар итми, һич кенә.
Уйларымның әле шундый чагы –
көнгә иләсләнеп,
Гел уйламый әле кичне дә.

Мин жәйләрдә генә калам,
йөрәк әле
Гел сәламли ярсу жилләрне,
Тынычлыкны үз итмичә генә,
әллә шулай
Мәңге-мәңге ярсып тибәрме?

Мин жәйләрдә генә калам,
әйдә, син дә,
Ияр әле шашып, яратып.
Тормыш тәмен татып булыр төсле,
дөнья матурлыгын,
Мәңге шулай жәйне яратып!



*Зилә Марат кызы Мөдәррисова 1978 елның 30 ноябрендә Самара өлкәсе Шенталы районының Денис авылында туа. Авыл мәктәбендә урта белем алганнан соң, Самара педагогика университетының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 2001 елда Лениногорск шәһәренә килеп, «Яшьлек иле» исемле балалар һәм яшьләр газетасы редакциясенә хәбәрче булып урнаша. Шул елларда аның иҗаты аеруча активлаша, кыска, шаян хикәяләре үзе эшләгән басмада, «Заман сулышы» һәм Самарада нәшер ителүче «Бердәмлек» газеталарында даими басылып тора.*

*2008 елда Зилә Мөдәррисова республика күләмендә үткәрелгән «Иделем акчарлагы» иҗади бәйгесендә катнашып, «Шәп концерт» исемле хикәясе белән проза номинациясендә икенче урынга лаек булды. Балалар өчен язылган «Диләрә — матур кыз», «Белдерү» хикәяләре «Рухият» нәшриятында чыккан «Балаларга — бүләк» һәм «Илһам чишмәләре» җыентыкларында дөнья күрде.*

*Зилә Мөдәррисова Лениногорскида яши, шәһәр җәмәгать үзидарәләренең берсендә рәис урынбасары булып эшли.*

# ХИКӘЯЛӘР

### Шәп товар, имеш!

Ничәнче көн рәттән кесә телефоныма мөлаем гына тавышлы бер кыз шалтырата да:

— Без фәлән компаниядән, бездә фәлән акция, без сезнең келәмне чистартырга булдык, фатирыгызда презентация үткәрергә телибез. Сездән берни кирәк түгел, бары тик игътибар һәм өйдә булуыгыз таләп ителә, — дип тенкәмне корыта.

Бу бәйләнчек кыздан котылыр өчен ризалашмый булдыра алмадым. Бушлай да дигәч, зинһар, күнеле булсын, әйдә чистартсын рәхәтләнеп дип, өйгә килергә рөхсәт иттем.

Хәләл җефетемә бу хакта авыз ачуым булды:

— Презентацияң миңа ни пычагыма? Бу тамашада катнашырга теләгем юк! — дип, телевизор карап утырган җиреннән җәһәт кузгалып, йокы бүлмәсенә кереп тә югалды.

Билгеләнгән вакытка минуты-секунды белән ишектә кыңгырау чыңлады. Ачсам, каршымда кәртинкә кебек бер яшь кенә егет елмаеп басып тора. Беренче соравы:

— Ирегез өйдәме? — булды.

Күз ачып йомганчы, үзе белән алып килгән әйберләрен идәнгә таратып салды. Аннан миңа тагын сораулы караш ташлап:

— Йә, кайда инде ирегез? Аннан башка һич кенә дә ярамый, презентациябезнең беренче шарты шул, — диде.

— Әйдә инде, чык! Презентация тыңлаганнан гына укаң коелмас. Ялгызымны шундый матур егет белән калдырмассың бит. Урлап китсә, нишләрсең? − дип, җан кисәгемне тәки күндердем.

Ул, чыраен сыта-сыта, яраткан диванына менеп кунаклады. Егет, җитди кыяфәт чыгарып:

— Борчылмагыз, сездән берни кирәк түгел. Кырык минут вакытыгызны миңа багышласагыз, шул җитә. Презентация барышында мин сезгә сораулар бирермен, ә соңыннан шушы келәмегезне чистартып китәрмен, — диде.

— Унбиш минутлап җир йөзендәге иң шәп, иң заманча тузан суырткыч хакында илһамланып сөйләгәч:

— Менә сез сәламәтлеккә ничек карыйсыз? — дип сорады.

— Бик яхшы карыйм! Исәнлек — зур байлык. Байлыкның башы – тазалык, — дидем укытучыга җавап тоткан бала шикелле.

Әлегә кадәр ваемсыз гына, дәшми-тынмый утырган ирем дә телгә килде:

— Туктатыгыз бу фәлсәфәне! Кара әле, әфәнде, нигә әле шундый ахмак сораулар биреп безнең башны катырасың син? Балалар бакчасына килдем диеп белдеңме әллә?

— Зинһар, атасы, кызма, нервыларыңны сакла. Хатыныңа хыянәт итәсеңме яки төрмәдә утырганың бармы, диеп сорамый ич, — дип хәләл җефетемне тынычландырырга керештем.

«Презентация» хуҗасы ачуын яшерергә тырышып дәвам итте:

— Сез белергә тиеш, бу искиткеч суырткыч! Ул келәмне генә чистартмый, һавадагы бөтен зарарлы микробларны да юк итә. Ә бит безнең тирәдә алар меңләгән, миллионлаган...

Калганын егеткә сөйләп бетерергә насыйп булмады.

— Шәп әйттең, егеткәй! Бу тылсымлы суырткычың барлык микробларны да бетерсен ди. Шуның белән бөтен авыру-сырхаулардан котылып булыр дисеңме? Подъезда, урамда авыз-борынны бәйләп йөрергә кушасыңмы, әллә инде кесә суырткычы да уйлап тапканнармы? Син бу уникаль товарыңны ал да сәламәтлек саклау министрына бар!

Китте тезеп, китте тезеп...

— Кара әле, атасы, презентацияне кем үткәрә монда? Бу егетме, әллә синме? — дип мин дә һөҗүмгә күчтем. Кунак егете сер бирмәде, башын кагып елмайгандай кыланды да робот кебек кабат такылдарга тотынды:

— Бу суырткычның мөмкинлекләре бик күп, ул шулай ук юа, киптерә, юрган-мендәрләрегезне дә яңартып җибәрә. Бу суырткыч шәп яшәргә теләгән, үзен яраткан һәрбер гаиләдә булырга тиеш! Менә әйтегез әле, ханым, сезгә шундый суырткыч кирәкме?

— Әлбәттә, баш тартмас идем, дизайны матур, программасы да күп төрле. Нинди хуҗабикә мондый булышчы хакында хыялланмас? Ә бәясе, бәясе күпмеррәк соң? — диеп кызыксына башладым мин. Әле ярый утырып тора идем. Хакын әйткән иде, валлаһи, күз алларым караңгыланып, авып ук киттем.

— Әлеге хикмәтле суырткычның бәясе 125 мең... Юк, юк, борчылмагыз, ташлама ясарга мөмкин. Бездә кичектереп түләү дә каралган, өйдән чыкмыйча гына үзегезгә ошаган банк аша килешү дә төзергә була, — диде егет.

Ир дигәнем сикереп торды да:

— Әһә, бар да аңлашылды! Карак, шпион син! Әле кичә генә телевизордан сак булырга куштылар. Шулай матур гына сайрап, суырткыч сатып, бер пенсионер әбине төп башына утырткаңнар. Мескеннең ничә еллар җыйган акчасыннан җилләр искән. Инде безне таларга уйлыйсызмы? 125 меңгә түгел, 125 сумга да алмыйм бу сәләмә суырткычыңны, — дип чак кына егетнең бугазына барып ябышмады. Мәскәүләргә хәтле барып та торасы юк, үземне Малахов тапшыруына эләккәндәй хис иттем.

— Зинһар, тынычлан, кадерлем! Күпме әйтеп килəм, бертуктаусыз телевизордан әллә нинди тапшырулар каравың бер дә хәерлегә булмас дип. Ник әле бу егеткә бәйләнәсең? Суырткычны да көчләп тагарга җыенмый, бары тик

таныштыра гына. Дөньяда бер машина бәясе торырлык суырткыч бар икәнен кайдан белер идек әле? — дип бәгырь кисәгемне көйләргә тотындым.

Яна гына май кояшы кебек балкыган егетнең нурлары әллә кая качты, бер агарынды, бер бүртенде. Алдан ятлап куйган сүзләрен онытып, кәжә тәкәсе кебек ык-мык килде.

— Әле шушы кыйммәтле суырткыч белән keләмемне чистарттылар дип мактаначакмын, гәҗиткә дә язачакмын! — дип күңелен күтәрмәкче булып, шаяртуга күчкән идем, мескен егет, «презентация»сен ташлап, яшен тизлеге белән келәмне чистартып чыкты да сыпырту ягын карады.

— Гомеремдә беренче тапкыр шундый презентация булды... — дип мыгырдаганы гына ишетелеп калды.

## Гафу ит, Иванова...

Эш сәгатебез җидедә башланса да, иртәрәк килергә сөйләштек. Ыгы-зыгы башланганчы иркенләп отчётларны теркәргә, эш кәгазьләрен тәртипкә салырга иде исәп. Ә бер ир бездән унганрак булып чыкты. Таң беленер-беленмәс килеп, директор бүлмәсендә гауга куптарып маташа иде.

— Сез — карак, бур, алдакчы! Әнидән гафу үтенмәсәгез, судка хәтле барып җитәм! Белегез, болай гына калдырмыйм, гәҗиткә язып чыгам! — дип җикеренгәне урамга хәтле ишетелә.

— Гагарин урамы кайсыгызда? — диде җитәкчебез безне күрүгә.

— Безнеке түгел...

— Алайса, бүген Гагарин урамының фәлән йорты өчен сез җаваплы. Хәзер үк Ивановның әнисенә барып гафу үтенергә кирәк. Җайлап кына аңлатып кайтыгыз, — дип боерды боеруын...

Директорыбыз ике сөйләп тормый, кабат кайтарып сораганны да яратмый, аның нәрсә теләгәнен бер күз карашыннан аңлау зарур... Аңламасак та, «аңладык» дип баш кактык та хезмәттәшем белән «задание» үтәргә керештек.

Иванова яши торган урам да, йорт та безнең карамакта түгел. Җитмәсә шушы йортлар өчен җаваплы кыз авырып эшкә чыкмады, үч иткәндәй, телефонын да алмый.

Нишлисең, компьютерда кирәкле программаны ачып, Иванованың 75нче фатирда яшәгәнен ачыкладык та абына-сөртенә гафу үтенергә киттек. Өч ел эшләү дәверендә ярты шәһәрне аркылыга-буйга узсак та, кирәкле йортны башта — табалмый, тапкач, подъездга керә алмыйча җәфаландык. Ә керү бәхетенә ирешкәч, ишек белән генә исәнләшергә насыйп булды. Күрше-күләннәрен йөреп чыктык, очраган һәрбер кешене туктатып төпчендек, тик Иванованың кайдалыгын тәгаен әйтүче булмады. Кәефләр кырылып, соңгы өметебезне югалтып, башларны түбән иеп кайтып бара идек... Каршыбызга салмак кына атлап бер хатын килә. Икебез берьюлы:

— Сез алай-болай Иванова түгелме? — дигәнне сизми дә калдык.

— Әйе, мин Иванова булам. Ни йомыш? — диде ул гаҗәпләнеп. Ә безнең шатлыктан башыбыз күккә тиде.

— Беләсезме, без инде сезгә дүрт тапкыр килдек! Гафу үтенәсебез бар иде... — дип сүзебезне ялгый алмый аптырап беттек.

— И-и, мескенкәйләрем! Минем бит бөтенләй өйдә торганым юк. Авыру сеңлемне карыйм. Өс-башымны алыштырырга гына кайтуым иде.

— Сез гафу итегез инде, теге су торбалары белән ялгышлык килеп чыккан бит...

— И-и, юкны сөйләп тормагыз. Онытым инде ул хакта, гаеп үземдә булган бит.

— Шулаймы? Ә мена улыгыз онытмаган, бик нык хәтерли.
— Улым дисезме? Булмас! Аның бит бер генә дә вакыты юк.
— Кирәк булгач, тапкан инде. Иртүк безнең оешмага килеп тавыш куптарды. Безнең килгәнне, гафу үтенгәнне аңа әйтерсез инде, яме?!
— Вәт, җәфа! Анасының хәлен белергә вакыты юк... — диеп зарлана башлады Иванова. Сүзне тизрәк башка якка борып:
— Ул бит сезнең хакта борчылып килгән. Шундый олы гәүдәле, чибәр абый, — дип куштанландык без.
— Минем бөтен балаларым да шәп, акыллы, тынычлар. Алай да, җиләк кебек кызларның эчен пошырып ник талашып йөрде икән? Әй, игътибарга алмагыз ла, исерек булгандыр ул.
— Ярый, алайса сау булыгыз! Улыгызга без килгәнне әйтергә онытмагыз инде, — дип кат-кат искәртеп, без кабат эшебезгә киттек.

Җилкәбездән авыр җик төште, иртәнге алтыда ниятләгән эшебезгә, ниһаять, кичке алтыда керештек, тик өлгерми калдык, бүлмәбезгә хуҗабыз атылып керде. Ә артыннан... артыннан... помидор шикелле кызарынган-бүртенгән ир килә. Әлеге дә баягы теге Иванов. Директорның: «Кызлар!» — диюе булды, солдатлар кебек сикереп торып та бастык.

— Кызлар, әй кызлар, сез миңа бер дә ошамыйсыз әле. Ник иптәш Ивановның әнисеннән гафу үтенмәдегез?
— Үтендек! Әле ничек кенә үтендек! — дип аклана башлаган идек, кая анда безне тыңлау, күгәргән тимер тавышы белән бездән алда Иванов кычкыра:
— Юк, килмәделәр! Алдакчылар! Әни сезне көне буе көтеп, ипигә дә чыкмыйча ач утырды! Судка барам, гәҗиткә язам! — дип дулапмы дулый.
— Ничек инде алай? Бардык, бөтен көнебез аны эзләп үтте. Әле генә гафу үтенеп кайттык. Әниегез өйдә юк иде ич, яңа гына авыру сеңлесеннән кайтып калды, — диган идек, Иванов болай да шар күзләрен тагын да акайтты:
— Нинди сеңел? Аның миннән башка беркеме дә юк! Кара әле, ялганлап та маташалар, оятсызлар!

Хуҗабызның да ут чәчкән күзләре, хәзер үк яндырып үтерердәй булып, безгә кадалды:
— Көн буе кайда буталып йөргәнсездер, анысы миңа карангы. Аңлатмагыз иртәгә үк өстәлемдә булсын! Ә мена Ивановның әнисе алдында хәзер үк гафу үтенергә кирәк! Хәзер үк! Ишеттегезме?!
— Вакыт соң бит инде... Бәлки иртәгә... — диеп авыз ача башлаган идек, директор:
— Знать не знаю! Тәүлектә егерме дүрт сәгать! — диде дә ишекне шапылдатып чыгып китте.

Компьютерны ачып, программага кабат күз салсак... Гагарин урамындагы теге йортта җиде Иванов яшәп ята икән...

## Ул бит... ямьсез!

Быел гына сиксән яшен тутырган Мәрфуга карчык тутыгып беткән калай чәйнегенә бер касәлек кенә су салды да газ плитәсен кабызып җибәрде.

Оныгы юбилеена бүләк иткән матур бизәкле чәйнекне күнел өчен генә дә тотып карамады ул. Хәер, башка бүләкләргә дә кагылмады, барсын да күз алдыннан җыеп алып, өенең аулак почмагына өеп куйды.

Зәңгәрсу төстәге җинел синтепон юрганын кат-кат кулына алып: «Нәрсәгә инде моны әрәм итим», — диде. Ипи салган көнне дә ачтан үлә торган

Мәрфугага хан заманындагы сиксән ямаулы юрган да ярап тора. Алсу бизәкләр төшерелгән кыйммәтле ак җаймаларне дә туздырып тормады ул: «Ай-һай, бигрәк матур! Тик мондый затлы җаймаларда йокларга мин инде карт. Әнә хәзер минем өчен... ак кәфенлек...» — дип баш чайкады.

Башкортстаннан туган көн бәйрәменә махсус кайткан килендәше бүләк иткәндә: «Кара аны, саклап ятма, барыбер теге дөньяга алып китә алмассың! Хет картлык көнендә булса да кадерлә үзеңне!» — дигән иде. Әмма кунагы китүгә аның бүләге дә сандык төбенә төшеп ятты...

Ә менә кызы бүләк иткән чәй сервизын Мәрфуга җыеп куярга батырчылык итмәде. Кызы: «Зинһар, әни! Бер генә булса да кителмәгән касәләрдән чәеңне тәмләп эч әле!» — дип ныклап кисәтте, иске савыт-сабаларны җыеп ук атты шул. Шуңа күрә бик җәл булса да, ике пар чынаягын көн дә кулланырга туры килә. Ник икәү дисезме? Чәйне ул уң як күршесе Зәйтүнә белән дөнья хәлләрен гәпләшә-гәпләшә эчәргә ярата. Билгеле, ялгыз кешенең ашы — аш, эше — эш түгел.

Кадерле күршесе генә өендә юк әле. Себердән кайткан балалары Ял йортына җибәрделәр үзен. Мәрфуганы да үгетләп караганнар иде, күндерә алмадылар. Йортын ташлап китәме соң?! Ник дисәң дә, монда үз өе, үз көе. Аягында йөри алганда, беркая да китмәячәк. Аллаһы боерса, шул иске караватында гына җан бирер. Тик әҗәл генә еракта йөри әле, Ходайның рәхмәте!

Менә инде ике атна Мәрфуга Зәйтүнәсен юксынып яши. Аның хәлен бары тик күршесе генә аңлый шул. Балалары, оныклары тыңламый да кебек үзен. Берәр җире авыртып зарлана башласа: «И-и әби! Әни! Сиңа ничә яшь әле? Сиксән яшенә җитеп, шулай йөри алгач, шөкрана кылып яшә!» — дияргә тотыналар.

Беркөнне газ плитәсен дөрес сүндермичә, газ чыгып торганын сизмәгән. Шул әлеге дә баягы күршесе коткарды. «Зәйтүнәм кермәсә, хараплар була идем. Менә ул булмаса, күмәргә генә килгән булыр идегез! Хәлемне дә белмисез!» — дип сукрануына да: «Үлмәгәнсең ич, яшисең! Шатланып тор!»— дип авызын томаладылар.

Нәрсәсенә шатланырга? Ятса — ялгыз, торса — ялгыз. Ичмаса, моң-зарын түгәргә күршесе генә дә китте...

Кинәт уйламаганда-көтмәгәндә, май кояшыдай елмаеп, куенына төргәк кыстырып, кунакка гына кия торган киемнәрен дә алыштырып тормыйча, Зәйтүнә килеп кермәсенме! Аны күргәч, Мәрфуга шаккатты!

— И-и, кайттыңдамыни? Рәхмәт яугыры! Кая әле, чәйнегемә су өстим. Бергәләп чәйләрбез!

Карчык, шатлыгыннан кабалана-кабалана, әле генә кайнап чыккан чәйнегенә башта бер йомры, аннан, бәлкем, бер утыргач, икене дә эчеп ташларбыз дип, тагын берне өстәп, чәйнеген янәдән куеп җибәрде. Зәйтүнә керә-керешкә:

— Исәнме, Мәрфуга! Ни хәлләрдә яшәп ятасың?— диеп сорашырга тотынган иде.

— Минеке нәрсә? Чигәләр кыса, йөрәк сикерә, тәнем сызлый, аяклар авырта... — диеп гелдәгечә зар-моң түкте Мәрфуга.

— Бетте-бетте, бүтән сорамыйм, — дип, сүз озайтып тормады Зәйтүнә дә. — Авылда нинди яңалыклар бар?

— И-и, беркая да чыгып йөргәнем булмады. Син белсәң генә инде, Зәйтүнә!

— Кара әле, сул як күршеңнең кечтек кызы әллә ирә белән тормыймы?

— Раниясеме, әллә Саниясеме?!

— Исемен белмим. Ин кечесе диделәр инде.

— Алайса Рания инде, Рания! Ул бит... ямьсез! Ир дигәне матурракны тапкандыр. Мин ничек бу картинкә кебек ир моңа өйләнде икән диеп гел баш ваткан идем.

— И-и, син бигрәк! Күрше кызынны бөтенләй юкка чыгарып ташлама инде! — диде Зәйтүнә, Ранияне яклап.

— Әйе, матур түгел ул, тик унган, унган! Ул кайтсамы? Ул кайтса, әнкәсенен бер эше дә калмый инде. Юасын юа, пешерә-төшерә, тозлый-кайната... Вәт мәхлук, ирен әйтәм, ничек шундый булган-унган хатыннан баш тарткан, ә?

— Карга Саматының уртанчы малае Камил дә Гөлчәчәге белән аерылышканнар, бергә тормыйлар икән, — диде Зәйтүнә, болар беренчесе дә, соңгысы да түгел дигәндәй кулын селтәп.

— Ул бит... ямьсез! Камилне әйтәм... ягымсыз... йолкынган чебеш сыман үзе ябык, үзе килбәтсез озын! Җиләк кебек хатыны үзе белән әле дә ничек яшәгән диген.

— Әй Мәрфуга, Мәрфуга! Чибәрлектәмени эш? Матурлык туйда гына кирәк бит ул! Иң мөһиме — холкың матур булсын!

— Анысы шулай инде, шула-ай! — дип килеште Мәрфуга.

— Камил ул болай тыныч, ипле генә егеткә охшаган. Артыгын сөйләми, эчми-тартмый! Хәзер андый ирләрне көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый! Хатын дигәнеңә нәрсә җитмәгәндер, ә?! Адәм баласы михнәткә чыдый, ә менә рәхәткә чыдый алмый, дип белмичә әйтмәгән шул борынгылар.

— Ишеттеңме соң әле? Бака Фираясының оныгы теге ни... лисме шунда, ласмы... реклам күрсәтәләр бит инде. Теге ни... чит илнең кипкән бәрәңгесен ашап, ун мең акча откан ди!

— Кит аннан! Ул бит... бигрәк ямьсез! — дигәнен сизмичә дә калды Мәрфуга.

— Алай димә, Мәрфуга, керпе дә баласына йомшагым диеп әйтә! Һәрберебезгә үз баласы якын, иң матуры, иң яхшысы шу-у-л!

Мәрфуга карчык тагы килеште:

— Әйе шул, Фираяның оныгы бик башлы ул, харап зирәк. Мәктәптә дә гел «5»леләргә генә укый дип ишеткән идем. Болай булса, мәктәпне алтын медальгә дә тәмамларга күп сорамас.

— Авылыбызга яңа табиб килгән икән. Син күрдеңме әле? — дип сорады Зәйтүнә.

— Күрдем, ул бит... ямьсез! Шундый ягымсыз!

— Мәрфуга! Ни пычагыма сиңа аның матурлыгы? Безгә ни, эшен белсен, кешелекле булсын! — дип шелтәләде күршесен Зәйтүнә.

— Анысы хак, яңа табибны болай бик мактыйлар. Әйе, бик яраталар. Үз эшен белә, җиренә җиткереп башкара, диләр.

— Сеңлең Розаның күршесе Бөрәйдәне дә җирләгәнсез икән... — диде Зәйтүнә дога кылып.

— Ул бит... ямьсез... карап торырга да коточкыч иде! Бичаракай, котылды инде.

— Өй сатып алганчы, күршеңне тикшер, диләр. Иң мөһиме, әйбәт, саф күңелле кеше булсын ул! — диде Зәйтүнә.

— Бөрәйдәнең урыны оҗмахта булсын! Бигрәк изге кеше иде! Роза белән бик тату яшәделәр, бик йөрешәләр иде! Нәкъ менә безнең кебек инде! — дип Мәрфуга мәрхүмәне мактый башлады.

— Күршекәем! Онытып та торам, сиңа дигән күчтәнәчем дә бар иде! Яшел чәй алып кайттым үзеңә! Бик файдалы ди! Онытканмын бирергә! Ну бу тишек хәтерне! Ну бу картлыкны!

— Ул бит... ямьсез, бик ямьсез!

— Кем?! Минме?

— Картлыкны әйтәм, картлыкны! Шундый ямьсез, шундый килбәтсез, үзе сөйкемсез... Үзе котсыз! — дип уфтанды Мәрфуга.

— Менә бусы дөрес! — дип хуплады ахирәте.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Әдип Маликов (1921-2009) — шагыйрь. 1950-1960 елларда Әлмәт шәһәрендә әдәби иҗат берләшмәсен оештыручы, рәсмиләштерелгән әдәби оешмага нигез салучыларның берсе.*



*Гариф Ахунов (1925-2000) — прозаик, Татарстанның халык язучысы. 1963 елда нефть төбәге язучыларын берләштергән Әлмәт язучылар бүлеге оешкач, аның беренче җитәкчесе.*



*Әлмәт язучылар бүлеге җитәкчесе Равил Фәйзуллин (уңнан икенче) Азнакай районында яшәүче яшь каләм ияләре белән. Сулдан уңга: Әсгать Сәгыйтдинов, Марсель Галиев, Ирек Бәдретдинов. 1968 ел.*



*Язучыларның Әлмәт бүлегендә. Сулдан уңга — Роберт Рәкыйпов, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Әхәт Гаффар (1982-1987 елларда бүлек җитәкчесе). 1985 ел.*




*Шагыйрә Клара Булатова – быел Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*



*Нефть төбәгендә яшәп иҗат итүче язучылардан бер төркем. 90нчы еллар башы.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

*Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин (1928—1991) — нефтьчеләр турында «Каты токым» (1972) һәм «Тирән катлам» (1980) дигән романнар язган автор. Романнар Мәскәү нәшриятларында рус телендә дә берничә кат басыла. Бу хикәя исә журналыбызда нәкъ илле ел элек — 1965 елның 7нче санында чыкты.*



Шамил Бикчурин

# КАЙТУ

ХИКӘЯ

## I

Кайрак кебек шома, тигез асфальт юлны калдырып, ул каен урманына таба борылды. Моннан инде барасы буровойның сәндерәсе дә, андагы верховойның гәүдәсе дә аермачык булып күренә иде. Ахры, бораулаучылар инструмент күтәрәләр — верховой шәмнәрне кабул итәргә менгән.

Мөнәвир, верховойга күренмәскә теләп, юл буендагы яшь каен куакларына табарак сыенды, үзе зур дулкынлану белән кызу-кызу бара бирде, йөрәге аның күкрәк читлеген җимердәй булып тыпырчына, сулыш алырга ирек бирми, ярсый. «Нәрсә диярләр, үзләренә кире алырлармы?» дигән уй җәфалый иде юлчыны.

Мөнәвир, нәрсәдер белергә тырышкан сыман, тагын вышка башына карап алды, тагын агачларга елыша төште. Назлы каен яфраклары аның битен сыйпап иркәләгәндәй иттеләр, аны бераз тынычландырдылар. Ул күлмәк изүен чишеп җибәрде, агачтан бер-ике салкынча яфрак өзеп алып, аның белән маңгай тирен сөртеп ташлады. Аннан, юл читендәге яңа киселгән агач төбенә күләгәгә утырып, тәмәке кабызды да ерактагы буровой гөрелтесе белән кушылган кошлар сайравын тыңларга кереште. Сигез айдан соң туган җирләргә кайтып, янадан таныш урманда утыру аңа чиксез ләззәт бирә иде.

Урман, урман! Хуш исле, сайрар кошлы урман, ничек сагындырдың син Мөнәвирне! Үзеңдә булган бар нәрсәне: һәр аяк тавышын, һәр агач шытырдавын, һәр кош сайравын һәм буровой торбасының һәр чыңын бәйнә-бәйнә сөйләп торган яңгыравыклы, беркатлы, гади урман, ничек юксындырдың син улыңны!

Тыңлап карагыз әле, чыннан да гаҗәп соң: шунда ук гөрләп буровой эшләп тора, шунда ук, тирә-юньгә әһәмият бирмәстән, агачлардан-агачларга кунып төрле кошлары, сандугачлары сайрый. Мондагы кошлар һич тә буровойны үзләренә комачау итеп карамыйлар — сайрыйсын сайрый бирәләр. Җитмәсә, оя да ясыйлар, бала да чыгаралар. Буровой һәм кошлар ничектер бер-берсен тулыландыралар. Кошлардан башка буровой, буровойдан башка кошлар яши алмастыр кебек.

Мөнәвирнең сынаганы да бар: урманнан вышка күченеп киткәч, кошлар монсуланып калгандай булалар, ямансу сайрый башлыйлар. Урман эче барабансыз оркестрны хәтерләтә. Көз көне, кошлар жылы якларга очкач, тагын да күнелсез — урман оркестрынын бер барабаны — тукраны белән буровое гына кала.

Мөнәвир киткәндә көз, урманнын әнә шундый күнелсез чагы иде. Тик Мөнәвир туган ягын урман күнелсез булган өчен ташлап китмәде.

Юк, ул чагында урманнын ямен дә, туган якларнын якынлыгын да белерлек дәрәжәдә түгел иде ул...

...Сонгы уйлар Мөнәвирнен кәефен генә жибәрде. Ул тәмләп тәмәкесен дә тартып бетерә алмады, төпчеген аяк астына салып изде дә, урыныннан авыр гына торып, кыяр-кыймас юлга төште. «Үткәннәрне бәлки гафу итәрләр» дигән өмет бетмәгән иде әле анарда. Бары шул бердәнбер өмет кисәге генә аны кире кайтырга, бирегә килергә мәжбүр итте дә.

— Сәләхетдин абзый бәлки читкә типмәс, алыр...

Бораулау мастерынын бөтен яхшылыкларын, иткән изгелекләрен хәтерләп, юл буе шул уйлар белән юанып килде Мөнәвир.

Менә буровой да яп-якын инде, каршыда гына. Бораулаучылар ашыга-ашыга забойга инструмент төшерәләр. Чынлап карасан, кешеләрен дә танырга була. Әнә, вышка башында верховой Әбүзәр — дус малай. Гәүдәгә озын булганы өчен Мөнәвир аны үз итеп кенә ирештерә, үрти торган иде: «Нигә сина вышка башына менеп йөрергә, үрелсән болай да житәсен ич...» Теге юаны — Фәрит, ахры. Әйе, ул. Ярдәмче урынына баскан. Димәк, күтәрелгән егет.

Тукта, бораулаучы кем сон? Зәнгәр шакмаклы күлмәк кигән, тәбәнәк буйлы бу кеше кем, Зыя түгелме?

Кайчандыр Мөнәвир генә басарга хаклы булган идарә пультына басып, тормоз рычагын тоткан Зыяны күргәч, Мөнәвир үзе дә сизмәстән кашларын жыерды.

— Зыя булып Зыя бораучы? Минем өйрәнчегем?..

Бөтен тәнен биләп алган тирән көнләшү хисе әлегәчә булмаган тәвәккәллек белән Мөнәвирне алга өстерәде.

Шулвакыт культбудка астыннан зур соры эт өреп чыкты һәм, ямьсез калын тавыш белән амалап, Мөнәвиргә таба килә башлады. Юлчы куркып, барган жиреннән шып туктап калды.

Бу эт Вертлюг иде. Шул — бервакыт эшкә барганда бораулаучыларнын юл буенда янгыр астыннан тапкан һәм автобуска утыртып вахтага алып килгән көчекләре.

Мөнәвир киткәндә Вертлюг йодрык кадәр генә иде, хәзер чын овчарка, кешене куркытырлык эт булган.

— Вертлюг, әллә үзеннекеләрне танымыйсынмы? — диде Мөнәвир, исәнләшкәндәй, эткә таба кулын сузып. Ләкин Вертлюг аны тынламады, эндәшкән саен усалланды гына.

Эт өргән тавышка культбудкадан бораулау мастеры Сәләхетдин абзый чыкты. Ул бөтенләй нефтьчеләргә хас булмаган челтәрле ак майка кигән, яланбаш иде. Чәчен, гадәтенчә, тап-такыр итеп алдырган, мыегын борын астында бармак башы кадәр генә калдырып кырган.

— Вертлюг! — диде эткә кисәтүле итеп Сәләхетдин абзый һәм, үзенә ялагайланып сыенган овчаркага бармак яный-яный, килүчегә каршы китте.

— Әллә Мөнәвир инде?

Мастер гажәпләнгәндәй итенде, туктады. Мөнәвир кабаланып ана кулын сузды.

— Мин, Сәләхетдин абзый, исәнмесез?

Очрашу, күрешү нәкъ Мөнәвир көткәнчә булды. Сәләхетдин абзый салкын гына, исе китмичә генә кул бирде һәм:

— Кайттынмы? — дип сорады мәгънәле генә итеп. Мөнәвирне баштанаяк

күзе белән капшап чыкканнан соң: — Ишеткән идем, ишеткән идем, — дип өстәде.

Мөнәвирнең йөрәге жу итеп китте: «Барысын да ишеткән икән».

Сәләхетдин абзый, чыннан да, Мөнәвир Гариповның кайтуы турында бораулау конторасында бер атна элек үк ишеткән иде инде. Халык дигәнең андый хәбәрне яшен тизлеге белән тарата бит ул. Мөнәвирнең мажараларын конторада бераз арттырып та сөйләделәр бугай. Имеш, Гарипов моннан киеп киткән күлмәген дә алыштырмаган. Имеш, кайтырга да хатыныннан акча соратып алдырган. Сәләхетдин абзый башта бу сүзләргә гайбәт кенә дип караган иде, кичә Мөнәвирнең хатыны Кәүсәрияне күреп сөйләшкәч, тәмам ышанды. Сүзләр шактый күпертелгән булса да, Мөнәвирнең өс-башын карый алмавы хас икән. Әмма кайту өчен акча сорамаган, сер бирмәгән, ничек итсә иткән, үзе кайтып егылган.

— Үзе чёрт с ним, холкы үзгәргәнме соң? — дип, уенын-чынын бергә кушып сорады Сәләхетдин абзый Кәүсәриядән.

— Һаман шул, кире беткән тәкәббер. Урамга да чыкмый, кешеләр белән дә сөйләшми, эш тә эзләми...

— Мөнәвирлеген итә дисең, алайса... Шулай инде, характер трактор түгел, тиз генә төзәтеп булмый. — Карт, үз кызыдай күреп, Кәүсәриянең аркасыннан какты: — Борчылма, килен, «кайткан малда бәрәкәт бар».

Моңа кадәр дә Сәләхетдин абзый белән Кәүсәрия очрашканда сөйләшә торганнар иде. «Ничек, килен, хат-хәбәре бармы?» — дип башлый иде мастер сүзен.

Мөнәвир турында сорашсалар, Кәүсәрия уңайсызланып кына җавап бирә иде. Мөнәвир башта озак кына хат язмады. Бичара Кәүсәриянең күңелендә ниләр генә булмагандыр дисең.

Мөнәвирдән беренче хат килү белән үк Кәүсәрия Сәләхетдин абзыйларга йөгерде. «Мөнәвирнең хәле мөшкел икән, әллә чакырып языйммы, Сәләхетдин абзый?» — дип, киңәш сорарга килгән.

— Кирәкми, чакырма, үзе кайта ул, үзе! — дип, мастер тәмам Кәүсәрияне ышандырган иде.

Картның әйткәннәре юш килде. Менә хәзер аның алдында күптән көткән «иске дусты» Мөнәвир басып тора.

— Куяннар базарда очрашалар дисең инде, ә? Ничек соң әле болай... Сәләхетдин абзый сәер генә итеп Мөнәвиргә тагын бер мәртәбә карап алды.

— Язмыш, Сәләхетдин абзый... — дип пышылдады Мөнәвир.

— Үзең эзләп тапкан язмыш, кем...

Мөнәвиргә шундый читен, шундый авыр. Элек аның өчен үлеп торган Сәләхетдин абзый да аңардан әнә ничек суынган, аңарга әнә нинди кырын күз белән карый. Чит иткәне, кунакны өенә дәшәсе килмәгәне әллә каян ук сизелеп тора. Эте булып эте дә тешләргә генә чамалый, каһәр.

Шулай да Мөнәвир кыстауны көтмәде, мастерга ияреп культбудкага керде. Йөзеңне ертып килгәч, кире китеп булмый инде...

Ике бүлмәле вагон эче пөхтә итеп җыештырылган, бизәлгән. Төрле плакатлар, рәсемнәр, диаграммалар... Түр стенада алтын хәрефләр белән язылган Кызыл байрак һәм рамга куелган Мактау грамотасы эленгән. Иң өстә, стена буена сузылган кызыл комачта «Елына егерме биш мең метр бораулау өчен!» дигән лозунг кычкырып тора. Өстәлдә телефон, зур радиоалгыч.

Ишек янындагы кием шкафы башында күзләрен шарландырып симез ала мәче утыра — таныш булмаган керүчене күзәтә.

Кызыл байрак, егерме биш мең метр, Мактау грамоталары. Болар барысы да Мөнәвиргә ничектер ят та, яңа да, гаҗәп тә булып тоелдылар. Алар әллә ничек Мөнәвирне әрнештерә, үкендерә, көнләштерә иде.

Бригаданың уңышлары турында Бохарада вакытта ук ишеткән иде инде

Мөнәвир. Хәтта. «Правда» газетасында Сәләхетдин абзыйның рәсемен дә күрде. Менә шунда инде ул тынычлыгын җуйды да...

Культбудканың энәсеннән-җебенә кадәр карап чыккач, Мөнәвир түзмәде, вахта журналына нидер язарга утырган мастерга дәште:

— Бай яшисез.

Сәлахетдин абзый башын күтәрми генә җавап бирде:

— Аллага шөкер, син юк дип тормадык.

Мөнәвир сүзсез калды. Дөрес сүзгә җавап юк. Уңайсызлануын яшерү өчен тәрәзәгә борылды.

Тышта бораулаучылар соңгы шәмне төшерәләр иде инде. Кара, ничек җәһәт эшлиләр. Мөнәвир күрә дә алмый калды — торбалар җир астына чумып та өлгергәннәр. Байракны тикмәгә генә бирмәгәннәр шул егетләргә. Хәзер булса Мөнәвир дә бригадасының кадерен белер, башын калкытмый эшләр иде, тик алсыннар гына иде.

Шул турыда сүз кузгатмакчы булып, ул яңадан мастерга таба борылды. Ә Сәләхетдин абзый, уйлап та бирми — такыр башын кырын салган да яза гына. Нәрсә яза икән журналга шулкадәр? Нигә соң ул дәшми? Ичмаса, нәрсә булса да сорашсын, йә булмаса, үткәндәге гаепләре өчен Мөнәвирне авызы туйганчы тиргәсен иде. Барысын да күтәрер иде Мөнәвир, җанына рәхәт, җиңел булып китәр иде...

Мөнәвир берничә мәртәбә: «Мин бригадама кайттым, зинһар, алыгыз, Сәләхетдин абзый», — дип әйтмәкче дә булып талпынган иде, тик моңа кыюлыгы җитмәде. Сәләхетдин абзый һичшиксез: «Исеңдәме, мин сиңа нәрсә әйттем?» — дип, үз сүзләрен хәтерләтәчәк иде.

Әйе, Мөнәвирнең бүгенгедәй исендә. Китәргә ниятләп гариза тотып кергәч, шушы культбудкада әйтте: «Уйлап эш ит, энем, үкенерсең, кайтсаң, яңадан алмам». «Алмасаң, кем сиңа ялына!» Менә шулай дип җавап биргән иде Мөнәвир.

Ул чагында Сәләхетдин абзый, башын чайкап: «Бозылса бозыла икән кеше!» — диюдән башка сүз әйтә алмады. Аның Мөнәвиргә бик нык хәтере калган иде.

Чынлыкта, Мөнәвирне кеше иткән дә, аны бозган да Сәләхетдин абзый үзе булды.

Тимәштә нефть мәйданы ачылган ел, бораулау эшләре чиксез зур. Бораулаучылар рәттән икешәр вахта торалар: бораулаучы кадрлар җитешми. Эшчеләр табу тәртибе дә шундый: юлда бер атлы колхозчыны күрсәләр, бораулаучылар аның каршысына йөгерәләр, үзләренә яучылый башлыйлар: «Әйдә безгә, бездә яхшы, бораулаучы булырсың». Ул кеше: «Мин бит нефть эшен белмим», — дип карышса да, тукталып калмыйлар: «Нефть вышкасын күргәнең бармы? — Бар. Шулай булгач булдырасың!»

Сәләхетдин абзый — карт төлке, Баку нефтьчесе, кадрны алай юлдан тотып җыймый. Вахтадан бушаган араларда Шөгергә баргалап, промысел операторларына агитация ясап йөри. Имеш, нигә монда скважина сагалап ятарга, ни эше, ни ашы. Әйдәгез безгә буровойга, кесә тутырып акча эшләрсез.

Сәләхетдин абзый Мөнәвирне шуннан, Шөгер промыселыннан ияртеп кайткан иде. Мөнәвир бригадага буровой эшчесе булып керде. Ләкин күрә: алтын таулары вәгъдә иткән мастер аңа акчаны санап кына бирә. «Минем үз эшем лутчы иде», — ди Мөнәвир. Эшчесез калудан курыккан мастер егетне акчалырак эшкә — верховой итеп күтәрә.

Гайбәтенә кереп булмый, Мөнәвир — тырыш, уңган егет, нәрсәгә тотынса, шуны эшли. Шуңа күрә дә контордан Мөнәвир Гариповны бораучы ярдәмчесе итеп билгелиләр һәм икенче бригадага күчерәләр.

— Кеше өчен табып кайттыммы мин аны? — дип, эшчесен алуга бик ачуланып йөри Сәләхетдин абзый. Күп тә үтми, Мөнәвир янына килә:

— Нәрсә син безне ташладың, Сәләхетдин абзыенда яхшырак урын булмас дип белдеңме әллә?

Мөнәвир үз кадерен үзе белә торганнардан була күрәсең, бораучы булып янадан Сәләхетдин абзый бригадасына күчә.

Үсенеп киткән Мөнәвирнең борыны яхшы ук күтәрелә. Гарипов иптәшләрен санга сукмый башлый. Анын чуар күңеле кайсы буровойда яхшы, кайда күбрәк түлиләр — шунда омтыла.

Ул елны Сәләхетдин абзый бригадасы бораулый торган мәйдан гаять көйсез булып чыкты. Бораулаучылар биш-алты йөз метр әйбәт кенә бораулап баралар да көтелмәгән җир асты куышлыгына юлыгалар. Бораулый торган су каядыр упкынга кереп югала. Куышлыкны томалап кырык-илле метр борауларга да өлгермиләр, тагын упкын, тагын су йотылу.

Башка чакта Сәләхетдин абзый дип кенә торган Мөнәвир сукрана башлый:

— Менә, авыртмас башка тимер таяк! Каян килеп эләктем мин бу эбер-чеберләр арасына! Монда эшләсәң, ыштансыз калырсың, билләһи! Китәм!

Мастерның да, бораулаучыларның да Мөнәвирне бригададан җибәрәселәре килмәде. Ни әйтсәң дә, Гариповның тәҗрибәсе зур, авыр хәлдән чыгарга ярдәм итә ала торган кеше.

Акча шаукымы тигән Мөнәвир бригададан китте. Мастерның фатихасыннан, иптәшләренең ризалыгыннан башка китте — буровой эшчесез, ятим калгандай утырып калды. Сәләхетдин абзыйның соңгы мәртәбә өзгәләнеп әйткән «Уйлап эш ит, энем, үкенерсең, әмма соң булыр, кайтсаң, янадан алмам» сүзе Мөнәвиргә хәтта көлке генә булып тоелды. Чөнки, үзенең әйтүенчә, аны теләсә кайда күтәреп алачаклар, кулына меңәрләгән сум акча тоттырачаклар иде.

Мөнәвир киткәч, Сәләхетдин абзый әллә никадәр исенә килә алмыйча, башын чайкап торды:

— Бозылса да бозыла икән кеше!

Сәләхетдин абзыйның Мөнәвиргә карата булган үпкәсе әллә ай буена барды тагын. Тик бераздан соң, йөрәк әрнүе басыла төшкәч кенә Мөнәвирне бозуда үзе гаепле икәнен төшенде. Картны күтәрә алмаслык вөҗдан газабы басты.

— Яшь баланы кәнфит ашатып бозгандай боздым шул. Башкалар сүзенә колак салмадым... — дип сөйләнә иде ул бораулаучылары янында. Бу Сәләхетдин абзыйның алар алдында үзенчә гафу үтенүе иде инде.

— Кайтса, кире алыр идеңме, Сәләхетдин абзый? — дип сорыйлар иде бораулаучылар, кызыксынып.

— Алыр идем. Гаебемне төзәтер идем, яңа баштан тәрбияләр идем мин ул каһәр сукканны, — дип йодрыкларын йомарлап куя иде мастер.

Ниһаять, теләге кабул булды: Мөнәвир кайтып төште. Сәләхетдин абзый нишләргә белми аптырап калды.

## II

Сәләхетдин абзый бригадасыннан киткәч, аны башка бригадалар кабул итмәделәр.

— Һәй, алмасагыз, ул кадәр шаккатканым юк әле, сездә генәмени эш! — диде дә, контора белән исәп-хисапны өзеп, гаиләсе белән дә киңәшеп тормыйча, күзе караган якка сәфәр чыгып китте Мөнәвир.

Башта ул Куйбышев бораулаучыларына кагылды. Бораулау конторасына кереп, үзенең тышы белән үк нефтьченеке икәнен белдереп торган хезмәт

кенәгәсен күрсәтте. Карчыга борыны кебек озын кылыч борынлы кадрлар бүлеге начальнигы кенәгәне ничектер җирәнеп кенә ачканнан соң болай диде:

— Ә документыгыз?

— Документ күрсәтәм! — диде Мөнәвир ирәебрәк.

Теге кеше күзлеген маңгаена күтәреп куйды да кылыч борынын югары чөеп сорады:

— Диплом, аттестат кебегрәк нәрсәгез дим?

Мөнәвирнең мона ачуы чыкты, нәрсә дип әйтергә белмичә, иреннәрен мимылдатып торды да, начальникның кулыннан кенәгәне тартып алып, чыгып китте.

Ачуы да килерлек иде шул. Ике ел эшләде, верховой булды, бораулаучы ярдәмчесе булды, бораучы булды — мона кадәр беркем дә аннан аттестат та, диплом да сорамады. Ул турыда хәтта телгә алучы да булмады.

Мөнәвир Башкортстанга китте. Туймазы шәһәрендә, бораулау контораларының берсендә исә үзенең сораулары белән бер башкорт анын теңкәсенә тиеп бетте:

— Нәмә дип эшенде ташланың, эшеңдән нәмә дип сыктын, узеңдекеләр ярамый инемени?

Мөнәвирнең мин-минлеге, тәкәбберлеге ул кадәр төпченүләрне күтәрә алмады:

— Анысы инде, абзый, безнең эш, китер кенәгәне! — диде дә кенәгәсен алып икенче конторага юнәлде.

— «Нәмә сыктың?» — дигән була тагын, үләрсең кыланышына!

Эченнән юл буе сүгенеп, төкеренеп барды Мөнәвир һәм шул ачулы хәлендә икенче бер контораның ишеген барып тартты.

— Сабыр итегез, егет, күрәсез, кешеләр, — дип, мөлаем генә бер хатын Мөнәвирне кире борды.

Мөнәвир ишек төбенә баскан хәлдә чират көтеп тора һәм уйлана: «Монда безнең контора түгел икән...»

«Татбурнефть» трестында бит аны теләсә нинди мәсьәлә белән, теләсә кайчан чиратсыз кертәләр иде. Ишектән башыңны гына күрсәтү кирәк: «Ә-ә, Гарипов, әйдә! Сез, кем, бераз сабыр итегез, кешенең вахтага барасы бар». Касса янына акча алырга килсә дә, бөтенесе юл биреп тора: «Читкәрәк китегез, башта эре акчаларны җибәрик».

Биредә ишек төбендә ярты сәгатьләр басып торгач кына кабул иттеләр.

Чибәр хатын кенәгәгә күз төшерү белән әйтте: «Ай-яй, эш алыштырырга яратасыз икән үзегез! Риза булсаң, бораучы ярдәмчесе итеп алабыз».

— Нәрсә сез, көләсезме әллә? Мин бит бораучы булып эшләдем!

— Эшләвен эшләгәнсез дә, ләкин... кем ничек эшләми!

Бу сүзләрдән соң инде Мөнәвир ничек чыгып киткәнен дә, кая барганын да хәтерләмәде. Ул ниндидер юл белән вокзалга килеп чыккан иде. Нишләргә? Промыселга, Шөгергә кире кайтыргамы? Юк, анда инде аны алмаслар. Яңадан әлеге ханым янына барып, ризалашыргамы? Булмый, түбәнгә тәгәрәү. Урта Азиягә юл тотаргамы?

Мөнәвирнең Бохарада бораулаучылар алалар икән дип ишеткәне бар иде. Шунда китәргә карар итте. Тик анда да Куйбышевтагы, Башкортстандагы кебек каршы алсалар, ул нишләр, тагын кая барыр?

Поездга утыргач та, төрле ямьсез уйларга бирелеп, ут йотып барды Мөнәвир. Ераграк киткәч, километрлар саны арткан саен, йөрәгенең дә сызлавы көчәя барды. Ә поезд туган җирләрен артка калдырып, көн-төн туктамый чаба гына. Гүя бу җәһәннәм машинасы аны мәҗбүри алып китә, каядыр җир читенә илтеп олактыру өчен ашыга — Мөнәвирдә шундый тәэсир.

Юл буена диярлек анын эче пошты, бик кыйммәтле әйберен югалткан кебек йөрәге әрнеде. Ул кемнәрнедер үзе дә белми юксынды, сагынды...

Инде вагон тәрәзәсеннән ят, ләкин гаҗәп матур бакчалар, гомер таныш булмаган яшел үзәннәр, биек-биек агачлар күренә башлагач, Мөнәвирнең күнеле күтәрелеп китте, авыр тойгылары таралды. Тышта чын гүзәллеге белән Азия кояшы балкый иде. Гаҗәпләнмәслек тә түгел: әле берничә көн генә элек салкын җилләр исә, вак яңгыр сибәли иде. Кирза итекләрдә туган якның лае да кибәргә өлгермәде — ул инде кояшлы Азиядә.

Хәзер инде Мөнәвирнең күнелен яна, берсеннән-берсе тәмлерәк хисләр кытыклый башлады. Имеш, ул мондагылар өчен бик кирәкле кеше булып чыгачак, аны монда күтәреп алачаклар. Ул атаклы бораучы булыр, даны шушыннан бөтен илгә таралыр. Исән булса, акчаны да көрәп алыр. Сәләхетдин абзыйны да, белеш-танышларын, хатынын да шаккатырыр әле ул.

Бохара вокзалына ул шундый хыяллар белән төште. Үткән-барганнан бораулау конторасын сорашырга кереште. Сәгатьләр буена йөрсә дә, беркем дә андый контораның барлыгын әйтеп бирә алмады. Ахырда, шәһәр советына кереп сорарга мәҗбүр булды Мөнәвир.

— Ай-вай, бала! — дип, тел шартлатып, Мөнәвирне кызганып баш селкетеләр шәһәр советындагылар.

Бораулау конторасы дигәннәре моннан йөз чакрым ераклыктагы далада икән. Нишлисең, башыңа төшкәч, барасың. Мөнәвир бер үзбәк картын яллап, ишәккә атланып далага чыгып китте. Чүлдә кызу кояш астында өч тәүлек барды, ниһаять, янып-пешеп килеп житте. Контораны эзләп бер киез чатыр эченә килеп керде.

— Исәнмесез?

— Вәгаләйкем әссәлам, мосафир, түрдән узың, чайдан авыз итең, — диде ана түр башында, киез өстендә аяк бөкләп утырган әкә.

Аларның искиткеч кунакчыллыгы, ачык йөзлелеге Мөнәвиргә ошап китте. Бик сусаган чагы иде, бер дә кыстатып тормыйча, чәй эчте, аннан татарчалап-русчалап үзенең ни өчен килүен сөйләп бирде.

— Хуп, мәйле! — дип сикереп торды әкә һәм кулына Мөнәвирнең әлеге дә баягы майланып, читләре бөрешеп беткән хезмәт кенәгәсен алды. Әкә дип дәшкән кеше үзе бораулау конторасының директоры булып чыкмасынмы!

— Без сине участок начальнигы итеп куябыз, хупмы? — диде директор, кенәгәне саклык белән карап чыкканнан соң.

Моны ишеткәч, Мөнәвир көлеп җибәргәнен шәйләми дә калды. «Начальник! Мөнәвир — начальник! Җиде класс белеме дә булмаган Мөнәвирне начальник ясамакчы булалар. Бар икән башның кадерле чаклары!»

Бераз аңгы-миңге килеп утыргач:

— Мин бит бораулаучы, бораулый беләм, әмма... — дип, хәлен аңлатырга да маташып караган иде Мөнәвир, тик әкә аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Бораулый белгәч, начальник була беләсең дә беләсең! Хуп, мәйле, язып куйдым, иртәгәдән эшкә!

Мөнәвирнен язмышка буйсынмый чарасы да юк иде. Акча тотылып беткән, шулай булгач, кая да булса бүтән җиргә китү турында уйларга да урын калмый.

«Әйдә, — диде ул эченнән генә, — мәйле икән, мәйле, начальник булып карыйк, соныннан күз күрер...»

«Күз күрер» дигәне инде бирелә, кайчан да булса урын табып, бораучы булып керү иде. Ләкин килүенә ике-өч ай үтте, конторада андый урын бушамады.

Югыйсә Мөнәвир өчен участок начальнигының эше дә зарланырлык авыр түгел иде инде. Станциядән буровойларга торбалар, җиһазлар кайтарта, машиналарга гына утырып йөри. Исәп-хисап, язу-сызу кебек эшләрне башкаруда аңа инженерлар, хисапчылар ярдәм итеп тора. Йөрәккә ятмагач, күнелең тыныч булмагач — эшең эш түгел инде.

Ничаклы гына тырышып хезмәт итмәсен, аңа ничектер бирелдәге кешеләр

ышанычсыз карыйлар, үз итмиләр, килмешәк дип әйтәләр төсле тоелды. Директор әкәнен кич саен диярлек үзенә чәйгә чакыруы да, бораулаучыларның иптәш начальник дип эндәшүләре дә — барысы да ясалма. Мөнәвирне сынау өчен генә эшләнә кебек. Шуңа күрә дә Мөнәвир әкә янына керми, бораулаучыларның күзенә артык чалынмый башлады.

Килгәннән беренче атналарында Мөнәвир «дала клубы» дип аталган күршедәге зур чатырга кереп йөри, кино-мазар карый иде, хәзер алардан да бизде.

Далага яз килде. Урта Азия табигате кунвшы кунак кызыдай көязләнде, матурланды. Апрель башларында ук инде күз күреме житмәс җирләрне җете кызыл тюльпан, алланып торган кыргый мәк чәчәкләре каплады, һәркайда кошлар сайраша. Озын койрыкларын җилбердәтеп кушаяклар, житез йомраннар чабыша, ояларыннан башларын тыгып, бер-берсен үртәшкәндәй суырлар сызгырына. Җансызга җан кертә, рухсызга рух бирә торган гүзәл яз иде бу.

Яз даланы җанландырды, ләкин Мөнәвирнең күңелен күтәрә алмады. Мөнәвир зарыгып көткән бораучы урыны һаман бушамады. Кешеләренә исең китәр, буровойга ябышып яталар, берсе дә эшен ташлап китәргә исәпләми.

Мөнәвирнең ачуы да килә башлады. Әкәне күргән саен тинтерәтеп бетерде: «Миңа кайчан үз эшемне бирәсез инде?»

— Башта бу эшендә үзеңне күрсәт әле, — ди Юлдаш әкә, көлә генә. Эх, үзен бу эштә күрсәтә алырмы икән Мөнәвир? Бер дә генә дә ошамый бит ана бу эш!

Мөнәвир кебек күңеле китек кеше өчен далада язгы төннәр ямансу була. Бүген дә ул эштән соң беркая чыкмады, чатыр эченә кереп, аның брезент ишеген чак кына күтәреп куйды да алсу офыкка карап уйланып ятты.

Күршедә күңел ачалар. Клубның җир идәне дер селкенеп тора. Шаяру, көлү тавышлары, төрле милләт көйләре ишетелә.

— Шулай да Татарстандагы кебек түгел инде, — дип үртәлеп куйды Мөнәвир. — Безнең Әбүзәр тальянын тартып җибәрсә...

Кәүсәриядән хат алган иде. Исәнме, качкыным, дигән... Сагынам, дигән. Илгизәр дә үсте инде, тәрәзәгә капланып: «Әти, кайт!» — дип кычкыра дигән. Сәләхетдин абзыйлар икенче скважинаны башлаганнар, алдынгылык алар кулында икән. Мөнәвир соң монда килеп ни майтарды? Йөри шунда, кеше булмаганнан начальник исеме күтәреп!

Мөнәвирнең төннәре гел әнә шундый кичерешләр белән үтә иде. Күзен йомса да, бригадасындагы иптәшләре, хатыны, баласы килеп баса. Бигрәк тә Илгизәре күз алдыннан китми. Туптай тәгәрәп әтисенең итәгенә менә, шаяра. Колак төбендә дә аның тавышы: «Әти, кайт! Әти, кайт!»

Мөнәвирнең күңеле әкренләп туган якларына күчте. Аны бары принцип дигән нәрсә генә тота иде инде хәзер. «Кайтмам» дип китте ич. Нигә бер дә уйламый әйтте икән? Нигә иптәшләрен, Сәләхетдин абзыйны, хатынын тыңламады икән? Каһәр суккан тәкәбберлеге булмаса, шушы минутта ук кайтып китәр иде...

Эшеннән, тормышыннан зарланып язган хатына җавап алды. Кире чакырмаслармы дип өмет иткән иде Мөнәвир. Юк, чакырырга исәпләмиләр. «Гелән җил куып йөрү булмасын. Кайтсаң да үз эшеңне таба алмассың», — дип язган Кәүсәрия.

— Чакырмасалар чакырмаслар, кайтам, — дип фикер йөртте Мөнәвир. — Мин иптәшләремне, Сәләхетдин абзыйны, хатынымны бәхилләтергә тиеш. Минем эшемме соң начальник булу, торбалар санап йөрү?

Уйлап-нитеп тормый гына күңеленә килгән бер халык мәкален дә үзенә яраклаштырып куйды Мөнәвир: «Чит җирдә солтан булганчы, үз җиреңдә олтан бул».

Китәргә төрле сәбәпләр эзләп, гомердә кыланмаган гадәтләр дә уйлап тапты — тимер юл станциясенә торбалар алырга баргач, буфетка кереп аракы эчә торган булып китте.

— Ай-вай, бу баланың яман гадәте дә бар икән, мәе булып йөри! — дип исе китте әкәнен.

Бораулаучылар да: «Моны Татарстаннан эчкәне өчен куганнар икән», — дигән нәтиҗәгә килделәр.

Беркөнне Мөнәвир буровойга лаякыл исереп кайтты. Кесәсеннән Сәләхетдин абзыйның рәсеме төшкән «Правда» газетасын чыгарып, аны бораулаучылар алдында селки-селки сөйләнә башлады:

— Күрәсезме, кемнең рәсеме? Бөек кеше ул Сәләхетдин абзый, кешенең көзгесе, әүлия! Минем монда килеп харап буласыны сигез ай элек үк әйтте. Мин тиле ышанмадым, бәхет эзләргә киттем, шундый алтын кешене ташлап киттем. Хәзер төшендем, әмма ләкин соң. Мин Сәләхетдин абзый янына китәм. Анардан гафу үтенергә кайтып китәм һәм вәссәлам!

Иртәгесен Мөнәвир гариза язып директор янына керде.

— Хуп, мәйле, — диде әкә, гаризаны укып караганнан соң. — Хәерле сәфәр! Игелексез кеше икәнсен...

Директор Мөнәвирне ничек алган булса, эшеннән дә шулай бик җиңел генә чыгарып җибәрде.

Менә күрәсез, Мөнәвир инде әкә янында түгел, ә абзый янында утыра. Шул ук күпне күргән хезмәт кенәгәсен тотып Сәләхетдин абзый янында утыра.

— Үткәннәрне онытыгыз, Сәләхетдин абзый, гафу итегез, гаебемне тирем белән юармын, аңлыйсызмы? — ди ул.

— Миндә эш тормас... Коллектив гафу итәрме соң? — Сәләхетдин абзый урыныннан торып ишекле-түрле әйләнеп килде дә яңадан урынына барып утырды. Күрәсен, үткәндәгеләрне ул Мөнәвирдән дә ныграк кичерә иде.

Икесе дә бер авыз сүзсез утырдылар.

— Әй, егетләр... — дип мастер көрсенеп алды һәм культбудкадан чыгып китте. Мөнәвир тәрәзә аша аның буровойга таба алпан-тилпән генә атлавын күзәтеп торды.

Сәләхетдин абзый кулы белән ымлап югарыдан верховойны чакырып төшерде, эшне туктатып торырга кушты. Бораулаучылар аяк өсте генә Сәләхетдин абзый белән нәрсәдер бик кызып-кызып сөйләштеләр, бераз кычкырышып алдылар. Мөнәвир тәрәзә аркылы кайсыныңдыр «кирәкми» дигән сүзен дә ишетеп калды төсле. Шуннан соң Сәләхетдин абзый тагын кемнедер үгетләде кебек, бармаклары белән культбудка ягына таба төртә-төртә Мөнәвирне күрсәтте.

Мастер биш-алты адым китте дә янә буровойга әйләнеп килде. Бу юлы инде алар тыныч кына сөйләштеләр.

Аларның хәрәкәтләреннән Мөнәвир үзенә хөкем ясаганнарын аңлады. Ул, тәрәзә янагына поскан хәлдә, аларның гадел карарын көтте.

Ниһаять, башын, муенын кульяулыгы белән сөртә-сөртә Сәләхетдин абзый культбудкага керде.

— Эшне дә, тормышны да яңадан башларга туры килер, энем, — диде ул, Мөнәвир янына утырып. — Буровой эшчесе итеп алырга булдык. Риза булмыйсың икән, әнә, үзең чыгып сөйләш...

— Рәхмәт, туганнар, мин риза, бик риза! — диде Мөнәвир. Шатлыктан аның күнеле тулган иде.

— Йә, йә, син ир бул! — диде Сәләхетдин абзый, Мөнәвирнең күз яшьләрен күргәч. — Яз гаризаңны. Мә каләм, мә кәгазь!

Мөнәвир берсүзсез каләмне тотып алдындагы кәгазьгә иелде. Күз яшьләре таммасын өчен керфекләрен кысты.

# КЕШЕЛӘРЕҢ СИНЕҢ ЧЫН ХӘЗИНӘ...

Лениногорск төбәгенең даны җырларда җырлана. Мәсәлән,

*Тальян гармун уйнаталар*
*Безнең Шөгер буенда.*
*Ятсам-торсам, керсәм-чыксам,*
*Тик син генә уемда,*

— дигән җырны белмәгән кеше юктыр.

Бу — халык җыры. Аның сүзләрен дә халык чыгарган, көен дә халык үзе язган. Һәм бу — татар халкы арасында иң яратып җырлана торган моңлы җырларның берсе. Ә Лениногорск каласы турында «Нурлы калам» дигән җыр җырлана (Р.Габделхакова сүзләре, К.Шәрәфов һәм А.Володин көйләре). Ул гына түгел, Лениногорск төбәгендәге һәр авылның үзенә багышланган җыры бар. Әйтик, «Керкәле таулары» (Г.Зәйнашева сүзләре), «Кирлегәч» (Т.Шәмсуаров сүзләре), «Чишмәле ил — Түбән Чыршылы» (Ф.Мотыйгуллин сүзләре), «Сугышлы авылы җыры» (Ж.Дәрзаман сүзләре) һ.б. Ә менә Зәй-Каратай авылына бер генә түгел, хәтта ике җыр багышланган: «Бәхет биргән авылым» (Ж.Рәхимов сүзләре, Р.Вәлиуллин көе) һәм «Зәй-Каратай» җыры (Ә.Шәрипов сүзләре, Р.Зарипов көе).

Илһам килмичә генә мондый җырлар язылмый, әлбәттә. Әгәр дә үзең яшәгән төбәк, аның табигате һәм кешеләре сине рухландырмый икән, мондый җырлар туа алмый. Ә безнең Лениногорск төбәгенең табигате искиткеч матур: таулар-урманнарга күз төшерәсеңме, җәйге җил уйнаклап торган кыр-басуларга чыгасыңмы, чишмәләрдәге тешләрне камаштырырлык сап-салкын суын эчәсеңме — син бу төбәкнең матур табигатенә сокланмыйча, аңа гашыйк булмыйча һәм илһамланмыйча кала алмыйсың. Ә кешеләре? Кешеләре аның чын-чынлап алтын хәзинә...

***

Лениногорск төбәгендәге татар әдәбиятының берничә гасырлык тарихы бар. XVIII-XIX гасырларда ук монда күренекле галимнәр, шагыйрьләр яшәгән, үзләренең үлемсез әсәрләрен иҗат иткән. Халкыбыз арасыннан мәгърифәтчелек байрагын иң беренчеләрдән булып күтәреп чыккан кабатланмас шагыйрь, энциклопедик галим, дин белгече Габдерәхим Утыз Имәнине аласынмы, тарихыбыз өлкәсендә титаник хезмәт күрсәткән, XVIII-XIX гасырлардагы татар зыялыларының тулы бер корпусын барлыкка китергән мәшһүр Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә мөрәҗәгать итәсеңме яисә әдәбият-мәдәният тарихында тирән эз калдырган Фазыл белән Кәбир Туйкиннарны искә төшерәсеңме — аларның барысының да тормышы һәм иҗаты шушы Лениногорск төбәге белән бәйле.

Узган гасырның 40-50нче елларыннан бу төбәкнең яңа тарихы башлана. 1948 елда Ромашкино нефть чыганагы ачылганнан соң, республикада нефть сәнәгате барлыкка килә һәм әлеге төбәктә зур үзгәрешләр башлана. Район үзәге Яңа Писмәнгә илебезнең төрле якларыннан бораулаучы, нефть чыгаручы, төзүче һ.б.лар килеп урнаша. 1955 елның августында Яңа Писмән бистәсе Лениногорск дип үзгәртелә һәм аңа шәһәр статусы бирелә.

1958 елда Лениногорск шәһәрендә татар телендә «Ильич васыятьләре»

дигән газета чыга башлый. Шул ук елны яшь язучы Шамил Бикчурин газета редакциясе каршында «Чишмә» дигән әдәби берләшмә оештырып җибәрә. Шушы төбәктә яшәп каләм тибрәтүчеләр, яшь язучылар өчен бу бик вакытлы гамәл була. Тиздән берләшмә утырышларына хикәя, шигырь язучылар гына түгел, рәссамнар, композиторлар, җырчылар да килә башлый һәм ул «Чишмә» әдәбият-сәнгать берләшмәсе» дигән исем ала. Күп еллар буена әлеге берләшмәгә Шамил Бикчурин җитәкчелек итә. «Чишмә» күп кенә каләм ияләренә канат куя, зур әдәбият дөньясына чыгара. Аның мәктәбе аша күпләгән прозаиклар, шагыйрьләр, рәссамнар, композиторлар, җырчылар үсеп чыга. Шамил Бикчуриннан соң берләшмәне Җәмит Рәхимов, Разим Вәлиуллин, Рәшит Шиһапов, Рәмзия Габделхакова, Альберт Хәсәнов һ.б. каләм ияләре җитәкли. Бүгенге көндә бу вазифаны Рәсим Хәбибулла алып бара.

Әдәби берләшмәнең исеме юкка гына «Чишмә» дип куелмаган икән. Чыннан да, Лениногорск төбәгендә яшәп иҗат итүче каләм әһелләренең әсәрләре чишмә булып татар әдәбияты дигән олы Иделгә килеп коя бит. Хәзер шуларны күздән кичереп үтик. Иң элек прозаиклар иҗатына тукталып алыйк. Аларның әсәрләре башлыча хезмәт кешеләрен зурлауга багышланган.

Лениногорск төбәгендәге әдәбият-сәнгать дөньясында язучы Шамил Бикчурин иҗаты аерым бер мөһим урынны алып тора. Ул әдәбиятка 1950-1960 елларда нефтьчеләр тормышыннан очерклар һәм хикәяләр язып килеп керә. «Ташлы тауда» (1959), «Истәлекле таш» (1961), «Могҗиза тудыручылар» (1968) кебек хикәя һәм очерк китапларын бастыра. Ә 1972 елда «Каты токым» дигән романын язып төгәлли. Әлеге әсәрне шул чорның «производство романы» дип атарга һәм аны производство темасына язылган башка романнар белән, мәсәлән, Г.Ахуновның «Хәзинә» (1963), «Хуҗалар» (1968), Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» (1958) әсәрләре белән чагыштырып карарга да мөмкин. Алардан аермалы буларак, «Каты токым» романында нефть эзләүчеләр, нефть разведчиклары тормышы, яна нефть мәйданын үзләштерү дәверендә төрле җирләрдән җыелган кешеләрдән эшче коллективы оешу процессы күрсәтелә. Роман үзәгенә гәрчә нефть разведчикларының җир куенынннан кара алтын чыгару өчен көрәше куелган булса һәм шушы максат әсәрнең буеннан-буена сузылып барса да, бу идея төрле холыклы һәм төрле милләттән булган Фазыл Урәзмәтов, Кадермәт, Тин-Тиныч, Сапарбай, Саакян, Фәрхетдин һ.б.ларның характерларын ачу, аларны укучы күз алдына җанлы кеше итеп китереп бастыру өчен бары гомуми фон ролен генә үти. Язучының төп игътибары кеше характерларын бирү, тормышның катлаулылыгын ачып күрсәтүгә юнәлтелгән: Ш.Бикчурин укучы күз алдына шушы кешеләрнең һәрберсенең эчке дөньясын, характер сыйфатларын, киләчәккә өмет-омтылышларын китереп бастыра, аларның тулы канлы образларын бирә алган. Һәм шунысы мөһим: язучы боларны алар турында сөйләп түгел, ә А.П.Чехов кебек геройларның хәрәкәт-гамәлләрен күрсәтеп, тасвирлап бирә. Бу аның язучылык осталыгы турында сөйли.

«Каты токым» романы бәхетле язмышка очрады. 1974 елда ул татарча һәм В.Чивилихин тәрҗемәсендә рус телендә аерым китап булып басылып чыкты, ә 1977 елда Чехословакиянең Братислава шәһәре нәшриятында словак телендә, бераз соңрак Киев дәүләт нәшриятында украин телендә дә дөнья күрде. Бу романы өчен әдип 1976 елда ВЦСПС Президиумы һәм СССР Язучылар берлеге идарәсенең эшчеләр сыйныфы турындагы әсәрләргә уздырылган конкурсында II дәрәҗә премиягә лаек булды (беренче премия бирәүгә дә бирелмәде).

1961 елда Ш.Бикчурин «Тальян моны» дигән музыкаль комедия яза. Нефтьчеләр белән авыл кешеләре арасындагы дуслык-хезмәттәшлекне оста чагылдырган бу әсәр шул ук елны Әлмәт татар драма театрында һәм соңрак Казанда М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә куела. Язучының татар һәм украин халыкларының дуслыгына багышланган «Бергә гомергә» исемле икенче драма әсәре 1964 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелде.

1980 елда Ш.Бикчурин укучыларны үзенең яна романы — «Тирән катлам» әсәре белән шатландырды. Бу романда язучы күбрәк Себер нефтьчеләре

тормышын сурәтли; әлеге әсәр дә тәнкыйтьтә унай бәя алды һәм, русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә һәм Казанда аерым китап булып басылып чыкты. Биредә шуңа да игътибар итәргә кирәк: «Каты токым» да, «Тирән катлам» да нефть чыгаручыларга бәйле төшенчәләр буларак китерелсә дә, алар символик мәгънәдә кулланылган. «Каты токым» дип автор нефть эзләүче разведчиклар коллективын — суыкларга чыдам, каты җилләргә биргесез, авырлыкларны теш кысып җиңә торган коллективны, ә «Тирән катлам» дип кеше күңеленең тирәнлеген атый; тирән катлам ул — кеше күңеле, чыннан да, тирән катлам! Биредә шулай ук Ш.Бикчуринның вакыйгаларны җиңелчә юмор белән тасвирлавын да әйтеп үтәргә кирәк.. Гариф Ахунов, мәсәлән, Ш.Бикчуринны: «Кеше күңеленең иң тирән төпкелләрендә яткан хисләрне ачып бирә алырдай, житди, төпле акыллы, эшлекле язучы», — дип атады.

Шамил Бикчурин вафатыннан соң, Лениногорск шәһәр хакимияте, аның исемен мәңгеләштерү максатында, 1992 елда «Шамил Бикчурин исемендәге премия»не гамәлгә куйды. Бу бүләк әдәбият-сәнгать өлкәсендә зур уңышларга ирешкән кешеләргә бирелә. Лениногорскиның бер урамы Шамил Бикчурин исемен йөртә.

Иске Шөгер авылында туып үскән Җәмит Рәхимов та (1935-1996) зур күләмле әдәби мирас калдырды. Әдәбиятка ул 1960-1970 елларда нефть чыгару төбәкләрендә барган зур үзгәрешләрне, авыл эшчәннәре белән нефтьчеләр тормышын яктырткан очерк һәм мәкаләләре белән килеп керә, «Алтын яткан җирләрдә» (1966), «Якташларым» (1972), «Батырлык чакрымнары» (1976) исемле очерклар җыентыклары бастыра. 1978 елда «Өлешемә тигән көмешем», 1981 елда «Тәвәккәл таш яра» повестьлары дөнья күрә. Бер үк вакытта ул төбәк тарихын да өйрәнә, нефть ягы авыллары тарихына караган материаллар эзләп, Казан, Мәскәү, Самара, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге архивларда эшли. Авыл тарихлары турында Әлмәт һәм Лениногорск район газеталарында күпсанлы мәкаләләр бастыра. Авылларның килеп чыгышы, аерым нәселләрнең шәҗәрәләре хакындагы ул мәкаләләр хәзер дә туган як тикшеренүчеләре өчен ышанычлы бай чыганак. Шул материаллардан торган «Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе» дигән китап авторның вафатыннан соң, 1997 елда басылып чыкты. «Җәмит Рәхимовның тарихчы буларак үзенчәлеге шунда ки, ул авыллар тарихын гына тикшерми, аның өчен беренче урында халык һәм аерым шәхесләр язмышы, — дип язды әдип турында академик Индус Таһиров. — Халыкның яшәү рәвеше, аның көнкүреше Рәхимов өчен беренче урында».

Шулай да Җ.Рәхимовның иң күренекле хезмәте — «Батырша» романы (1992). Татар халкының патша колонизаторларына каршы 1755 ел күтәрелешенең җитәкчесе, милли азатлык хәрәкәте идеологы, имам-хатип һәм мәдрәсә мөдәррисе Абдулла Алиевнең (Батыршаның) каһарманлыгы тарихи документаль чыганаклар нигезендә тасвирлана бу әсәрдә. Анда шул чор татар тормышы, аның гореф-гадәтләре, төрле катлау кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр калку итеп сурәтләнгән. Әлеге роман XX йөз татар әдәбиятының тарихи роман жанрында язылган иң күренекле әсәрләренең берсе булып санала.

Җәмит Рәхимов исеме дә мәңгеләштерелде: шәһәрнең бер урамы хәзер аның исемен йөртә.

1970-1990 елларда «Чишмә» әдәби берләшмәсенең терәге булып торган язучыларның тагын берсе — Әсрар Галиев (1938-1998). «Төнге җыр» исемле беренче китабына (1980) кертелгән «Йөрәгем хәзинәсе» повесте һәм бер бәйләм хикәяләрендә ул татар халкы яшәү-көнкүрешенең милли үзенчәлеген сурәтләргә омтыла. «Асыл кошым минем» повесте (1987) һәм «Көн яктысы» романында (1993) шахтёрлар тормышы сурәтләнә. Гомеренең соңгы елларында ул татар халык әкиятләренә кергән Гали батыр оныклары Әбрар батыр, аның уллары Мөсәвир, Мөнәвир, Разак һәм Әсләм батырлар тормышына багышланган «Гали батыр» исемле җиде томлы трилогия иҗат итте. Әлеге киң планлы әсәр XIX-XX гасырлардагы вакыйгаларны инләп ала, Гали батыр оныкларының XX гасыр башында һәм Ватан сугышы елларындагы каһарманлыклары зур әдәби осталык белән тасвирлана. Әмма бу трилогия бүгенге көнгә кадәр безнең әдәбиятта үзенә лаеклы бәясен ала алмады әле. Аның томнары

да 1996-1997 елларда бик кечкенә тираж белән «Татнефть» акционерлык җәмгыяте «ТатАСУнефть» идарәсенең тизләтелгән басмалар бүлегендә генә дөнья күрде һәм бик аз гына укучыга барып ирешә. Әдәби тәнкыйть тә бу әсәрне читләтеп үтте. Әлеге зур хезмәт киләчәктә, һичшиксез, әдәбиятыбыз тарихында үзенә тиешле урынны алырга тиеш.

Биш дистәдән артык басма китап авторы Альберт Хәсәновның иҗаты да Лениногорск шәһәре белән бәйле: 1960 еллардан бирле ул шушы шәһәрдә яшәде, Шамил Бикчурин белән тыгыз бәйләнештә иҗат итте. 1966 һәм 1967 елларда табигать һәм җәнлекләр турындагы хикәяләрдән торган «Озын аяк», «Таң йолдызы» китапларын, 1976 елда «Юллар үргә илтә» дигән очерклар китабын, алдынгы хезмәт коллективлары турында «Байрак тапшыру», «Фәндәм фонды» кебек документаль повестьларын бастырып чыгарды. 1985 елда «Дружба народов» журналында басылган «Несказанный свет» повесте өчен журналның махсус бүләгенә лаек булды. Соңгы еллардагы әсәрләре «Сөенеч», «Кемгә сөйлим серләремне», «Кан үче» исемле китапларында дөнья күрде. Аның совет матрослары тормышын сурәтләгән «Данәгөл» романы башта «Казан утлары»нда (2011, №7-8), аннан 2012 елда аерым китап булып басылып чыкты. Бу әсәрдә совет солдатының үз антына тугрылыклы булып калу проблемасына ялганып, чит илдә торып калган өлкән яшьтәге татар кешесенең туган илен сагынып җирсүе, чит илдә дә үзенең татар икәнлеген тоеп, татарча яшәү рәвешен, ахыр чиктә үзеннән соң нәкъ менә татар токымы калдырырга омтылуы сурәтләнә. 2014 елда А.Хәсәновның 2 томлык «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде; рус телендә балалар өчен «Чатан» китабы нәшер ителде.

Рәмзия Габделхакова — күпкырлы талант иясе, төрле жанрларда иҗат итә. Ул шагыйрә дә, прозаик та, драматург та. Башка күп әдипләр кебек, ул да әдәбиятка шигърият аша килде. «Кар өстендә миләшләр» (1996), «Күзге яшен» (2005) җыентыкларындагы әсәрләрне укучылар яратып кабул иттеләр. Аларда хатын-кыз мәхәббәте, яшьлек хыяллары, кеше язмышы хакындагы фәлсәфи уйлар, ихлас хис-тойгылар сурәтләнә. Аның поэзиясе хакында Ләйсән Кәшфиева: «Кабатланмас назларын, сагышларын калдырып, гомер язы артта калган, тормышның ачысын-төчесен татыган, күнелен каната-каната чытырманнар ерган, акыл утырткан, шулай да шагыйранә хыялый булып калган лирик шәхес үзенең уй-кичерешләре аша заманга җитди бәя бирә, укучыны уйланырга, сагышланырга, сагынырга, табынырга мәҗбүр итә», — дип язды. Шигырьләренең байтагына композиторлар көйләр иҗат итте. Гомумән, Рәмзия Габделхакова поэзиясе безнең рухи дөньябызга бай азык бирә, тормышның кадерен белеп яшәргә чакыра, кеше күңеленең моңа кадәр тын гына яткан нечкә кылларын уятып җибәрә.

Проза өлкәсендә Р.Габделхакова таланты тагын да тулырак ачылып китте. Әдәбият сөючеләр аны күбрәк хикәяләр остасы буларак беләләр. 2006 елда ул «Көмеш тун» исемле хикәяләр китабын бастырды. Аеруча да «Сират күпере», «Айның соңгы чиреге», «Мөгез», «Китүчеләр», «Даладан килүче», «Көмеш тун», «Җылы карлар яуганда» хикәяләре зур уңыш казанды. Аның турында шәһәрдәш язучы Альберт Хәсәнов: «Әдәбиятыбызга үзенә хас мамык телле, яңача фикерләү стиле белән бик сәләтле прозаик килде. Бу автор тагы шул ягы белән кызыклы: ул — XXI гасыр язучысы. Геройлары да, тырышып-тырмашып дигәндәй, яңа гасырны үзләштерәләр, үзләренчә бииләр. Рәмзия Габделхакова оста итеп конфликтны кора белә, образларына, персоналына хас төсмерләрне дә оста таба», — дип язды.

Сонрак язучының «Тау артында кояш бар» дигән роман һәм хикәяләр җыентыгы басылып чыкты (бу китабы «Ел китабы — 2011» бәйгесендә беренче өлкәккә керде). Әлеге романга галим Хатыйп Миңнегулов: «Ул үз каһарманын бизәү, идеаллаштыру, аның эш-гамәлләрен аклау юлы белән бармый, кызны табигатенә хас яшәештә, хәрәкәттә, хаталары, кимчелекләре, шатлык-куанычлары, үкенеч-газаплары белән күрсәтә. Автор Наргизәнең психологиясен, ир-ат әдипләр тәмам ачалмаган уй-кичереш дөньясын шактый белеп, үтемле шәкелдә гәүдәләндерүгә ирешкән», — дигән бәя бирде. 2014 ел әдибә өчен мул уңышлы булды: Татарстан

китап нәшриятында «Нишләттегез Гөлкәйне?» дигән китабы дөнья күрде. Анда «Кояшлы мизгел», «Соңгы сорау»,«Син икәнсен...» һ.б. повестьлар урын алган. Шул ук елны Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры Р.Габделхаковаңың «Өзелгән яфраклар» дигән пьесасын сәхнәләштерде. Тамашачы әсәрне бик җылы кабул итте.

Татар әдәбиятына «Соңарган сөю» исемле повесть һәм хикәяләр җыентыгы белән (2012 ел, «Рухият» нәшрияты) Наил Шәрифуллин да үз өлешен кертте. Бүгенге көн сулышын чагылдырган «Дала әсире», «Күнел күзе» повестьлары, «Көттермәгән каһәр», «Гөлзадә», «Урыс уеннары һәм татар кызы» кебек хикәяләрендә язучы бүгенге кырыс чынбарлыкка аек күз белән карап, үз бәхетен өчен көрәшергә чакыра. 2014 елда Н.Шәрифуллинның «Кая бара бу дөнья?» исемле публицистик мәкаләләр җыентыгы дөнья күрде. Соңгы елларда үзе баянчы, үзе шагыйрь Ринат Вилданов «Сина багышлыйм» дигән шигырьләр китабын һәм ике томлы «Күргән вә ишеткәннәрем» дигән проза китапларын бастырып чыгарды.

Шагыйрьләргә дә бай Лениногорск төбәге. «Бер дуска» дигән шигырендә бу турыда Таһир Шәмсуаров болай ди:

*Туры әйткәнеңә үпкәләмим,*
*Куанамын гына, бел, бәгырь!*
*Урамыбыз саен җырчы безнең,*
*Авылыбыз саен бер шагыйрь!*

Моны укыгач, кылт итеп искә XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьяр килеп төшә. 1540 елда ул да Казан турында болай ди бит:

*Бу шәһәрнең гаҗәп тулы эче дә:*
*Шагыйрь булган барча олы-кече дә.*

Исләрең китәрлек: Мөхәммәдьярдан соң бүгенге көнгә кадәр биш гасырга якын вакыт узган, ә әдипләр халкыбызның шагыйрьлеге турында бер үк төрле сүзләр әйтәләр! Бу туган халкыбызның, чыннан да, бөеклеген, аның илһам чыганагының саекмаслыгын күрсәтеп тормыймы, Тукаебызның «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул» дигән сүзләрен куәтләмиме әллә?!

Әйе, Лениногорск төбәге әдәбиятыбызга Гәрәй Рәхим, Җәүдәт Дәрзаман, Рамазан Байтимеров, Разим Вәлиуллин, Рәшит Шиһапов, Җәдит Хәбибуллин, Мәхмүт Газизов, Таһир Шәмсуаров, Мәһәрша Вәлиуллова, Әгъләс Шәйхетдинов, Наил Гыйләҗев, Рәхимә Габделганиева һ.б. шагыйрьләрне бирде. Аларның һәрберсенең үз йөзе, үзләре ирешкән биеклекләре бар. Алар барысы да безнең туган төбәкнең кабатланмас матур табигатеннән илһам алып иҗат итәләр.

Лениногорск халкы, әлбәттә, беренче чиратта, Татарстан гимны авторы, фронтовик шагыйрь Рамазан Байтимеров белән горурлана. 1923 елда Башкортстанның Авыргазы районы Исмәгыйль авылында туган Рамазан, Казанда югары белем алгач, 1958 елдан алып соңгы көннәренә кадәр Лениногорскида яши: район газетасы редакциясендә эшли, «Чишмә» берләшмәсенә йөри, әдәби хәрәкәттә актив катнаша. Лирик һәм патриотик рухтагы шигырьләр, поэмалар яза, чын шагыйрь булып монда житешә. Ул барыннан да элек җыр текстлары остасы булды, халык күңеленә җырлары белән кереп калды. Күренекле композиторлар Р.Яхин, С.Садыйкова, Б.Мөлеков, Ә.Бакировлар белән тыгыз бәйләнештә иҗат итте. Аның «Туган ягым» шигыре Рөстәм Яхинны җыр язарга рухландырды, соңыннан ул җыр Республикабызның гимны булып әверелде. 1980-1990 елларда аның «Туган ягым», «Җырларым-солдатларым», «Канатларым» дигән шигырьләр җыентыклары дөнья күрде. 2013 елда 90 еллык юбилее уңаеннан «Җырга күчкән язмыш» дигән зур күләмле җыентыгы, ә җырлары ноталары белән 2015 елда «Очрашырбыз әле җырларда» дигән китапта басылып чыкты.

Шагыйрь, композитор, җырчы, укытучы, Татарстан Язучылар һәм Композиторлар берлекләре әгъзасы Разим Вәлиуллинның (1942-2010) да иң актив иҗат иткән чоры — 1967-1993 еллар — Лениногорскида үтә. Биредә ул башта «Чишмә» әдәби берләшмәсенә йөри, 1983-1993 елларда аның җитәкчесе була. Төрле жанрлардагы әсәрләр — лирик һәм публицистик шигырьләр, поэмалар, балладалар, җырлар иҗат итә. Беренче әсәрләре 1970 елда «Беренче карлыгачлар» күмәк җыентыгында дөнья күрә. Аннан бары 1990 елларда гына башта Әлмәт, аннан Чаллы нәшриятларында бер-бер артлы шигырь җыентыклары басылып чыга. Әсәрләрендә автор милләт гаме, Ватан язмышы, мәхәббәт һәм сөю-сәгадәт, шәхес һәм аның борчулары, гомумән, күп кенә шундый катлаулы мәсьәләләргә җаваплар эзли. Үзенең шагыйрьлек кредосын ул 1980 елда ук:

*Мин бары шигырьдән торамын,*
*Минем һәр күзәнәк*
*Шигърият, шигърият,*
*Шигырь дип сулкылдый,*

— дип тасвирлады.

Әйтергә кирәк, биредә Р.Вәлиуллинның зур күләмле һәм тирән мәгънәле поэзиясенең идея-эстетик үзенчәлеген анализлау максат итеп куелмый. Шуна күрә ул шигъриятнең төп мотивларыннан бары берсенә генә тукталыйк. Ул мотив шул — шагыйрь үз иҗатында гомумкешелек әхлакый һәм эстетик идеалларны алга сөрә, шуның өчен көрәшергә өнди:

*Көрәш өчен туган кешеләр без!*
*Көрәш безнең яшәү байрагы!*
*Без планета буйлап атлаганда,*
*Чыны балкый, чүгә ялганы.*

Композитор буларак, төрле шагыйрьләр сүзләренә үзе язган җырларны ноталары белән ул 1994 елда «Үз ягым» дигән җыентыкка туплап чыгарды. Бу китапка язган сүз башында композитор Фасил Әхмәт болай ди: «Композитор җыр һәм романсларында үз интонацияләрен, үз аһәнен формалаштырырга тырыша, күп очракта ул аңа ирешә дә. Татар җырларында сирәк очрый торган септима, октава кебек интервалларны уңышлы куллануы исә аңа үз стилен табарга ярдәм иткән».

2010 елда «Ихлас» нәшриятында Разим Вәлиуллинның 5 томлы «Сайланма әсәрләре»н бастырып чыгару планлаштырылган булган. Әмма бүгенге көнгә аның бары ике томы гына дөнья күрде. Безнең белүебезчә, икенче томга Ләйсән Кәшфиева язган мәкаләдән тыш, Р.Вәлиуллинның зур күләмле, киң колачлы иҗат мирасы әдәбият тарихында әле бүген дә үзенең лаеклы бәясен алмаган көе кала килә.

Яна Иштирәк авылында туып үскән Таһир Шәмсуаровны Лениногорск якларында «Туган як җырчысы» дип атыйлар. Һәм бу чыннан да шулай. Шөгер, Лениногорск якларын аның кебек чын күңелдән яратып, шунда яшәвенә горурланып иҗат иткән башка бер шагыйрь дә юктыр, мөгаен. Туган ягын ул үзенчә, самими, балаларча ярата шикелле. 2010 елда чыгарган «Моң коесы» җыентыгындагы байтак шигырь туган якны данлауга багышланган. Мәсәлән, бер шигырен генә алып карыйк:

*Туган якның болыты да әнә*
*Моңнар сибә, яңгыр түгел лә.*
*Шөгер, диеп әйтеп өлгермисең,*
*Шигырь бөреләнә күңелдә,*

— ди ул.

Аның шигырьләре туган халкыбызга тирән хөрмәт, ярату хисләре белән сугарылган. Алардан татар халкының зурлыгы, бөеклеге, гадилеге, тыйнаклыгы, кешелеклелеге, кунакчыллыгы кебек сыйфатлары аңкып тора. Шунысы әһәмиятле: шагыйрь бу сыйфатларны әби-бабаларыбызның ерак гасырлардан килә торган иң күркәм гореф-гадәтләре традицияләре яктылыгында сурәтли. Безнең фикеребезчә, Таһир Шәмсуаров — бүгенге татар әдәбиятында иң халыкчан шагыйрьләрнең берсе. Аның дүрт шигырьләр җыентыгы бар: «Әтиләр нигезе» (1977), «Гомер дисбесе» (2008), «Моң коесы» (2010), «Яу кырыннан хатлар» (2010). «Мәйдан» журналының 2013 ел, 12нче саны Таһир Шәмсуаров иҗатына багышланып чыгарылды. Иҗаттагы уңышлары өчен 1994 елда Шамил Бикчурин исемендәге премия белән бүләкләнде.

Ә Мәһәрша Вәлиуллованы Лениногорскида «Кояшлы шагыйрә» дип атыйлар. Әйе, аның шигырьләреннән ниндидер күңел җылылыгы, яктылык, нур сибелеп тора шикелле. 2012 елда аның «Тормышка мәхәббәт» дигән шигырьләр китабы дөнья күрде. Җыентыкның исеме, чыннан да, дөрес куелган. Андагы әсәрләр туган табигать матурлыгына, туган тел, әни, Тукай, милли йола-бәйрәмнәргә багышланган; анда шулай ук авторның әдәбият-сәнгать әһелләренә багышламалары да бар. Гомумән алганда, Лениногорск шәһәрендә әнә шундый саф күңелле, матурлыкны җырлаучы шагыйрә дә яши.

Лениногорск төбәгендә туып үскән бер төркем талант ияләре, үсеп җиткәч, әлбәттә, туган якларында гына калмадылар, ә төрле башка шәһәрләрдә, күпчелеге башкалабыз Казанда яшәп иҗат иттеләр. Ләкин алар барыбер безнең якташлар булып калды. Шундыйлардан без Роза Хафизова (Сарабикколдан), Гәрәй Рәхим (Федотовкадан), Җәүдәт Дәрзаман (Сугышлыдан), Мәхмүт Газизов (Туктар Урдалысыннан), Халисә Ширмән (Зәй-Каратайдан) һ.б.ларны әйтә алабыз. Алар да туган төбәкләреннән илһам алып иҗат итәләр. Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш бүләге иясе, балалар шагыйре Рәшит Бәшәрнең иҗаты да Лениногорск шәһәрендә башланып киткән иде.

Лениногорск районы хаклы рәвештә үзенең атаклы галимнәре белән дә горурлана. Абыйлы-энеле профессорлар, тарих фәннәре докторлары, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзалары Индус Ризакович һәм Энгель Ризакович Таһировларга фән юлына фатиханы Иске Шөгер мәктәбе укытучылар коллективы биргән, алар ун ел буе шушы мәктәптә укыганнар. Техник фәннәр докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе Әсфәндияр Хәлиуллович Хәйруллин исә Сугышлы мәктәбендә белем алган.

Лениногорск төбәгендәге илһам чыганагы булган «Чишмә» әле бүгенге көндә дә саекмый, саф суын биреп тора: өлкән яшьтәге Әгъләс Шәйхетдинов, Рәхимә Габделганиева, Наил Гыйләҗев, Нурия Сәлманова, Рузидә Даутова кебек каләм ияләренең үкчәләренә басып, әдәбият мәйданына яшьләр килә. Людмила Аланлы, Гөлназ Хәкимова, Фәридә Әхмәтшина, Зилә Мөдәррисовалар һәрберсе үз тавышы, үз язу стильләре белән әдәбиятыбызга яңадан-яңа әсәрләрен биреп торалар.

Яшеллеккә күмелгән Лениногорск шәһәрендә шагыйрь һәм язучылар гына түгел, ә сәнгатьнең башка төрләрендә иҗат итүчеләр дә яши. 1958 елда шәһәрнең Мәдәният сарае каршында Татар халык драма театры оештырылды. 1990-1995 елларда аның белән талантлы режиссёр һәм шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ш.Бикчурин бүләге иясе Рәшит Шиһапов җитәкчелек итте (театр хәзер аның исемен йөртә). Шул ук Мәдәният сарае каршында 2003 елда татар яшьләренең «Ядкәр» җыр һәм бию студиясе ачылды, аны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Миләүшә Идиятова җитәкли. Ә авылларда үзешчән сәнгать коллективлары эшләп килә.

Лениногорск шәһәрендә бер төркем композиторлар, баянчылар, җырчылар да иҗат итеп яши. Бу төбәк халкына Марат Габитов, Александр Володин, композитор, баянчы һәм педагог Каюм Шәрәфов, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре Фәйзи Хөснуллин, Миләүшә Идиятова һәм үзе композитор, үзе шагыйрә, үзе җырчы Людмила Аланлының җырлары яхшы таныш. Шәһәрдә һәм

авылларда үткәрелә торган әдәби кичәләрне атаклы җырчылар Ринат Хәбипов, Әнвәр Ямалиев, Тәслимә Рафикова, Миләүшә Идиятова, Әлфия Низамова, Таһир Шәмсуаров, Рәйсә Якупова, Фәридә Әхмәтшина, җырчы һәм баянчы Равил Гыйматдинов һ.б.ларның моңнары бизи; бу моңнар, күңелләргә үтеп кереп, тамашачыларны яңа эшләргә рухландыра.

Лениногорскида Татарстан Рәссамнар берлегенең Көньяк-Көнчыгыш төбәге бүлеге урнашкан. Ул 40 рәссамны берләштерә, шуларның унөче Лениногорскида яши. Алар төрле жанрларда иҗат итәләр. Мәсәлән, СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Ш.Бикчурин исемендәге премия лауреаты Тамара Самойлова бер үк вакытта графика, сынлы сәнгать һәм монументаль жанрларда иҗат итә. Агуник Таманян да графика, сынлы сәнгать һәм скульптура өлкәләрендә эшли. Аларның күбесе иҗатларын укыту эше белән бергә алып бара: Мәгъшия Мөхәммәтова, Ирина Хөсәенова, Нина Крылова, Владимир Чихановлар — Лениногорск сәнгать колледжында, ә Асия Гречная Х.Мәснәви исемендәге сәнгать мәктәбендә укыта. Иҗат ялкынын өлкән яшькә кадәр саклап килүче, пенсия яшендәге рәссамнар да бар. Шөгер бистәсендә яшәүче ветеран, Рәсәй һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Мансур Закиров, шулай ук Вячеслав Гецев һәм Владимир Степановлар бүгенге көндә дә кулларыннан пумалаларын төшермиләр. Дәрәҗәле исемнәргә лаек булучылардан Олег Кульпинны (Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССР, Рәсәй һәм Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы) һәм Яскәр Зиннәтуллинны (Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, Ш.Бикчурин премиясе лауреаты) атарга мөмкин. Рәссамнар берлеге бүлеге белән Татарстанның халык рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мөдәррис Минһаҗев җитәкчелек итә. Әлеге бүлек әгъзалары халыкка хезмәт күрсәтүдә унышлы гына эшләр башкара: төрле шәһәр һәм авылларда даими рәвештә күргәзмәләр оештыра. Соңгы вакытта гына шундый күргәзмәләр Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Уфа, Октябрьск, Баулы, Азнакай, Ижау шәһәрләрендә, Җәлил, Актүбә, Шөгер бистәләрендә, Зәй-Каратай авылында оештырылды, хәтта Казакъстанның Җаек шәһәренә кадәр барып җитте.

Биредә, безнеңчә, бер хакыйкатькә игътибар итәргә кирәк: Лениногорск шәһәре һәм шушы төбәк авыллары, чыннан да, табигатьнең матур бер почмагына урнашкан. Тауларына менсәң, тирә-якта уннарча чакрымга сузылган иген кырлары, үзәнлекләр, урманнарга гаҗәеп бер манзара ачыла. Күкрәгеңне тутырып бер сулыш аласың да: «Нинди матур бу яклар!» — дип куясың. Шушы матур табигать әдәбият һәм сәнгать әһелләренә илһам бирә дә инде.

Җәмит Рәхимов үзенең бер шигырендә:

*Таулар зәңгәр, мәгърур. Ә шулай да*
*Кешеләрең синең чын хәзинә! — дип язган иде.*

Әйе, чыннан да шулай, дөрес сүзгә җавап юк.

Әнвәр **ШӘРИПОВ,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

# БАТЫРША ЭЗЕННӘН

## ҖӘМИТ РӘХИМОВНЫҢ «ЭСКЕРТТӘГЕ ЭНӘ» ЭССЕСЫНДА АВТОР ШӘХЕСЕ

Кырык елдан артык гомерен татар әдәбиятына, матбугатына багышлаган Җәмит Рәхимов тормышның үзәгендә кайнады, әдәби һәм милли хәрәкәтнең алгы сафларында булды, башкаларны да үзе артыннан ияртә алды.

Баһадир гәүдәле, олы җанлы, киң күңелле горур кеше иде Җәмит ага. Үз илендә, үз җирендә солтан була алган гали зат... Газиз халкы өчен җанын фида кылырга әзер булган милләтпәрвәр. Тормышны үз төсендә күрсәтеп, бары чынбарлыкны язган талантлы әдип... Заман сулышын тоеп яшәгән, һәр нәрсәдә, һәр вакыйгада эше булган үткен каләмле көчле публицист... Вакыты, исәнлеге, матди хәле белән исәпләшмичә, Уфа, Мәскәү, Казан, Оренбург, Петербург архивларында казына-казына, вакыт тузанын актарып, үз төбәгенең, туган халкының үткәнен эзләп тапкан тарихчы...

Аның журналистлык эшчәнлеге 1955 елдан башлана. Башта район, соңрак республика матбугаты өчен репортажлар, очерклар, мәкаләләр яза.

Җ.Рәхимовның журналист булып формалашуына табигый сәләте, иҗат кешесе өчен әһәмиятле сыйфатларның яшьтән үк тәрбияләнүе, укыган мәктәбендә табигый сәләтне үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру нигез булып тора. Әлмәттә эшләгән чорында әдәби хәрәкәттә катнашу, иҗат әһелләре белән аралашу, югары белем алу, редакциядә эшләү аның иҗади шәхес булып формалашуына зур йогынты ясый. Туган җирендә нефть сәнәгате үсеп чыгып, зур төзелешләр башлануын һәм шул яңалыкны замандашларына җиткерү теләген Җ.Рәхимовны язарга этәргән, иҗатка рухландырган сәбәпләр итеп күрсәтергә мөмкин. Туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, халык, милләт язмышы белән яшәү — аның талантлы әдип һәм оста публицист булып җитешүендә нигез һәм илһам чыганак.

Җ.Рәхимов – очеркларында Татарстан нефтенең җанлы тарихын язып калдырган журналист. Ул нефтьчеләрнең Татарстандагы уңышларын язу белән генә чикләнми, башка республика һәм чит илләр белән бәйләнешен дә сурәтли, очерклары географик киңлеге, колачлыгы белән үзенчәлекле. Публицист нефтьчеләрнең тормышчан, актуаль проблемаларын яктырта, аларның чишелешен факт, деталь, күренеш, вакыйгалар белән дәлилли, проблемаларны хәл итәрлек көчле шәхесләрне — заман геройларын күрсәтә.

Җ.Рәхимовның киң эрудицияле, мәгърифәтле, тирән белемле шәхес булуы, тормыш материалын тирәнтен өйрәнеп, очеркларында публицистика алымнарын әдәби чаралар белән бергә үреп, бербөтен әсәр тудыру осталыгы, миллилеге, халык язмышы белән яшәве яшь журналистларга кешелек үрнәге һәм һөнәри осталык мәктәбе булып тора.

1992 елда Җәмит Рәхимовның «Батырша» романы дөнья күрә. Ул укучылар тарафыннан җылы кабул ителә, тәнкыйтьчеләр дә аңа унай бәя бирә. «Батырша» романы өчен Җ.Рәхимов Татарстан Язучылар берлегенең махсус премиясенә лаек була.

Язучы, публицист Фәүзия Бәйрәмова Татарстан Язучыларының XIII корылтаенда ясаган чыгышында болай диде: «Тарихи әсәрләр язган авторлар публицистик документаль мөмкинлекне бигрәк тә киң файдалана башладылар. Вакытында үз бәясен алалмаган мәрхүм язучы Җәмит Рәхимовның «Батырша» романы тарихи документлар, архив язмалары белән аралаштырылып, монтажлап эшләнгән. Бу әсәрнең бәясен һич кенә дә киметми, киресенчә, әлеге кырыс документлар аша укучы шул рәхимсез чорга суырылып килеп керә, әдәбилек белән чынбарлык кушыла, шулай итеп бербөтен тарих — татарның фаҗигале тарихы туа».

Ж.Рәхимов үзе дә «Батырша» романын гомерлек эше дип саный: *«Мин аны язарга гомерем буе әзерләндем. Анда милли мәсьәлә буенча әйтәсе килгән бөтен сүзләремне әйттем. Һәрхәлдә язучы күпме генә әсәрләр иҗат итмәсен, аның күз өстендә каш кебек бер генә китабы була. «Батырша»ны мин әнә шундый китабым дип исәплим».*

Татарның үткәнен һәм киләчәген берьюлы йөрәге аша кабул итү язучыга гомере буена җитәрлек әрнү-уйлану, димәк, иҗат чыганагы, илһам бирә, көрәшкә этәрә торган олы вазифа йөкли, аның иҗат кыйбласын билгели.

1995 елның гыйнварында «Казан утлары» журналында Ж.Рәхимовның «Эскерттәге энә» исемле эссесы дөнья күрә. Әлеге әсәрендә әдип «Батырша» романының язылу тарихын бәян итә, укучыны яңа әсәр туу процессы белән таныштыра. Эссе гади укучыны гына түгел, татар зыялыларын, галимнәрне, гомумән, киң катлау аудиторияне күз алдында тотып язылган.

Татар әдәбиятында вакыт сынауларын үтеп, бүген дә яратылып укыла торган уңышлы әсәрләр бихисап, китап киштәләренә язучыларыбыз каләме астыннан чыккан яңа повесть-романнар да өстәлеп тора. Алар арасында «Батырша»га тиң тарихи әсәрләр дә юк түгел. Ләкин Ж.Рәхимовка кадәр татар әдипләренең берсе дә әсәрләренең дөньяга туу тарихы турында болай зурдан кубып язмады, язучының иҗат газаплары үзенә генә билгеле булып, пәрдә артында калды.

«Эскерттәге энә»нең язучы вафатына бары бер ел кала дөнья күрүе дә уйланырга мәҗбүр итә. Эссены укып чыккач, аңлыйсың: юк, бирелә сүз роман язылу тарихы хакында гына түгел, язучының үз укучысы алдында хисап тотуы бу, күңелен бушатуы, бәлки, хушлашуы, соңгы догасы...

Ж.Рәхимовның шәхси архивында күренекле публицист Айдар Хәлимнең хаты саклана. «...«Казан утлары»ның беренче санында чыккан искиткеч игелекле, нигезле, кечелекле, мәгълүматлы һәм ниндидер сафлык, яналык, олуглык бөркеп торган мәкаләләреңне укыганнан соң, мин күптән башымда йөргән фикерне тагы да бер тапкыр тәкрарладым: Җәмит Рәхимов – Кама аръягы төбәгенең зур һәм чын язучысы. Рәхмәт сиңа, дускай. «Батырша» романының язылу тарихын мин җылый-җылый укыдым. Бу биеклек Кама аръягыннан бөтен татар, бөтен халыклар әдәбиятларының күренекле тавы булып күтәрелде. ...Архивта казыну, аларны иренмичә, матур итеп язу һәм матбугатта бастыру өчен никадәр мәгърифәти җан булырга кирәк?!» – дип яза ул, каләмдәшенең батырлыгына сокланып һәм аның иҗатына югары бәя биреп.

«Эскерттәге энә» әсәре жанры белән дә, тематикасы белән дә татар әдәбиятына, журналистикасына яңалык алып килде. Җәмит Рәхимов күргән-белгәннәрен, шәхси тәҗрибәсен, күңел кичерешләрен, уйларын башкаларга җиткереп калырга ашыга, гүя үзе туплаган тормыш һәм иҗат тәҗрибәсенең югалуын теләми, шулай итеп, яшь каләмдәшләренә юл күрсәтә, башкарырга өлгерми калган эшләргә үкенеч белдереп, аларны дәвам итүче варислары булуына өметләнә.

*«Аксакаллар белән очрашу-сөйләшү мине еш кына тарих чытырманлыкларына илтеп ташлый»*, – дип башлана эссе. Батырша исемен тәүге тапкыр картлар авызыннан ишетә ул. Һәрбер детальгә, факт-вакыйгага игътибар белән карарга өйрәнгән журналист бу серле исемне күңел төбенә салып куя. Әмма аксакаллардан алынган мәгълүмат гаять аз: *«...мулла, диләр, ахун, хәзрәт, диләр, кайсылары аны әүлия дип тә атады. «Батырша галим булган, халыкка ниндидер хатлар, өндәмәләр дә язган»*, – дигән фикер дә ишетергә туры килә.

Эссенең башламы шундый. Әмма бу әсәрнең генә түгел, эзләнүләрнең дә башы. Нәкъ менә аксакаллар белән сөйләшкәннән соң, Ж.Рәхимовның күңелендә кызыксыну хисе уяна: *«Алай да кем соң ул Батырша? ...Батырша дигән серле дә, тылсымлы да исем һич кенә дә тынгылык бирмәде миңа»*.

Кызыксынучанлык, тынгысызлык Рәхимовны китапханәгә алып килә. Ул дистәләгән китап, белешмәләр актарып, Батырша турында мәгълүмат эзли. Йомгак очы урыс мәктәпләре өчен язылган тарих китабында табыла: *«1755 елда Башкортстанда Батырша җитәкчелегендәге крестьяннар восстаниесе булып уза»*. «Батырша» романының нигезе менә шул бер җөмләдән гыйбарәт.

«Тарихи әсәр язарга алынган шәхеснең әзтабар булуы, гадәти кеше игътибар итмәгән чыганакларда, тарихи өзекләрдә мәгънә күрә белүе һәм хыялга, интуициягә искиткеч бай булуы мөһим», — дип әйтүе белән Тәлгат Галиуллин хаклы.

Халкының язмышына, аның үткәненә, каһарманнарына битараф булмаган, балачактан ук тарих белән кызыксынган Ж.Рәхимов, Батырша турында мәгълүмат эзләп, Мәскәү архивына юл тота: *«Бәй, әнә шундый илкүләм санлы архивта әлеге серле шәхес хакында материаллар булуы бик мөмкин ләбаса! Бу фикер мине ашкындырып җибәрде, йөрәк кагарга тотынды».*

Ләкин кулында тиешле документлар булмау сәбәпле, Рәхимовны архивка үткәрмиләр. Аның юлында беренче каршылык бу. Нинди хисләр кичерә автор? Юлыннан, ниятеннән чигенеп, кире кайтып китәме? Юк! *«Туксан тугыз бәла белән меңнәрчә чакрым җир килеп, сине шул кадәр ваемсыз каршыласыннар әле! Ачудан кызарып чыктым, аңа (пропусклар бюросындагы ханымга) очып-очып кунганнан соң да берни чыгара алмагач, аны башкачарак шурләтәсе иттем, очып диярлек икенче катка, архив директоры янына менеп киттем»,* — бу юллар автор хакында шактый мәгълүмат бирә. Ж.Рәхимов — эш кешесе, аңа үз бурычын үтәргә комачауларга, хокукларын кысарга беркемнең дә хакы юк. Шушы илнең тәртипле гражданы буларак, үзенә хаклы рәвештә ихтирамлы мөнәсәбәт көтә. Мин-минлегенә, кешелек горурлыгына тияләр икән, ул үз хокукларын яклап көрәшергә әзер. Бюродагы «маржа»ның тупаслыгы Рәхимовта үҗәтлек тудырса, архив директоры «сабырлыгы һәм әдәплелеге белән аны бөтенләй коралсызландыра». Тәрбияле кеше буларак, ул хәлнең җитдилеген аңлый, әмма җинелүе белән килешергә теләми: *«Кирәк бит, шуннан ары кил дә, берни торгыза алмый кайтып кит, имеш. (...) Башкалада вакытны бушка уздырмаска, ...Ленин исемендәге иң зур китапханәгә сугылырга ниятләдем».*

Әлеге сүзләр Ж.Рәхимовның максатчан, каршылыклар алдында туктап калмыйча, вакыт кадерен белеп, аның һәр мизгелен эш өчен файдаланучы шәхес икәнен раслый. Китапханәдә кичергән хисләре исә аның китап яратучы, күп белергә омтылучы кеше икәнен күрсәтә: *«...китапханәдәге гыйлем байлыгын, күреп түгел икән, ишетеп булса да һәркем күз алдына китерәдер дип уйлыйм. Ул — тулы бер рухи диңгез, бер уку залындагы ... белешмә-энциклопедияләр генә дә «аһ» итәрлек».* Менә кайда ул язучы өчен чын байлык! Китапханәдән күнеле, кәефе күтәрелеп чыга: *«Мине тагы да канатландырганы шул: илнең үзәк китапханәсендә Батырша эзенә төштем. Сөенечемнән җиде кат күккә аштым. Мин бит ул китапларны барыбер табачакмын, һәркайсын укып ләззәтләнү бәхетенә ирешәчәкмен!»* — Яшьтән үк китапларга, үзе әйткәнчә, «гыйлем байлыгына» мәхәббәт-хөрмәт белән карарга, рухи хәзинәне матди байлыктан өстен күрергә өйрәнеп үскән кеше сүзләре бу. Китап укып, ләззәт алу — Ж.Рәхимов өчен зур бәхет, ул чын мәгънәсендә укымышлы, зыялы шәхес.

Язучының Мәскәү архивларына икенче сәяхәте уңышлы була, беренче баруыннан шактый тәҗрибә — сабак алып кайткач, ул бу юлы баштанаяк документлар белән коралланып килә. Ниһаять, архив ишекләре аның өчен дә ачыла, *«дүрт тәгәрмәчле арбага төяп, аңа да кәгазь тавы»* китерәләр. Боларны күреп, егылып китә яздым, ди автор: *«...мавыгып китеп, заявкаларны күбрәк биреп ташлаганмын, күрәсен. Берүзем бер олау документ!»* Баштарак бу кадәр документны ничек карап-актарып бетерермен дип борчылса да, язучы үз көченә ышана: *«Йә, ярар, күз курка, кул эшли»* .

Мәскәү архивына *«бер ай рәткә эшләргә дип килгән»* кеше бу вакытның бик аз булуын беренче көнне үк чамалап ала, җитмәсә архивта казынып, диссертация язып ятучы берәү мыскыллап әйтеп тә куя: «Бер ай архивта ни генә торгызырсың икән соң?»

Әмма язучының бирешергә исәбе юк, ул җиң сызганып эшкә чума: *«Юк, шалишь, брат, ...вакытны дөрес файдалансаң, ни дә булса майтарып булырга тиеш».* Эш вакытын дөрес файдалану Ж.Рәхимовча болай икән: *«...көненә уникешәр сәгать эшли башладым, архив ачылганчы ук килеп җитәм, соңгы кеше булып чыгам».* Әлеге юллар авторның гадәттән тыш эшчән, чыдам, сабыр һәм үҗәт зат икәнен дәлилли.

Сәфәре уңышлы килеп чыкса да, Рәхимов ирешелгәннәрдән генә канәгать түгел, чөнки: *«...тарихның гамәли билгеләре булган иске архив кәгазьләре гаҗәп үзенчәлеккә ия икәннәр ич. Алар әйтерсең лә Гомер поэмасындагы сихерче, үзләренең искиткеч тавышлары, тылсымлы җырлары белән сәяхәтчеләрне юлдан*

*яздыручы канатлы кызлар-сиреналар, гел үзләренә тартып, чакырып торалар. Инде араларына кереп баттыңмы, ул саргайган кәгазьләр чоңгыллы баткакка әвереләләр, сине һичкая чыгармыйча, һаман эчкә, тирәнгә суыралар. Аларның әнә шул хасияте мине дә ырымлады, кальбемне сихерләде».* Гап-гади кәгазьләр турында шулай образлы итеп язу, аларны шундый әкияти сыйфатларга төрер өчен, тарихны һәм тарихка кагылышлы һәр нәрсәгә изге итеп карау кирәктер.

Ж.Рәхимов өчен архив – *«гыйлем йорты», «хәзинә мәгарәсе», «әбугалисина мәгарәсе» булса, «борынгылык исе килеп торган» документлар – «мәдәни байлык», «гыйлем хәзинәсе», «калын-калын томнар» «ымсындыргыч»* һәм *«кызыктыргыч»*. Бу бәя-чагыштыруларда авторның гыйлем йортына хөрмәте, тарихи документларга сак мөнәсәбәте чагыла.

*«Акча һәм вакыт дигән ике тышау аякларга бик нык уралса да, мин инде җай чыккан саен, зур архивлар урнашкан калалар ягына каера башладым»,* – ди Ж.Рәхимов.

Халкына югалган тарихны, хаксыз рәвештә онытылган каһарманның исемен кайтару өчен вакыты белән дә, хәләл акчасы белән дә исәпләшеп тормый ул. Архивтагы документларның күчермәләрен, фотоларын ясату, микрофильм төшертү өчен үз кесәсеннән түли: *«Кулыма счёт бланкы китереп биргәч кенә, суга төшкән тавык хәлендә калдым: анда күрсәтелгән сумма шактый зур иде, ә минем кесә ягы шактый сыек. Нишлисең, Мәскәү маржалары алдында сер биреп булмый бит инде, кайту юлына дип аерып куйган акчаны чыгарып салдым».* Зарланмый, уфтанмый Рәхимов, кесә ягының сай булуына гадәти хәл итеп карый, ул моңа күнгән, өйрәнгән инде. Югыйсә үз мәнфәгатен кайгыртып йөрүе түгел бит, халкына, милләтенә хезмәт итү юлында. Әмма әдип вакланмый, изге эш өчен җаны фида, малы фида. Әлеге детальдә Ж.Рәхимовның риясызлыгы, фидакарьлеге генә түгел, горурлыгы, эчке бәйсезлеге дә ачык чагыла. Матди яктан мескен хәлдә булса да, «бөек милләт» вәкиле алдында сер бирми, милли горурлык хисен югалтмый, үзен кимсетми, түбәнсетми. Милләтен дә горур һәм бәйсез итеп күрәсе килә аның. Батырша – әдипнең горурлыгы, нинди генә җылы сүзләр, олуг исемнәр, эпитетлар белән атамый ул аны: *«Саллы архивларда һәм зур китапханәләрдә татарлар хакында ымсындыргыч мәгълүматлар, «эскерттәге энәләр биниһая күп булса да», язучының күнелен «даими борчыган, хафаландырган, җилкеткән һәм дәртләндергән, ниһаять, газаплаган нәрсә ул Батырша язмышы».*

Ж.Рәхимов өчен Батырша – «бөек шәхес», «олуг зат», «каһарман», «шөһрәтле», «башбирмәс узаман», «батыр», «көрәшче», «күренекле җәмәгать эшлеклесе, фикер иясе, акыллы, гыйлемле һәм тәрәккый кеше», «көрәш мәйданына каурый каләм һәм Коръән алып чыккан изге җан». Язучы үз героена – Абдулла Галиевкә гашыйк, ул аңа соклана, Батыршага булган хөрмәт-ихтирамы чиксез. Батыршаның үз кулы белән язган хаты кулына килеп эләккәч кичергән хисләре дә шул турыда сөйли: *«Алдымда моннан 240 еллар элек шөһрәтле Батырша кулындагы каурый каләм белән тигез итеп язылган юлларны күргәч, әллә нишләп киттем. Әйтерсең лә тарих дигән нәрсә тере һәм ул күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора. Ирексездән, маңгаема чыккан тирне сөртеп алдым һәм, бераз тынычлану нияте белән күзләремне йомдым. ... Ул атнада нинди дер хыялый дөньяда яшәдем – бәһасез табышка юлыгу шатлыгы зур иде».*

Мәскәү архивында тупланган документлар, мәгълүматлар Батыршаның *«шәхесен, акылын-фигылен, гыйлем-тәрәккыятен, уй-фикерләрен, халык алдындагы иманына тугрылыгын һәм башка сыйфатларын күзалларлык, аның якты образын гәүдәләндерерлек»* булса да, язучы ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнми, Батырша турында өстәмә мәгълүмат эзләп, Петербургка юл ала, каһарманы соңгы сулышын алган Шлиссельбург кальгасын үз күзләре белән күреп кайта. Аның бу гамәле төгәллеккә, каһарман язмышын тулырак яктыртырга, Батырша шәхесен тирәнрәк аңларга омтылуын күрсәтә.

Экскурсовод кызның Батырша турында бер сүз әйтмәве язучыны гаять гаҗәпләндерә, ул бу хәлгә битараф кала алмый:

*«Түзмәдем, сорау бирдем:*

*– Монда татар-башкорт восстаниесе җитәкчесе Батырша утырган, диләр?*

*Ханым миңа канәгатьсез караш ташлады, иренеп кенә әйтеп куйды:*

*— Андый сүзләр бар барын.*

*— Ул яктан хөжрәне, һич югы хөҗрә урынын күрсәтә алмассызмы? Бәлки, аның кабере билгеледер?*

*— ?*

*— Ни хикмәттер, музейда Батырша турында экспонатлар юк. Ә архивларда аның хакында кызыклы гына мәгълүматлар бар, диләр. Моны соң ничек аңларга?»*

Әлеге диалог Ж.Рәхимовның тарихи дөреслеккә, гаделлеккә омтылуын дәлилли. Ул үз фикерен ачыктан-ачык белдерә, хакыйкатьне эзли.

«Эскерттәге энә» эссесында роман язылу тарихы турында гына сөйләнми, әдипнең милләт язмышы турында уй-фикерләре дә ачык чагыла. Аның максаты — үз халкына хезмәт итү: *«...зур калаларның гыйлем йортларында булганда, мин бит авыллар тарихы белән генә шөгыльләнмәдем, татарларга караган һәрнәрсәгә ...игътибар итәргә тырыштым. Мин туплаган материаллар гына да дистәләгән диссертация язарга җитәрлек. ...Мин, әлбәттә, диссертация язарга җыенмыйм, әгәр, гомер булса, алар хакында эсселар, әдәби очерклар язарга ният бар»*, — ди ул.

Мәскәү, Петербург, Оренбург, Самара, хәтта Тубыл архивларында татар халкына кагылышлы, гарәп хәрефләре белән язылган тау-тау белешмә, документлар булып та, аларга тарихчыларыбызның кулы тимәве, шулкадәр гыйлем байлыгының бүгенге көнгә кадәр өйрәнелмәве өчен борчыла автор: *«Капшап та карадым, кулыма алып актаргаладым да — барысы да гарәп хәрефләре белән язылган документлар — хәзинә мәгарәсе! Бу кадәр гыйлем байлыгын күргәч, соравым үзеннән-үзе атылып чыкты: «Килүчеләр, өйрәнүчеләр бармы?» Соравына тискәре җавап алгач: «Авыр, бик авыр иде мондый сүзләр ишетү. Татарлар турында нинди генә серләр, без белмәгән мәгълүматлар ятмыйдыр бу ганимәт өемендә. Аяныч ки, алар бер файдасызга ауный бирә, ул гынамы, акрын-акрын сафтан чыга, һәлак була»*, — дип сыкрана автор, татар тарихчыларына үпкә дә белдереп куя. Ләкин аларны гаепләргә ашыкмый, чөнки белә, мохтаҗлык галимнәребезгә нәтиҗәле эшләргә ирек бирми. Хәер, үзендә дә шул ук проблема. Татар язучысының мескен хәле турында уй-фикерләрен укучыдан яшерми ул.

Тарихи әсәр язучыга күп эзләнергә, ил буйлап йөреп, материал тупларга кирәк. Реаль шәхес турында, тарихи фактларга нигезләнгән документаль әсәрне өйдә утырып язып булмый. Ә татар әдибе өчен чит илләр гизү түгел, Мәскәүгә барып кайту да зур проблема, чөнки юл хакын түләүче, чыгымнарны финанслаучы юк. Шуңа күрә татар язучысы вакытын, сәләтен иҗатка файдаланасы урынга казна эшендә эшләргә мәҗбүр. Җәмит Рәхимов, бу хәлгә борчылып: *«Казна эше кулны тота, иҗатка вакыт казна эшеннән соң гына»*, — ди, әдипләр өчен актуаль булган проблеманы җәмгыять хөкеменә чыгара. «Бал корты» эссесында язучы шәхесе турында уйланулары тагы да кинрәк: *«Сәгать чыкылдап куйды. Карыйм — төнге өч. Мин, дивана, һаман утырам. Арка куна тактасыдай каткан — селкенгәләп алам, үземне үзем тиргәвемне дәвам итәм. Соң миңа җәфаланырга кем кушкан? Ипилек-тозлык акчаны башка җирдә эшләп ала алмас идеммени?! ... Айлар-еллар буе шулай. Көндез — казна эшендә, төнлә өстәлем артында. Язучылык эше нәрсә ул, аннан да аз түләнә торган кәсеп юктыр».*

«Эскерттәге энә» эссесында дә язучы хезмәтенең кадерсезлеге, арзанлыгы хакында ачынып әйтелгән фикерләр бар: *«...гыйбрәтле бер деталь: тышлыгына минем фамилия язылган кирпеч калынлыгы китап дөнья күргәч, ...кайберәүләр очрашканда кинаялерәк сүзләр әйтә башладылар: янәсе ... бер олау каләмхак алдың, миллионер булдың. ...Әйе, ун еллык хезмәтем өчен мин ... күршемдәге нефтьче егетнең ике атналык эш хакы күләмендә гонорар алдым. Үкенечле хәл, гаделсез дөнья, билгеле. Әмма мин андый чакларда да зарланмыйм-сукранмыйм, бары тик Мәскәү архивында микрофильм алдырган өчен, кайту юлына диган акчамны түләвем һәм билетка дип аны бурычка эзләп йөрүем искә төшә. Менә шунда йөрәк сыкрап куя инде...»* Бу юлларны укыгач, язучының олы хезмәтенә гадел бәя бирелмәвенә җан әрни. Хезмәте өчен бары тиеннәр генә аласын алдан ук белсә дә, ниятеннән чигенмәгән, үз максатына ирешкән Җәмит Рәхимовка ихтирам хисе тагы да арта.

Романның үтә дә четерекле, кешеләрнең милли хисләренә, иманына тәэсир итә

торган бүлеген. Батыршаның Пётр-Павел чиркәү-кальгасында урыс миссионеры Стефан Левицкий белән бәхәсен, хакыйкатькә хилафлык китерми, укучыны ышандырырлык итеп тасвир итү язучы өчен гаять авыр бурыч булып тора, «чөнки бәхәс беркая да теркәлмәгән». Батырша иманын сатмый, дөньядан иманлы мөселман булып китә. *«Шулаен шулай да, бу ике дин вәкиленең бәхәсен әдәби әсәрдә ничек бирергә? Сүз дә юк, иң элек һәр ике диннең асылын белергә кирәк. Әгәр бүлек язылмый кала икән, Батырша образы ачылып җитми дигән сүз. Минем көймә комга терәлде»*, — ди автор, әмма шунда ук үзенең чигенергә исәбе юк икәнен дә белдереп куя: *«Әмма ул төпкә утырды диеп кул кушырып утыру да ярамый»*. Ж.Рәхимов диннәр турында китаплар җыя, төннәр буе шуларны укый. Эш буенча командировкага барганда да чемоданына китап тутыра: *«...чемоданым инде таш тутырган сандыкны хәтерләтә иде»*. Әдипнең башында бары бер нәрсә: *«...диннәр, аларның охшашлыклары һәм аермалары. Мин әле Батырша булам, әле Левицкий... бәхәс кыза, бәхәс куера...»*

Эзләнүләр, кочак-кочак китап-белешмәләр уку, йокысыз төннәр бәрабәренә туа татар әдәбиятына гына түгел, дин белеме китапларына да кереп, ислам динен тотучылар горурланып, бу диннең хаклыгы турында күкрәк киереп бәхәсләшерлек, тирән фикерле, төпле дәлилле, искиткеч тәэсирле бәхәс. Батырша белән урыс попы арасындагы әлеге әңгәмәне әсәрнең иң биек кульминацион ноктасы дияргә була. Ул — Батыршаның дошманны әхлакый җиңүе, аның рухи өстенлеге. Димәк, әлеге бәхәсне тудырган автор үзе дә Батырша биеклегенә күтәрелә, чөнки каһарманы булып ул сөйли.

Ж.Рәхимовның хакыйкатькә, дөреслеккә, гаделлеккә хезмәт итүче зат булуына эсседа тагын бер дәлил бар. *«Батырша хакында укучыларның күңелен җәлеп итәрлек әсәр тудыруы җиңел булмаячак. Мин боларны белдем, Батырша образын гәүдәләндерүе кыен булачагын да, роман басылып чыккан тәкъдирдә ... «Батырша берни эшләмәгән икән» кебек беркатлы хат-мәкаләләрнең матбугатта басылу ихтималын да чамаладым. Мәгәр тарихи чынбарлыкка хыянәт итә алмадым»*, — ди ул. Чөнки белә: *«Батырша яуның гамәли җитәкчесе биеклегенә күтәрелә алмый. Бу аның фаҗигасе. Әсәремдә мин шуны күрсәтергә тырыштым да»*.

Авторның батырлыгын, кыюлыгын раслаучы фактларның тагын берсе — аның милләтче дигән исем күтәрүдән курыкмавы. Югыйсә «шактый укымышлы акыллы кешеләр» киңәш бирә: *«Ташла син аны, төкер, Батыршадан барыбер каһарман ясый алмассың, ул бит — ата милләтче!»* Дуслары, танышлары, милләттәш зыялылары да: «КГБ кармагына кабасың килмәсә, Батырша хакында авызыңны да ачма!» — диләр. Рәхимов үзе дә: *«Мин Батырша темасын кузгатканда, әле 70нче еллар... коммунистик администрация — команда җитәкчелегенең шау чәчәктә чагы... һәрхәлдә куркырга җирлек, тупланган материалларга кул селтәргә сылтау җитәрлек иде»*. Әмма курыкмый, эшен дәвам итә. Романны яза башлаганчы ук, Ж.Рәхимов аның теле турында уйлана. Ана XVIII гасырга хас, «шул заманның рухын чагылдыручы һәм шул чорда яшәгән кешеләрнең сөйләменә хас» телне яхшы өйрәнергә кирәк. Роман рухына туры килә торган тел итеп Батыршаның үз телен файдалана. *«Билгеле инде, үзем белгән борынгы сүзләр дә бик ярап куйды»*, — ди автор. Димәк, аның тел байлыгы тарихи роман язар өчен җитәрлек була.

«Эскерттәге энә» эссесының теле дә әсәрнең темасына туры килеп тора. Ж.Рәхимов — бала чактан ук татар сөйләмен, татар җырларын тыңлап, милли мохиттә үскән милли язучы. Ул иҗатына кирәк азыкны халык традицияләре чишмәсеннән ала, татар әдәби теленең хәзинәсен баета. Әдип көндәлек сөйләм теле белән генә чикләнми, телебезнең гасырлар артында калган ерак бабаларыбыз сөйләшкән борынгы хәзинәләрен дә бик белеп, урынлы куллана. Алар сөйләмне бозмый, киресенчә, затлы ташлар кебек ялтырап, аны бизи, баета. Архив хезмәткәрләрен автор «хадимнәр», ди, монастырь сүзен «хөҗгә» дип тәрҗемә итә. Эсседа бик урынлы кулланган архаизмнарга тагын берничә мисал: *«әбинең хәерхаһлыгына ирешергә»*, *«ганимәт өеме»*, *«төгәлсезлекләрдән хали түгел»*, *«аларның әнә шул хассияте мине дә ырымлады, кальбемне сихерләде»* һ.б.

Ж.Рәхимов татар халкына, бары мөселманнарга хас милли сөйләмне дә шактый

куллана: *«Тәвәккәл тәгаллаллаһи!», «Шөкер, монысы да барып чыкты», «Хак, аларның хәлен анлыйм», «Мәгәр берни эшләр чараң юк»* һ.б.

Автор, халык мәкальләрен кулланып, әсәрнең телен баета, теге яки бу күренешне, фикерне көчәйтә, дәлилли: *әмма башына төшкәч, башмакчы буласын дигәндәй, тырышасын, тырмашасын», «Чынлап еласан, сукыр күздән дә яшь чыга», «Тегермәнчегә тегермәннән он ияреп кайта», «Урманга кергән саен утын күбәя», «Минем көймә комга терәлде»* һ.б.

Шулай ук риторик сорау һәм өндәүләр дә әсәрнең укучыга тәэсир итү көчен арттыра, авторның күңел халәтен аңларга ярдәм итә: *«Йа Ходә, бу кадәр кәгазьне ничек карап-актарып чыгармын?», «Менә кайда икән ул жан азыгы – тулы бер дәрья!», «Юк, булмый, Алла сакласын!»*

Батырша хаты – Ж.Рәхимов өчен *«алтыннан да кыйммәт хәзинә»*. Чөнки анда *«безнең иске татар теле тулы куәтенә чагыла, әлеге язма истәлектә авторның үзенә генә хас стиле, тел бизәкләре, шул чорның жөмлә төзелеше һәм фигыль формалары, инверсияләр пәрады»*.

Батырша әсәрен укучылар белә, аның сөйләме бүгенге татар теленнән шактый аерыла, анда кулланудан төшеп калган борынгы сүзләр еш очрый.

«Эскерттәге энә» эссесын укыгач, Батырша романының нинди зур кыенлыклар, ижади эзләнүләр, фидакарьлек, титаник хезмәт бәрабәренә тууын яхшы аңлыйсың. Тарих чытырманнарын мең авырлык белән ера-ера, Ж.Рәхимов олы максатына ирешә. Милләтпәрвәрлек, батырлык ягыннан ул үзе дә Батыршадан ким түгел икән! Татар әдәбиятында бөек шәхеснең якты образын калдыру өчен нәкъ менә Ж.Рәхимов кебек тынгысыз фидакарь зат, талантлы әдип һәм публицист кирәк булгандыр.

«Эскерттәге энә» эссесында Ж.Рәхимовның мондый сүзләре бар: *«...Батырша миңа бик тә якын, аның язмышы, эш-гамәлләре, идеаллары жанга һич кенә дә тынгылык бирми. Чөнки аның ният-омтылышлары минекенә туры килә, уй-исәпләре минем милли мәсьәләдә фикер йөртүләремә тәңгәл диярлек. Менә шуңа да мин Батыршага артым белән борыла алмыйм, киресенчә, олуг остазның рухын, идеалларын яшь буынга житкерәсем килә»*.

Әлеге сүзләр Ж.Рәхимовны үз каһарманына тагы да якынайта.

«Эскерттәге энә» эссесын укыгач, күңелдә авыр хис, үкенеч кала. Күпме мәгълүматны, хакыйкатьне халкына житкерергә өлгерми, олы хыялларын тормышка ашыра алмый дөньядан китеп бара талантлы әдип һәм публицист. *«Илебездәге (дөньяныкы турында сөйләп тә тормыйм) язма хәзинә, шул исәптән татарлар турында рухи байлык шулкадәр күп икән ки, аларны карап чыгу өчен генә дә, бер кеше гомере димим, мең кеше гомере дә житмәс»*, – дип язган иде Ж.Рәхимов. Аның эш бүлмәсендәге калын-калын папкаларда киләчәктә мәкалә, эссе, очерк, китап булып дөньяга чыгасы, халкыбызның рухи хәзинәсен баетасы күпме документлар, мәгълүматлар калды. Энциклопедик белемле шәхес иде ул.

«Жәмит Рәхимов – милләтпәрвәр әдипләребезнең иң күренеклеләреннән. Ул халкының бөеклегенә инанган зат. Тарих фәне гаделлекне ярата. Ж.Рәхимовның әдәби әсәрләрендә язучы фантазиясе түгел, тарихи дөреслек ята. Ул тарихи документларга таянып эш итә», – дип язган иде академик Индус Таһиров якташы турында. «Эскерттәге энә» эссесы бу сүзләрнең хаклыгына ныклы дәлил булып тора.

«Бал корты», «Эскерттәге энә» эсселарында Ж.Рәхимов тормыш һәм ижат тәжрибәсе белән уртаклаша, ижади шәхеснең тормышта тоткан урыны, яшәү максаты, уныш-табышларның нигезе, осталыкка ирешү мәсьәләләре турында уйлана. Эсселарда әдип һәм публицистның дөньяга карашы, яшәеш турында уй-фикерләре, милли хисләре ачык гәүдәләнә. Автор мәгърифәтле, югары әхлаклы, милли жанлы, гуманлы, Батыршага тиң фидакарь көрәшче шәхес булып ачыла.

«Бал корты», «Эскерттәге энә» эсселары – татар әдәбиятына, журналистикасына жанр һәм тема яңалыгы белән кереп калырга лаеклы әсәрләр. Алар Ж.Рәхимовның тормыш һәм ижат юлына, әдәби һәм журналистлык эшчәнлегенә йомгак булып тора.

**Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА**

# ГАМЬЛЕ РӘССАМ



Чиксезлекне берәү дә күз алдына китерә алмый. Очсыз-кырыйсыз дөньяны биниһая көчле сәнгать кенә колачлый ала. «Табигатьнең чиге булмаган шикелле, сәнгатьнең дә чиге юк», — дип язган иде күренекле язучы Адлер Тимергалин. Ә без исә, илһам — күңелнең канаты, сәнгать әһелләре нәкъ менә шул канатлар талпынуына ияреп, безне дә биеклеккә дәшәләр, диярбез. Дөньяның матурлыгын күреп, аны төрле буяулар белән киндергә индерүче кылкаләм осталары, шөкер, шактый. Татарстанның Халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев — шундыйлардан.

Тынгысыз, эзләнүчән һәм куйган максатына омтылучан иҗат остасы Мөдәррис Минһаҗев — гүзәл табигатькә, андагы һәр тереклек иясенә, гасырлар хәтерен саклаучы тау-ташларга гашыйк рәссам. Вакыт дигән тылсымлы дәрьяны чорлар аша бүгенгесе белән тоташтыра ул. Югыйсә, изге Болгар хатирәләрен үз картиналарында янарта алыр иде микән? Әлбәттә, тарихи китаплар актарыла, хәтер аша әллә ничә гасыр үткәнгә кайтып иман янартыла һәм шул туфракка ялантәпи басып картиналар иҗат ителә. Болгарда пленерда булганда, тулы бер «Болгар сериясе» туа. Зур күләмле уңлап эш — иҗатчының тынгысыз хезмәт җимеше. «Болгар кызы — Айсолтан», «Бөек Болгар җирендә», «Багышлау» триптихы, «Болгар капкасы», «Болгар кунагы» һәм башка картиналарында үткән тарих белән бүгенге яшәеш чагылыш таба. Картиналарында автор үткән тарихыбызга алып кайта, уйланырга чакыра. Аларда — халкыбыз рухы, тарих сулышы...

Аларның җылысын, кайтаваз аһәнен рәссамның эшләрендә тоемлап була. Юл йөргәндә, этюднигын үзеннән калдырмаска тырыша ул. Дөньяның матурлыгы киндергә күчми калыр да, башка бик күпләр бу матурлыкны күрүдән мәхрүм булыр, ди сыман. Шуңадыр да ул кылкаләмен табигатьнең кабатланмас төсләренә манып, шул сихри гүзәллекне ак киндергә индерә бара. Олы иҗаты белән тамашачыларын матурлык дөньясына алып керә рәссам. Дөньяны матурлык коткарыр, дип юкка гына әйтмиләрдер.

Рәссам Мөдәррис Минһаҗевның таланты соңгы елларда бигрәк тә тарихи жанрда тулырак ачыла кебек. «Иҗатымны татар халкының тарихын яктыртуга багышлавым юктан гына түгел, изге Болгар җирләре минем дөньяга карашымны, иҗатымны янабаштан барлап чыгарга этәрде, — ди кылкаләм остасы. — Болгар ташларына кагылып, изге туфракка басып иҗат итү минем өчен әйтеп бетергесез бәхет», — дияргә ярата ул.

Чыннан да, син рәссам миссиясен үтәр өчен дөньяга килгәнсең икән, гомерең буе Сәнгать дигән бөек могҗизага хезмәт итәргә мәҗбүрсең. Мөдәррис Минһаҗев та күңел күзе генә күрә алган табигатьнең яшерен серләрен, тын гүзәллеген, әйләнә-тирәдәгеләрнең эчке кичерешләрен тоемлап, берәм-берәм киндергә индерә бара. Ул олы иҗаты белән заманның бертуктаусыз үзгәреп торган вакыйгаларының асылына төшенергә, үткән һәм киләчәкне тоташтыручы җеп очын ялгарга омтыла. Шунсыз биеклеккә омтылу мөмкин дә түгелдер, мөгаен.

Рәссам булу теләге М.Минһажевка туган як табигатенең башка берни белән дә алыштыргысыз гүзәллеген сабый чагында ук күнел күзе белән күрә, матурлыкка соклана белүеннәндер, мөгаен.

1953 елда Татарстанның Шәмәрдән эшчеләр бистәсендә дөньяга аваз салган Мөдәррис Минһажев, мәктәпне тәмамлаганнан соң, Ижау каласына юл тота. 1976 елда Ижау дәүләт университетының сәнгать-графика факультетын тәмамлый һәм армия хезмәтенә алына. Армия хезмәтеннән кайткач, Арчада сәнгать остаханәсен оештырып җибәрә. Сонрак, 1978 елда, ул Түбән Кама каласына күченеп килә һәм анда сәнгать студиясе ача. Һәрдаим камиллеккә омтылучы рәссам анда шәһәр диварларын, урам мәйданнарын һәм башка билгеле биналарны бизәүдә катнаша, Кызыл Чишмәдә мәчет бизәүгә алына һәм даими рәвештә күргәзмәләрдә катнаша башлый. Иҗатчының күнеле һәрдаим эзләнүдә, яңа образлар тудыруда. Ул әле монарчы кеше күзе күрмәгән тын табигатьне, сабый чагында әби-бабасы сөйләгән шанлы үткәнебез, чишмә моңнарын, буй җитмәслек кыя-тауларны эзләп кабат юлга кузгала. Бу юлы аны Лениногорски каласы үзенә сыендыра. 1998 елдан бүгенгәчә Мөдәррис Мөхетдин улы әлеге калада яшәп иҗат итә. Шул еллар дәвамында кылкаләмен шактый чарлый һәм чын рәссам булып җитлегә. Аның әледән-әле оештырылып килә торган күргәзмәләре, Зәй, Яшел Үзән, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Ижау калаларын узып, башкалабыз Казанны яулап ала. Башкортстан, Казакъстан кебек тугандаш республикаларда яшәүче халыклар да кылкаләм остасының гүзәл иҗат әсәрләре белән хозурлана алды.



*«Әни» картинасы*

Рәссамның иҗатында дөньяны үзенчә күзаллавын, фәлсәфи фикер йөртүен тоемлыйбыз. Үткән тарихыбызны барлау, милли хис-тойгылар, рух бөеклеге, татар милләтенә генә хас нур, моң киндергә үзенчә җете төсләргә төрелеп иңдерелә. Һәр әсәрендә останың гармоник сиземләвенә юлыгасың. «Туган йорт истәлеге», «Чалгы белән натюрморт», «Ак ат» картиналары исемнәре белән гадәти тоелса да, аларда халык язмышы, истәлек-хатирәләр, авыл халкы өчен кадерле булган эш кораллары янәшәсендә сусауны басар өчен авыл киленнәре иртән генә савып чүлмәккә салган сөт, яшь кызлар җыеп китергән җиләкләрне күреп хозурланасың. Рәссамның «Ак ат»ын авыл осталары ясаган дуга-камытлары, бизәкле йөгәннәре көтә.

«1000 еллык Казан», «Болгар тамгалары», «Изге урыннар» кебек әсәрләрдә иҗатчы милли үзаң тәрбияләү, ватанпәрвәрлек кебек олы хисләрне иңдерүне максат итеп куя.

М.Минһажев иҗатында милли бизәкләр, шамаилләр дә зур урын алып тора. Мөгаен, ул аның авыл өендә, әби-бабай нигезендә сабый чагында күнеленә, рухына сеңеп калган хатирәләреннән киләдер. Гарәби язу алымын ул үзенең гади генә тоелган «Натюрморт», «Тукайга чәчәк бәйләме», «Түбән Кенә авылы өлкәннәре» һәм башка бик күп картиналарында да бизәк итеп кушып җибәрә.

«Чишмәләр» темасы аеруча игътибарга лаек. Анда челтерәп аккан саф сулы чишмәләрнең моңын ишетәсең, түмен тоясың, аның янәшәсендә ак ашъяулыкка куелган көнкүреш кирәк-яраклары, савыт-сабалар, бизәнү әйберләрен күреп сөенәсең. Бу — иҗатчының олы табышы.

Рәссамның пейзажлары, туган як болыннарында утлап йөргән атлары, колыннары, су буенда бәбкә үләне чемченеп йөргән каз-үрдәкләре кемнәрне генә сокландырмагандыр да күнел кылларын тибрәтеп уйландырмагандыр...

Иҗатчының һәр картинасы киләчәккә якты өмет, күтәренке хис, яшәү шатлыгы белән сугарылган. Автор, шушы гүзәл табигать кочагында иҗатына тугры калып,



*«Әткәм хатирәсе» картинасы.*

халкым рухын саклап, киләчәккә якты өмет-хыяллар белән яши. Чын мәгънәсендә татарлыгыбызны, аның мәнфәгатен кайгыртып, милләт, дәүләт хакында уйланып, сәнгать дөньясында нык адымнар белән иҗат итүче, Ш.Бикчурин исемендәге премия лауреаты, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Халык рәссамы ул.

...Кояш әле офыкка күтәрелеп кенә килә, ә рәссам күптән инде мальберты янында.

Ул, күнеле белән кояш нурларына үрелеп, кылкаләмен нурга мана да ак киндергә чиксез галәм күген суреткә төшерә. Һай, бу гүзәллек!..

Аның үзенчәлекле, күз явын алырдай гаҗәеп табигать күренешләре майлы буяулар белән генә индерә алганча, тормышның чынбарлыгын сурәтләп бирә. Рәссамның үткер тойгысы, тормышның син моңарчы күрми йөргән бер парчасын күз алдына китереп, күнел кылларына кагылып үтә. Бөтен барлыгың белән останың сурәтләре аша сәяхәт итәсең.

Иҗат юлында күп өйрәнергә, эзләнергә, тәҗрибә-сынаулар аша үтәргә туры килә рәссамга. Бер карашка бу кадәр төсләр балкышын, мизгел эчендә туган хисләрне бер полотнога салу мөмкин дә түгел сыман. Табигатьтән алынган картиналарда үзгә бер садәлек, сафлык бөркелә.

Чорлар белән чорлар, буыннар белән буыннар очрашуы, күз карашы белән генә аңлашу, фикер алышу, кайдадыр өзелеп калган кылны бүгенгегә ялгау... тагын әллә ниләр...

Төрле жанрда, төрле техника белән иҗат ителгән пейзажларда туган як табигате яктыртылса, төрле чор кешеләренең уйчан да, мөлаем да йөзләрендә күреп туймаслык гамь, моң яшеренгән.

Мөдәррис Минһаҗевның әсәрләре — татар мәдәниятенә саллы өлеш кертә һәм дөньякүләм заман сәнгатенең хәзинәсе булып саналырлык гүзәлләр. Рәссамның Жирдә кешенең иҗади хезмәтен, туган як табигатенең матурлыгын данлаучы эшләре шигъри аһәң һәм мәхәббәт белән сугарылган. Аларны үз күзләрең белән күреп, сокланып, хозурланып калу кирәктер.

Чишмәләр, җир-суларыбыз да аңа рәхмәтледер, югыйсә картиналарда аларның агышын, җырын, моңын тоемлап булмас иде. Су буеннан кайтып килгән казлар да бер-берләренә аваз салгандай каңгылдашалар сыман. Әйтерсең лә бу гүзәл картиналар сине табигатьнең үзенә сәяхәткә алып чыгалар!..

Һай, бу бәхетле мизгел... Әйтерсең лә ул үзенең тамашачысы хозурына әлегә барып ирешмәгән сурәтләре аша табигатьнең моңарчы гади күз белән генә күреп булмый торган яшерен серләрен, кодрәтен, илаһилеген ачып, мизгел эчендә ак болытлар хозурына иярпеп җибәрә, инеш-елга, чишмә сулары хәтерен яңарта, шушы матурлык, моң белән өретелгән әсәрләрен шаян җилләргә бүләк итә. Аның ак болытларга ияреп киткән, яңгыр тамчылары юган, дулкыннар ялмаган сурәтләре Табигать-Ана тарафыннан хупланып, тамашачы хозурына барып ирешә. Ә иҗатчы өчен шуннан да зуррак бәхет булуы мөмкинме соң!

Гомер уза, еллар үтә... Тарих тәгәрмәче алга тәгәри. Кешелек ашыга-ашыга киләчәккә атлый. Тик бер генә мизгелгә артка борылып карыйсы, халкыбыз үткән дәвер, чорлар аша еракта калган хатирәләрне барлыйсы килә. Рәссам Мөдәррис Минһаҗев картиналары да безне хәтер яңартырга өнди сыман.

**Дания ГАЙНЕТДИНОВА**

# ЕРАККА КИТЕП КАРАСАҢ...

Лениногорск районы республикабызның Түбән Кама, Тукай, Минзәлә, Мөслим, Актаныш, Сарман, Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә, Ютазы районнары белән бергә Татарстанның Көнчыгыш Кама аръягы зонасына керә. Ул — республика территориясенең ин биек (380 метрга кадәр) өлеше. Монда көньякка таба урманнарны дала алмаштыра. Табигый-климатик шартлар унай булганга күрә, бу жирдә төрле этник төркемнәр, кабиләләр хужалык итүнең утрак һәм күчмә юлларын сайлаганнар. «Әлмәт энциклопедиясе» программасы нигезендә Лениногорск территориясендә 14 археологик һәйкәл ачыкланган. Алар нигездә бронза һәм тимер чорларына карый. Мондагы жирләр жентекләп өйрәнелгән тәкъдирдә аларның саны тагын да күбрәк булыр иде.

Район Евразия мәдәният һәм цивилизация системасында мөһим урын алып тора. Урта гасырда биредәге жирләр Идел-Уралдагы дәүләтләрнең, шул исәптән Алтын Урда, Нугай Урдасы, Казан ханлыкларының чиге булып исәпләнгән һәм халыкның үзара бәйләнешләрендә зур роль уйнаган. Бу җәһәттән Һиндстанга чыгу мөмкинлеген бирә торган Себер — Идел буе юлыннан файдаланганнар. Мондагы жирләр XVII-XVIII гасырларда Россия дәүләте территориясенә кертелгәч, халыкның бирегә күпләп күченеп килүе күзәтелә.

Татарстан жирендә 500ләп «бура культурасы» һәйкәлләре булуы ачыкланды. Шуларның күбесе — Кама аръягында. ТР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор, остазым А.Халиков сүзләренә караганда, алар безгә көньяктан килгән. Күп кенә галимнәр бу һәйкәлләрнең безнең эрага кадәр XV-XVI гасырларга каравын әйтә. Аларның безнең эрага кадәр VIII-IX гасырларга бәйле булуын раслаучылар да бар.

Кабиләләр игенчелек-терлекчелек белән шөгыльләнгән, мөгезле эре терлек, кәҗә, сарык асраганнар. Монда табылган бөртек тарту җайланмалары, ураклар эш кораллары булган.

Тимер чорында дала, урман-дала киңлекләрендә яшәүчеләр күчмә тормыш алып барганнар. Алардан соң курган-каберлекләр генә калган. Кабиләләрнең тормыш-яшәү рәвешен шуларны казып кына белә алабыз.

V-VIII гасырларда Идел-Урал территориясендә төрле культураларның һәм этник төркемнәрнең үзара бәйләнешләре күзәтелә. VII-VIII гасырларда Урта Идел территориясенә элекке болгар кабиләләре үтеп керә. Алар чыгышлары белән төрки, угыр, көнчыгыш фин булган жирле кабиләләрне үзләре тирәсенә берләштерә башлый. IX гасыр ахыры — X гасыр башында Болгар дәүләте төзелә һәм Идел-Уралда беренче мөселман цивилизациясе барлыкка килә. Идел Болгарстаны составына Кама аръягы һәм Көньяк Урал жирләре керә. Лениногорск районы Сарабиккол авылы янында шул чорның байтак һәйкәлләре, шул исәптән 3 борынгы шәһәр, 20 авыл урыны билгеле.

1236 елда Болгар монгол гаскәрләре тарафыннан басып алына һәм Алтын Урда барлыкка килә. Алтын Урда чорына караган әйберләр Бөгелмә, Әлмәт, Ютазы районнарында табылды. Хәлбуки, алар Лениногорск районы территориясендә дә булырга тиеш, шәт, киләчәктә табылыр.

XIV гасыр ахыры — XV гасыр башында Алтын Урда таркала, аның территориясендә берничә ханлык, шул исәптән Казан ханлыгы барлыкка килә. Тарихи чыганакларга

караганда, Кама аръягындагы җирләрнең бер өлеше — аңа, көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш өлеше Нугай Урдасына керә. Без күздә тоткан территориядә нигездә нугай кабиләләре яши. Алар күчмә тормыш алып бара, терлекчелек белән шөгыльләнә. Ныгытылган стационарлары булса да, бер урында озак тормаганнар.

1708 елда Казан губерниясе төзелә. Аңа Бөгелмә өязе составында хәзерге Лениногорск җирләре дә керә. XVIII гасырда шушы территориядә барлыкка килгән авыллар: Зәй-Каратай (1720-1740 елларда нигез салына), Федотовка (Ана авылы, 1720-1740), Урмышлы (1720-1740), Юлтимер (1720-1740), Куакбаш (1730), Түбән Чыршылы (1730), Иске Шөгер (1730), Иске Иштирәк (1730), Иске Куак (1730), Сугышлы (1730), Туктар-Урдалы (1730), Медведка (1732), Иске Писмән (1738), Сарабиккол (Әби авылы, 1746 елдан билгеле), Кирлегәч (1746 елда нигез салына), Керкәле (1748 елдан билгеле), Кузай (XVIII гасыр уртасында нигез салына), Спиридоновка (1750), Яңа Иштирәк (1760-1780), Чүти (1760-1780), Бәкер (1760-1780), Глазово (1760), Тимәш (1762), Яңа Чыршылы (1770), Яңа Үтәмеш (1770), Югары Чыршылы (1785 елдан билгеле), Мөэмин-Каратай (1785), Мордовская Ивановка (1785), Мордовская Кармалка (1785), Новое Серёжкино (1785), Алешкино (1785), Түбән Писмән (1795 елда нигез салына). XIX гасырда барлыкка килгән авыллар: Сходнево-Чертанла (гасыр башында нигез салына), Ивановка (гасырның беренче чирегендә), Савочкино (гасырның беренче чирегендә), Дурасово (гасырның беренче яртысында), Михайловка (1812), Горкино (1820), Иске Варваринка (1830), Сергеевка (1830), Кузьминовка (1830), Вәли авылы (1840) Петропавловка (1850).

Шушы торак пунктларның берсе — Түбән Писмәннән (монда 1858 елда 1416 кеше яши) Лениногорск шәһәренең тарихы башлана.

1860 елга кадәр мондагы халык түбәндәге категорияләргә бүленә: Алешкино, Бәкер, Югары Чыршылы, Ивановка, Керкәле, Кузай, Кузьминовка, Медведка, Мордовская Ивановка, Мордовская Кармалка, Түбән Писмән, Яңа Серёжкино, Савочкино, Сергеевка, Спиридоновка, Иске Куак, Сходнево-Чертанла, Тимәш авылларында — дәүләт крестьяннары; Зәй-Каратай, Кирлегәч, Куакбаш, Яңа Иштирәк, Сарабиккол, Иске Шөгер, Иске Иштирәк, Сугышлы, Туктар-Урдалыда — типтәрләр һәм дәүләт крестьяннары; Мөэмин-Каратайда — башкортлар һәм дәүләт крестьяннары; Түбән Чыршылыда — башкортлар, типтәрләр һәм дәүләт крестьяннары; Глазово, Горкино, Дурасово, Иске Варваринкада — алпавыт крестьяннары; Яңа Үтәмештә — типтәрләр; Петропавловка, Михайловкада — удель крестьяннары; Иске Писмәндә — отставкадагы солдатлар (1820 елда алар дәүләт крестьяннары исәбенә кертелә).

1860 еллардагы аграр реформалар Россия икътисады, беренче чиратта, авыл хуҗалыгы үсешенә зур этәргеч ясый. Җирдән файдалану мөмкинлеге арта. XIX гасырның икенче яртысында — XX гасыр башында бу төбәктә халык санының кискен үсүе күзәтелә. Авыл халкы да күпкә арта. Җир җитми башлый. Урманнарны кисәләр. Агачлар үсеп утырган яшеллек мәйданының байтак өлеше иген кырларына әверелә.

Халыкның төп өлеше игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Авылы-авылы белән башка һөнәрләрне үзләштерүчеләр дә була. Мәсәлән, Бәкер халкы умартачылык белән шөгыльләнә. Югары Чыршылыда яшәүчеләр — итек басучылар, балта осталары. Горкинолылар известь, алебастр алу өчен таш вата. Зәй-Каратай халкы сәүдә эшенә маһир. Куакбашта сатарга көл җыялар, Түбән Писмәндә он тарталар, Сарабикколда кием тегәләр, чабата үрәләр. Спиридоновкада шулай ук он тарталар, базарга тозлы балык чыгаралар. Сугышлылар Бөгелмә өязе авылларында йорт салып йөри. Иске Куак кешеләре җирләрен күрше-тирә авылларда яшәүче татарларга арендага биреп тора.

XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында тагын берничә торак пункт барлыкка килә. Болар — Яңа Елхово (1895 елда нигез салына), Яңа Варваринка (1905), Аккүл (1910), Александровка (1910). 1883 елда Түбән Писмән волость үзәгенә әйләнә. Монда чиркәү, аның каршында мәктәп, хәрби хезмәткә чакыру урыны, станция, земство мәктәбе, 8 су тегермәне була. 1910 елда халкы — 1959 кеше.

«Жир турында декрет» нигезендә кырлар, урманнар, болыннар, туфрак эшкәртү кораллары крестьяннарга бүлеп бирелә. Элек хосусый милек булып саналган җирләргә крестьяннар күченеп килеп утыралар. Авыл хуҗалыгы кооперацияләре, коммуналар һәм, әлбәттә, яна торак пунктлар барлыкка килә. Яна Шөгер (1919 елда нигез салына), Марьяновка (1920), Тукмак (1920), Үзбәк (1920), Карагай (1921), Воздвиженка (1922), Восход (1922), Мичурин исемендәге бистә (1923), Болгар (1924), Үрнәк-Кумәк (1924), Бохар (1924), Алтай (1924-1925), Югары Каран (1927), Ялтау (1928), Чиялетау (1929), Яшеллек (1940), Урманасты (1954) — болар XX гасыр башында һәм уртасында барлыкка килгән торак пунктлар.

Хәзерге Лениногорск районы җирләре 1920-1930 елларда — ТАССРның Бөгелмә кантонына, 1930 — 1935 елларда Бөгелмә һәм Шөгер районнарына керә. 1935 елның 10 февралендә Яна Писмән районы оештырыла. 1940 елда районның мәйданы — 889 квадрат километр, халкы — 22,8 мең кеше, торак пунктлары саны — 55, авыл советлары — 16. 1955 елда Яна Писмән бистәсе Лениногорск шәһәренә әверелә. 1959 елның 12 октябрендә ана Шөгер районын кушалар. ТАССРның административ берәмлекләрен эреләндерү максатында 1963 елның 1 февралендә Лениногорск районы территориясенә тагын элекке Беренче Май районының бер өлеше кертелә. Шулай итеп район территориясенең мәйданы — 2936 квадрат километрга, халкы 78,8 мең кешегә житә. 1965 елда ТАССРның административ-территориаль бүленешенә үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Лениногорск районы территориясенен мәйданы — 1827 квадрат километрга, халкы 41,8 мең кешегә кала. Торак пунктларының саны — 79, авыл советлары — 17.

1948 елда Ромашкино нефть чыганагының ачылуы бу төбәкнең үсеш тарихын тамырдан үзгәртә. 1950 елда «Бөгелмәнефть», «Татбурнефть» трестлары барлыкка килә. Халык бу якларга эшкә күпләп агыла. Лениногорск нефть промышленностенда иң эре үзәкләрнең берсенә әверелә. Бу җәһәттән без иң әүвәл «Лениногорскнефть» идарәсе, «Татнефть Лениногорскбурнефть» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, пластларның нефть бирү мөмкинлеген арттыру һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау идарәсе, «Тампонаж эшләре» идарәсе, «Геотех» акционерлык җәмгыятьләре эшчәнлеген күздә тотабыз.

Лениногорск районының тарихи-мәдәни мирасы — халкыбыз, Татарстаныбыз тарихи-мәдәни мирасының бер өлеше ул. Киләчәктә ул тагын да ныклап өйрәнелер, яңадан-яңа ачышлар һәм кыйммәтле табышлар белән баетылыр.

**Рафаэль ВӘЛИЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать*
*университеты проректоры,*
*ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни*
*һәм табигый мирасны саклау оешмасының*
*Россия милли комитеты рәисе урынбасары,*
*Һәйкәлләрне һәм истәлекле урыннарны саклау*
*Халыкара советының Россия комиссиясе*
*вице-президенты*

# ГОМЕРЕМНЕҢ ЧИШМӘ БАШЫ — ШӨГЕРЕМ

Данлыклы Шөгер. Безнең өчен аннан да якынрак, аннан да кадерлерәк җир юк. Ул — туган җир, безне тудырган һәм дөньяга чыгарган җир. Аның моңнары, аның сагышлары, кичерешләре һәммәбезнең күңеленә сеңгәндер. Туган илгә, халкыбызга, телебезгә мөнәсәбәтләр шунда яралган. Милли рухның нигезе шунда салынган.

Хәтерлим, бабабыз Шәйхетдин шушы җирнең никадәр шифалы икәнлеге турында сөйли иде. Имештер, монда яшәгән кешеләрнең озын гомерле булуы шушы җирнең изгелегеннән. Мондагы кешеләр чиргә бирешмиләр. Аларга җир үзе дәва һәм шифа биреп тора. Шушыларны сөйли-сөйли, бакчабыз кырыенда челтерәп аккан инешебезгә тәрәлеп үскән калын әрекмәннәрнең тамырларын иске чалгыдан ясаган үткен пычагы белән чистартыр, аны инеш суында чайкап алыр иде дә, мә әле, улым, ашап җибәр, моннан да файдалы ризык юк, дип кулыбызга тоттырыр иде. Шуннан соң инешебезнең никадәр суы Шушма елгасы аша Кама вә Иделгә, шушы дәрьялар аша Каспийга аккандыр. Инде шул бабабызның дөнья куйганына да шактый вакыт үтте. Атасы Таһертдин һәм без белгән җиде бабабыз белән бер зиратка җирләнде.

Шөгер — ул батырлар җире. Моннан Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган җиде каһарман чыккан. Ул халкыбызга күп галимнәр, язучылар, шагыйрьләр үстереп биргән җир. Татар нефтенә юл ачкан җир дә — Шөгер.

Аңа багышланып китаплар языла, җырлар туа. Аңа дан җырлау дәвам итә. Шулай булырга тиеш тә. Чөнки тирән тамырлы, мәңгелек җир ул — безнең Шөгер.

Әйе, Шөгер безнең күңелебез түрендә. Тик шулай да, әгәр дә Әлмәт турында фикеремне белдермәсәм, дөрес булмас иде. Безне дөньяга китереп, үстергән, аякка бастырып, тормышка юл ачкан әниебез Әминә Габдулкаюм кызына карата гаделсезлек булыр иде бу. Ул — изге ил аналарының безнең өчен иң якыны. Телебезне дә ул ачты, туган халкыбызга карата мәхәббәт хисләрен дә ул уятты. Мәктәпкәчә үк укырга да ул өйрәтте, яшәү тәртипләрен дә аның аша белдек. Яхшылыкның яманлыктан өстен булырга тиешлеген дә безгә ул сеңдерде. Ул — безнең беренче укытучыбыз.

Әни Әлмәттә туып үскән. Атасы, безнең бабабыз Габделкаюм, хатыны үлгәч, 65 яшендә икенче мәртәбә күрше Түбән Мактама авылы кешесе Хәмидулла кызы Бибигайшәгә өйләнә. Алар икесе биш бала үстерәләр. Әниебез дөньяга килгәндә, аңа 83 яшь була. Ике елдан соң әниебезнең сеңлесе Галимә апабыз дөньяга килгән. Бабай балаларын аякка бастырып, аталык вазифаларын тулысы белән үтәгәннән соң, йөз яшен тутырып, дөнья куя.

Анабыз әтиебез Таһиров Риза Шәйхетдин улы белән Шөгердә кавыша. Аны Бөгелмә шәһәрендәге ике баскычлы педагогик юнәлештәге мәктәпне тәмамлаганнан соң, яңа оешкан Шөгер районына укытучы итеп җибәрәләр. Анда Бөгелмәдә Һади Атласи, Фазыл Туйкин кебек галим-педагоглар ныклы белем биргәннәр. Ул Шөгерне чын күңеле белән ярата, шушында ныгый, тәҗрибәле педагог булып өлгерә. Мондагы укытучыларын, аларның изгелекләрен гомере буе онытмый яшәде.

Әниебез үзенең гомерлек дусты, Бөгелмәдәге сабакташы Сәҗидә апа белән булган бер вакыйганы кат-кат сөйли иде. Аның турында язып чыкканы да булды.

Бервакыт мәктәпнең икенче катыннан аска төшеп барганда, Сәҗидә апага Һади Атласи очрый һәм аңардан: «Сәҗидә, син намаз укыйсыңмы?» — дип сорый. Җавабын да көтеп тормастан тиз-тиз генә «укы, укы», дигән сүзләрен әйтеп, үз юлы белән китеп бара. Язмыш Сәҗидә апаны да Шөгергә китерә. Алар икесе дә остазларының васыятен онытмадылар, гомерләре буе динебезгә, милләтебезгә турылыклы булып яшәделәр.

Ул елларны гореф-гадәтләрне саклау авыр булса да, халык татарча яшәвен туктатмады. Шөгернең мәчете беркайчан да ябылмады. Дөрес, анда йөрү, бигрәк тә яшьләр өчен мөмкин түгел иде. Шунлыктан интеллигенция вәкилләре, укытучылар намазларын кача-поса гына укыдылар. Балаларга кайбер догаларны әбиләре өйрәтә иде. Безгә

догаларны әниебезнең әнисе (без аны барыбыз да әнкәй дип йөртә идек) өйрәтә иде. «Бисмилла» әйтеп ашагыз, ашап туйгач, дога кылыгыз, дип әйтә торган иде мәрхүмә.

Әни әтиебез Риза Шәйхетдин улы белән гаилә корып җибәрәләр, гөрләтеп яши башлыйлар. Безне, Дамир абыебызны, мине һәм энебез Энгелне, дөньяга китерәләр. Әтиебез авылда колхоз оештыручы да, авыл советы рәисе булып та эшли. Гомумән, ул бик актив кеше була. Җыелышларда ул сөйләгәнне таң калып тыңлый торган булалар. Ул — романтик рухлы, җыр-моңга гашыйк кеше. Үзе дә матур итеп җырлый торган булган.

Әниебез Казан педагогия институтында читтән торып укуын дәвам иттерә. Бер елны аның сессиядән кайтуына әтиебез йорт өлгертеп куя.



*Сулдан уңга: әтиебез кулында мин, уртада әниебез итәгендә энебез Энгел, уң кырыйда әниебезнең бертуган Фатыйх абыйсы кочаклаган Дамир абыебыз.*

Ләкин шушы рәвештәге матур тормышка 1941 елның 22 июнендә башланган сугыш кискен үзгәреш кертә. Авылыбызның затлы ирләрен сугыш кырлары йота тора. Яшәүне төп дәвам иттерүчеләр булып хатын-кызлар һәм өлгерер-өлгермәс үсмерләр кала. Бу язмыш безне дә читләтеп үтмәде.

1941 елны әти фронтка китә. Аны, гомумән, күпләгән авылдашларыбызны озаткан көн бүгенгедәй күз алдымда.

Әти абыебыз Дамирны, мине җитәкләп кибеткә алып керә һәм безгә мандолина сатып алып бирә: «Мин кайтканчы уйнарга өйрәнеп куегыз»! Без аның бу васыятен үтәдек. Абыебыз да, шушы көнне өйдә бабасы янында калган бер яшьлек Энгел дә үсеп җиткәч, мандолинада уйнарга өйрәндек.

Менә китүчеләр, аларны Келәүле стансасына кадәр озата баручылар кибет каршындагы олауларга төяләләр. Әниебез дә әтине озата бара. Арбалар кузгала. Без елыйбыз. Әтиебезнең бертуган абыйсы Кыям абзый безне юата: «Еламагыз, балалар, еламагыз», — ди, ләкин үзенең дә күзеннән яшь ага. Озакламастан үзе дә китте һәм шул китүеннән әйләнеп кайтмады.

Булачак хәләл җефетем Люциянең атасы Мөгыйн Шакирҗан улы Шәрипов Шөгер районы барлыкка килгәч, аның «Тоташ колхоз» исемле газетасының редакторы була. 1941 елны сугыш афәте башлангач, фронтка китә. Анда ул политработник булып, капитан дәрәҗәсенә ирешә. Воронеж тирәсендәге канлы сугышларның берсендә, дошманга каршы атакага күтәрелеп, «ур-ра, фашистларга үлем», дип кычкырып, сугышчыларга дәрт һәм дәрман биреп барганда, фашист пулясы аның гомерен өзә. Шулай да атака уңышлы була, дошман җиңелә һәм чигенергә мәҗбүр була. Мөгыйн Шакирҗан улы Шәрипов шушы батырлыгы өчен югары дәүләт бүләгенә тәкъдим ителә.

Мин Шөгер дим, аның тауларын, урманнарын мактыйм. Ләкин Шөгер ул бер авыл гына түгел. Сүз Шөгер яклары, аның тирә-ягындагы кайчандыр тәгәл бер районны тәшкил иткән авыллар турында бара. Шушы районга кергән Түбән Чыршылы авылы да күнелемә ныклап урнашкан. Революциягә кадәр бу авылда тирә-якта дан тоткан мәдрәсә эшләп килгән. Анда күпмедер вакыт Ризаэтдин Фәхретдинов та эшләгән.

Сугыш башлангач, әниебезне ул вакыттагы Шөгер районының иң зур авылларыннан булган Түбән Чыршылы авылына мәктәп директоры итеп билгелиләр. Без сугыш елларын шунда үткәрдек. Мәктәптә — 500дән артык бала. Барысының да диярлек әтиләре һәм туганнары фронтта. Ятимлек, ачлы-туклы тормыш...

Әнине партия оешмасы секретаре итеп тә сайлыйлар. Аңа халык арасында агитация эшләрен оештыру да йөкләнә. Укытучыларның барысы да аның тирәсендә. Барысы да — агитаторлар. Алай гына түгел, үзешчән сәнгатьтә дә шулар ук. Клубтамы, колхоз кырларындамы — халык булган һәммә җирдә алар. Концертлар оештыралар, фронттагы һәм илдәге хәлләр белән таныштыралар. Халыкка яшәү көче биреп торалар.

Укытучылар үз көчләре белән «Ак калфак», «Наёмщик», «Талир тәнкә» кебек пьесаларны куялар. Ирләр рольләрен дә хатын-кызлар башкара.

Укытучылар печән өстендә дә, уракта да колхозчылар белән. Ял вакытларында фронттан килгән хатларны уку, кемнендер төшләрен юрау... Жыр да була. Елаулар да өзелми.

Без — шул укытучыларның балалары да, сәхнәгә менеп жырлый һәм декламацияләр сөйли идек.

Чыршылының да табигате матур. Шөгердәге кебек таулар. Ике Чыршылыны, Түбәнен һәм Югарысын, Куак суы бүлеп тора. Бу авыллар бер булып яши иде.

Мин шушы авылда мәктәпкәчә үк хәреф танырга, укырга өйрәндем. Беренче класста да шушы авылда укыдым. Мине укыткан Мөнәвәрә апа Чапаеваны, Зифа апа Гыйлажеваны һаман да оныта алмыйм. Мөнәвәрә апа инде гүр иясе, урыны жәннәттә булсын. Зифа апа әле исән. Ел саен Чыршылыда очрашып, хәтер яңартабыз.

Әтиебез турында да сөйләп китү урынлы булыр. Ул һөнәре буенча укытучы булмаса да, тормышта һәрвакыт укытучы булып яшәгән. Шөгердәге беренче колхоз да, авыл советы да — аның тынгысыз хезмәте нәтижәләре. Аның жыелышлардагы чыгышларын таң калып тыңлый торган булалар. Ә бит ул вакыттагы сүзен үтемле, һәммә кешене ышандырырдай булмаса, уңышсызлыкка очравыңны көт тә тор, чөнки кискен борылыш еллары бу. Заман житәкчеләреннән укытучы-педагог, психолог булу да таләп ителгән.

Әти чын педагогларга хас хисле, күңеле жыр-моң белән сугарылган кеше булган. Аның дары исе сеңгән хатларыннан да сафлык, табигатькә соклану хисләре бөркеп тора. Фронттан, ике сугыш арасында язган хатыннан өзек китерми булдыра алмыйм.

*«Әминә, менә бүген 9 май. Күрсәң иде мондагы урманның, кырларның матурлыгын! Урман тулы төрле чәчәкләр, ямь-яшел чирәм. Иртән сызылып тан атканда, күкеләр кычкыра, сандугачлар сайрый. Кызарып кояш чыга, урмандагы чәчәкләрне коча. Әкрен искән жил туган илебез ягына саф һава алып китә. Жылы жилләр чәчәк исләрен тарата. Кичләрен күлдәге бакалар да үзләренә хас моң белән кычкыра. Барлык кошлар төнге ялга кадәр ашыга-ашыга үзләренең моңнарын суза.*

*Шул вакытта күңелдә кузгалган ике төрле ашыгыч уй шундый матурлыктан файдаланырга ирек бирми: берсе, безгә һәркөнне кайгы-хәсрәт китерүче немец-дошманны галәттәгечә үтереп тора алмыйм (озакламый безгә аларның ояларын туздырырга приказ килеп житәр), икенчедән, сезнең белән бергә булмау. Юкса кайгысыз булганда, тирә-якта урман-яланнар күп, һава яхшы, су керә торган жирләр бар.*

*Элеккегечә жиләккә бардым. Андый жиләкне күргәнем юк иде. Монда жир жиләге юк икән, гел каен жиләге, кызыл япма япкан кебек, бер кеше дә жыймаган. Башта таптамыйча-нитмичә сокланып карап тордым. Мин әйтәм, хәзер шушы урынга Әминә белән балаларны китереп куясы иде дә, сөйләшә-сөйләшә, жиләк жыясы иде, дим...*

*Ярый, Әминә, 30-35 көннән бәрәңгегез өлгереп, әкренләп ашый башларсыз. Бәрәнге ашый башладык дигән хәбәрегезне ишетсәм, жаным беркадәр тынычланыр иде. Кәжәгез торамы, балаларга әзрәк сөт бирә аламы? Әминә, көзгә дошманнарны тар-мар иткәч, кайта башларбыз. Тизрәк күрешүне теләп, сагынып, сәлам белән,*

*Риза. 9 май, 1944 ел».*

Бу аның соңгы хаты. 1944 елның 26 ноябрендә Латвиядә фашистларга каршы барган каты сугышларда рота командиры Риза Таһиров һәлак була.

Безгә аның Ауцк өязенең Звани хуторында жирләнгәнлеге турында хәбәр килде.

1967 елның август аенда, аның каберен эзләп, Ауцк шәһәренә юл тоттым. Автобустагы латышлар үз милләтләреннән булмаган кешенең илләрендә ни эшләп йөрүе белән кызыксыналар. Мин аларга сәфәремнең максатын сөйләп бирдем. Алар миңа теләктәшлек белдерделәр, автобустан төшкәндә, жылы саубуллаштылар, уңышлар теләделәр.

Тик менә Ауцкта бу шәһәрнең беркайчан да өяз үзәге булмаганлыгы ачыкланды. Анда миңа Ригага барып, республика хәрби комиссариатыннан тиешле мәгълүмат алырга киңәш иттеләр. Кайсы полковникка мөрәжәгать итәргә икәнлеген дә әйттеләр.

Шуннан соң мин Ригага бара торган автобуска кердем. Күрәм, анда минем теге юлдашларым. Алар юлым уңмаганга бик нык борчылдылар.

Автобусыбыз Ригага чаба. Кинәт күкне кучкыл болытлар каплап, яңгыр коя башлады. Алда берни күренми, автобусыбыз туктады. Мин борчылам: эш вакыты

беткәнче военкоматка барып житә алырмынмы икән? Минем бит кайту өчен кичке поездга алынган билетым кесәмдә. Ана кадәр эшләремне башкарып өлгерергә кирәк. Миннән дә ныграк юлдашларым борчыла. Аларның берсе шофёр янына килде дә хәлне аңлатты, бернигә дә карамастан, юлны дәвам иттерүен сорады. Мона башка пассажирлар да дәррәү кушылды. Автобусыбыз яңгыр киртәсен ерып, юлын дәвам итә. Ә көн ахырына якынлаша. Мин ул военкоматны кайчан һәм ничек табармын икән? Монда да юлдашларым ярдәмгә килде. Алар шофёрдан мине военкоматка кадәр илтүне сорадылар. Ул аларның сүзен тыңлап, автобусны военкоматның ишеге төбенә кадәр китереп куйды. Минем шушы латыш дусларның изге гамәлен һич тә онытасым юк.

Сәгать кичке алты. Военкоматка кереп барам. Каршыма өйләренә кайтырга чыккан офицерлар очрый. Мин аларның һәрберсен диярлек туктатып, аның мина исеме мәгълүм кеше түгелме икәнлеген сорашам. Шуларның берсе нәкъ менә кирәк кеше булып чыкты. Гафу үтенеп, йомышымны аңлаттым. Шуннан соң ул хәлемне аңлап, мине тиз генә үз бүлмәсенә алып керде. Тиешле документларны бик тиз тапты. Әтиебезнең җәсәде Салдус шәһәрендәге туганнар каберлегенә күчереп жирләнгәнлеге ачыкланды.

Берничә елдан соң мин шул калага барып, туганнар каберендә жирләнгәннәрнең исемлегеннән әтиебезнең исем-фамилиясен таптым.

1987 елны без энем Энгел белән әниебезне шунда алып бардык. Әни Коръән сүрәләре укыды. Әтиебез белән кавышты да, хушлашты да. Кабер туфрагын Казанга алып кайтты һәм шуна гөл утыртып үстерде.

Инде янә Шөгер хатирәләрен дәвам иттерәм.

Сугыштан соң без янә анда кайттык. Шушма буенда, инешебез кырыенда. Иске Шөгер мәктәбендә безне Асия апа Гыйльметдинова укытты. Аның дәресләрен, бигрәк тә жинел ысул белән тапкырлау таблицасын өйрәтүен һаман да оныта алмыйм. Алай гына да түгел, үзем дә шактый кешене, шул исәптән улларыбызны да, шул ысулга өйрәттем. Әйе, Асия апа безне күп нәрсәләргә өйрәтте. Мин анардан матур язарга гына өйрәнә алмадым һәм гомерем буе интектем. Язуымны башкалар түгел, кайвакыт үзем дә танымыйм. Шунлыктан машинканы, аннан соң компьютерны үзләштерергә туры килде.

Әйткәнемчә, безнең беренче укытучыбыз — әниебез. Аны укучылар да, укытучылар да, гади халык та бик тә ярата иде. Аның эшләгән елларын һаман да сагынып сөйләүчеләр бар әле.

Тормыш юлы жиңелләрдән булмаса да, аның язмышы бәхетле. Чөнки башына төшкән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне, берсеннән-берсе зур югалтуларны батырларча жиңә белгән зат иде ул. Ата-анасыннан васыять итеп алган «сабыр төбе — сары алтын» дигән сүзләр аның яшәү кагыйдәсе булды. Аны безгә дә васыять итеп калдырды.

Ул чын мәгънәсендә кешелекле зат иде. Гомере буе берәүдән дә көнләшмәде, киресенчә, кеше шатлыгына шатланып яшәде, беркайчан да беркем турында да начар сүз әйтмәде, берәүгә дә рәнжемәде, берәүне дә рәнжетмәде, берәүне дә каргамады, берәүгә дә ачу сакламады, берәүгә дә начарлык теләмәде. Ул һәрвакыт безнең өчен ихласлык үрнәге булды.

Без Шөгер балалары тигез ятимлектә үстек. Урам тулы бала, берсенең дә әтиләре юк. Шулай да, балачак хатирәләре күбрәк романтика белән бәйле.

Шөгер малайлары китап укырга хирыс иде. Без — абыем Дамир һәм тагын 4-5 малай, атна саен тау бите буйлап битум заводы бистәсендәге китапханәгә йөри идек. Анда татарча китаплар күп иде. Аларның күбесе — латин шрифтында. Безнең мәктәптә инглиз теле дәресләре булганлыктан, латиницадагы бу китапларга бик тиз ияләштек. Аларны өйгә бирәләр иде. Бер-беребезнең китапларын алмашып укый идек.

Без үскән заманда, кая барсаң да, рус телен белү кирәк иде. Аны белмәсәң, югары уку йортларына керү мөмкин түгел. Шунлыктан әни безне русча да укытты. Татар мәктәбендә өч классны тәмамлагач, ул мине район үзәгендәге рус мәктәбенә урнаштырды. Шуңа кадәр мин русча белми идем. Ничек өйрәнүемне хәтерләмим. Күрәсең, ул минем өчен әллә ни авыр булмагандыр.

Бу мәктәптә дә безне бик яхшы педагоглар укытты. Аларның берсе — Николай Михайлович Дементьев. Искиткеч таләпчән. Әллә ни кызыклы булмаган рус грамматикасын аңлаешлы һәм мавыктыргыч итеп аңлата белә иде ул.

Әнием белән бәйле хатирәләрне яңарткан, Әлмәтне искә алган идем. Бабабызның

вафатыннан соң тормыш авырлыгы безне тагын Әлмәткә китерде. Әтиебез һәм аның туганнарының берсе дә сугыштан әйләнеп кайтмагач, әниебезнең туганнары безнең шунда күчүебезне теләделәр. Сигезенче класска шушында бардым. Унны шушында тәмамладым. Әниебез анда да, Шөгердәге кебек үк, РОНО инспекторы булып эшләде.

Әтиебез салып калдырган алты почмаклы йортны әниебезнең бер туганы — сугыш афәтеннән исән-имин кайткан мәрхәмәтле җан — Фатыйх абыебыз үз йорты каршысындагы бер буш урынга күчереп салды.

Әлмәт — район үзәге. Ул — ямьле Зәй буенда урнашкан саф татар авылы. Аның тирәсе тау, урманнар. Зәйнең аръягында — куе әрәмәлек. Әрәмәлегендә — шомырт, карлыган. Урманында — җир җиләге, бөрлегән. Болар җыеп бетерерлек түгел. Без моңа кадәр белгән Әлмәт шундый иде.

Монда нефть табылу сәбәпле, авыл руслаша башлады. Төрле яклардан килгән халык өчен бараклар һәм йортлар төзелде. Берничә рус мәктәбе ачылды. Кыскасы, Әлмәт русча сөйләшә башлаган еллар бу.

Хрущёв заманындагы амнистия, монда урнашкан ике хезмәт хәрби полкын таратып, солдатларын Әлмәттә калдыру, ирекле тормышка күчерү аркасында үтереш, кеше кыйнау-талау гамәлләре бермә-бер артты.

Ләкин ничек кенә булмасын, тормыш дәвам итә. Тиздән нефтьчеләрдә эшли башлаган абыебыз Дамирны хәрби хезмәткә алдылар. Ул Германиянең Потсдам шәһәрендә хезмәт итте. Частьларында «зав. секретным производством» вазифасын башкарды. Шушы җаваплы урынга урнашырга аның пөхтәлеге, тырышлыгы, матур итеп яза белүе ярдәм иткәндер.

Кече энебез Энгел шулай ук укуын дәвам иттерде. Туганнарыбыз белән аралашып гөрләшеп яши башладык. Әниебезнең олы туганы Хафиз абзый, аның хәләл җефете Сәрвәр апа, аларның берсеннән-берсе чибәр кызлары Шаффа, Шифа, Флёра белән озак еллар бергә булдык. Абзыебыз бик тә тапкыр кеше иде. Менә аның тормышыннан бер кызыклы факт.

Колхозлашу елларында кулаклар исемлегенә кертелгәнен белгәч, абзыебыз гаиләсе белән Урта Азиягә китә. Эш кирәк, ә ул юк. Үзбәкләр аннан мич чыгара беләсеңме, дип сорыйлар. Нишләсен абзый, башка җай юк, «беләм», дип җавап бирергә мәҗбүр була.

Гомерендә бу эшне эшләгәне булмаган абзыйның беренче миче тартмый, төтенли. Моны күреп торган үзбәкләр, аны «алдакчы татар» дип тирги башлыйлар. Абзый югалып калмый: «Беләсезме, мин бит мичне Европада чыгара идем, ә монда Азия, һава башка», — ди. Һәм шунда ук хатасын аңлап, төзәтә. Мич дөрләп яна башлый. Үзбәкләр риза, көлешәләр. Ә абзый 20 елдан соң иленә шушы һөнәрне үзләштереп кайта.

Инде телгә алынган Фатыйх абзыебыз. Ул — сәнәкчеләр фетнәсен оештыручыларның берсе. Совет власте аны шуның өчен гомер буе эзәрлекли. 1921-1922 елларда авылдашларын ачлыктан коткару максаты белән, Себергә барып, аннан зур авырлыклар белән икмәк алып кайта. Халкыбыз өчен шундый изге гамәлләр кылган кеше булуына да карамастан, аны партиядән чыгаралар. Фронтта аны партиягә тагын кабул итәләр. Тагын чыгаралар. Ләкин үзе гомере буе оптимист булды. Абзыебыз хәләл җефете Рабига абыстай белән дүрт бала үстереп, аларны зур тормыш юлына чыгардылар. Без алар белән көн саен аралашып яшәдек. Сальма апабыз, Рубин абый, Луиза туганыбыз һәм Зилә сеңелкәш белән һәрвакыт диярлек бергә булдык.

Әниебезнең бертуганы Галимә апабыз бигрәк тә йомшак күңелле, туган җанлы, ярдәмчел кеше иде. Әниебез командировкага киткән вакытларда безне үз балалары кебек сыендыра иде.

Монда да укытучыларыбыз яхшы. Мирза Каюмович Таһиров географиядән керә иде. Шушы тәҗрибәле, тирән белемле кеше безгә бик күп тарихи мәгълүматлар да бирде. Җае белән бездә милли хисләрне дә уята белә иде. Тарих фәнен Зоя Анатольевна Кашаева укытты. Бу искиткеч кешелекле мөлаем ханым да безгә шулай ук бик күп тарихи мәгълүматлар ирештерде. Ул бүген дә исән, үзенең туган җире Тәтеш шәһәрендә гомер кичерә.

Классыбыз төрле милләт балаларыннан тупланган. Монда татар, рус, мукшы һ.б. бар. Җан дустым — Разим Ибраһимов. Без аның белән һәрвакыт бергә. Бергә мәктәпкә барабыз, бергә кайтабыз, рәхәтләнеп су коенабыз. Икебез дә җырларга

ярата идек. Өебез баскычына утырып, татар, рус җырларын җырлыйбыз. Күп вакыт йә аларда, йә бездә кунабыз. Серләребез уртак.

Мәктәптән соң ул гади шофёр булып эшләде. Мин армия хезмәтеннән кайтып, университетта укый башлагач, аның да шунда килүен теләдем. Үзенең дә укыйсы килде. Анда керү өчен документлар да хәстәрләдек. Ләкин фаҗигале язмыш бу планыбызны чәлпәрәмә китерде. 1963 елның 24 июлендә аның бензовозы авариягә эләгеп, дөрләп яна башлый һәм шартлый. Дустым шунда һәлак була.

Изил Йосыпов — искиткеч тырыш, миннән аермалы буларак, бик пөхтә кеше. Мин сызымны яратмыйм. Ә ул, киресенчә, аны, гомумән, төгәл фәннәрне ярата иде. Һәм мине, көчләп диярлек, линейка, циркуль белән эш итәргә өйрәтте. Дөрес, бу өлкәдә әллә кая китә алмадым. Шулай да бу фәннән начар билгеләр дә алмадым.

Без аның белән дә сердәшләр идек. Ул да Разим дустым кебек сер саклый торган, гомумән, дуслыкка тугрылыклы җан иде. Мәктәптән соң Уфа нефть институтын тәмамлап, бик тиз фән юлына кереп китте. Баштарак — кандидатлык, аннары докторлык диссертацияләрен яклады. Бөгелмәдәге ТатНИПИ нефть институтының директоры дәрәҗәсенә иреште, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайланды. Ни кызганыч, бүген ул да юк инде арабызда.

Дусларымның тагын берсе — Нур Гарипов. Нур мәктәптән соң Рязаньда хәрби училище тәмамлап, бераз вакыт армиядә хезмәт иткәннән соң, Мәскәүдә Бауман исемендәге Югары техник училищеда белем алды. Ул шунда укыган елларда мин, Казан университетының аспиранты буларак, Мәскәүгә архивларда эшләргә килә идем. Үзәк хәрби тарих архивында /ЦГВИА/ бик еш утырырга туры килә иде. Ә ул архив шул институтның тулай торагы урнашкан Бауман урамында. Мин анда бик еш керә идем. Хәтта Нурның дуслары белән дә дуслашып киттем.

Укуын тәмамлагач, Нур Мәскәүдә калып, фәнни-тикшеренү институтында эшли башлады. Ләйлә белән кавышып, матур тормыш корып җибәрделәр. Без һаман да бик еш очрашып торабыз.

Классташларым турында күп язып булыр иде. Алар мона лаек. Мордва егете Фёдор Алаев — һәрвакыт турысын әйтә торган кеше. Без аларның өендә еш була идек. Ата-анасы да игелекле, кунакчыл кешеләр булып истә калган. Рубин Әхмәтов йомыграк кебек күренсә дә, сөйләшә башлагач, белмәгәне юк икәнлегенә инандыра. Поляк Виталий Юрьевич — ышанычлы, дуслыкка тугрылыклы шәхес. Армиядә чагымда миңа хатлар язып торды.

Кызларыбыздан зифа буйлы, мөлаем Разита Нугаева, күпләребезне гашыйк иткән киң күңелле Эмма Михайлюк, барыбызга карата да игътибарлы Ләйсән Ризвановаларны искә төшерәм. Гомумән, кызларыбыз алма кебекләр, берсеннән-берсе чибәр иделәр.

Шулай итеп, Әлмәт миңа Шөгеребез кебек үк якын, кадерле. Без ел саен берничә мәртәбә кайтабыз. Әниебезнең, абыебыз Дамирның, әби-бабаларыбызның, башка туганнарыбызның каберләрен зиярат кылабыз.

Әйткәнемчә, гаиләдә без өч ир бала үстек. Олы абыебыз Дамир нефтьче иде. Кызганыч ки, 1994 елны автокатастрофада һәлак булды. Ике улы югары белем алып, матур гына тормыш корып җибәрделәр. Энем Энгел — минем кебек үк тарихчы, фәннәр докторы, профессор, финанс-икътисад институтында кафедра мөдире. Аның да ике кызы, бер улы бар.

Нәселебез ике яктан да ныклы. Бабаларыбыз йөзгә җитеп үлгән. Аллаһы Тәгалә үзләрен озын гомерле итеп яраткан. Шул яшькә җитүләренә, булганына шөкерана кылып, ризалыкта яшәүләре, ярдәмчел, миһербанлы, мәрхәмәтле булулары да ярдәм иткәндер.

**Индус ТАҺИРОВ,**
*ТР Фәннәр академиясе академигы,*
*тарих фәннәре докторы, профессор*

# МӘҢГЕЛЕК ҺӘЙКӘЛ



*1990 елның 23 августында Казан Кремлендәге Сөембикә манарасы янә айлы булды. Бөтендөнья Татар лигасы президенты Гали Акыш бу гамәлне Суверенитет турында декларация игълан ителү белән янәшә куйган. Ошбу вакыйгадан соң беренче мәлләрдә күпләр (шәхсән үзем дә) әлеге гамәл «өстәгеләр» кушуы буенча чынга ашырылды дип уйласалар, соңыннан моның асылда мәдәният министрының төзелеш-архитектура һәм мәдәни мирас ядкарьләрен төзекләндерү буенча урынбасары Габбас Нурулла улы Мөхәммәтшинның тырышлык нәтиҗәсе икәне мәгълүм булды. Аның бу изге һәм тәвәккәл адымга баруының нигезендә нәрсә ята соң? Әлеге сорауга җавап эзләүне ошбу шәхеснең ерак үткәненнән башлау дөрес булыр кебек.*

## Тугач ук ятим

1935 елда Лениногорск (элекке Шөгер) районының Кирлегәч авылында дөньяга килгәндә үк ятим булырга язган икән Габбаска. Ил буенча колхозлаштыру шаукымы башлангач, ике атын, ике сыерын, танасын, бик күп ашлыгы һәм башка байлыкларын Нурулла агайның күмәк хуҗалыкка керергә теләмәвенә үч итеп тартып алалар. Бусы инде — талауның өченче дулкыны. Бу хакта Габбас Нурулла улының туганнан туган абыйсы Шамил Хәнифов күп еллар узгач менәниләр дип искә ала:

— Нурулла абыйны кайткан унайда эләктереп, авыл советына алып килерсен, дип кеше калдырып киттеләр. Сакчы бик яхшы абзый иде. Кеше-кара күргәнче дип, ана үзе качарга булышкан. Абый авылдан чыгып китеп, Үзбәкстандагы Коканд шәһәренә барып урнашты, ләкин ярты ел да үтми вафат булды. Алтынчы бала булып Габбас туа. Шундый авырлыклар, кимсетелүләр аша узып та ул, югары белем алып, житәкче урыннарга күтәрелә.

Репрессия тәгәрмәче бер гөнаһсыз миллионнарча жаннарны һәлак иткән, тагын күпме миллионнарның язмышларын чәлпәрәмә китергән шул куркыныч елларда алты баласы белән япа-ялгызы торып калган Бибигайшә жиңги кеше чыдамаслык авырлыкларга ничек түзгәндер дә балаларын ничек аякка бастыра алгандыр — анысын үзе генә белә. Властьлар алай да тынычлыкта калдырмый, куркыту-җәберсетүләр һаман дәвам итә. Ахырда, золымга түзмичә, Мөхәммәтшиннар гаиләсе башта Оренбург өлкәсенең Богырыслан ягына күчә, берничә елдан Әлмәт районының Чупай авылында төпләнә. Шул чагында 1939 елның көзендә Габбас сабый варварлыкка тиң яманлыкка шаһит була. Үзенең атаклы «Семь ступеней минарета Сююмбеки» китабында болай дип язачак ул:

— Мәчет янәшәсендәге бакчалардан бәрәңге алып ятканда, район үзәгеннән авылга вәкилләр килеп төшеп, халыкны жыйды һәм мәчет манарасын кисеп, аны сүтүне оештырды. Без, әле мәктәп яшенә дә житмәгән кечкенә балалар, дәшмичә генә күз яшьләрен сөртүче өлкәннәр белән беррәттән, бу кыргыйлык актын котыбыз очып читтән генә күзәтеп тордык. Манараны аудару вакыйгасы, бик күп кешеләрнең бер урынга жыелуы, аларның чарасызлыктан гажизлек бәреп чыккан чырайлары, яшь белән тулган күзләре, дәшмәсәләр дә, явызлык гамәленә ризасызлыклары, бөтен халык алдында ачыктан-ачык кылынучы гөнаһ безнең сабый аңыбызга вә жаныбызга шулкадәр тирән үтеп кергән ки, инде менә 60 елдан артык вакыт узуга да карамастан, мин әле хәзер дә ул вакыйгалар агышын бөтен ваклыкларына кадәр, тетрәнеп хәтеремә төшерәм.

Мәчет манараларын саклыйсы, кадерлисе килү хисе әнә шул чактан ук күнеленә кереп калгандыр, мөгаен, Габбас Нурулла улынын... Мәчетне ничек яратмасын ди ул. Жирдә кар эреп, аз гына сукмак салынуга, алар күрше малае белән икәүләп яланаяк якындагы шул мәчеткә чабып килә торган булалар. «Мәчет баскычыннан менеп, ачык ишек аша эчкә үткәч, чарлакка алып менүче агач басмалар буйлап өскә күтәреләбез, ә аннан, селкенеп торучы күперчекләр аша, куышып, манаранын аскы өлешенә кучәбез, — дип сөйли Габбас ага. — Аннан, бормалы баскыч буйлап, калай белән тышланган түгәрәк галерея-балконга күтәреләбез. Моннан, кошлар оча торган биеклектән, авылнын бөтен жире күренә, кардан арчылган текә тау битләре, кырлар һәм ерактарак урман шәйләнә. Кояш астында жылынган калайлы идән һәм балкон култыксалары жылысында безгә рәхәт, һәм без, озын кыш буенча жәйне сагынганлыктан, кеше күзенә чалынмыйча гына (юкса анда йөрүләргә чик куярлар дип куркып), вакытыбызны шунда үткәрә идек...»

Әнисе Бибигайшә апанын кечкенә китапханәсе дә булган. Анда гарәп һәм фарсы телендә язылган иске китаплар сакланган. Әнисенен читләр күзеннән яшереп саклаган китаплары барын яхшы белгән кечкенә Габбас, мәчет чарлагында аунап яткан дини эчтәлекле байтак язмалар арасыннан яхшыракларын сайлап (гарәп имласы белән язылган китапларны шәхес культы елларында юк иткәннәр), кулмәге астына яшереп өенә алып кайта торган булган.

— Яшь чагында абыстайдан сабак алудан башка белеме булмаган, мәктәп, университетлар да тәмамламаган әнием галимнәр белеменә һәм акылына ия иде, — ди әнисе турында Габбас Мөхәммәтшин. Укыган китапларынын эчтәлеген бик теләп балаларына, үзе янына кинәш сорап яисә гәп корырга килүчеләргә дә сөйләгән ул. Сөембикә-ханбикә һәм анын манарасы турындагы легенданы да беренче тапкыр әнисеннән ишетә төпчек малай. Һәм ул анын зиһененә инде беркайчан онытылмаслык булып кереп кала.

## Казан ямьле каламы?

Шулай да Казанга тәүге тапкыр, армия чыныгуы үткәннән сон, шактый тормыш тәжрибәсе туплаган белемле һөнәр иясе булып, 1960 елда гына килә ала ул. Бөгелмә аэропортыннан ике апасы белән очкычка утырып оча. Казан аларны август ахырына хас булмаган салкын һавасы, шыксыз күренешләре белән каршы ала. Алтмышынчы еллардагы Казан бер ягы белән дә эре провинциаль шәһәрләрдән аерылып тормый диярлек. Шундый ук шыксыз соры биналар, каядыр ашыккан карангы чырайлы кешеләр. Кайчандыр монастырь булган, ташландык хәлгә китергән барак-складка охшаган озын корылмалар яныннан үтеп, Кремль каршындагы тар мәйданга килеп чыккач та егет каршылыклы хисләр кичерә.

Кремль туфрагында да күзне сөендерерлек нәрсә күренми: ун кулда зур тәрәзәләрен елтыратып ике катлы озын биналар сузылып китә, ә сул якта шундый ук эчпошыргыч бертөрлелеккә өртелгән хәрби казармалар сураеп утыра. Аларны үткәч, ун тарафта дәү чиркәү силуэты калкып чыга, ә аннан сон, Кремль калкулыгынын көнчыгыш ягыннан, кальганы камап алган тешле стеналар өстеннән, Казансу елгасына сырышкан бер, ике катлы иске кирпеч һәм агач йортлар күзгә ташлана. Салкын төньяк жиле исә. Бу күренешләр Габбаста һәм апаларында авыр тойгылар калдыра.

Ниһаять, Сөембикә манарасы! Әнә ул — очын горур рәвештә күккә чөеп, бу изге урын өчен ят тоелган башка биналар арасында үзенен төгәл һәм нәфис формасы белән аларны магнит кебек үзенә тартып, жаннарны иркәли. Тик ул күптәннән адәм балалары игътибарыннан мәхрүм шул инде, юньле-рәтле төзәтү эшләре үткәрелмәгәнлектән, ятим, ялгыз һәм монсу күренә. Чак кына көнчыгышка авышып, өслегендәге кайбер урыннарда чүп үләннәре һәм вак куаклар үсүгә һәм фасад өлеше жимерелә башлауга карамастан, ул егеткә һәм анын апаларына барыбер газиз. Менә ул — әниләре легендаларга төреп сөйләгән кадерле манара. Тик очында ае гына юк. Шул чагында бөреләнә башлаган инде Габбас күнелендә манара очына ай куйдыру уе.

## Без белмәгән Габбас

Татарның холкына элек-электән эзләнүчәнлек, яңалыкка омтылу хас. Габбас Мөхәммәтшин әүвәл башлангыч мәктәптә укып, аннары өлкән апасы чакыруы буенча Урта Азия якларына яшәргә күчкәч, анда җидееллык мәктәпне гел «бишле»гә тәмамлый. Шуннан соң күңеленә якынрак һөнәр үзләштерү нияте белән Себер кинлекләрендәге ерак Иркутск каласына юл тота. Андагы хәрби техниклар әзерләүче мәктәпне сайлый ул. 1954 елда уку йортын «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлый. Хезмәт юлын Владивосток тимер юлларында махсуслаштырылган эшләр буенча мастер булып башлап җибәрә. Армиягә чакырылыр вакыты да җитә. Ике ел Ерак Көнчыгышта, Сахалин утравының Охот диңгезе ярларын саклаучы полкта хәрби хезмәттә үтә.

— Озакка сузылган көзге яңгырлар астында чыланып, күз ачкысыз бураннарда, кышның зәмһәрир салкыннарында өшеп-туныл, текә кыялы диңгез ярларында еш кына көннәр-төннәрне окопларда үткәрә идек. Минем белән бергә хезмәт итүче татар егетләре аз булмады. Безнең полктагы ике Советлар Союзы Героеның берсе утыз яшьләрдәге майор Гобәйдуллин иде. Утрауда татар авыллары да бар икәнен белдек. Кайларга гына сибелмәгән безнең татар! — дип искә ала Габбас ага ул ерак көннәрне.

Ватан алдындагы бурычы үтәлгәннән соң, егет кабат Владивостокта өч кенә ай эшләп өлгергән мастерлык вазифасына кайтып урнаша. «Матур булса да торган җир, сагындыра туган җир», дип юкка гына җырламыйлардыр. Бер ел үтәр-үтмәс Габбас өзелеп-өзелеп Әлмәт якларын, балачагының ялан тәпиле чакларын үзендә калдырган Чупай яны чирәмлекләрен һәм урманын сагына. 1957 елда Әлмәткә кайтып, тимер-бетон эшләнмәләр заводына өлкән мастер булып эшкә керә. Егетнең тырышлыгын, алдына куелган йөкләмә-бурычны төгәл һәм вакытында үтәвен күреп, карьера баскычыннан күтәрүне дә тоткарламыйлар — күп тә үтми аны предприятиенең производство-техник бүлеге җитәкчесе итеп тәгаенлиләр.

Хәрбиләрчә төз гәүдәле, үтә пунктуаль егет тормышның бөтен сынауларын һәм андагы каршылыкларны үзбаш хәл итәргә, һәр биеклеккә үз тырышлыгы белән күтәрелергә өйрәнсә дә, никтер һаман шәхси тормышын «кешечә көйләү»не кичектерә килә. Бары 1963 елның август аенда гына булачак гомер юлдашын очратып, бер атна эчендә гаилә корып җибәрә ул. Светлана апа иренә турылыклы хатын булып яши, татарларны бик хөрмәт итә һәм аларның телләрен өйрәнеп, кирәк чагында аралашырга да авырсынмый.

Габбас Нурулла улының Әлмәттәге хезмәт юлын ике этапка бүлеп карарга ярыйдыр: 1978 елга кадәр һәм 1980-1987 елларда. Ике дистә елдан артыкка сузылган беренче өлешендә ул тимер-бетон эшләнмәләренең берләштерелгән заводы директоры вазифасына кадәр күтәрелсә һәм эш күрсәткечләрен моңа кадәр күрелмәгән югарылыкларга җиткерсә дә, кайбер хөсетле бәндәләрнең астыртын гына «югарыдагылар»ны өстереп торуларыннан туеп (турысын әйткән — туганына ярамаган), Латвиянең Лиепая каласына китүне һәм анда төзелеш материаллары вә конструкцияләре җитештерүче комбинатны җитәкләүне хуп күрә.

Ике ел Лиепаяда эшләү дәверендә латышларның да ихтирамын казанырга өлгерә Габбас Нурулла улы, ул җитәкләгән комбинат күркәм нәтиҗәләргә ирешә. Мондагы яшәү шартлары Әлмәттәгедән күпкә яхшырак булса да, «Востокмонтажгаз» тресты управляющие Мөхәммәт Сабиров кабат нефтьчеләр төбәгенә (инде югарырак урынга) чакыргач, 1979 елда Әлмәткә кайта. Мөхәммәт Галләм улы аның ни-нәрсәгә сәләтле икәнлеген чамалый шул — берничә ел аякка баса алмаган йортлар төзү комбинатын җитәкләр өчен Габбас Мөхәммәтшиннан да кулайрак затны табып булмаячак. Шулай булып чыга да, яна җитәкче, яна эш алымнарын гамәлгә кертеп, инде ике ай дигәндә предприятиене алдынгылар сафына чыгара. Орден-медальләр, дәрәҗәле исемнәр белән бүләкләнү бер нәрсә, кешеләрне сөендерүдән дә зуррак бәхет бармы икән дөньяда? Йортлар төзү комбинаты сиксән беренче елдан башлап кала нефтьчеләре өчен һәр елны планнан тыш 120 фатирлы бер йортны файдалануга тапшыра.

Мөхәммәт Сабиров 1984 елда Казанга, ТАССР Министрлар Советы рәисе

урынбасары (1989-1995 елларда ТР премьер-министры) вазифасына күчә. «Гади» халыктан чыккан премьер «гади» халык баласы, республиканың атказанган төзүчесе Габбас Мөхәммәтшинның халык өчен мәркәздә күбрәк файда китерәсен белә, әлбәттә — 1987 елда аны үз хозурына дәшеп, 1989 елда Татарстан мәдәният министрының төзелеш һәм тарихи ядкарьләрне төзекләндерү буенча урынбасары вазифасын тәкъдим итә.

## Ай күрдем аман белән

*«...Ай күрдем аман белән,*
*Күңелем тулды иман белән.*
*Шушы айларда вафат булсам,*
*Кабул кылсын Ислам белән...*

— Бу тирән мәгънәле сүзләр — яшәүгә өмет итеп, иманыбызга тугрылык йөзеннән әйтелә торган изге дога», — дип яза үзенең истәлекләрендә Габбас Нурулла улы. Ул — гомере буена иманына тугрылыклы булып калган зат. Аның мәдәният министры урынбасары булып эшли башлаган еллары Михаил Горбачёвның империя киңлекләренә «жепшеклек» алып килгән чагына туры килә. Зирәк акыл, югары интеллектка ия шәхес өчен бу бер дигән жирлек инде. Урынбасар вазифасына керешүенең беренче көнендә үк министрлыкның исәп-хисап эшчәнлегенә җаваплы баш хезмәткәрен чакыртып, милли проектларны гамәлгә ашыруга бюджеттан күпме акча бүленүе белән кызыксына. Финанслау мәсьәләсе ул елларда жинелләрдән булмаса да, республикабызның төрле районнарында 180нән артык яңа Мәдәният йорты һәм клуб сафка баса. Күренекле шәхесләребез Гаяз Исхакый, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче, Евгений Боратынский музейлары төзекләндерелеп яисә төзелеп файдалануга тапшырыла. Сынлы сәнгать музеенда фондлар саклау һәм күргәзмә оештыру өчен өр-яңа ике катлы бина, Ирек мәйданында Зур концерт залы төзелә. Минзәлә театрында озак елларга сузылган реконструкция эшләре тәмамлана һәм ул заманча жиһазландырыла. Казанда Жыр һәм бию ансамбле бинасы, музыка училищесының яңа корпусы, хореография училищесының төзекләндерелгән бинасы сафка бастырыла. Башкалабызның архитектур бизәлешен милли төсмерләр белән баету максатыннан да биниһая күп эшләр башкарыла: Әҗем, Иске Таш, Кабан арты мәчетләре төзекләндерелә, аларның манараларына ай куела. Киров урамындагы элекке Печән базары, Тукай урамындагы Солтан мәчетләренең XX гасырның 30нчы елларында юк ителгән манаралары янәдан торгызыла. Арча, Балтач, Кукмара һ.б. район-авылларның милли архитектура үрнәкләре булган, тарихи һәйкәлләр исәбенә кертелгән барлык иске агач мәчетләр төзекләндерелеп һәм манаралары куелып рәткә китерелә. Мондый эшләр Болгар тыюлыгында, Зөя утравындагы һәйкәлләрдә дә алып барыла. Бу кадәр эшләрне гамәлгә ашыру өчен бюджет акчаларын гына берничек тә житкереп булмас иде, әлбәттә. Габбас Мөхәммәтшинның газиз милләтен өзелеп яратуы, бөтен рухи һәм физик егәрен, вазифаи һәм эчкерсез дуслык мөмкинлекләрен файдаланып, бәгъзе химаячеләрне уртак милли проектларга җәлеп итә алуы да зур ярдәм була.

Милләтенә бирелгәнлеген, татарның ерак гасырлардан килгән шанлы үткәнен, югары культурага ия икәнлеген шик астына куеп пычрак атучыларны, кемнең кем булуына карамастан, һәркайда үз урынына утыртуын Габбас Нурулла улының Япониягә баргач, Нагасаки шәһәрендә гидның туристларга:

— Татар-монголлар берничә гасырлар элек, кораблларга төялеп, ике мәртәбә Нагасаки тирәсендәге Япония ярларына чирүләрен төшерергә маташып караганнар, тик икесендә дә көчле штормга очрап, һәлакәткә тарыганнар. Әгәр жил-давыл купмаса, алар утрауларны оккупацияләр һәм японнар тора-бара татарлардан әшәке сүзләргә өйрәнерләр иде, безнең Русиядәге шикелле, — диюен ишеткәч, җавап итеп әйткән сүзләре раслый.

— Мин монда нәкъ менә сез әле генә «мактап» телгә алган татарның бер

вәкиле, — ди ул. — Монгол-татарлар флотилиясе көньяк Япония утрауларын оккупацияләргә омтылу фактын шик астына куярга җыенмыйм. Шулай да, безнең арадагы башка мөселман-төрки вәкилләре миңа ялганларга ирек бирмәс, бездә — мөселманнарда — әшәке сүз, сүгенү иң авыр гөнаһлардан санала һәм төрки халыкларда кабахәт сүзләр куллану гадәткә кермәгән, ә инде сөйләшкән-аралашканда тозлап-борычлап «әни» дигәнне дә искә алсаң, гомумән, ник дөньяга туганына үкендерүләре бар. Русиядә гадәткә кергән кулланыштагы «матур» сүзләрне, киләчәктә туристларның башларын бутап, татарларныкы димәскә кинәш итәр идем, — ди ул. Моның асылында «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» дигән мәкерле сәясәт ятуын, «зур кешеләр» җыелган җирдә татарга каршы коткы тарату эффектының дистәләрчә мәртәбә арту ихтималын (ошбу публиканың, ялгыш фикергә килеп, соныннан башкаларга да шуны таратачагын) яхшы аңлый Габбас. Анарга мәдәният министрлары дәрәҗәсендә уздырыла торган «Тюрксой» симпозиум-очрашуларында катнашырга туры килә. Шул чагында ул аеруча Азәрбайҗан мәдәният министры Полад Бюль-Бюль углы белән дуслаша. Инде Габбас ага лаеклы ялга чыгып ун ел үткәннән соң, 2005 елда Полад Бюль-Бюль углы Казанга килә, шунда ул Габбас ага белән очрашып, җылы әңгәмә кора. Араларындагы дуслык-туганлык хисләре әле бүген дә сүрелмәгән.

Габбас ага, республикага исем биргән милләтнең турылыклы улы һәм дәүләт эшлеклесе буларак, Татарстан парламенты республиканың дәүләт флагы эскизын эшләүгә конкурс игълан иткәч, анда бик теләп катнаша. Аның проекты 1991 елның 16 августында «Комсомолец Татарстана» газетасында басылып чыга. Проект эскизындагы яшел һәм кызыл төсләр арасында ак полоса сузылып, яшел җирлектә ак төстәге йолдыз һәм ай урагы янәшә урын алса, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтовның «Шәһри Казан» газетасының 1991 елның 22 август санында тәкъдим ителгән зәңгәр, ак, кызыл полосалары белән килешми. Бәхеткә күрә, Югары Совет 1991 елның 29 ноябрендә Габбас Мөхәммәтшин тәкъдим иткән төсләрне (яшел, ак, кызыл) төп өлге итеп ала. Үзгәреш — яшел һәм кызыл төсләрнең тигез күләмдә һәм ак полосаның таррак булуында гына. Мөхәммәтшин проектында яшел төс өстенлек итә). Аннары шунысы: флагта тәкъдим ителгән ай вә йолдыз сурәтләре урын алмаган.

## Сөембикә манарасы киртләч–киртләч

Шулай да Габбас Нурулла улының татар халкы, бөтен төрки галәм өчен кылган иң олы гамәле — Казан Кремлендәге ханлык заманыннан калган бердәнбер тарихи корылма — Сөембикә манарасына ай куйдыртуда башлап йөрү. Манара очында ай торган була инде. 1918 елның 8 мартында куелып, утызынчы елларда алына ул. Бу олы һәм изге ният һич тә күп кешедә берьюлы тумый, әлбәттә. Габбас аганың тәкъдименнән башлана бар да. Тәкъдим иҗтимагый фикер булып үссен һәм гамәлгә ашсын өчен, шактый көч салына аның тарафыннан. 1990 елда гаммәви мәгълүмат чаралары манара очына нинди билге халыкта киңрәк яклау табуын белер өчен, җәмәгатьчелек фикеренә үз битләрендә киң урын бирә. Аерым кешеләр, оешмаларның җавапларыннан күренгәнчә, тәкъдимнәрнең сиксән процентлабы манара очына кабат ай куюны хуплый. Моны ТАССР Министрлар Советы каршында тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклау буенча оештырылган «Мирас» комиссиясе дә 1990 елның 25 маенда уздырылган киңәйтелгән утырышында яклап чыга. Җәмәгатьчелектә киң яклау табылу бер нәрсә, кайбер эшем ияләренең икеләнүе-читләшүе, беришләренең куркып-каушап калуы, ә бәгъзеләренең хөсетләнүе һәм аяк чалуы (яшерен һәм ачыктан-ачык та) — боларның һәммәсе белән очрашырга туры килә Габбас Нурулла улына. Шундый вазгыятьтә уйланылган проектның чынга ашмау куркынычы килеп туа. Әмма 1960 елның октябрендә Казанга килеп, Кремльдә күргәннән соң ук күңеленә кереп урнашкан Сөембикә манарасын ифрат якын итү хисен болар гына сүрелдерә аламы соң? Ул инде психологик яктан үзен төрле вариантларга әзерләгән, шул исәптән, иң начарына да. Изге күнелле кешеләр бар бит алар. Шундыйларның



*Габбас Мөхәммәтшин*

берсе — Казанның «Вакууммаш» заводындагы цех җитәкчесе Шамил Сәфәров (мәрхүм инде, урыны җәннәттә булсын). Үзләре өчен таныш түгел, уникаль заказны әлеге игелекле зат бушлай үтәргә теләк белдерә. Әлеге хәлләргә чирек гасыр узганнан соң да, элекке мәдәният министры урынбасары Шамил әфәндене һәм аның коллегаларын, рус кешесе булуына карамастан, гозеренә хәерхаһлык күрсәткән заводның баш инженерын рәхмәт сүзләре белән искә ала. Айны һәм башка детальләрне манара очына урнаштыру матавыкларына турыдан-туры җитәкчелек иткән Александр Костинны үзен ярты сүздән аңлаучы (рус кешесе булса да, татарча да яхшы сөйләшүче) фикердәше һәм булышчысы дип атый. Конус, шарлар һәм ай урагын кую эшләре 23 августта төгәлләнә. Татарстанны Югары Совет утырышында суверен республика дип Декларация кабул итүгә төгәл бер атна калган, димәк. Сөембикә манарасы очында алтынай ялтырауның да өлеше зур бу тарихи җиңүдә (шунысын да әйтмичә булмыйдыр: суверенитет бүгенге көндә кәгазьдә генә калды, ә татар халкының символы горур төстә балкуын дәвам итә).

Габбас Нурулла улы әлеге изге гамәлне чынга ашыруда хәлиткеч рольне ул чагында ТАССР Министрлар Советы рәисе Мөхәммәт Галләм улы Сабиров уйнавын ассызыклый. «Тирә-юньдәге бу проектка бик үк уңай булмаган мөнәсәбәткә карамастан, Министрлар Советының 317нче карарын 1990 елның 24 август датасы белән имзалавы (ай урнаштырылганның икенче көнендә) барлык ыгы-зыгы чыгу мөмкинлекләренә нокта куйды», — ди ул.

Шулай да Сөембикә манарасына ай куюның рәсми датасы (алтын йөгертелгән ахыргы варианты) булып 1990 елның 26 сентябре санала. Габбас Мөхәммәтшин менә ни дип искә ала бу гамәлне:

— 26 сентябрьдә, айны алтынлап, бөтенләйгә ныклап беркетү тантанасы булды. Ай өчен киләчәккә бүгенгедән бүләк-аманәт итеп Коръәни Кәрим китабы, манарага ай куюны үтенеп язылган иллеләп хат, бу изге эшне башкаруда тырышып йөргән, ярдәм күрсәткән берничә кешенең исеме һәм шул көннәрдә генә чыга башлаган «Шәһри Казан» гәзитенең беренче саны куеп калдырылды. «Хәерле сәгатьтә» дип язып куйдым мин гарәп хәрефләре белән ул төргәкнең тышына. Бу теләкне Габдулла хәзрәт дога кылып раслады. Ул көз болытлы, җилле-яңгырлы көннәре белән истә калды. Әмма озак көтелгән кояшлы көннең һаман булмавы сәбәпле, эшне озакка сузарга теләмичә, айны 26 сентябрь көнне урынына беркетергә ниятләдек. Изге ният буш булмас, ди безнең халык. Чыннан да, эш башларга килгәндә, ни гаҗәп, яңгыр туктаган, балкып кояш чыккан, күктә берминди болыт әсәре дә күренми, йомшак кына җылы җил исә иде.

Манара янында, ай кую хәбәрен ишетеп, 60-70 кеше җыелган. Сәгать 12ләрдә бу, өйлә вакытында эш инде азагына якынлашып килә иде. Җыелган халык, бик кызыксынып күзәтеп торганнан соң, таралыша башлады. Менә шунда бер гаҗәеп, серле вакыйга булып алды. Айны урынына беркеткәч һәм аны чорнавыннан азат итә башлагач, зәңгәр күктә кыйбла ягыннан килгән зур гына ак болыт күренде. Нәкъ безнең өстә кинәт кенә бер-бер артлы чатнатып өч мәртәбә яшен яшьнәде. Һәм кояшлы яңгыр сибәли башлады.

Манарабызга айны кайтару, беренче карашка, кечкенә генә вакыйга кебек, әмма ул күңелләрдә яңа өмет, шатлык-куанычлар тудырды. Күпләр моңа сөенде. Ләкин бу изге эшне юкка чыгарырга тырышучылар да булмады түгел. Ә без уяу, сизгер булып, саф акыл белән эш итеп, үз кыйблабыздан тайпылмыйча гына алга атласак иде.

## Җиде баскычлы манара

Ярый, хуш. Татар халкының риваятьләренә кергән, аңа багышлап бәетләр чыгарылган легендар манара очына, тарихи гаделлек тантана итеп, алтынай куелды шулай. Инде тынычланырга да була кебек. Юк икән шул, үз милләтебездән булсалар да, кайберәүләр (бик күп белүләрен күрсәтергә теләптерме, әллә кемнәрнеңдер заказын үтәпме) кызып-кызып манараның урыс чорына караган архитектура үрнәге икәнен исбатларга алыналар. Аларча корылма XVII гасырга, ә кайберәүләр раславынча, XVIII гасырга карый. «Урыс варианты»н яклаучыларның дәлилләре, комнан бау ишкән шикелле, гади сорауны да күтәрә алмый анысы. Шулай да азартка бер кергәннәрне тиз генә туктатырмын димә. Боларның барысына җавап йөзеннән Габбас Нурулла улы, дәүләт хезмәтеннән китеп, Казан, Мәскәү һәм башка шәһәрләрнең архивларында озак вакытлар казынып, үзенең «Семь ступеней минарета Сююмбеки» дигән хезмәтен яза. Ошбу урында әлеге исем белән 2002 елда китап басылып чыкканнан соң, кайбер танылган милләттәшләребез язып җибәргән фикерләрдән сөземтәләр китерү урынлы булыр.

Филология фәннәре докторы, академик Марсель Әхмәтҗанов: *«...Ярый, Сөембикәнең паспорты юк ди, хәтта Сөембикәнең үзенең дә кабере мәгълүм түгел, күршеләребезнең шундый гадәтләре булганга безнең гаеп юк. Эзләрбез. Әйе, менә мәдәниятебез, тарихыбыз өчен «аһ» дип йөргән Габбас Мөхәммәтшин бюрократлар кебек паспорт юк дип тормый, аны таба. Менә минем алдымда Габбас батырның Сөембикә табышмагына җавап рәвешендә язылган яңа китабы. Ул үзенең «Семь ступеней минарета Сююмбеки» исемле зур хезмәтендә, данлы манараның җиде ярусын өеп менгән кебек, үзенең тарихи чыганакларын югары күтәрә. Габбас Мөхәммәтшин тапкан һәм әйләнешкә керткән чыганаклар бөек архитектура һәйкәленең югалганы урынына бирелгән ышанычлы паспорты хезмәтен үтиләр. Йә, моңа кадәр әле кайсы галимнең манараның кирпечләренә әтрафлы фәнни анализ ясаганы бар?!»*

Шагыйрь Рафис Корбан (2012 елның маеннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе) болай ди: *«Кешенең ин зур, мөһим, төп эше була. Үзен, үзенең гомерен фидакарьләрчә бары тик шуна гына багышлаган изге хезмәте. Урыста аны «дело жизни» диләр. Бу китап — Габбас Нурулла улы Мөхәммәтшинның әнә шундый олы эше. Ләкин укучылар берүк Габбас Мөхәммәтшинны бөтен гомерен шушы китапны язуга гына багышлаган кеше икән дип уйлый күрмәсен. Бу китапны укып, алар аның тормыш һәм хезмәт юлы белән, әлбәттә, танышырлар. Ә бу китап үзе — Габбас әфәнде башкарган бөек хезмәтнең бер өлеше, икенче зур кисәге. Аның беренчесе — халкыбызның йөзләрчә елларга сузылган михнәтле язмышының татлы өметләрен гәүдәләндерүе Сөембикә манарасына Ай куюны оештыру булса, икенчесе — шушы газиз манарабызның үзебезнеке икәнен (әйе, үзебезнеке булуын! Китапны укып чыкканнан соң, укучылар монысын да аңларлар) исбатлавы, шунын өчен көрәше, манарабызны яклавы. Шушы хезмәте белән ул күрше итеге астында тапталып та, хөр булып калган, үз йөзен, кыйбласын югалтмаган, рухы сынмаган, горур халкыбызның зурлыгын, бөеклеген күрсәтеп бирә...»*

**Фирдәвес ХУҖИН**

***Редакциядән.***

*9 майда Габбас Нурулла улы Мөхәммәтшинга 80 яшь тулды. Ходай аңа озын гомер, шәп сәламәтлек һәм Сөембикә аен гел күреп йөрү сөенечен бирсен!*

# ҖИҢҮЛӘР ҖИҢЕЛ БИРЕЛМӘДЕ

ТАРИХИ-ПУБЛИЦИСТИК ЯЗМА

## Өметләрнең акланмау һәлакәте...

*Бер өйләрдән чыгып киткәч,*
*Кайтып булмый тиз генә...*

Ике ил арасында көтелгән сугышны берникадәр вакытка чигендереп тору, шул арада көч-куәт туплау нияте белән 1939 елда СССР белән Германия арасында төзелгән «дуслык, уртак хезмәттәшлек пакты»ның гомере бик кыска булып чыга. Өметләр акланмый. Ул килешүне башлап СССР бозды дип әйтмәсеннәр өчен, безнең ил җитәкчелеге чик буендагы гаскәрләргә бик сак кыланырга, дошман як тарафыннан әледән-әле кабатланып торган провокацияләргә җавап бирмәскә куша. Мондый саклык чире бик йогышлы була.

Кыска вакыт аралыгында булып алган дустанә мөнәсәбәтләр, Мәскәү тарафыннан әледән-әле «сак кыланыгыз» дип кисәтеп торулар безнең кайбер югары дәрәҗәле гаскәр башлыкларының да башын әйләндергән, ваемсызландырган. Шул сәбәпле бездә Германия гаскәрләренең бер кояшлы иртәдә кинәт һөҗүм итүе көтелмәгән хәл буларак кабул ителде. «Һич көтмәгәндә герман сугыш башлады», дип аклануга җирлек булды.

Бөек Ватан сугышы башлануның икенче көнендә батальон комиссары (майор) дәрәҗәсендәге хәрби корреспондент Константин Симонов Мәскәү-Минск поездына утырып юлга чыга. Шунда ул үзе белән бергә баручылар арасында көнбатыш чик буендагы гаскәри берәмлекләренә ялдан кайтып килүче күп кенә командирларны очрата. Күпчелеге урта буын дәрәҗәсендәге кешеләр, полк, дивизияләр белән идарә итәрдәй майор, подполковниклар һәм хәтта бер полковник та бар араларында. Шуларны күргәч, журналист аптырабрак кала. «Казалось, что половина командного состава Западного фронта была в отпуске. Я не понимал, как это случилось», — дип яза ул «Разные дни войны» китабында. Димәк, яна Хәрби министр булачак лейтенантларны тизрәк үз гаскәрләренә барсын өчен чаралар күргән бер мәлдә, кемнәрдер ул сугышчан берәмлекләрнең командирларын ялга озаткан булып чыга түгелме? Моны ваемсызлык димичә, ни диярсең?

Мондый хәлләрне, чик буе сагында торучы кайбер гаскәр башлыкларының ярымйорты хәзерлек белән сугышны каршы алуларын, булачак дошманның ялган вәгъдәләренә ышанудан башлары әйләнгәнлек белән генә аңлатырга буладыр, мөгаен.

Сугышның беренче көннәрендә үк чик буенда урнашкан аэродромнарда самолётлар, гаражларда килеш танк, машиналар күпләп юк ителгән. Штабы Минск каласында урнашкан Көнбатыш хәрби округы (сугыш башланган көннән Көнбатыш фронт) идарәсе беренче көндә үк төрле типтагы җиде йөз утыз сигез самолётын югалта. Шуларның күпчелеге аэродромнарда килеш бомбага тотылып юк ителәләр. Тарихчы Анатолий Иванов хәбәр итүенчә *(«Боевые крылья Татарстана» китабы, Казан, 2005)*, Кара диңгездән алып Төньяк боз диңгезенәчә сузылган бөтен көнбатыш фронт буенча ул көннәрдә безнең бер мең дә ике йөз очкыч һавага күтәрелмәс дәрәҗәгә китерелгән. Дөресрәге, аларның күпчелеге бер генә очыш та ясарга өлгермәстән, үз аэродромнарында килеш бомбага тотылган. Югыйсә, шул ук автор хәбәр итүенчә, сугыш башланырга дүрт сәгать калганда округ штабларына Мәскәүдән: «Бу төндә дошманның һөҗүм итүе мөмкин», дигәнрәк эчтәлекле телеграмма да җибәрелгән була. Ни сәбәпледер, күпчелек очракта әлеге хәбәр алгы сафтагы гаскәри берәмлекләр штабларына җиткерелмәгән булып чыга. Югыйсә меңләгән самолёт үз очу кырларында, башка төр техника үз базаларында

*Ахыры. Башы узган санда.*


*Фәрит Фәтхуллин.*

ук юк ителмәгән булыр иде. 1980 елда басылып чыккан «Советский энциклопедический словарь» белешмәлегендә китерелгән саннарга ышансак, сугыш башланыр алдыннан СССРда 1540 очкыч исәптә торган. Шулардан 1200ен сызып ташлагач ни кала? 1941 елның июнендә мондый башбаштаклык очракларының кабатланып торуын югары дәрәҗәле кемнәрнеңдер ваемсызлык нәтиҗәсе димичә, тагын ни дип кенә аңлатып була инде?

Дөрес, үз вакытында өлгерлек күрсәтердәй уяу командирлар да очраштыргалаган. Яисә үз өстенә җаваплылыкны алып, тиз арада чара күрергә керешүчеләре дә булган. Сугыш башланырга бер атна калганда, үз белдеге белән шундый бер чараны батыр милләттәшебез, очучы Фәрит Фәтхуллин (1914-1942) да башкарган. Көнбатыш Украина биләмәсенә кергән Луцк шәһәре тирәсендәге очу кырыннан күтәрелеп, ул чик буен күзәтүгә керешә. Шунда Фәрит чик буе кагыйдәләрен санламыйча, безнең якка кереп, безнең гаскәрләр урнашкан җирләрдән очып баручы дошман самолётын күреп ала. Һәм тиздән аны, беркемнән дә рөхсәт сорап тормастан, бәреп тә төшерә. Хәер, сорап та тора алмаган ул — күпчелек очкычларда әле җитәкчелек белән элемтәгә керердәй җиһазлар куелмаган була. Ә вермахт самолётлары ул вакытларда үзләрен бик иркен тоткан, даими рәвештә безнен биләмәләргә унар-егермешәр чакрымга кереп йөргән. Андый-мондый хәл килеп тумасын, сугыш башлауда без гаепле була күрмик, дигән сылтау белән аларга элек тимәгәннәр. Ә бу батыр, андый кисәтүләрне онытып, көнчыгышта япон самолётлары белән көрәшкән мизгелләрне истә тотып, шушындый гөнаһ эшләп ташлый. Бу кыю очучыга карата катгый чаралар күрелер дип йөргән арада чын сугыш башланып китүе генә Ф.Фәтхуллинны көтелгән җәзадан коткара.

Сугышның беренче көннәрендә дә шундый батырлык кылучы очучылар табыла. Бу көндә көнбатыш юнәлештә дошманның унсигез самолёты бәреп төшерелә. Шундый өлгер очучылар исәбендә тагын бер якташыбызның булуы сөендерә. Татарстан егете, 9нчы Һава көчләре дивизиясенә кергән 124нче истребительләр полкының звено командиры кече лейтенант Дмитрий Кокорев (1918-1941) бу иртәдә бер дошман бомбардировщигын, атар патроннары беткәч, үз МиГ-3 самолёты «күкрәге» белән бәреп төшергән, дип хәбәр итә А.Иванов алдарак күрсәтелгән китабында. Бу вакыйга 22 июньдә иртәнге бишенче сәгатьтә Замбрув шәһәре тирәләрендә була. Димәк, Бөек Ватан сугышы барышында иң беренче булып бик гаярь эшкә — таранга барырга батырчылык кылган лачын да безнең якташыбыз икән ләбаса. Ләкин аның ул батырлыгын үз вакытында бәяли генә белмәгәннәр. Шул ук китапта хәбәр ителгәнчә, Ленинград фронтының Һава көчләре гаскәрләре командующие А.А.Новиков та сугыштан соң нәшер иткән бер хезмәтендә: «Дмитрий Кокоревның һавада таран кылуы хакында соңлап белдем», — дип үкенеп язган икән.

Шул җәйдәге Ленинград фронты тирәсендәге сугышлар вакытында Д.Кокорев вермахт гаскәренең тагын биш самолётын бәреп төшергән. Октябрь аендагы бер бәрелеш барышында үзе дә һәлак булган.

Сугышның башланган көннәрендә Ленинград фронты сугышларында тагын бер якташ очучыбыз катнашкан. 1910 елда Казанда туган, 1934 елда атаклы Оренбург хәрби мәктәбендә очучы һөнәрен үзләштергән Василий Михайлов Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк яу кырында. 125нче бомбардировщиклар полкында ул — эскадрилья, соңрак полк штурманы була. Алар полкының эскадрильялары һәр төнне диярлек тылдагы дошман көчләренә каршы һөҗүмнәр оештыралар. Көнбатыш

Белоруссия белән Көнбатыш Украина өчен барган сугышларда туплаган тәҗрибәсе аңа даими рәвештә дошман тылына оештырылган очышларны уңышлы төгәлләп кайтырга ярдәм итә. 1941 елның декабренә кадәр ул житмеш биш сугышчан очышта катнашып, дошманның тылдагы хәрби объектларына, корал складларына, төрле техника тупламышларына үз кулы белән йөзләгән тонна бомба ташлый. (Әйе, бомба ташлау урыннарының адресларын минутлап санап билгеләү, үз вакытында бомба ташлау рычагларына баса белү — штурманнар эше. Андый очышларның уңышы очучы белән штурманның уртак осталыгыннан тора.) Һәм яу кырындагы уңышлары өчен ул шул айда Ленин ордены белән бүләкләнә. Майор Василий Михайловка икенче Ленин ордены һәм Алтын Медаль 1943 елның 10 февраль карары белән тапшырыла. Советлар Союзы Каһарманы В.Михайлов шул ук җәйдә Курск тирәләрендә барган мәгълүм зур сугыш мәйданындагы һава көчләре бәрелешләрендә дә катнаша. 1943 елның 6 июлендә сугышчан бурыч үтәгәндә һәлак була. Курск шәһәрендә җирләнгән.

Шул ук көннәрдә Львов шәһәре тирәләрендә хезмәт иткән очучы Илья Иванов та дошман самолётына таран ысулы белән зыян китергән. Һавада дошман белән көрәшкәндә башка чаран калмаса, таран ысулын кулланырга кирәк, дигән фикерне яшь очучыларга кайчандыр талантлы очучы Валерий Чкалов әйтә торган булган икән... Безнең кулда хәрби очучы И.Иванов турында тулырак мәгълүмат юк. «Таран кылган» дигән факт теркәлгән бер хәбәр генә бар. Мондый вакыйгаларны тирәнрәк өйрәнгән галим Анатолий Иванов: «Сугыш башланган көндә дошманның унсигез самолёты безнең очучылар тарафыннан бәреп төшерелгән», — дип хәбәр итә. Шулар исәбендә Д.Кокорев, И.Иванов, И.Калабушкиннар тарафыннан сафтан чыгарылган самолётлар да бардыр, дип фаразларга кала. Очучы-истребитель Иван Калабушкинның сугыш башланган атналарда өч дошман самолётын юк иткәнлеге шулай ук гомуми фактлар китерелгән бер хезмәттә генә теркәлгән.

Дошманны коралдан атып юк итү мөмкинлеге беткәч, үз очкычы белән дошманга зыян китерү үрнәген бер айдан соң икенче бер гаскәри полкның эскадрилья командиры капитан Николай Гастелло (1907-1941) да кабатлый. 26 июльдә ул үзенең «яралы, тәтенләп янган» самолётын дошманның танк, машина колонналары өстенә юнәлдерә. Шулай батырларча һәлак булып, ул берничә танк һәм машинаны юк итә, дошман көчләренең алга барышын берникадәр вакытка тоткарлый. 1941 елның 26 июлендәге батырлыгы өчен Н.Ф.Гастеллога, һәлак булганнан соң, Советлар Союзы Каһарманы исеме бирелә.

Ә шушы вакыйгадан бер ай элек, 4 июль иртәсендә, Н.Ф.Гастеллоның яшьтәше, икенче бер авиация полкы командиры подполковник Степан Супрун (1907-1941) да дошман карчыгаларына каршы батырларча көрәшеп һәлак булган. Көнчыгышта, японнарга каршы сугыш-бәрелешләрдә очучы осталыгы белән дан казанган, Советлар Союзы Каһарманы исеменә лаек булган С.П.Супрунга бу көнне берүзенә дошманның алты истребителенә каршы сугышырга туры килә. МиГ-3 истребителендә ул аларның икесен бәреп төшерергә өлгерә. Ләкин үз лачыны да, «каты яраланып», җиргә таба мәтәлә. СССР Югары Советы Президиумының 1941 елның 22 июль карары белән С.П.Супрунга, һәлак булганнан соң, икенче мәртәбә Советлар Союзы Каһарманы исеме бирелгән.

Дошман явының икенче көнендә 39нчы истребительләр дивизиясе очучысы кече лейтенант Михаил Жуков (1917-1943) та Псков шәһәрен бомбага тотарга килүче берничә дошман самолётына бер ялгызы каршы төшә. Беренче сугышчан очыш ясаган шул көндә үк зур уңышка ирешә — дошман бомбардировщигын бәреп төшерә. Гитлерчылар инде безнең тәмам тар-мар ителгән һава көчләре вәкилләреннән мондый шуклыкны көтмәгән булганнардыр, мөгаен. «Без аларның барлык очкычларын аэродромнарында ук юк иттек», дип тынычланган булганнардыр. Безнең Кокорев, Жуков, Супрун, Иванов, Фәтхуллиннар кебек кыю лачыннарыбыз буласына фәһем итмәгәннәрдер, күрәсең. Сугышның беренче көннәрендәге батырлыгы өчен Советлар Союзы Каһарманы исеменә лаек булган Михаил Жуковка шушы вакыйгадан соң да байтак кына сугышчан очышларда катнашырга, тагын берничә дошман самолётын дөмектерергә туры килә. Әмма бер очыш вакытында үзе дә «өлешсез» калмый — 1943 елда бу тапкыр һәм батыр очучы да һәлак була.

Балтыйк буенда хәрәкәт итүче 5нче истребительләр полкы очучысы, азәрбайҗан егете Гөсәен Алиев (1919-1941) та сугыш башланган беренче атналарда дошманга каршы

бәрелешләрдә бик актив катнаша. Нибарысы егерме җиде көн яшәп калган лейтенант Алиев кырык тугыз мәртәбә сугышчан очыш ясап һавага күтәрелгән. Дошман самолётлары белән бәрелешләрдә дә, җир өстеннән һөҗүм итеп килүче көчләргә каршы көрәштә дә катнаша ул. Шәхсән аның тарафыннан дошманның бер танкы, өч автомашинасы, берничә мотоциклы һәм дистәләгән гаскәрие юк ителгәнлеге теркәлгән Г.Алиевне бүләкләү документында. 18 июльдә ул берүзе дошманның өч «Юнкерс»ына каршы ташланырга мәҗбүр була. Шул бомбардировщикларның икесен бәреп төшергәннән соң, үзе дә каты яралана. Көч-хәл белән үз самолётын аэродромга утырканнан соң, ул озак яшәми — вафат була. Батырлык кылып вафат булган очучы Гөсәен Алиевне СССР Югары Советы Президиумы Ленин орденына лаек дигән карар чыгара. Ә бераз соңрак «Правда» газетасында күренекле журналистка Вера Кетлинская егерме ике яшен дә тутырмыйча һәлак булган бу егетнең данын илгә белгертә — «Воля» исемле очеркын бастырып чыгара.

Әйе, Г.Алиев дошманның бер генә самолетын бәреп төшермәгән очракта да, 27 көн дәвамында 49 очыш ясавы һәм үлем хәлендә булып та үз самолетын саклап җиргә төшерә алуы белән генә дә данлауга лаек.

Бу мисаллардан күренә ки, сугышның беренче көннәреннән үк вермахт очучыларына да «үз күрәчәкләрен күрергә» туры килгәләгән. Сугышның беренче айларында аларның да шактый гына «Юнкерс», «Хейнкель», «Фокке-Вульф», «Мессершмидт» һ.б. самолётлары безнең батыр очучыларыбыз һәм тупчы-зенитчыларыбыз тарафыннан дөмектерелгән. Тарихчы А.Иванов китабында мондый факт та китерелә: 25 июньдә безнең гаскәрләрнең һава көчләре дә дошманның унтугыз аэродромына берьюлы контрһөҗүм оештырган икән. Ул һөҗүм барышында безнең 263 бомбардировщик һәм 224 истребитель катнашкан. Шул көнне дошманның кырык бер самолёты аэродромнарда юк ителгән. (Автор бу контрһөҗүмнәрнең кайсы фронт тарафыннан оештырылган булуын гына хәбәр итми. Мөгаен, ул кыю һөҗүм дә Ленинград фронты Һава көчләре гаскәрләренеке булгандыр. Бу вакытта Көнбатыш һәм Көньяк-көнбатыш фронтларның авиациясе тәмам сафтан чыгарылган була ич.)

Вермахт гаскәрләре мондый югалтуларның нәтиҗәсен сугыш башлануның беренче елында ук — Мәскәү шәһәре өчен барган яу вакытында ук сизә башлый. Кайбер мәгълүматларга караганда, алар бу чорда бигрәк тә очучылары җитмәүдән җәфа чиккән.

Әйе, сугышның иң авыр айларында да дистәләрчә, йөзләрчә сугышчы яу кырында батырлык үрнәкләре кылган, гомерләрен корбан итү исәбенә алар җиңү көнен якынайтуга үз өлешләрен керткәннәр.

* * *

Сугыш башланган көннәрдә үк безнең самолётларның күпләп юкка чыгарылу фаҗигасе үзен әле байтак вакыт сиздереп торачак. Шундый бер фаҗигале вакыйга Константин Симоновның әлеге китабында да тасвир ителә. К.Симонов һәм аның белән бергә корреспондент вазифасын үтәүче «Правда», «Известия» һ.б. газеталар вәкилләре, үзләренә беркетелгән полуторка яисә «Пикап» машиналарында һәркөн кая да булса йөреп торган. Көнбатыш фронт штабы карамагында сугышның беренче атналарында ул төркемдә хәрби корреспондент һәм шагыйрь Алексей Сурков, «Известия» газетасы фотографы Павел Трошкин бергәрәк йөриләр. Үзләренә бирелгән машиналарда алар фронт карамагындагы гаскәри берәмлекләргә яна чыккан газета бәйләмнәрен өләшә. Һәм бер үк вакытта үзләренә кирәкле мәгълүматны туплап кайталар. Кичләрен сугыш вакыйгаларын чагылдырган язмаларын әвәләп, үз газеталарына җибәрә торган булалар. Шуның өстенә К.Симонов күргән-белгәннәрен көн саен диярлек көндәлек дәфтәренә теркәп барырга да иренмәгән.

Менә шул куен дәфтәренә бер аяныч вакыйганы күргәннән соң язылган юлларны күздән кичерик әле. Чик буенда урнашкан һәм сугышның беренче көннәрендә үк бомбага тотылган аэродромнарның күпчелегендә истребитель самолётлары тупланган була. Алар дошман очкычлары һөҗүменә каршы торучы төп көч бит. Аларның беренче бурычы — дошман самолётларын һавада юк итү, үз биләмәсенә аларны үткәрмәү. Икенче бурычлары — дошман гаскәре өстенә яисә хәрби корылмалар, заводлар өстенә бомба ташларга баручы үз бомбардировщикларыбызны каршы як истребительләреннән саклау.

Яу кырында жинел хәрәкәт итүчән шундый очкычларның житешмәве безнең авыр йөк белән еракка очарга тиешле һава көчләренә дә зур зыян китергән. Алар дошманның ажгырып килгән танк колонналарын, гаскәрен вакытында бомбага тота алмаганнар. Истребитель сагыннан мәхрүм ителгән бомбардировщикның язмышы хәтәр.

Чалт аяз көн — 30 июнь иртәсе. Совет гаскәрләренең Минскидан соң Борисово шәһәрен дә калдырып, Березина елгасының көнчыгыш тарафына чигенгән чагы. Шул көнне Могилёвта урнашкан фронт штабында вермахт гаскәрләренең Березина елгасын кичә башлавы турында хәбәр алына. Хәрби корреспондентларның полуторка машинасы ул иртәдә шул тарафтагы бер дивизиягә барырга чыккан була. «Элек безнең өстән әкрен хәрәкәт итүче унбишләп ТБ-3 самолётьы көнбатышка таба очып үтте, — дип яза К.Симонов шул көндә күргәннәрен. — Аларны озатып баручы истребительләр күренмәде. Халхин-Гол сугышында әкрен хәрәкәт итүчән ул ТБларны төнлә генә куллана башлаганнар иде. Болар саксыз-нисез көпә-көндез очып бара. Бераздан безнең ТБлар тирәсендә дошманның берничә «Мессершмидты» пәйда булды. Тиздән бер ТБ-3 яна да башлады. Аннан сикереп төшкән берничә парашютчының якындагы урман читенә таба юнәлгәне күренде. Без бу күренешләрне күзәткән арада тагын безнең жиде ТБ-3 бер-бер артлы аска мәтәлделәр. Дөрес, бер «Мессершмидт» та, кара төтенгә уралып, түбән таба тәгәрәгән иде», — дип яза әдип. Штабка кайткач ачыклыйлар — бу самолётлар ул көнне Березина елгасын кичә башлаган танк колоннасын бомбага тотарга жибәрелгән булган икән. Аларның беришe билгеләнгән урынына барып житә алмаган. Барып житеп, үз эшләрен башкарганнарының күпчелеге дә кире әйләнеп кайта алмаган икән. «Березина кичүен бомбага тотарга жибәрелгән егерме бер бомбардировщик бүген кире әйләнеп кайтмаган», — дип яза көндезге аяныч вакыйганы күзәткән автор.

Армия штабында теркәлгән документларга караганда, шул ук көнне Минск, Борисово калаларын бомбага тотарга дигән боерык та булган. Тарихчы Анатолий Иванов та, шул көнгә Көнбатыш фронт штабы документларына нигезләнеп, мондый фактны бәян иткән: «Фронт буенча 30 июньдә йөзгә якын СБ, ТБ-3 кебек авыр самолётлар кире әйләнеп кайтмаган».

Күнелләре әрнеп, күз төпләре дымланып бу фажигале вакыйганы күзәтеп торган корреспондентлар, парашют белән төшкән үзебезнең очучыларны урманнан эзләп табып, штабка алып кайталар. Яралыларын врачлар карамагына, исән-сауларын кирәкле урыннарга тапшыралар. «Аяныч, янган өч самолётның очучы-стрелоклары, соңгы секундкача дошман очкычлары тарафына атып, парашютта сикерергә өлгермәгән икән. Аларны бергәләп искә алдык. Яралы очучы капитан, кулларын болгый-болгый бик хәтәр сүгенеп, кемнәргәдер ләгънәт укыды», — дип яза К.Симонов. Ләгънәтләр укырлык та шул. Бер көндә генә дә бит Көнбатыш фронт үз карамагындагы бомбардировщикларның байтагыннан колак кага.

* * *

Шушы юлларны укыганда күнелдә: «Мондый хәлдә калуыбызда кемнәрдер гаепледер бит?» — дигән уй туа. Әлбәттә, иң беренче чиратта, ил житәкчеләре — И.В.Сталин, В.М.Молотов, сугыш алды елларында хәрби министр булган К.Е.Ворошилов, алар тәркемендә йөргән С.М.Будённыйлар искә төшә. (Әйе, С.Будённый шул елларда хәрби министрның урынбасары да бит әле.) Гражданнар сугышы заманында гаярь сугышчы булган, «ат уйнаткан» соңгы ике шәхесне яшьрәк буын замандашлары соныннан еш кына: «Приверженцы к старым порядкам, к кавалерийским атакам», — дип искә алырга ярата. Нәкъ шушы кешеләр Блюхер, Тухачевский кебек алдынгы карашлы хәрби житәкчеләр вакытында армиядә башланган янарышка каршы булалар. Киләсе сугышның төп коралы булачак Т-34 танкларын, танкка каршы атучы куәтле тупларны житештерүне тоткарлау карарларын кабул итәләр. Маршал Г.К.Жуков та үз хезмәтләрендә сугыш алды еллары аксакалларын бик аямый. Дөрес тә инде, яна заманның танк колонналарына кылыч болгап кына каршы торып буламы соң? Сугышның башлангыч дәверләрендә еш макталган кавалерист командирлар Лев Доватор белән «Шәйморатов генерал» (милләттәшебез Минлегали Шәйморатов) житәкләгән атлы гаскәри дивизияләр дә бит әнә 1942 елдан соң яу мәйданында бик күренмиләр.

Әйе, сугышның беренче чорындагы уңышсызлыкларыбыз барысы да менә-менә сугыш башлана дип көтелгән көннәрдә кемнәрнеңдер нәрсәләрнедер эшләп бетермәве, ваемсызлыгы яисә җитәкчелек итү тәҗрибәсе җитмәве аркасында туган хәлләрдер. Шул вакыттагы иң җаваплы юнәлештәге Көньяк-көнбатыш һәм Көнбатыш хәрби округлары командующийлары М.П.Кирпонос белән Д.Г.Павлов элек зур хәрби берәмлекләр белән җитәкчелек итмәгәннәр. Ул чорда күпчелек дивизия командирлары полковник дәрәҗәсендә була. Боларны исә бер ел дигәндә берничә дәрәҗә баскычын сикертеп, генерал-полковник һәм армия генералы дәрәҗәләренә күтәрәләр. Дөрес, икесе дә — Совет-фин яки Халхин-Гол сугышларында катнашкан, дивизия командирлары булган шәхесләр. Икесе дә — Советлар Союзы Каһарманнары. Ягъни икесе дә биологик яктан куркаклар рәтенә кермиләр. Күпмедер дәрәҗәдә хәрби белемнәре һәм осталыклары да булгандыр. Аларын һичкем инкяр итә алмас. Ләкин, хәрби корреспондент буларак барлык ул дәвер сугышларында катнашкан К.Симонов берничә урында билгеләп киткәнчә, 1937-1939 еллардагы репрессияләр нәтиҗәсендә байтак кына эре хәрби берәмлекләргә оештыру тәҗрибәләре җитенкерәп бетмәгән командирлар да билгеләнә. Шул ук «үзебезнең» Кирпоносны алыйк. Гражданнар сугышы елларында туган ягында — Украинада аз санлы бер полк командиры. Фрунзе исемендәге академияне тәмамлагач та диярлек (шул ук елларда анда безнең хәрбиләрдән Муса Мортазин, Хөсәен Мәүлүтовлар да укыган) Казанга эшкә билгеләнә, урта белемле хәрбиләр хәзерләүче гадәти бер уку йортын җитәкли. Әйе, 1934-1939 елларда ул Татар-башкорт кызыл командирлар хәрби мәктәбе башлыгы булган. Кыска вакытлы Совет-фин сугышында ул — янарак оешкан 70нче укчы дивизия командиры. (Үзе теләп сугышка киткән, дип яза Җәмил ага Гыйльманов.) Шуннан соң ук аны Киевка зур бер хәрби округ командующие итеп җибәрәләр. Өч-дүрт ай чамасы фәкать дүрт полк белән идарә иткән бер дивизия командирын! Ә ни өчен анда кырык-иллешәр мең гаскәри тупланган корпус яисә йөзәр меңләп сугышчысы, дистә меңләп заманча техникалы берәмлекләре булган армия башлыкларын билгеләмәскә ди? Кемнәргәдер яраклаша белгәнгә генә шулай эшләнгәнме? Әллә соң... шундый эшкә барырдай тәҗрибәле шәхесләргә кытлык заманы булгангамы? Үз фикереңдә нык торган андыйларның меңәрләп юк ителгән чоры иҷ. (Утызынчы еллар ахырына кырык мең чамасы хәрби командир репрессияләнгән, дип язалар хәзерге белешмәлекләрдә. Шул исәптән кайберәүләрнең милләтенә бәйле рәвештә репрессияләнүе турында үзәк «Известия», «Комсомольская правда» газеталарында аерым мәкаләләр дә булгалады.) Эзәрлекләнүчеләр арасында югары дәрәҗәле командирлар бик ишле булган. Сугыш башлангач та аларның кайберләре, исән калганнары, мәхбүслектән азат ителеп фронтка озатыла. Шундый язмышлы генераллардан К.К.Рокоссовский әнә Мәскәү яны сугышларында 16нчы армия командующие буларак танылачак. Л.Г.Петровский һ.б. кайберәүләр армия, корпус ише зур-зур хәрби берәмлекләр белән оста җитәкчелек итәчәкләр.

Кирпонос, Павловларның үз округларында хәрбиләрчә нык тәртип урнаштырып өлгерә алмаганлыгын чик буе сагындагы дивизияләрнең беренче көннәрдә үк авыр хәлдә калуы, хәрби техниканың күпләп юк ителүе дәлилли. Әйе, дошманның беренче һөҗүменнән соң ук меңәрләгән самолёт, танк, туп һәм башка төр корал яу кырына чыгар-чыкмастан ук юк ителгән. Шул округлар өчен дип җибәрелгән снаряд, мина һ.б. корал төяүле ике мең тимер юл вагоны да, безнең гаскәрләргә барып җитмичә, дошман кулына эләгә. Дөрес, ул чорда көчләр дә тигез булмагандыр. Ләкин булган кадәрле корал, көч белән уңышлы идарә итә белмәү очраклары да хәттин ашкан. Сугышның беренче көннәрендә үк чын осталык күрсәтеп сугышкан гаскәри берәмлекләр дә бар иҷ. Әйтик, Брест сагында торган 44нче укчы полк һәм аның командиры Пётр Гаврилов — шундый үрнәкләрнең берсе. Яисә Ленинградтан төньяктарак, Карелия җирләрендә урнашкан бер чик буе отряды, якташыбыз Никита Каймановның оста җитәкчелек итүе нәтиҗәсендә, бер ай чамасы үз урыныннан чигенмичә сугыша. Шул хакта «Правда» газетасының 27 август санында (1941) түбәндәге сүзләр язылган: «Өлкән лейтенант Кайманов группасы сугышның беренче көннәрендә дошманның алтмышлап һөҗүмен кире какты. Басып алучылар озакламыйча бу отрядның тылына үтеп керделәр... Отрядтан исән калганнар, күпчелеге яралылар, фәкать 22 июльгә

каршы төндә генә үз позицияләрен калдырып китәләр». Совет-фин сугышында чыныгу алган, шуннан соң Мәскәүдә югары «Выстрел» курсларын тәмамлаган Никита Кайманов Бөек Ватан сугышында татарстанлылардан икенче кеше буларак Советлар Союзы Каһарманы исеменә ия була. СССР Югары Советының шул хактагы указы 1941 елның 26 августында кабул ителгән.

Могилёв шәһәре сагында сугышучы 172нче укчы дивизия һәм шул дивизиягә кергән «Кутепов полкы» сугышчылары батырлыгы да күпләргә үрнәк булырлык. Аларны бераз сонрак искә алып китәрбез...

Генерал Кирпонос сугыш башланган көздә, гаскәрләр тәртипсез рәвештә чигенгән вакытта һәлак булган дип исәпләнә. Ул житәкләгән хәрби округта хәрби газета корреспонденты булган шагыйрь Евгений Долматовскийның «Зелёная брама» дип исемләнгән документаль әсәрендә аның мескеннәрчә үлеме вакыйгаларына ишарә ителгән юллар бар.

Икенче иң зур, иң җаваплы хәрби округның командующие булган генерал Павловның язмышы да гыйбрәтле — сугыш башланганның беренче көннәрендә үк ул округ гаскәрләренең дә күпчелеге шулай ук тәртипсез рәвештә чигенә. Менә-менә сугыш башланачак дип көтелгән көннәрдә бу округ гаскәрләренә беркетелгән самолёт, танкларның бер ишенең ремонтка куелуы, байтак кына полк һәм хәтта дивизия командирларының вакытында үз урыннарында булмавы (хәтерлисезме, сугыш башлангач, Мәскәү-Минск поездында «ашыгып» хезмәт урынына кайтып килүче майор, подполковникларны), туп белән танкларга кирәк булган снарядларның чик буе гаскәрләрендә беренче көндә үк диярлек житешми башлавы — болар барысы да шушы округ командующийларының житешсезлеге нәтижәсе. Вермахт танк колонналары безнең чик буена бәреп кергән вакытта Брест каласы тирәсендә торган 30нчы танк дивизиясе танкларының бер өлеше ремонтта була. Алар шунда кала (аннары дошман шуларны үзебезгә каршы кулланачак). Ике атна чамасы сугыша-сугыша чигенгәннән соң, дивизиядә нибарысы ике жинел Т-26 танкы үз-үзен йөртер хәлдә була. «Чигенгәндә танкларның бер ишен без үзебез шартлаттык, — дип сөйли К.Симоновка дивизиянең бер берәмлек командиры. — Ягулык та, снарядлар да беткәч, аларны дошманга калдырып китү зур хыянәт булыр иде».

Унбер-унике көн дигәндә бу округ штабы да, урыннан-урынга күчә-күчә, Мәскәү өлкәсе белән янәшәдә булган Смоленск шәһәренә барып сыена. 16 июльдә исә Смоленскины да дошман көчләре яулап ала. Кайбер белгечләр хәбәр итүенчә, шушы егерме-егерме биш көн эчендә Көнбатыш фронт унбер-унике дивизиясен югалта. Дөрес, округ штабы Смоленскига күченгәндә, Д.Павлов инде вазифасыннан азат ителгән һәм кулга алынган була. Ул шунда ук Мәскәүгә озатыла һәм кылган гаепләре, җавапсызлыгы өчен шул көздә төрмәдә атып та үтерелә. Мөгаен, аны «немецларга сатылгансың» дип гаепләгәннәрдер. (Ә аның һәм аның кул астындагы югары дәрәжәле командирларның җавапсызлыгы нәтижәсендә бу фронтның сугыш мәйданында берничә йөз мең сугышчы юкка чыгарылган.) Берара аның вазифасын — Көнбатыш фронт белән идарә итү мәшәкатьләрен хәрби министр С.К.Тимошенко үзе һәм бераздан соң М.С.Будённый башкаралар. Дошман көчләре Мәскәүдән утыз-кырык чакрым ераклыктагы Звенигород каласына һөжүм башлаган көннәрдә Югары Ставка житәкчелеге бу авыр вазифаны үтәүне Георгий Жуковның үзенә — кайчандыр шул дәрәжәле кәнәфине биләсен дип Павловны кодалаган кешегә ышанып тапшыра. (Алар Халхин-Гол сугышында бергә катнашканнар.) Һәм ул андый ышанычны, бик усал чаралар күреп, аклый. Мәскәүне коткарып кала. Мона ул шактый ук рәхимсез карарлар кабул итүе белән ирешә. Аның иң беренче катгый әмере — артка чигенү, качу хәрәкәте ясаган һәр сугышчының шунда ук атып үтерелергә тиешлеге турында була. Гади гаскәриме ул, командирмы — шундыйрак талпыныш ясаган икән — шунда ук атып үтерелсен! Шул чара башкаларга үрнәк булсын! — дигән максатны истә тоткан кискен чара — яңа командующийның әмере — бу очракта үзен аклаган да, ахрысы. Звенигород, Истра кебек Мәскәүгә якын калалардан соң, башкаларына дошман кул суза алмаган. (Илленче еллар башында авторларның берсенә шушы ике кала аралыгында хезмәт итәргә туры килде. Сугыш чоры окоплары да, җир өстендә аунаган бомба, снаряд ярчыклары да күмелеп бетмәгән иде әле.)

Ул җәй һәм көздәге сугыш мәхшәрен үз җилкәсендә татыган күпчелек хәрбиләр



*Казанда җыелган У-2 самолёты.*

Кирпонос, Павлов ише оештыру сәләте, вакытында дөрес чара күрү сәләте булмаган югары дәрәҗәле командирларның байтак булуыннан зарлана. Оештыру сәләте чикле шундый командирларның кайберләре аннары, артистларча кыланып, «эмка» машиналары, танк түбәләренә басып, үз-үзләрен атып та үтергәли. Көнбатыш хәрби округы һава көчләренең хәрби хәзерлеге өчен җаваплы генерал Копец та, ана буйсынган гаскәрдәге йөзләгән самолётның сугышның беренче көнендә юк ителүен белгәч, округ штабы янындагы мәйданда кызыл флаг төсенә буялган самолёты канатына басып, үз-үзен шулай атып үтерә. Ләкин ул уңышсыз командирларның андый үлеме генә тиңдәшсез яу кырында йөзәр меңнәрләп кырылган, шәһит киткән гаскәриләр белән бергә үк җир куенына кергән байтак гади халык үлемен акламый шул. Сугышны тупчы лейтенант буларак башлаган күренекле совет язучысы Юрий Бондарев та «Горячий снег» романында шундый сәләтсез бер командирның, «эмка» машинасы түбәсенә басып, үз-үзен атып үтерү күренешен китерә дә роман геройларының яу кырында дошман сугышчылары белән соңгы сулышкача көрәшеп үлгәнлекләрен үрнәк итеп күрсәтә. Әлбәттә, кылган гөнаһлары өчен үз-үзен үлемгә «хөкем иткән» генерал Копец һәм аның үрнәген кабатлаган кайберәүләр чын егетләрчәрәк юл да сайлый алган булырлар иде. Әйтик, шул ук Копецның үз самолётында томырылып очып менеп, немецның берәр «Юнкерс»ын кызыл әләм төсендәге лачыны күкрәге белән бәреп төшереп үлү мөмкинлеге дә, алай эшләрлек осталыгы булмаган очракта дошманның җирдәге гаскәре, танк колонналары өстенә төшеп, каһарманнарча үлү очрагы да бар иде ич. Ә ул, артистларча кыланып үрә катып басып, «менә күрегез, менә ничек мин үземә җәза бирәм» дип, җыелган кешеләр алдында үз-үзенә ата. Яу кырында һич югы бер дошманны юк итеп үлүең күпкә отышлырак бит.

## Тынгысыз көннәр һәм төннәр

*Җиңү белән, сау-сәламәт*
*Кайтсак иде әйләнеп...*

Сугышның беренче атналарында, беренче айларында ук дошман армиясе тарафыннан юк ителгән, таркатылган безнең гаскәри берәмлекләр байтак булган. Мәсәлән, А.Иванов әлеге китабында хәбәр итүенчә, полковник Ванюшкин командалык иткән 23нче авиация дивизиясе сугышның беренче атнасында ук юкка чыгарылган. Милләттәшебез, генерал-майор Миркас (Мирхуҗа) Салихов командалык иткән 60нчы укчы дивизиянең язмышы да шуңа охшаш. Бу дивизия янарак кына Советлар Союзы биләмәсенә кергән Балтыйк буе республикасының бик хәтәр бер чигендә урнашкан була. Беренче көннән үк бик авыр сугышларда катнаша. Вермахт армиясенең танк колонналары тиздән шул төбәктәге гаскәри берәмлекләрне камап үткәч, 60нчы дивизия сугышчылары да, төрле тарафка таркатылып, камалышта калалар.

Данлы гаскәри берәмлек башлыгы Чапаев исемен йөрткән укчы дивизия бөек Ватан сугышын көньяк-көнбатыш чик буенда каршылый. Шул дивизиягә кергән 396нчы укчы полк командиры, милләттәшебез, Балык Бистәсе районында туган Алексей Яковлевның сугыштан соң нәшер ителгән, «Сквозь огонь» дип исемләнгән китабын кулга алыйк. Анда бу полк һәм дивизия сугышчыларының нинди мәхшәрләр кичеп, көн саен диярлек зур югалтулы сугыш-бәрелешләрдә катнашып, көньяк Днепр буйларына таба чигенүе тасвирлана. «1941 елның сентябрь урталарына безнең 135нче укчы дивизиядән аерым төркемнәр генә калды. Дивизия бетте, таркалды», — дип яза автор.

Тагын бер милләттәшебез, шул ук Көньяк-Көнбатыш хәрби округына кергән 789нчы укчы полк командиры урынбасары Хәйретдин Мөҗәйнең көндәлекләре нигезендә нәшер ителгән «Сугыш язмалары» китабында да сугыш башланган атналардагы таркаулык, бер дивизиягә кергән берәмлекләр арасында да үзара элемтә булмау кебек «кыямәт»ләр бәян ителә. «Дошман безнең өскә танклары, машиналары, мотоцикллары белән ябырыла торды. Без сугыша-сугыша, командирларыбызны, сугышчыларыбызны югалта-югалта һаман чигендек. Югалтулар күп булды», — дип яза ул. Күп тә үтми полк командиры да яраланып сафтан чыга. Х.Мөҗәйне аның урынына билгелиләр. «Һаман сирәгәябез, — дип яза ул берничә көннән соң. — Әйе, дошман «моторы» белән һөҗүм итә. Бездә моторлар юк. Мылтык-пулемётлардан никадәр куе ут ачылса да, ул «моторларга» зыян тими. Алар җинә...»

Беркөнне ике авыл арасына сыенган урман эчендә тупланган дивизия сугышчылары өстенә иртәдән тугыз самолёт гөжләп килеп чыга. «Әйләнеп-әйләнеп килеп бомбаларын ташлагандагы мәхшәр, хәзер күземне чытырдатып йомсам да, һич күз алдыннан китми. Туракланып, кисәкләнеп һавага ыргытылган гәүдәләр, куллар, аяклар, ат гәүдәләре... Дивизия командиры Макарчук, һава белән әллә кая ыргытылып ташланса да, гомере бетмәгән икән, сау-сәламәт калды», — дип язган Х.Мөҗәй шушы хәтәр вакыйгадан соң кулына алган куен дәфтәренә.

Шушындый фаҗигаләрдән соң күпме кеше юкка чыккан. Әйе, укчы дивизия һәм армия кебек зур хәрби берәмлекләр беренче айлардагы сугыш барышындагы башбаштаклык һәм тәртипсезлекләрне күп күргән. Хәер, мондый хәлләр Көнбатыш һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларга гына хас күренеш түгел. Шундый ук хәлләр Төньяк боз диңгезе буеннан алып Кара диңгезгәчә сузылган бөтен фронтның барлык төбәкләрендә дә диярлек кабатланып торган. Гаскәрләр ашыгып чигенгәндә, снарядлар булмау сәбәпле, тап-таза тупларны яисә ягулыгы булмаган машина, танкларны, дошманга калмасын өчен дип, шартлатып китүләр еш кабатланган. (Аларның барысы да шулай юк ителдеме икән әле? Бер өлеше, дошман кулына эләгеп, үзебезнекеләргә каршы сугышларда да кулланылгандыр, мөгаен.) Шул рәвешле күпме корал, машина юк ителгән бит. Ә менләгән берәмлек коралның, шул исәптән ике мең вагонга төялгән снарядларның яу кырына барып җитмичә, дошман кулына эләккәнлеге турында да язалар. Андый хәлләрне ишеткәч һәм белгәч, йөрәк әрнеми нишләсен! Әмма, гади сугышчы һәм урта буын командирларның бу тәртипсезлекләрдә, ваемсызлык очракларында һич тә гаебе юк. Әйе, шушы дәһшәтле, гарасатлы сугышның барлык кыенлыкларын беренчеләрдән булып үз җилкәләрендә татып, үз язмышларында чагылдыручы ул кешеләр ваемсызлык күрсәтсә — шундук аларны үзләрен яки иптәшләрен үлем көтәчәк ич. Ә безнең халык вәкилләре нәкъ менә шундый язмышлы сугышчылар иде — һәрвакыт ут эчендә, сугыш мәйданының үзәк өлешләрендә йөрүче гади сугышчы һәм кечерәк берәмлек командиры. Хәер, андый кечерәк берәмлек белән түгел, полклар белән идарә итүче командирлар да сугышның беренче дәверләрендә гади сугышчыга тиң дәрәҗәдә атака, һөҗүмнәрдә турыдан-туры катнашырга мәҗбүр булган ич. Әйе, һөҗүм-бәрелешләр вакытында еш кына гаскәриләрне әйдәп атакаларга алгы сафта ташланырга тиешләр арасында ул чорда еш кына полк командирлары да булганы истәлекләрдән мәгълүм... Һәм нәкъ шундыйлар — үз-үзен аямастайлар, сугыш барышында үрнәк булып алдан атлаучы командирларның сугышчылар арасында абруе да зур булган. Мондый батырлыклар бигрәк тә сугышның беренче айларында, беренче өлешендә үзен нык аклады. Шуңа күрә дә батальон, дивизион, полк кебек гаскәри берәмлекләр белән җитәкчелек иткән командирлар арасында бик-бик тә көтеп алынган Җиңү көненәчә яши алганнары, исән калганнары уннан бер өлеш чамасы гына да.

Полк — теләсә кайсы гаскәри берләшмәнең иң актив звеносы. Безнең милләттәшләр башлыча полк һәм шуннан түбәнрәк гаскәри берәмлекләр белән җитәкчелек иткән. Чик буендагы Брест кальгасы сагында торып сугышкан Пётр Гаврилов, катюша туплары дивизионы командиры Барый Йосыпов, икенче чик буе саналган Днепр тирәләрендәге авыр сугышларда сынатмаган Фёдор Баталов, Барый Кадыйрмәтев, Хәйретдин Мөҗәйләр, Ленинград шәһәре сагындагы иң җаваплы юнәлешләрнең берсендә сугышкан полк башлыгы Әхмәт Мостафин — шундый үрнәк командирлар булганнар. Язучы Александр Фадеев 1942 елда Әхмәт Мостафин

һәм аның полк сугышчылары унышларын үрнәк итеп очерк та язып бастырган. Европа үзәгендәге бер шәһәрне азат иткәндә һәлак булган полк командиры Зәки Хәбибуллин батырлыгы да онытылмас. Истребительләр полкы командиры, Советлар Союзы Каһарманы исеменә лаек булган Фәрит Фәтхуллин да башкаларны әйдәп алдан баручы үрнәк командирларның берсе була. Һәлак буласы көнендә дә ул өч мәртәбә һавага күтәрелеп, дошманның өч самолётын юк иткән.

Бөек Ватан сугышы чорында дивизия, берничә дивизияне берләштергән корпус, армияләр белән житәкчелек иткән командирларыбыз да бар. Севастополь оборонасының соңгы көннәрендәге язмышы өчен бөтен җаваплылыкны үз өстенә алган милләттәшебез Пётр Новиков (әсирлектә вафат була), 1942 елда Харьков тарафындагы бер контрһөҗүмнең алгы сафтагы дивизиясе командиры Зәки Котлин (шул һөҗүм барышында һәлак була), Курск төбәгенә бәйле сугышларда укчы дивизия командиры булган Фатих Булатов, Сталинград сугышы барышында сугышчылары шактый уңышларга ирешкән дивизия командиры Гани Сафиуллин (соңрак 25нче укчы корпус командующие) — халкыбызга горурлык хисе китергән шәхесләр. Көнбатыш чик буе сугышларында полк командиры буларак тәҗрибә туплаган генерал Алексей Яковлев та соңыннан сугышны дивизия командиры һәм армия штабы башлыгы буларак дәвам иттерә. Халкыбызның горурлыгы булган, Гражданнар сугышы чорында ук эре бер хәрби бригада белән житәкчелек итүдә катнашкан Якуб Чанышев Бөек Ватан сугышы елларында укчы корпус белән командалык иткән. *(«Вспоминая былые походы» китабы авторы да ул. Казан, 1973.)*

Аерым гаскәри берәмлекләр белән дәвамлы житәкчелек итмәгән, әмма сугыш барышында бик җаваплы оештыру эшләре башкарган шәхесләребез дә бар. 1943 елда авиация һәлакәтендә һәлак булган, 1939 ел ахырыннан Идел буе хәрби округында гаскәр туплау бүлеге башлыгы вазифасын башкарган генерал Ярулла Хәбибуллин (Әлдермештә туганлыгын яңарак кына белдек) безгә икеләтә якын. 1932-1938 елларда ул Казанда тупланган 1нче татар укчы дивизиясенең штаб башлыгы урынбасары да булган бит әле. Икенче бер генералыбыз, Совет-фин сугышы алдыннан Генераль штаб академиясен тәмамлаган, Бөек Ватан сугышын генерал-майор дәрәҗәсендә Генераль штабның оператив бүлеге хезмәткәре буларак каршылаган Шакир Гыйниятуллинны да онытмаска тиешбез. Шул бүлекнең башлыгы С.М.Штеменко, «Генеральный штаб в годы войны» китабында, яу кырыннан штабка сирәк кайтып, даими рәвештә төрле юнәлешләрдәге фронт, армия тарафларында йөреп житди бурычлар үтәгән хезмәттәшенең эшчәнлеген бик унай бәяли. Шул сугышчан бурычларны уңышлы башкарганы өчен хөкүмәт тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнгән генерал Ш.Гыйниятуллин турында белешмә нишләптер үзебезнең «Татар энциклопедиясе» китапларына гына керми калган. Республикабызга читтәш Оренбург өлкәсендә туган булгангадыр, бәлки. Бөек Ватан сугышы елларында иң югары хәрби дәрәҗәгә ирешкән, С.Штеменкога чаклы әлеге оператив бүлек башлыгы булган, аннары Генераль штаб башлыгы урынбасары вазифасын үтәгән армия генералы Алексей Антоновның нәселендә дә безнең милләткә бәйле буыннар бар, дип язалар кайберәүләр. Хәер, «Война и мир» романында Лев Толстойның Наполеонга нисбәтләп әйтелгән һәм башка кайбер тарихчылар тарафыннан да кулланылган бер җөмлә бу очракта һич тә шикләнергә урын калдырмаска тиеш. XX йөзнең урталарында гына да әле илебезнең үзәктән көньяктагырак өлешләрендәге байтак авыл, шәһәр читләрендәге зиратларда ай янсә төркиләрнең Хәзәр каһанлыгы заманнарыннан калган алты кырлы йолдызлары сурәтләрен очратып була иде... Күпчелек хәрби житәкчеләр, шул исәптән Г.Жуков та Антоновның эшчәнлеген югары бәялиләр. 1943-1944 елларда Генераль штаб башлыгы маршал Александр Василевский, Югары Ставка кушкан йөкләмәләрне үтәп, айлап, атналап фронт штабларында булган вакытларда, үзәк штабтагы төп эшләрне һәм көненә ике мәртәбә Югары Ставка вәкилләре белән И.Сталин алдында исәп-хисап тоту бурычларын да бик төгәл рәвештә А.И.Антонов башкарды, дип яза Г.Жуков та.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
**Булат ХӘМИДУЛЛИН**

# БАР КАДЕР БӘКЕРДӘ

Лениногорск, Шөгер яклары турында сөйләгәндә, «Бәкер» шифаханәсе турында әйтми калу мөмкин түгел. «Бәкер» үзе бер дәүләт, үзе бер Швейцария кебек ул. Татарстанның гына түгел, Россиянең шифаханә-курорт системасында лидерларның берсе.

1933 елда төзелгән әлеге дәвалау-профилактика учреждениесенең чишмә башында бер шәхес тора. Ул — земство табибы М.И.Игнатьев. Максим Игнатьевич берничә ел дәвамында кешеләрнең Бәкер авылы янындагы сазлыкка җыелуын күзәтеп йөри. Күрше-тирә авыллардан да крестьяннар килә. Алар сазлыкка кереп утыралар да тәннәренә пычрак сылыйлар. Табиб аларның ләмне өйләренә алып кайтканнарын да күрә. Шуның белән мунча керәләр икән. Беркөнне табиб үзе дә шушы сазлыкка килә һәм сероводород исен тоя. Ул әлеге юеш балчыкның кешегә дәвалану өчен табигать тарафыннан бирелгән кыйммәтле бүләк булуын аңлап ала. Бу хакта республика Сәламәтлек саклау комиссариатына, СССР Сәламәтлек саклау наркомына хәбәр итә. Бәкергә профессорлар Алексеев, Пономарёв, Блюмштейн һәм тау инженеры Соболевтан торган махсус комиссия килә. Комиссия сазлыкны җентекләп тикшерә, ләмнең һәм сероводородлы суның чыннан да югары нәтиҗә бирерлек дәвалау үзлегенә ия булуын таный. Ләмнең күләме дә ачыклана — 100 мең тоннадан артык. Комиссиянең соңгы карары: монда «Грязебальнеология» курорты ачарга! «Бәкер» шифаханәсенең тарихи елъязмасы әнә шуннан башлана. Баш табиб урынына Максим Игнатьев үзе тәгаенләнә.




*«Бәкер» курортының баш табибы Фаил Ибраһимов (сулдан уңга), шифаханәнең 80 еллык бәйрәменә килгән кунаклар: ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Премьер-министры урынбасары Юрий Камалтынов (хәзер ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары) һәм ТР профсоюзлар федерациясе рәисе Татьяна Водопьянова «Алтын шар» бильярд клубын ачу тантанасында. 13 сентябрь, 2013 ел.*

Хәлбуки, кешеләрне савыктыруга хезмәт итәчәк бу урынның башта үзен тазартырга кирәк була. Эш гади генә проектны гамәлгә ашырудан башлана. Шифаханә территориясенә агачлар, куаклар утырталар. Кечкенә генә электр станциясе сафка бастырыла. Багана башларындагы беренче лампочкалар кичләрен табигатьнең әлеге кадерле җирен нурга күмә. Шул җәйне беренче корпуслар, җыйнак кына дәвалау үзәге төзелә. Монда елның җылы вакытында — 15 майдан 15 сентябрьгә кадәр 50 кеше дәвалана ала.

1941 елның башында курорт кинәя, яңа дәвалау үзәге, корпуслар, котельный файдалануга тапшырыла. Иң мөһиме — шифаханәнең генераль планы эшләнә. Тик аны гамәлгә ашыру насыйп булмый — Бөек Ватан сугышы башлана. Курорт госпитальгә әверелә. Үз статусы аңа 1948 елда гына кайтарыла. Шифаханә 1951 елда — 100, 1959 елда — 150, 1967 елда 230 кешене кабул итә башлый. Үткән гасырның 70нче елларында яңа дәвалау үзәге, чистарту корылмалары төзелә.

1991 елда монда җирне ике урында бораулап, сульфат, натрий, магний, кальцийга бай дәвалану өчен «Мацеста» суына ия булалар. 2003 елда тагын бер чыганак тибеп чыга. «Бакыр» изге чишмәсеннән чыккан бу су «Бакировская» дип атала һәм соста-



*«Аккош» корпусы.*

вында бакырның күп булуы белән аерылып тора. Аның белән Украинадагы Трусковец һәм Ундар сулары гына тиңләшә ала. 2003 елның июнендә мондагы торфның да (сары-зәңгәрсу балчык) дәвалау максатында файдалану мөмкинлеге ачыклана. Аны косметологлар да бик теләп куллана.

Игнатьевтан соң баш табиблар булып Җиһаншин, Комендатский, Бельтер, Кутуевалар (язучы Гадел Кутуйның хатыны) эшли, сугыш чорында һәм сугыштан соң курортны үстерүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертә. Ф.Кельматова, К.Свечников, Ф.Янгуразова, Ф.Камалетдинова, Ф.Әюпов, В.Одушкин, Т.Федотова, Н.Андрияшин, Ф.Әхмәтҗанов, Р.Абашев, Н.Хәйретдиновлар һ. б. җитәкчелек иткәндә дә курорт уңай үзгәрешләр кичерә.

Шифаханәнең тамырдан үзгәрешләр кичергән еллары, чәчәк ату чоры яңалыкны тиз тотып ала, киләчәккә карап эшли белә торган зирәк, талантлы, энергиясе ташып торган җитәкче Фаяз Ибраһимов исеме белән бәйле. Ул 20 ел баш табиб булган дәвердә биредә ниләр генә эшләнмәде: «Аккош», 150 урынлы рестораны булган «Карлыгач» корпуслары, административ бина, хезмәткәрләр өчен күп фатирлы йорт, ике кунакханә, шифалы су заводы, «Аккош» кафесы, бассейн төзелде, «Сандугач» корпусына, мәдәни-күңел ачу үзәгенә реконструкция ясалды. Дәваланучылар киенеп-чишенеп тормасын өчен, корпуслар ашханә, ресторан, дәвалау комплексы бер-берсенә җылы коридор белән тоташтырылды, «Сихәт» чишмәсенә, «Мәхәббәт тавы»на тимердән һәм тимер-бетоннан баскычлар ясалды, мини зоопарк, таудан чаңгы шуу комплексы, бильярд залы, музей ачылды, шифаханә территориясе, шул исәптән буаның ярлары тазартылды, анда 10 мең төптән артык агач утыртылды, үзәк аллеяга «брусчатка» түшәлде. Дәвалану өчен менә дигән «Мацеста», «Нафтуся» дигән сулар табылды.

Иң мөһиме — дәваланучыларга хезмәт күрсәтүнең сыйфаты яхшырды. Монда заманча җиһазлар, яңа технологияләр белән Европа дәрәҗәсендә эшли башладылар. Курортка медицина хезмәте күрсәтүнең 30 төренә лицензия бирелде. Су-ләм белән дәвалау комплексы, функциональ диагностика, физиотерапия, матурлык салоны һ.б. — болар барысы да дәваланучылар өчен. Һәр елны «Бәкер»дә 15 меңләп кеше сәламәтлеген ныгыта. Аларга 450ләп кеше хезмәт күрсәтә. Биредә сөяк, буыннарны, нерв, гинекология, тире авыруларын дәвалыйлар.

«Бәкер» шифаханәсенең даны бөтен Россиягә билгеле. Аны чит илләрдә дә беләләр. Бу курортка бирелгән бүләкләрне дә санап бетерерлек түгел. Төрле елларда үткәрелгән «Здравница» Бөтенроссия форумында алган егермеләп алтын медале бар аның. 2003 елда ЮНЕСКО һәм Татарстан Президентының Рәхмәт хатларына лаек булды.

Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган табибы Фаяз Ибраһим улы һәр эшкә изге ният белән алынды, башкаларны да канатландыра белде. Үзенең яраткан шифаханәсе өчен ул әле тагын бик күп эшләр эшләячәк иде. Ни кызганыч, мәрхәмәтсез үлем аны вакытсыз арабыздан алып китте.

Хәзер «Бәкер» шифаханәсе коллективы белән аның улы Марат Ибраһимов җитәкчелек итә.

**Миләүшә МОРТАЗИНА**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Адлер ТИМЕРГАЛИН**

## Пауза турында хикәя

*(Кыскартып бирелә)*

Егерме алтынчы елның көз айлары... Комсомол ячейкасында җыелып сөйләштек тә авыл яшьләре көче белән театр куярга ниятләдек.

Пьесаны әзерли башлагач күрәбез: китап текстында урыны-урыны белән әллә ниткән Пауза да очрый бит, әй.

Сезгә мәнә көлке, ә без аптырашта калдык... Исеменә карасаң, Пауза хатын-кыз булырга тиеш. Берәр җиңгиме ул? Кыз баламы? Нигә теләсә кем арасына килеп керә, ник авыз ачып бер сүз дәшми үзе? Болары аңлашылмый. Мөгаллимебез дә кистереп әйтә алмады. Аны да гаепләрлек түгел, чөнки ике ай кантонда курста булып кайткан, әлегә бөтен гыйлеме шул да гәзит-журналда укыганы гына. Шулай да ул безгә төпле киңәш бирде. Пауза ролен мәктәпнең иң чая малае Җиһангиргa тапшырыйк та вәссәлам, диде. Кызлар итеп киендерербез, ерып чыгар, диде.

Малайны чакырып сөйләштек. Сәхнәгә чыгарга атлыгып тора.

Мәнә кичәбез дә килеп житте. Иске клуб халык белән шыгрым тулды. Шунысы гына беraз шикләндерә: алгы рәтләрдә җыен алыпсатар, кулак иярчене, куштаннар, койрык болгаучылар утыра һәм астыртын усаллык белән елмая иде.

Тамашабыз шома гына башланып китте.

Берзаманны суфлёрыбыз: «Пауза! Пауза кирә!» — дип пышылдады. Черт-черт кенә атлап, сәхнәгә Пауза-Җиһангир чыкты. Ботинкасы биек үкчәле, ялт та йолт килә, әллә апасының кершәнен сылаган инде... һәрхәлдә, дегет түгел. Керде дә, аны-моны сөйләмәстән, билгеле, сәхнә аркылы үтеп, почмакка кереп басты. Залда, җанланып:

— Тау ягы Кәраметдин кызы бугай, и хәерсез!

— Вәт малай, ыспай кием нишләтә! Кәртинкә бит! — диешеп алдылар.

Мәнә шул чагында гына башыбызда «Пауза сәхнәгә керүен керә, тик кайчан чыга икән соң ул, каһәр?» дигән әкәмәт бер сорау оешты.

Ашык-пошык киңәшләштек тә, тәнәфес арасында суфлёрны чакырып алып, Пауза сәхнәдән чыгып китәргә тиешле урыннарны китапта үзебезчә тәрткәләп куйдык.

Тагын пәрдәне ачтык. Берзаман суфлёр: «Пауза!» — дип дәште. Башка артистлар, Пауза кергәнне көтеп, сүздән туктадылар. Ә Җиһангир юк та юк. Суфлёр, оясыннан башын тыгып: «Пауза, дим! Җәтрәк бул!» — дип кабатлагач кына, Җиһангир-Пауза, бу юлы инде икенче яктан кереп, почмакка, пәрдә янына басты. Ботинка бавы чишелгән булган икән, шуны бәйләп азапланган. Ботинка күргән малаймыни?

Алгы рәтләрдән:

— Тагы керде бит әле бу... — дигән сүзләр ишетелде.

— Әллә телсез инде... И мескен... — дип куйды берсе.

Ул ара да булмады, спектакльнең иң җитди төшендә бот чабып көләргә тотындылар.

Өченче пәрдәнең буеннан-буена залда көлеш бер дә тынмады, кайчагында тәрәзә өлгеләре «зың!» итеп куя иде...

Чибәр Паузабыз сәхнәдә тик кенә тормаган икән. Сүз дәшәргә роле кушмагач, халык белән «анлашу» жаен Жиһангир үзе тапкан: башта егерме беренче елгы ачлыкта баеп калган Гаптеринең олы кызы аяк өсте ничек йоклаганны күрсәткән, аннары куштан Толып Фәләхетдиннең ифрат ачы телле хатынына да эләккән...

Без, өлкән артистлар, соңыннан Паузабызны нишләтергә дә белмәдек. Тотып тиргәргә дә вөждан кушмый, хупласаң да, пьесаны үз белдегең белән үзгәрткән сыман килеп чыга. Ахырда шулай хәл иттек: әгәр арттыра башласа, суфлёрга Жиһангирны сәхнәдән озатырга кушылды. Паузаның чынлыкта «кем» булуын белгәләгәнче, театр белән күрше авылларны да әйләндек. Ә Жиһангирыбыз андагы «тискәре типлар»ны алдан ук өйрәнеп куя иде, усал.

Соңыннан, гыйлем якларыбыз ныгый төшкәч, Паузаны тора салып чыгармый башлаганнан соң да әле, халык: «Нигә Пауза юк? Паузаны нишләп катнаштырмыйсыз? Әллә пауза чирлиме?» — дип теңкәгә тия иде.

**Гәрәй РӘХИМ**

## ҮТЕНЕЧ

***(Каләмдәшләрем Нур Әхмәдиев һәм Рәшит Бәшәргә)***

*Мин соңыннан китсәм, и Бәшәрем,*
*Оҗмах ишегеннән керү белән:*
*– Нихәл, дустым! — диеп дәшәрмен.*
*...Безнең урын, шиксез, оҗмахтадыр.*
Нур Әхмәдиев

Сез оҗмахта... Моңа сокланмыйча
Кала алмый сыңар шагыйрь дә!..
Бераз гына көнләшүем бар да,
Зур бер йомышым да бар сезгә.
Нык ышанам сезгә, бәрадәрләр,
Сөйлисез сез һич тә ялгансыз.
Исән чагыгызда ук оҗмахтан
Бик блатной урын алгансыз.
Үтенеч шул: алдан әйтеп куям,
Зинһар, бер-бер җаен табыгыз —
Оҗмах дигән шул санаторийга
Миңа да бер бронь алыгыз.

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## Яра

Туфан Миңнуллин ТНВдан сөйли: «Шагыйрьнең җанында, эчендә һәрвакыт яра булырга тиеш. Ул һәрвакыт авыртып торырга тиеш. Шул чагында гына ул әйбәт шагыйрь була ала...»

Шифаханәдә телевизор карап яткан Роберт Миңнуллин бу сүзләрне ишеткәч, сөенеп куя: «Миндә дә ашказаны язвасы таптылар, минем дә эчем постоянно авыртып тора. Димәк, мин дә әйбәт шагыйрь булып чыгам», — ди эченнән генә, эчен уа-уа.

## Җырчы Асаф Вәлиевкә

Асаф нигәдер сәхнәгә
Сирәк кенә чыга.

Аякларын көчкә-көчкә
Сөйрәп кенә чыга.

Жырларын да жырлап тормый –
Сөйләп кенә чыга.

## Равил Шәрәфигә

Равил Шәрәфинең юморы:
Билдән түбән... тездән югары.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Акыл теше

Марсель Гали, телефоннан Ркаил Зәйдуллага чылтыратып, шатлыгынмы, кайгысынмы белдергән:

— Бүген соңгы акыл тешен алдырып кайттым. Гади кешеләрнеке икәү генә була бит. Минеке — дүртәү иде.

— Минем берәү дә юк иде ул.

— Әйтәм аны... сизелә иде шул...

Бу сүзгә Ркаил Зәйдулла яшен аткан кебек чытырдап көлгән дә ахырдан:

— Акыл тешләреңне яшь чакта ук алдырып аткан булсаң, ару гына урында түрә булып утырасы идең бит хәзерге көндә, — дигән.

## Хикмәт исемдә генәме?

Исмәгыйль Шәрәфиевме? «Татарстан яшьләре»нең баш мөхәррире. Әйе, кырыс чырайлы. Үзе дә кешедән елмаю өмет итмичә, гел шаяртып сөйләшер. Шаяртуының кайсы төшендә көләргә икәнен сиздереп тормас. Аның иң тотрыклы сыйфаты — соңгы утыз биш ел эчендә үз гәҗитендә бер шигырь дә бастырмавында. Чөнки ул, гомумән дә, шигырьне яратмый, яратмый гына түгел — күралмый, күралмый гына түгел — жене сөйми! Һәрхәлдә, болгавыр шагыйрь халкы шулай уйлый.

Ә бер көнне... Шагыйрь Газинур Морат «Татарстан яшьләре» гәҗитен селкеп йөри. Ни гаҗәп! Авызы ерылган, кызылча йөзе пар бөркеп тора. Аның болай ук та шатланганын күргән кеше булды микән — көпә-көндез бит, эш вакытында! Әллә, минәйтәм, Нобель премиясе алганмы бу?! *(Өметеннә сузма яһүд премиясенә, үзеңнекен булдыр, кысмыр төрки кавеме!)* Юк ла! XXI гасырда күрелмәгән вакыйга булган бит — Газинур Моратның бер көлтә шигыре «Татарстан яшьләре» гәҗитендә басылып чыккан! Күпләр, бу хәлгә ышанмыйча, гәҗитне тотып-тотып карыйлар.

«Ни булган Исмәгыйль Шәрәфигә?», «Ничек рөхсәт биргән?», «Оныгы туган шатлыктанмы әллә?», «Кан басымы күтәрелеп, күңеле нечкәреп китмәгәндер бит?» — диләр.

— Менә шулай чын шигырь языгыз, егетләр, «Татарстан яшьләре» бастырырлык булсын! — ди Газинур Морат, куанычыннан «р» авазын да буксовайт иттермичә, тел өстеннән тибеп шома гына төшерә.

Исмәгыйль Шәрәфиев аның шигъри көлтәсен укып мәшәкатьләнмәгән, исемен генә күргән дә шунда ук «б а с а р г а!» дип кул куйган. Ә исеме ничек дип атала дисез? — «К А Р А К Л А Р!»

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# «ЧИШМӘ» АГА ДА АГА

1958 елның август ахырларында, Лениногорск шәһәре үзенең өч еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, әле генә бу калага күчеп килгән яшь язучы һәм журналист Шамил Бикчурин әдәби түгәрәк оештырып, аның беренче утырышын уздыра. «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясенең бер кечкенә бүлмәсендә барган бу утырышта Ш.Бикчуриннан кала газета редакторы Кыям Галләмов, башлап каләм тибрәтүче Әсрар Галиев һәм тагын ике-өч кеше катнаша.

Түгәрәккә йөрүче егетләр алны-ялны белми корыч манаралар янында, бораулаучы разведчиклар вагоннарында, вахта автобусларында, төзелешләрдә үзләренең булачак геройлары янында кайныйлар. Тиздән нефтьчеләр, кала төзүчеләр турында репортажлар, әдәби очерклар, шигырьләр, хикәяләр район газетасы битләрендә, республика матбугатында бер-бер артлы дөнья күрә башлый.

Шулай итеп, «Чишмә» мул сулы инешкә әйләнә.

Тора-бара Шамил Бикчурин, Гәрәй Рәхим СССР Язучылар берлегенә алыналар. Күренекле язучылар Флёра Гыйззәтуллина, Мәхмүт Газизов, Шамил Маннапов, Альберт Хәсәнов, Җәмит Рәхимов, Рәшит Шиһапов, Кәшшаф Әмировлар да шушы «Чишмә» суын эчеп көч тупладылар, тәрбияләнделәр, канат чыгардылар.

Күренекле композитор Рөстәм Яхин фронтовик-шагыйрь Рамазан Байтимеров шигыренә Татарстан Гимнын иҗат итте. Әнвәр Шәрипов, Әнәс Исхаков, Рәшит Бәшәр, Җәүдәт Дәрзаманнар да әдәбият-сәнгать өлкәсендә танылу алдылар.

Бүген «Чишмә»нең актив әгъзалары Таһир Шәмсуаров, Наил Шәрифуллин, Әгъләс Шәйхетдинов, Рәйсә Фәтхуллина, Рәхимә Габделганиева, Халидә Бигҗанова, Нурия Сәлманова, Наил Гыйләҗев, Гөлгенә Әхмәтова, Ринат Хәбипов, Каюм Шәрафов, Рузидә Даутова һәм башкалар буыннар чылбырын дәвам иттерәләр. Каләмне юлдаш итәрдәй яшь алмашчыларыбыз да үсеп килә.

**Рәсим ХӘБИБУЛЛА,**
*Шамил Бикчурин исемендәге «Чишмә»*
*төбәк иҗат берләшмәсе рәисе*

## Һич аңламыйм

Әллә нәрсә булды,
Ямь табалмыйм яздан.
Юктан кызып китәм,
Үпкәлимен аздан.

Нинди сагыш соң бу,
Тыныч түгел күңел.
Барына бит шөкер,
Ач-ялангач түгел.

Кояшым да чыга,
Янгырым да ява.
Тик тынгысыз җанга,
Һич табалмыйм чара.

Әллә «картлык чире»,
Әллә үзем кире,
Үзем аңлый алмыйм,
Кем аңласын мине!

Башка суктымы соң
Язгы дымлы һава?
Ник жанымны телеп,
Гөрләвекләр ага?

Бәлки гомеремдер,
Гөрләп агып бара?
Нинди назлы яз ич,
Ник сагышка сала?..

...Жанга сагыш сара...

**Наил ГЫЙЛӘЖЕВ**

## Ятимлек

Гади бер көн. Уен-көлке
Балалар бакчасында...
Бәхет урап алган сыман
Аларның барчасын да...

Әмма дөнья тигез түгел,
Һәркемнең үз өлеше.
Бирәүгә булса бакыры,
Икенчегә — көмеше...

Уйный сабыйлар онытылып,
Тирә-як гөрләп тора...
«Син — әтисез», — диде берсе...
Бу сүзләр йөрәк яра.

«Минем әти бар, ул килә!
Син белмисең, син тиле!» —
Өзгәләнде бала жаны,
Канлы сүз уктай тиде...

Шул чагында нарасыйның
Сытылып чыкты яшьләре...
Әйтерсең лә аяз көнне
Күкрәде дә яшьнәде...

И сабыем, артык иртә
Сынауларың башланды...
Тигез, жылы пар кочактан
Ятимлеккә ташландың...

Нык бул, балам, тормыш авыр,
Бөек затны онытма...
Изгелек булсын юлдашың,
Бозыклыкка юлыкма...

**Нурия СӘЛМАНОВА**

## Әткәй назы

Туган йортым, синнән аерылунын
Авырлыгын тойдым үзем дә.
Сиздем, әткәй, тыштан сабыр булдың,
Яшьләр тулды күңел күзенә.

Күзләренне тутырып карап калдың,
Хәерле юл теләп балаңа,
Шушы караш –
Кат-кат күз алдыма килде,
Йөргән чакта иркен далада.

Әткәй назы күңелемдә йөрде,
Уч төбендә сөеп үстергән.
Авырлыкка каршы торсыннар дип,
Яшәр өчен куәт-көч биргән.

Аерса да еллар аргамагы,
Ерагайтып юллар арасын,
Тормышымда гүя киңәш биреп,
Янәшәмдә атлап барасың.

**Халидә БИГҖАНОВА**

## Сагышыңны ничек яшерәсең син?..

Сагышынны ничек яшерәсең син?
Сары яфрак белән күмәсеңме?
Көз янгыры әрнеп елаганда,
Тамчы итеп җиргә түгәсеңме?


Сагышыңны ничек яшерәсең син?
Сахраларга чыгып җырлыйсыңмы?
Яшьләреңне җилгә яшереп,
Качып кына әллә елыйсыңмы?

Сагышыңны ничек яшерәсең син?
Тешең кысып кына түзәсеңме?
«Сагынмыйм да, юксынмыйм да», — диеп,
Үзәгемне генә өзәсеңме?

Сагышыңны ничек яшерәсең син?
Очраганда дәшми узасыңмы?
Еллар арасыннан еракларга
Күңел жепләреңне сузасыңмы?

Сагышыңны ничек яшерәсең син?..

**Гөлгенә ӘХМӘТОВА**



МАССАКҮЛӘМ МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫ БӘЙГЕСЕ
ЛЕГЕНДАЛАРНЫ БЕЛЕГЕЗ!
БРЕНДЛАРНЫ САЙЛАГЫЗ!
татмедиа
ЛЕГЕНДАР БРЕНДЛАРЫ
TATMEDIA.RU САЙТЫНДА
ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШЫГЫЗ
ДҮРТ НОМИНАЦИЯДӘ ТАВЫШ БИРЕРГӘ МӨМКИН:
ЛЕГЕНДАР ГАЗЕТА
ЛЕГЕНДАР ЖУРНАЛ
ЛЕГЕНДАР ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯ
ЛЕГЕНДАР МУЛЬТИМЕДИАЛЕ РЕДАКЦИЯ
TATMEDIA.RU
татмедиа
Реклама. 16+. Акцияне оештыручы - "ТАТМЕДИА" АҖ. Үткәрү сроклары һәм акция турында тулырак мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында
ПРОСТО МОЛОКО
КОНКУРСНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ ПАРТНЕРЫ
«ПРОСТО МОЛОКО» ИК ҖЧҖ

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ПРАЙМЕРИЗ

27 июньдә Татарстан Республикасы Президенты вазифасына сайлау уңаеннан, Казандагы Теннис академиясендә праймериз үткәрелде. Бу — «Бердәм Россия» партиясе идеясе. Ул Татарстанда гына түгел, Россиядә дә беренче тапкыр гамәлгә ашырылды. Исемлеккә түбәндәге кандидатлар теркәлде: Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов, республикадан сенатор Сергей Батин һәм Россия Президентының элеккеге эчке эшләр идарәсе җитәкчесе Олег Морозов. Праймеризда Рөстәм Миңнеханов җиңеп чыкты.

Рөстәм Миңнеханов кандидатурасын 12 иҗтимагый оешма, предприятие, вузларның хезмәт коллективлары күрсәтте.

ТР Президентын сайлау көне дә билгеле: 2015 елның 13 сентябре. Бу көнне республикада муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарына да сайлаулар үтәчәк.

## ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ

Болгар шәһәрендә Изге Болгар җыены уздырылды. Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны рәсми төстә кабул итү вакыйгасына багышланган җыенны ачу тантанасында Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, ТР тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу буенча «Янарыш» республика фонды попечительлек советы рәисе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия Югары мөфтие, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте рәисе Шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин, Россия мөфтиләре шурасы һәм Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил Сәмигуллин, Төньяк Кавказ мөселманнарының координация үзәге рәисе, мөфти Исмәгыйль хаҗи Бердиев катнашты.

## БӨТЕНРОССИЯ ҺӘМ ЕВРОПА САБАНТУЙЛАРЫ

Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылында IV Бөтенроссия Сабан туе булды. Бәйрәмгә ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич килгән иде. Рөстәм Миңнеханов үзенең котлау сүзендә Оренбург өлкәсендә барлык милләт вәкилләренә, шул исәптән татарларга игътибарның зур булуын билгеләп үтте, милли бәйрәмебезне әйбәт оештырган өчен губернатор Юрий Бергка рәхмәт белдерде. М.Бабич Бөтенроссия авыл сабантуйларын Идел буе федераль округы территориясендә генә уздыру идеясен хуплады. Киләсе бәйрәм Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы авылында уздырылачак.

Берлинда исә икенче тапкыр Европа Сабан туе уздырылды. Бәйрәмгә дөньяның 22 иленнән кунаклар килде. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова җитәкчелегендә Татарстан делегациясе катнашты. Ул ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов исеменнән котлау сүзләрен җиткерде.

## ЮБИЛЕЙ

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенең 75 еллык бәйрәмен билгеләп үтте.

Юбилей чаралары Татарстанның Фәннәр академиясе бинасында «түгәрәк өстәл» янында сөйләшүдән башланды. ТР Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Сәләхов, Халыкара төрки академия президенты Дархан Кыдырали, Төркия Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Җәвад Ажар, А.Халиков исемендәге Археология институты директоры Айрат Ситдыйков, Гамәли семиотика институты директоры Җәүдәт Сөләйманов, Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлегендәге Филология институты директоры Игорь Силантьев, Тува гуманитар фәннәр институты директоры Марианна Харунова котлау сүзләрен ирештерде.

Рәсми утырыш Казанның IT-парк залында дәвам итте. Анда юбиляр оешманы Мәкъзүм Сәләхов, Дархан Кыдырали һәм Әхмәт Җәвад Ажар котлады. ТӘҺСИ директоры Ким Миңнуллин институт үткән данлы юл турында доклад укыды. Аннары республиканың Премьер-министр урынбасары — мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, Кыргызстан Республикасы Фәннәр академиясенең гыйльми сәркатибе Габделгани Габдерәсүлов, Азәрбайҗан дәүләтенең Архитектура һәм сәнгать институты директоры Эртегин Сәламзадә, Хакас тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Валентина Ту-

гужекова, Башкорт тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Фирдәвес Хисаметдинова, Чуваш гуманитар фәннәр институты директоры Юрий Исаев, Удмурт тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Алексей Загребин, Мари тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Александр Казимов, Коми тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Юрий Железнов институт коллективына изге теләкләрен җиткерде.

### ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЬ

Казанда төрки театрларның XII халыкара «Нәүрүз» фестивале булды. Быел ул Казакъстанның театр сәнгатенә багышланды. Алматыдан М.Ауэзов исемендәге Казакъ дәүләт академия драма театры «Коркыт тәүбәсе» спектаклен (аны сәхнәгә Литва режиссёры Йонас Вайткус куйган) күрсәтте. Фестивальдә куелган спектакльләргә театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр (алар арасында исемнәре театр дөньясында киң даирәгә билгеле шекспирчы Алексей Бартошевич, Елена Ковальская да бар иде) бәя бирде.

### МУСА ҖӘЛИЛГӘ ҺӘЙКӘЛ

Казакъстанның Усть-Каменогорск шәһәрендә каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды. Аны ачу тантанасында республикабыздан ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин җитәкчелегендә делегация катнашты.

### ОЧРАШУ

Татарстан Республикасы Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының утырышлар залында Евразия Язучылар берлеге рәисе Якуб бәй Өмәроглы белән очрашу булды. Очрашуда сүз төрки әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрне ныгыту, әсәрләрне төрки халыклар телләренә тәрҗемә итү, мәдәни мирасны дөньяга күрсәтү турында барды.

### КҮЧМӘ УТЫРЫШ

Лениногорскиның төбәкне өйрәнү музеенда Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсенең күчмә утырышы булды. Анда Россиянең һәм Татарстанның күренекле рәссамнары белән бергә җирле кылкаләм осталары да катнашты. Музей хезмәткәрләре кунакларга төп урынны картиналар алып торган «Останың кораллы» дигән әр-яна күргәзмә күрсәттеләр. Бу чарада катнашучыларны Лениногорск шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Гөлфирә Рафикова, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе Зөфәр Гыймаев котлады.

### БӘЙГЕ

Төрек драматургы Һальдун Танәрнең туууына 100 ел тулу уңаеннан, «Евразия» Язучылар берлеге, Төркия Җөмһүрияте дәүләт драма театры, ТЮРКСОЙ оешмасы иң яхшы пьесага халыкара бәйге игълан итте.

Бәйгегә тәкъдим ителгән пьесаның темасы чикләнмәгән. (Балаларга адресланган яки кыска сәхнә уеннары моннан чыгарма булып тора.) Һәр автор бары тик бер әсәр генә тәкъдим итә ала.

Бәйгедә катнашучы пьеса беркайда да басылып чыкмаган, сәхнәдә куелмаган һәм бүләкләнмәгән булсын. Әсәрләр «Птез Котап шрифтында, 12 кегельдә, ворд форматында җыелырга, юл арасы 1,5 үлчәмендә булырга тиеш. Аерым дискта һәм 6 нөсхәдә тапшырыла (барысы бер конвертта). Әсәрләр ике пәрдәдән артмаска тиеш. Әсәрләр ябык тәртиптә, авторы күрсәтелмичә, девиз белән тәкъдим ителә. Автор турында тулы белешмә (исем-фамилиясе, паспорт мәгълүматлары, тәрҗемәи хәле һәм бер фоторәсеме) аерым конвертта тапшырыла. Электрон почта белән җибәрелгән әсәрләрдә әлеге мәгълүматлар өстәмә рәвештә кушылачак һәм оештыручыларда бәйге азагына кадәр яшерен сакланачак. Жюри әсәрләргә бәя биреп, җиңүчеләр ачыкланганнан соң гына, конвертлар жюри әгъзалары алдында ачыла.

Бәйгедә катнашучы әсәрләр, почта аркылы җибәрелгән очракта, түбәндәге адреска юллана: «AYB Sakarya Maha11esi Coztepe Sokak 5/A-Ankara-Turkiye». Әсәрне электрон почта адресы белән җибәрүчеләр htoyunyaris@ayb.org.tr адресына салалар. Оештыручы идарә, кирәк тапкан очракта, бәйгене ике турда үткәрергә мөмкин. Әсәрләрне бәяләп, хөкем чыгару өчен, пьесалар төрек теленә тәрҗемә ителәчәк. Жюри әгъзалары, аларның якыннары һәм туганнары конкурста катнаштырылмый. Бәйгедә катнашкан әсәрләр авторга кире кайтарылмый һәм автор әлеге әсәр буенча бернәрсә дәгъвалый алмый. Җиңеп чыккан әсәрләр Төркия Җөмһүрияте дәүләт театрлары репертуарына кабул ителгән булып исәпләнә. Әлеге шартнамәгә туры килмәгән мөрәҗәгатьләр кабул ителми. Бәйгедә катнашучылар әлеге шартларны кабул иткән дип санала.

Бәйге календаре:

— Пьесаларны тапшыруның соңгы көне — 30.09.2015.

— Урыннарны игълан итү көне — 15.11.2015.

— Бүләкләү тантанасы — 2015 елның декабрь ае.

1 нче урын өчен — 30 000 (утыз мең) төрек лирасы.

2 нче урын өчен — 20 000 (егерме мең) төрек лирасы.

3 нче урын өчен — 10 000 (ун мең) төрек лирасы.

1 нче кызыксындыру бүләге — 5 000 (биш мең) төрек лирасы.

2 нче кызыксындыру бүләге — 5 000 (биш мең) төрек лирасы.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Статья Р.ХУСАИНОВА «На родине нефти Татарстана».
Статья Р.НУРМУХАМЕТОВА «От славного прошлого — в достойное будущее».
«Проза и поэзия»: литературно-документальная повесть Ш.ХАНИФОВА «Остаться человеком»; рассказы Ш.БИКЧУРИНА, Р.ГАБДУЛХАКОВОЙ; стихи Г.РАХИМА, З.ДАРЗАМАНА, Т.ШАМСУАРОВА, А.ИСХАКОВА, Л.АЛАНЛЫ.
«Конкурс на повесть малого формата»: Н.ШАРИФУЛЛИН. «Записки одинокого человека».
«100-я страница»: Г.РАХИМ. «Они были первыми».
«Новые имена»: рассказы З.МУДАРРИСОВОЙ.
«Литературная критика»: А.ШАРИПОВ. «Люди твои — истинный вклад»; Р.ГАБДУЛХАКОВА. «По следам Батырши».
«Искусство»: статья Д.ГАЙНУТДИНОВОЙ о творчестве художника М.МИНГАЗОВА.
«Наука»: статья Р.ВАЛИЕВА об истории становления Лениногорского района.
«Память»: И.ТАГИРОВ. «Исток моей жизни — Шугурово»;
Ф.ХУЗИН. «Вечный памятник».
Л.ХАМИДУЛЛИН, Б.ХАМИДУЛЛИН. «Тяжёлый путь к победе»;
статья М.МУРТАЗИНОЙ о санатории «Бакирово»;
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«В литературных объединениях»: стихи Н.ГИЛЯЗОВА, Н.САЛМАНОВОЙ, Х.БИГЖАНОВОЙ, Г.АХМЕТОВОЙ с предисловием Р.ХАБИБУЛЛЫ.
«Из фотоархива журнала»: рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Нефтяные просторы Лениногорска». Художник — М.Мингазов; санаторий «Бакирово».

## IN THIS ISSUE:

Article by R.HUSAINOV «In the homeland of oil in Tatarstan».
Article by R.NURMUHAMETOV «From glorious past to a dignified future».
«Prose and poetry»: literary and documentary story by SH.HANIFOV «Be a human»; stories by SH.BIKCHURIN, R.GABDULHAKOVA; poems by G.RAHIM, Z.DARZAMAN, T.SHAMSUAROV, A.ISKHAKOV, L.ALANLY.
«Competition for a small-format novel»: N.SHARIFULLIN. «Notes of a lonely man».
«100th page»: G.RAHIM. «They were the first».
«New Names»: stories by Z.MUDARRISOVA.
«Literary criticism»: A.SHARIPOV. «Your people are true contribution»; R.GABDULHAKOVA. «Following Batyrshy».
«Art»: article by D.GAYNUTDINOVA about the artist M.MINGAZOV.
«Science»: article by R.VALIEV about the history of Leninogorsk district.
«Memory»: I.TAGIROV. «Source of my life is Shugurovo»;
F.HUZIN. «Eternal monument».
L.HAMIDULLIN, B.HAMIDULLIN. «Heavy road to victory»;
article by M.MURTAZINA about the sanatorium «Bakirovo»;
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«In the literary associations»: poems by N.GILYAZOV, N.SALMANOVA, H.BIGZHANOVA, G.AHMETOVA with a foreword by R.HABIBULLA.
«From photo archive of the magazine»: section is led by R.FAYZULLIN.
Diary of social-cultural activities.
On our covers: «Oil expanses of Leninogorsk». Artist M.Mingazov; sanatorium «Bakirovo».

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Лениногорскиның нефть киңлекләре».
*Рәссам* ***М.Миңнаҗев*** *эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Бәкер» шифаханәсе.

# БАЛКЫЙСЫҢ, ГҮЗӘЛ КАЛА!

*(Лениногорск шәһәре күренешләре)*



*Ротонда.*



*«Ихлас» мәчете.*



*Чернобыльчеләр истәлегенә монумент.*



*«Балерина» фонтаны.*



*Кала күле.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)